


# КАЗАН УТЛАРЫ

1
ЯНВАРЬ
1981

А, партия,
Синең иртәгәңә бару өчен,
Авырлыклар аша үтү кирәксә,
Безнең бүген күргән авырлыклар
Җиңүең өчен файда бирәлсә,
Шатлыгым да, янар яшьлегем дә,
Җырларым да сиңа булсыннар...

ҺАДИ ТАКТАШ

ЗНАК ПОЧЕТА

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

1

ЯНВАРЬ
1981

## *Бу санда*

КПССның XXVI СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

У. БЕЛЯЛОВ. Бүгенге һәм киләчәк хакына . . . 3
Ш. ХАММАТОВ. Муса Җәлил — партия солдаты 7

С. ХӘКИМ. Егерме бишенче август. Шигырьләр 17
Җ. РӘХИМОВ. Тәвәккәл таш яра. Повесть . . . 22
Ә. БАЯНОВ. Ак канатлар. Шигырьләр . . . . . . 95
Г. БӘШИРОВ. Сарут. Хикәя . . . . . . . . . 103
Р. ЮНЫСОВ. Исталекка. Шигырьләр . . . . . . 127

ОЧЕРКЛАР

С. ШАКИР. Намус кушканча . . . . . . . . . 130

ҺАДИ ТАКТАШНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Синең Такташың бар . . . 135
Х. ТУФАН. Җырланган җырлар турында . . . 143
Г. ИДЕЛЛЕ. Сөекле шагыйребезне сагынганда . 145

ГОМӘР БӘШИРОВКА 80 ЯШЬ

Р. МИҢНУЛЛИН. Әңгәмә дәвам итә . . . . . . 151
С. ПОВАРИСОВ. Энҗе бөртекләре . . . . . . 155

НӘҖИП ҖИҺАНОВКА 70 ЯШЬ

Я. ГИРШМАН. Иҗади казанышлар юлыннан . . 159

СӘНГАТЬ

Х. ЯКУПОВ. «Зур Идел» киңлекләре . . . . . . 165

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

К. ПЕТРОВ. Василий Юдинга 70 яшь . . . . . . 171
Т. ГАЛИУЛЛИН. Нил Юзиевка 50 яшь . . . . . 173
С. МАННАПОВ. Адлер Тимергалинга 50 яшь . . 177

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ә. КӘРИМУЛЛИН, Р. ХӘЙРЕТДИНОВ. Фәндә зур адым . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
Н. ХИСАМОВ. Әдәбиятка тарихи караш . . . . 183

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ТӨРЛЕСЕННӘН

**К. ФӘСӘХОВ.** Татарстан АССР төзелү һәм вакытлы матбугат . . . . . . . . . . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 191

**Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ**

**Редколлегия: ӘХСӘН БАЯНОВ** (баш редактор урынбасары), **ШАМИЛ БИКЧУРИН, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА** (җаваплы секретарь), **СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Шакирҗанова*

**Редакциянең адресы:** Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 23/IX-1980 ел. Басарга кул куелды 18/XII-1980 ел. ПФ 09045. Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 102 948 экз. Заказ У-404. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1981 ел.

## КПССның XXVI СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

**У. Б. Белялов,**

тарих фәннәре докторы

# БҮГЕНГЕ һӘМ КИЛӘЧӘК ХАКЫНА

Марксизм-ленинизм классиклары барлык җәмгыять членнарының һаман саен үсә барган матди һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек машина техникасына һәм фән-техника прогрессының башка казанышларына нигезләнгән, югары җитештерүчән коммунистик җәмгыятьне ачык күз алларына китергәннәр. Бөек Октябрь революциясенең җиңүе илебездә шундый җәмгыять төзү мөмкинлеген ачып җибәрде. Коммунистлар партиясе һәм дөньядагы беренче Совет дәүләтенең даһи юлбашчысы бөек Ленин социализм төзүнең фәнни нигезләнгән планын эшләде. Илне индурстрияләштерү, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү һәм культура революциясен тормышка ашыру әлеге планның төп буыннарын тәшкил итте.

Планлы, тигез дәвамлы үсеш — социалистик хуҗалык челтәренең иң төп закончалыгы һәм өстенлеге. Ул капитализмга хас экономик кризис, эшсезлек кебек күңелсез хәлләрне китереп чыгаруга юл куймый. Социалистик җәмгыять төзүне халык хуҗалыгын үстерүнең фәнни нигезләнгән киләчәк һәм агымдагы планлаштырудан башка күз алдына китереп булмый. Моның хәлиткеч әһәмиятенә басым ясап, В. И. Ленин: «Экономика һәм хуҗалык кыйммәтләрен тигез файдаланырга омтылып, зур гомуми план буенча алып барыла торган төзелеш кенә социалистик төзелеш дип атала ала»,— дип язды. (Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 28 т., 20 б.)

В. И. Ленинның халык хуҗалыгын планлаштырудагы комплекслы якын килү, планның фәннилеге, директивалылык, партиялелек, экономик һәм техник нигезләнгәнлеге, аны эшләүгә тармакчыл һәм территориаль якын килүне рациональ аралаштыру, үтәлешкә тиешле контроль урнаштыру, киләчәк планлаштыруны агымдагысы белән тыгыз бәйләүнең хәлиткеч роле кебек принципларын эшләүдәге хезмәте бәяләп бетергесез.

Хезмәт ияләренең актив катнашуын Владимир Ильич халык хуҗалыгы планнарын эшләү һәм тормышка ашыруның төп принципларыннан берсе дип санады. Ул бердәм үзәкләштерелгән планлаштыруны халык хуҗалыгы планнарын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда җирле партия-хуҗалык органнары һәм барлык хезмәт ияләренең актив катнашуы белән тайпылышсыз аралаштыру кирәклеген басым ясап күрсәтте.

Аның бу өйрәтмәләре тормыш һәм вакыт сынавын уңышлы үтеп чыкты. Алар хәзер дә теоретик һәм практик әһәмияткә ия, яңа тарихи шартларда КПССның экономик политикасы өчен төгәл юнәлеш булып хезмәт итә. Бөтен ил күләмендә халык хуҗалыгын планлы җитәкләү җәмгыять байлыкларыннан максатчанрак файдаланырга, барлык тармакларны үстерүдә тигезлеккә ирешергә, халыкның тормыш дәрәҗәсен туктаусыз яхшыртырга мөмкинлек бирә.

СССР халык хуҗалыгын планлаштыруның ярты гасырдан узып киткән тарихы өч төр дәүләт планы булган озак вакытка исәпләнгән бишьеллык һәм агымдагы планнар зарурлыгын ышандырырлык итеп күрсәтте. Илебездә халык хуҗалыгын планлаштыруның төп рәвеше булып бишьеллык планнар санала. Алар алдагы чорга социаль-экономик максатларны һәм бурычларны, җәмәгать ихтыяҗларын, фән-техника прогрессын гамәлгә ашыру һәм халык хуҗалыгы структурасын максатчан үзгәртү мөмкинлекләрен җитәрлек кадәр төгәл һәм тулы билгеләргә мөмкинлек бирәләр.

Тугызынчы бишьеллык планлаштыруны тагын да камилләштерүнең мөһим чоры булды. Иҗтимагый җитештерү күләменең үсүе, киңәюе, бәйләнешләренең катлаулануы план бурычларын фәнни нигезләүгә һәм тигезләүгә яңача якын килүне, тармакчыл һәм территориаль планлаштырудагы бердәмлекне тагын да яхшыртуны таләп итте. Җәмгыятьне үстерүдәге фәнни-техник, экономик һәм социаль мәсьәләләрне тыгызрак бәйләргә кирәклеге ачыкланды. Болар барысы да КПССның социалистик җитештерүне үстерүне тизләтүгә ирешү, нәтиҗәлелеген күтәрү, хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү һәм фән-техника прогрессын тизләтү, шуның нигезендә халык тормышының матди һәм культура дәрәҗәсен сизелерлек яхшыртуны төп бурычлар итеп билгеләгән XXV съезды карарларында якты чагылыш тапты.

Билгеләнгән зур чараларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә илебезнең экономик куәте сизелерлек үсте, күләме һәм әһәмияте белән моңарчы күрелмәгән социаль программа уңышлы үтәлде. Л. И. Брежнев нәкъ менә шуның өчен тугызынчы бишьеллыкны иң яхшы бишьеллык дип атады. 1971—1975 елларда тулай җәмгать продукты җитештерү — 36, промышленностьта җитештерү күләме 43 процентка артты.

КПССның XXV съезды Коммунистлар партиясе һәм бөтен совет халкы тормышында әһәмиятле вакыйга булды. Ул «1976—1980 елларга СССР халык хуҗалыгын үстерүнең төп юнәлешләре»н кабул итте. Шуңа туры китереп, унынчы бишьеллыкның планы эшләнде. Аны тормышка ашыру коммунизмның материаль-техник базасын төзү, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне тагын да камилләштерү, совет кешеләре тормышының матди һәм культура дәрәҗәсен күтәрү дә мөһим чара булды.

Унынчы бишьеллык план барлык тармакларны кискен үстерүне, социалистик экономиканың нигезе саналган авыр индустрияне тагын да алгарак җибәрү нәтиҗәсендә тармак ара һәм территориаль бүленешләрне тагын да камилләштерүне күздә тотып төзелгән иде. Билгеләнгән коммунистик төзелеш бурычлары хуҗалык итү механизмын яхшырту, барлык планлаштыру эшенә иҗади якын килү кирәклеген ачыклады. КПССның XXV съезды экономиканы идарә итүне нык үскән социализм шартларына туры китерү таләбен куйды, чөнки, съезд карарларында күрсәтелгәнчә, хуҗалык итү механизмының күпчелек буыннарын бик нык яхшырту сорала иде әле.

Партия һәм хөкүмәтнең шушы юнәлештә эзлекле рәвештә тормышка ашырган чаралары арасында КПСС Үзәк Комитетының «Хуҗалык итү механизмын тагын да камилләштерү һәм партия һәм дәүләт органнарының бурычлары турында», КПСС Үзәк Комитеты белән СССР Министрлар Советының «Планлаштыруны яхшырту, хуҗалык итү механизмының җитештерү нәтиҗәлелеген һәм эш сыйфатын күтәрүгә йогынтысын көчәйтү турында»гы карарлары (1979 ел) аеруча зур әһәмияткә ия.

Дөрес хуҗалык итү нәрсә соң ул? Әлеге карарлар менә шушы сорауга тулы җавап бирә. Бу — беренчедән, экономика үсешенең интенсив, сыйфат мәсьәләләренә юнәлеш тотарга, халык хуҗалыгында югары нәтиҗәләргә ирешергә; икенчедән, алга карап эшләргә, агымдагы һәм озак вакытка исәпләнгән максатларны дөрес аралаштырырга, кабул ителгән карарларның якындагы һәм киләчәктәге нәтиҗәләрен дә исәпкә алырга, идарә итүнең, планлаштыру һәм экономик кызыксындыруның хәзерге заман ысулларын үзләштерергә, консерватизмны һәм үзагым көчен кыю җиңәргә; өченчедән, экономика мәсьәләләренең социаль һәм идеологик процесслар белән тыгыз бәйлелеген күрергә, аларны җыелма төстә хәл итәргә; дүртенчедән, барлык буыннарда оештыру эшен яхшыртырга, дәүләт, план дисциплинасын сакларга; бишенчедән, хезмәт җитештерүчәнлеген кискен тизлектә күтәрү максаты белән, заман фәне һәм техникасы казанышларыннан оста һәм оператив файдаланырга кирәк дигән сүз.

Планлаштыру партия һәм хөкүмәтебез карарларында хуҗалык механизмын камилләштерүнең үзәк буыны итеп күрсәтелә. Аларда киләчәк һәм еллык планнарның бердәм үзара бәйләнешле чылбырына күчү, шулай ук предприятиеләрнең эш күрсәткечләренә бәя бирүне камилләштерү, шушы нигездә планлаштыруның үзенчәлексезлегенә ирешү күздә тотыла.

Промышленностьта һәм төзелештә хуҗалык итүнең яңа ысуллары кертелә башлауга бер елдан артык вакыт үтеп китте. Шушы вакыт эчендә планлаштыру органнары, партия һәм җәмәгать оешмалары, хезмәт коллективлары зур эзерлек эше үтәделәр. Барлык тармакларда, берләшмәләрдә, заводларда, төзелешләрдә әлеге карарларны, шулай ук алар нигезендә эшләнгән норма-ысул материалларын өйрәнү оештырылды. Хуҗалык итүдәге камилрәк чаралар коллективларның элегрәк кулланылган эш тәҗрибәсе башка урыннарда кертелә. Байтак күрсәткечләрне яңача бәяләү 1980 ел планнарында да күздә тотылган иде. Аерым алганда, берләшмәләргә һәм предприятиеләргә эшләүчеләр саны лимиты җиткерелде, җитештерелгән продукциянең бер сумына эш хакы түләү тәртибен куллану киңәйде. Мондый нормативлар 1980 ел башыннан 9 министрлыкта кулланыла башлады. Меңнәрчә эре производство берләшмәләре үз эшләрен турыдан-туры, дәвамлы хуҗалык элементләре нигезендә оештыра башладылар.

Инде унынчы бишьеллыкта ук планлаштыруның программ-максатчан ысулының әһәмияте ачык күренде. Аның нигезендә халык хуҗалыгын үстерүнең тармак ара мөһим мәсьәләләре хәл ителә. Бу ысул билгеләнгән максатка ирешү өчен матди һәм финанс ресурсларының тигезләнешен яхшыртуны тәэмин итә, бишьеллык һәм озак вакытлы планнарның анализын киңәйтү яки тирәнәйтүгә булыша.

Планлаштыруның яңа ысуллары, барыннан да элек, халык хуҗалыгында тигезләнеш һәм тиешле пропорцияләр булдыруны, барлык тармакларның тотрыклы эшләвенә тиешле шартлар булдыруны таләп итә. Тормыш күрсәткәнчә, уйланмаган, ягъни «көчләп тагылган» планнар начар нәтиҗәләргә китерә. Мәсәлән, унынчы бишьеллыкта Түбән Кама комплексында яңа производство куәтләре сафка кертелү уңае белән яңа төр продукцияләр җитештерү билгеләнгән иде. Ләкин җиһазлар белән тәэмин итү, төзү һәм кору оешмаларының мөмкинлекләре төгәл исәпкә алынмаган була. Нәтиҗәдә бишьеллыкның дүрт елында файдалануга тапшырылырга тиешле 8 эре объектның берсе дә төзелеп бетмәде. Шактый зур суммалык продукция җитештерелмичә калды. Бу исә унынчы бишьеллык контроль бурычыннан артка калуга китерде.

Яңа шартларда җирле планлаштыручылар белән хуҗалык оешмаларына шәһәр төзелешенең җыелма планын төзү һәм раслау бурычы йөкләнә. Тормыш раслаганча, әле шәһәр төзелешендә зур ялгышлар җибәрелә. Әйтик, Татарстанның промышленность үзәкләрендә электр һәм җылылык энергиясенә кытлык сизелә. Ул — төзелеш һәм энергия белән тәэмин итү планнарының үзара килештерелмәгән-көйләнмәгән булуы нәтиҗәсе. Нәтиҗәдә 1980 елда Чаллы, Түбән Камада һәм Казан шәһәренең кайбер районнарында җылылык энергиясе белән тәэмин итүдә киеренке хәл килеп чыкты.

Хуҗалык исәбендәге төп оешмалар сыйфатында эре производство берләшмәләре төзү промышленность һәм төзелештә хуҗалык механизмын тагын да камилләштерүгә мөһим этәргеч булыр иде. Партия һәм хөкүмәт карарында, производство берләшмәләре төзү нигезендә промышленность һәм төзелештә үзгәртеп коруларны тизрәк төгәлләү бурычы куела. Анда берләшмәләр һәм предприятиеләрнең хуҗалык эшчәнлеген бәяләү өчен яңа план күрсәткечләре кертү күздә тотыла. Бу исә аларның эшчәнлеген тулай продукция күләме, хезмәт җитештерүчәнлеге, эш хакы фонды һәм төп фондлардан файдалану дәрәҗәсе белән билгеләүдәге кимчелекле якларны бетерергә булышлык итәчәк.

Хәзер Татарстанда 42 производство берләшмәсе бар. Алар республикадагы промышленность продукциясенең шактый күп өлешен җитештерә. Тик әлегә республикада 200 дән артык предприятие мөстәкыйль хуҗалык берәмлеге булып исәпләнә. Аларның һәркайсының дирекциясе, ярдәмче службалары бар, әмма зыянсыз, нәтиҗәле эшләү өчен тиешле производство-техник базалары юк.

КПССның XXVI съездын лаеклы каршыларга әзерләнгән чорда илебез хезмәт ияләре унынчы бишьеллыкка йомгак ясый. Эшче һәм колхозчыларның, совет интеллигенциясенең фидакарь хезмәте белән, куәтле экономик куәт булдырылды, коммунизмның матди-техник базасын төзүдә, халыкның тормышын яхшыртуда зур уңышларга ирешелде. Унынчы бишьеллыкның дүрт елында гына да меңнән артык эре промышленность предприятиесе төзелде, төп производство фондлары 300 миллиард

сумлыктан күбрәккә артты. Техника прогрессын билгели торган тармакларны үстерү, илебезнең ягулык-энергетика базасын ныгыту дәвам иттерелә. Бишьеллыкны тәгълаү елында илебездә тиз рәвештә Байкал-Амур тимер юлы салына. Производствога фән һәм техника казанышлары актив кертелә. Бишьеллыкның XXV съезд билгеләгән социаль программасы тайпылышсыз гамәлгә ашырылды. Хәзер СССР корыч, нефть, ташкүмер һәм кокс, тимер рудасы, чуен, минераль ашламалар, тепловоз һәм электровозлар, цемент, агач материаллары, йон тукымалар, күн аяк киеме, суыткыч һәм башка төр продукция җитештерү буенча дөньяда беренче урында бара.

Унынчы бишьеллыкта Татарстан халык хуҗалыгының барлык тармакларын үстерүдә дә алга зур адым ясалды. Әйтик, ул бишьеллыкның 4,5 елында промышленностьта җитештерү күләме 49 проценттан күбрәккә артты, хезмәт җитештерүчәнлеге 31,7 процентка үсте. Продукция реализацияләү планы 494 миллион сумга артып үтәлде. Соңгы бер елда гына да республикабыз халык хуҗалыгына чыгым салулар күләме 2,6 миллиард сум тәшкил итте. Инде унберенче бишьеллык планының төгәл бурычлары билгеле. 1981 ел башыннан алып, планнар: фән-техника прогрессының җыелма программасы егерме елга, экономик һәм социаль үсешнең төп юнәлешләре ун елга исәпләнгән, шулай ук бишьеллык һәм еллык планнардан торачак.

Иптәш Л. И. Брежнев КПСС Үзәк Комитетының ноябрь (1978 ел) Пленумында ук СССР Госпланы якын арада илебез халык хуҗалыгын 1990 елга кадәр үстерү юлларын эшләп тәкъдим итәргә тиеш, дигән иде. Озак вакытка исәпләнгән киләчәк план хуҗалык үсешенең төп юнәлешләрен билгеләргә тиеш. Бу исә фән һәм техниканы үстерүнең аеруча мөһим мәсьәләләренә игътибарны көчәйтергә, производствоны отышлы урнаштыруга, аның челтәрен яхшыртуга һәм киң социаль бурычларны тормышка ашыруга булышлык итәчәк.

1990 елга кадәр киләчәк план төзегәндә байтак кына социаль-экономик һәм фәнни-техник программалар җыелмасы эшләнде. Әлеге җыелма программаларның нәтиҗәләрелеге күп кенә территориаль-производство комплексларын төзү һәм үзләштерүдә ачык чагылыш тапты. Аларга Көнбатыш Себер, Оренбург, Түбән Кама, Братск, Павлодар-Экибастуз кебек комплекслар керә. Алар унынчы бишьеллыкта электр энергиясе эшкәртү, тимер рудасы белән ташкүмер чыгару, йөк автомобильләре белән тракторлар җитештерүнең зур үсешен тәэмин иттеләр. Аларны үстерү программалары, кагыйдә буларак, халык хуҗалыгының байтак тармакларын һәм илебезнең зур өлешен үз эченә ала. Мәсәлән, Көнбатыш Себердә яңа ягулык, нефть-газ районын төзү программасында 6 министрлык белән 3 өлкә катнаша. Шуның белән бергә, тармак ара программалар эшләү моңарчы булган тармак яисә территориаль планлаштыру челтәрен бернichек тә йомшарту дигән сүз түгел, ул аларга зур халык хуҗалыгы мәсьәләләрен тизрәк һәм нәтиҗәле хәл итү юнәлешен тулыландырып тора.

Озак вакытка исәпләнгән киләчәк планлаштыруның әһәмияте һәм кирәклегенә В. И. Ленин да күп тапкырлар игътибар иткән иде. Советларның VIII Бөтенроссия съездында чыгыш ясап, ГОЭЛРОның киләчәк планы турында сөйләгәндә ул, аерым планнардан тыш, беренче тапкыр гомумиләштерелгән, шактый елларга исәпләнгән план барлыкка килүен дә күрсәтеп үтте.

Озак вакытка исәпләнгән планлаштыруның зарурлыгы турындагы Ленин өйрәтмәләре нык үскән социализм чорында аеруча зур әһәмияткә ия. Ул хәзерге вакытта планлаштыру тәртибенең бер генә бишьеллык чикләрендә хәл итеЛә алмый торган мәсьәләләр белән һаман саен ешрак очрашуыннан килеп чыга. Мәсәлән яңа фәнни-техник фикерләрне эшләүдән башлап, аларны гамәлгә ашыру, файдалану һәм искерүләре сәбәпле, производстводан алу өчен, гадәттә, 10—15 ел вакыт үтеп китә. Мондый шартларда озак вакытка исәпләнгән планнар нәтиҗәлелекне күтәрүнең резервларын тулырак ачыкларга, фән-техника прогрессы үсеше киләчәген күрергә мөмкинлек бирәләр.

Киләчәк һәм агымдагы планлаштыруны отышлы аралаштыру аның комплекслылыгын, өзеклексезлеген тәэмин итәргә, җәмгыятьне үстерүнең зур социаль-экономик шартларын үз вакытында эшләргә һәм тормышка ашырырга булышлык итә.

Нык үскән социализм шартларында аның өстенлекләреннән тулырак файдалану, экономиканы халыкның тормыш хәлен яхшыртуга кору өчен мөмкинлекләр тагын да

арта. Икенче яктан, совет кешеләренең тормыш дәрәҗәсен тагын да яхшырту безнең хуҗалык үсешенең үз ихтыяҗы, җитештерүне тагын да үстерү, эшчеләр, колхозчылар һәм интеллигенциянең хезмәт дәртен күтәрү өчен әһәмиятле экономик алшартларның берсе булып санала. Димәк, коммунизмның материаль-техник базасын төзүдә матди җитештерүнең халыкның тормыш хәлен яхшыртуга йогынтысын гына түгел, шулай ук киресенчә тәэсирен дә тирән тикшерү, исәпкә алу һаман саен әһәмиятлерәк була бара. Ул планлаштыруга комплекслы якын килү ролен көчәйтүне, ягъни политик, экономик һәм социаль мәсьәләләрне киң, үзара бәйләнештә карауны таләп итә.

В. И. Ленинның фәнни планлаштыруга караган фикерләре тантана итә. Планлы социалистик хуҗалыкның гаять зур өстенлекләре барлык социалистик дуслык илләренең экономик яктан тиз үсешендә һаман саен тулырак чагыла бара. Экономик Ярдәмләшү Советының 30 ел яшәү дәверендә социалистик илләр арасында экономика һәм фән-техника хезмәттәшлеге туктаусыз киңәйде һәм тирәнәйде. 60 нчы еллардан башлап, Экономик Ярдәмләшү Советы члены илләре халык хуҗалыгының киләчәк планнарын үзара бердәмләшеп эшли башладылар. Бу хәл 1971 елда Экономик Ярдәмләшү Советының XXV сессиясендә Социалистик экономик интеграцияне тагын да тирәнәйтү, хезмәттәшлекне киңәйтү һәм үстерүнең комплекслы программасын кабул иткәннән соң аеруча күп кулланыла. Ул җитештерүче көчләрне тизләтелгән үстерүдә һәм әлеге илләрнең һәркайсында социалистик төзелешнең яңа уңышларга ирешүендә хәлиткеч чараларның берсе булды.

Совет кешеләре Коммунистлар партиясенең чираттагы XXVI съездын политик бердәмлек шартларында каршылыйлар. Съезд алды социалистик ярышы киң җәелде. Унынчы бишьеллыкны тәгәлләү елы һәм тулаем бишьеллык планны уңышлы үтәүгә һәм арттырып үтәүгә күп хезмәт һәм иҗади илһам тотылды. Уберенче бишьеллыкның халык хуҗалыгы планын эшләүдә һәр совет кешесе актив катнаша.

**Шәмси Хамматов,**
доцент, тарих фәннәре кандидаты

# МУСА ҖӘЛИЛ—ПАРТИЯ СОЛДАТЫ

*Вакыт җитте...*
*Хәзер ярты юлда*
*Куеп торып тыныч эшемне,*
*Багышларга Ватан сугышына*
*Үземне һәм каләм көчемне.*

Муса Җәлил

„Социалистик Татарстан» газетасында (1979 ел, 28 август һәм 1980 ел, 7 май) һәм «Казан утлары» журналының 1980 ел, 2 нче санында «Идел бөркете — ил бөркете» исемле язмалар басылып, аларда Муса Җәлил тормышының моңа чаклы аз билгеле булган Марьино чоры яктыртылган иде.

Әлеге мәкаләләр дөнья күргәч, безгә күп кенә хатлар килде, телефон шалтыратулар, шәхси әңгәмәләр булды. Шагыйрьнең эшчәнлеген аны белгән кешеләр исән чакта ачыклап, өйрәнеп калырга кирәк, диләр безгә мөрәҗәгать иткән иптәшләр.

Мамадыш районының Түбән Тәкәнеш авылыннан укытучы Әмир Ганиев: «Муса Җәлил дуслары-курсташлары турындагы мәкаләне мин букчамда озак саклап йөрт-

тем һәм авылдашымның да (сүз Нәзирҗан Габитов турында бара — Ш. Х.) ул вакыйгаларда кайнавын, Муса белән бергә укуын, күптәннән таныш булуын Сезгә язып җибәрергә исәпләдем», — дип язды.

1923—1925 елларда Казан рабфагында укыган чагында Зиннәт Ибәтович Муратов Муса Җәлилне якыннан белгән, аның сабакташы һәм кордашы булган. Ул озак еллар КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре булып эшләде. Аңардан да хат бар. «Безнең якташыбыз герой Муса Җәлилнең, — дип яза З. И. Муратов, — Бөек Ватан сугышының беренче айларындагы эшчәнлеген, Марьино чорын күрсәтү, партиябез җитәкчелегендә оештырылган политработниклар курсында марксизм-ленинизм тәгълиматы белән коралланган шагыйрь-патриотның үсеш юлын чагылдыру— идея-политик эшебездә бик кирәкле чара».

Муса Җәлилнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә, пропагандалауга әдәбият белгече, тәнкыйтьче, шагыйрьнең якын дусты Гази Кашшаф бик күп көч сарыф итте. Үзе төзеп һәм эшләп Татарстан китап нәшриятында 1964 елны чыгарган «Муса турында истәлекләр» китабын Гази ага Кашшаф, «тирән ихтирам һәм хөрмәт белән» дигән сүзләр язып, миңа 1965 елның 11 гыйнварында бүләк итте. Журналистлар белән очрашканда ул һәр вакыт Муса Җәлил турында истәлекләрне тизрәк җыярга, тупларга өнди иде.

«— Муса турында истәлек кирәк!

Шушы сүзләр белән кемнәргә генә мөрәҗәгать итмәдем! Язучыларга, артистларга, композиторларга, белеш-танышларына, дусларына, көрәштәшләренә... Берсе дә тәкъдимне кире какмады, бик яхшы эш, изге эш, диделәр, андый истәлекләрнең киләчәк буыннар өчен аеруча кыйммәтле булачагын искә төшерделәр һәм истәлекләр ява башларга тиеш иде, билгеле. Тик... истәлекләр туплау эше шактый катлауланып китте һәм авырлашты. Миңа дистәләрчә кешеләр белән хат язышырга, дистәләрчә иптәшләр янына барып кайтырга, бик күпләрне күреп сөйләшергә һәм хәтерләрендә сакланган энҗе бөртекләрен инә белән казып алырга туры килде» [1].

Гази ага Муса Җәлилне якыннан белгән кешеләргә, аеруча аның белән Казанда рабфакта бергә укыган, башта гади эшче, соңыннан партия һәм дәүләт эшлеклесе булып үскән, шагыйрь истәлеген Бөек Ватан сугышы елларыннан соң мәңгеләштерү өчен күп көч түккән З. И. Муратов турында повесть язарга җыена иде. Ул аның белән Мәскәүдә һәм Казанда берничә тапкыр очрашты, Зиннәт Ибәтович белән минем заманында партия аппаратында бергә эшләвемне, аның тормыш юлын һәм эшчәнлеген якыннан белүемне искә алып, үз фикерләре белән уртаклаша иде.

Гази ага Кашшаф йогынтысы белән мин дә Муса Җәлил турында, бигрәк тә аның аз билгеле булган Марьино чоры турында истәлекләр, мәгълүматлар җыю, «энҗе бөртекләрен инә белән казып алу» эшенә керештем. Әлегә андыйлардан Гази Кашшаф эзләп тапкан И. Г. Степанов, Б. Х. Зязиков, Ф. Е. Герасев билгеле иде.

Мәсьәләне тулырак ачыклау өчен, бу юлларның авторы СССР Оборона министрлыгының Подольск шәһәрендә урнашкан Үзәк архивында булды, шагыйрьне белгән иптәшләргә мөрәҗәгать итте, курсташларына хатлар язды. Материал җыйнауда Муса Җәлилнең тормышы, иҗаты белән кызыксынган журналистлар, авыл хәбәрчеләре авторга шактый ярдәм иттеләр. Бу каләмдәш дусларга матбугат аркылы рәхмәтемне җиткерәм.

Муса Җәлил — 1929 елдан Коммунистлар партиясе члены. «Үземнең эшем белән, — дип яза ул ВКП(б) членлыгына кабул итүне үтенеп биргән гаризасында, — партиябез өчен һәр яктан файда китерергә, марксизм-ленинизм белемнәрен өйрәнергә, большевистик сафларда большевизм рухында тәрбияләнергә тырыштым... Ленинчыл Үзәк Комитет позицияләрендә нык һәм чын күңелдән ышанып тордым» [2].

Шагыйрь шул антына үзенең соңгы сулышына хәтле турылыклы булып калды. Бу язмада М. Җәлилнең Марьинода политик курсларда укыган чорда ук чын патриот, партия солдаты булганлыгын күрсәтү максат итеп куела.

---

[1] Муса турында истәлекләр, 306 бит.
[2] Муса Җәлил. Әсәрләр, дүрт томда. 3 т., Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976, 456—457 битләр. Алда М. Җәлилдән барча цитаталар шул басма томнарның санын һәм битләрен күрсәтеп һәр өзек азагында күрсәтеләчәк.

«Казан утлары» журналының алда әйтелгән санында политработниклар курсында шагыйрь белән бергә укыган кайбер кешеләрнең исемлеге бирелгән, анда Хәй Нуруллович Галимовның исем-фамилиясе дә күрсәтелгән иде. Ул Апас районының Чирмешән авылында яши икән. Газета һәм журналдагы язмалар белән танышкач, редакциягә хат җибәрде. Х. Галимов Муса Җәлил белән бергә курсларда Татарстаннан бүтән егетләр булганлыгын да хәбәр итте. Алар Актаныш районыннан Әмир Закирович Закиров, мәрхүм Арслан Мөхәммәтшович Мадияров, Мамадыш районыннан Нәзирҗан Миннекәевич Габитов. Белгород шәһәрендә яшәүче лейтенант Сергей Дубровин да шунда укыган.

«Мин, бервакытта да армиядә булмавыма һәм тәҗрибәм юклыкка карамастан, хәрби белемне тырышып үзләштерәм һәм сугышчан бурычларны начар башкармыйм» (3 том, 548 бит). Бу юлларны Муса Җәлилнең иң якын дусты Гази Кашшафка язган хатыннан укый идек. Ә менә хәзер шундый ук расләуны авыр хәрби хезмәтне бергә башлаган коммунист иптәшләреннән дә ишетәбез.

... 1941 елның июле. Казан тирәсе. Яшел урман. Каенлык. Кошлар моңына гына күнеккән урман кырмыска оясыдай мыжлап тора. Монда хәрби лагерь урнашкан. Дәһшәтле көннәр. Еракта, ил читендә туплар гөрселди. Явыз дошман Ватан тынычлыгын җимерергә, изге җиребезне мәсхәрәләргә, ирегебезне буарга тели. Шул илбасарларга каршы бөтен халык күтәрелә. Эшче һәм колхозчы, укытучы һәм инженер, галим һәм әдип — бары да яшел гимнастерка киген, бөтенесе дә ил азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен аяусыз көрәшкә әзерләнә.

Әнә укытучы Хәй Галимов та хәрби политработниклар курсында укырга чакыру алган. Марьино курсларына (Курск өлкәсе) хәрби хезмәтен Казанда рядовой булып башлаган Муса Җәлил дә җибәрелә.

Хәй ага Галимов бу хакта түбәндәгеләрне расләый:

«Ул көннәр бүгенгедәй хәтеремдә, — ди ул. — Очраштык, таныштык. Муса ачык күңелле, тиз аралашучан кеше булып чыкты. Сөйләшәбез. Ул безнең петлицадагы билгеләргә карый да көрсенеп куя: «Миңа бервакытта да армиядә булырга туры килмәде шул. Күнегүе кыен булыр инде»,— ди. Без, кадровыйда булучылар, аны үз итеп тынычландырабыз».

Моннан соң алар гел бер сафта булалар. Бергә товар вагонында Курскига киләләр, аннан Марьинога юнәләләр.

Марьино. Сугышчылар күңелендә ул туган илнең гүзәл бер җире булып сакланган. Сарай-бакчаның бик матур алма бакчасы бар, ә алмалары кызарып пешеп килә. Күл. Уртасындагы атауга сыгылмалы басмадан керәсең. Марьино кунакларны шулай каршылый. Ләкин кунаклар үзгә, алар барысы да хәрби киемнән, бөтенесенең дә йөзләрендә тирән уйчанлык чагыла.

«Марьинога июль урталарында килеп кердек, — ди Хәй Галимов. — Безнең беренче ротаны төп бинаның беренче катына урнаштырдылар. Казаннан килгән егетләр барыбыз бергә, Муса да безнең белән. Ләкин бинада бер ай чамасы гына яшәп калдык. Бакчадагы палаткаларга күчерделәр. Без Муса белән бер взводта идек, бер палаткага урнаштык. Миннән сул якта Муса койкасы, аңда тагын бер татар егете бар. Башкалары руслар иде. Уку киеренке, тын алырга да вакыт юк».

Х. Галимовны тыңлагач, Мусаның ул вакыттагы өлгерлегенә таң каласың. Көн саен 14 сәгать занятие. Тактик өйрәнүләр. Фронт шартларына туры китереп, корал һәм башка сугыш кирәк-яракларын тулы килеш алып һәм тагып чыгалар. Палаткага кайткач, корал чистарту, политик әңгәмәләрдә катнашу, тагын әллә никадәр мәшәкатьләр була. Шундый шартларда да шагыйрь идеалына тугрылыклы шигырьләр яза, дуслары һәм гаиләсе белән хатлар язышырга да вакыт таба.

Ул хәрби хезмәткә өйрәнү белән бергә, илне сөйгән йөрәк тибешен дә җырында гәүдәләндерә:

Каләмемне салдым юл сумкама,
Автоматым тактым аркама.
Фашистларга каршы пуля һәм җыр
Бил каешымда бергә саклана.

(2 том, 16 бит)

— дип яза ул Марьино иманнәре астында корылган палаткада. Аның «Әйдә, җырым!» шигыре һәм башка әсәрләре хәрби өйрәнү шартларында иҗат ителгән.

— Мусага уку, ничектер җиңел бирелә иде, — дип дәвам иттерә Хәй Галимов сүзен. — Русча әйбәт белгәнгәдер, күрәсең. Материал частьны да тиз үзләштерде. Ә без станоклы һәм кул пулеметларын да, башка коралларны да өйрәнә идек. Укытучының русча сөйләвен кирәгенчә төшенеп бетермәсәк, Муса шунда ук татарчалап аңлатып бирә иде. Аңа курсантлар өчен политик темага лекция укырга кушуларын да хәтерлим.

Тагын Мусаның Казанга җибәргән хаты искә төшә. «... Хәрби белемне тырышып үзләштерәм һәм сугышчан бурычларымны начар башкармыйм», — дип ул Гази ага Кашшафка нәкъ шушы чагында язгандыр, армиядә булмавына элекке көрсенүләрен читкә куеп, укуыннан канәгать булуын эчке бер горурлык белән хәбәр итәргә теләгәндер. Әмма Хәй Галимов әлегераслауның үтә тыйнак булуына игътибарны юнәлдерә.

— Бер көнне взводны тактик занятиегә Муса алып барды, — ди ул. — Фронт шартларында топографик карта белән эш итәргә өйрәнәбез. Муса миңа мөрәҗәгать итә: «Курсант Галимов, сез — взвод командиры,— ди.— Дошман фәлән ноктада урнашкан. Сез взводыгыз белән шул ноктаны алырга тиешсез. Ничек хәл кылырсыз?» Шулай күнегүләр ясыйбыз. Курсантларның барысы да шартлы рәвештә взвод командиры булып карый. Аннары Муса занятиегә йомгак ясый. Кырдан арып, әмма канәгать булып кайтабыз.

Бөтен күңеле, хисе, тормышы белән шагыйрь кешенең әгәр дә аның йөрәк тибешен сиземләсәң, хәрби һөнәрне бирелеп өйрәнүенә гаҗәпләнмисең. Чөнки:

**Фашист кердe басып җиребезгә,**
**Аркасына асып балтасын...**
**Ул яндыра, вата илебезне,**
**Ничек шуңар түзеп ятасың!..**
**Киттем, кызым, якты бәхетебезне**
**Бирмәс өчен фашист кулына;**
**Егылсам да алга егылырмын**
**Киртә булып дошман юлына.**

**(2 том, 17 бит)**

— ди ул яраткан һәм бик сагынган кызы Чулпанга атап язган шигырендә.

— Безне төрле сугыш коралларыннан атарга өйрәтәләр иде, — ди Хәй Галимов.— Хәрәкәт итүче мишеньга да төбәп атабыз, бер урында торганда да. Һич онытмыйм: бервакыт атулар тәгәлләнгәч, командир курсантларны сафка тезде. Көр тавыш белән дәшә:

— Курсант Җәлилов.

— Мин.

— Курсант Галимов.

— Мин.

— Ике адым алга!

Без, гаскәриләрчә атлап, саф алдына чыгып бастык.

— Ату күнегүләрен бик яхшыга үтәвегез өчен сезгә рәхмәт белдерәм.

— Советлар Союзына хезмәт итәбез! — дип без беравыздан җавап бирәбез. Ул вакытта мин шат һәм бәхетле идем. Муса да мөгаен, шундый тойгылар кичергәндер. Шунда тагын болай уйлап куйдым: мин, дим, өч ел кадровыйда хезмәт иттем, корал белән эш итүдә күпмедер тәҗрибә алган кеше. Башка курсантлар да элекке хәрбиләр. Муса да мылтыктан атарга безнең шикелле тиз өйрәнде.

Әлбәттә, Муса Җәлилгә мылтыктан оста атарга, хәрби эшкә тиз өйрәнергә егерменче еллар башында ук аның Оренбург губерна хәрби-партия мәктәбендә укуы ярдәм иткәндер. «Бу мәктәптә, — дип яза М. Җәлил үзенең биографиясендә, — укучылар гаскәри хезмәтне дә үтиләр иде: шәһәрдә каравыл эшен алып баралар, бандаларга каршы көрәшәләр иде. Мин шулай бик яшьли винтовка тотып, гаскәри эшне үти башладым». (3 том, 450 бит).

Шулай «тиз өйрәнүнең» серен шагыйрь хатларында да ачып бирә. «Әле хәзергә фронт тирәсенең авыр шартларында, тылда яшәгәндә, мин үземне алдагы сугышлар өчен чыныктырам», — дип язганы мәгълүм безгә. «... Фронт тирәсендәге чын тормыш алай ук уңайлы түгел. Без аны гражданлык шартларында (күбесенчә кинодан күреп) икенче төрлерәк күз алдына китерәбез. Әгәр мин элек ул тормышның бары романтикасын гына белсәм, хәзер инде тупас реаль шартларда барысын да үзем кичердем һәм күрдем!!! Ләкин көч һәм җиңүгә булган ышаныч көннән-көн үсә бара» (3 том, 548 бит), — дип дустыннан бернәрсәне дә яшермичә һәм рухи ныклык белән яза ул Гази Кашшафка.

Без монда үзен алдагы сынаулар өчен чыныктыручы, дошманга нәфрәт, туган илгә мәхәббәт хисләре белән яшәүче һәм башкаларга патриотик үрнәк күрсәтүче шагыйрь-солдат образын күрәбез һәм шул хакта әллар аша гүя үзе белән сөйләшәбез.

— Мусаның күңеле бик күтәренке чаклар була иде, — ди аның курсташы Хәй Галимов. — Белеп торасың: я гаиләсеннән, я дусларыннан күңелле хәбәр алган яки яңа шигырь язган. Шуны белдерергә, шатлыгы, яңалыгы белән уртаклашырга җай эзли.

Солдат хезмәте кешеләрне аеруча якынайта. Әә бергә яшәү, бер сафта йөрү, авыр хәрби задание үтәгәч, янәшә койкада рәхәтләнеп гәпләшеп алу мөнәсәбәтләрне шулкадәр ныгыта ки, кеше үзен бертуган итеп сизә башлый. Монда тойгылар да, омтылышлар да, ризыклар да уртак була. Хәй Галимов бу уңайдан кызыклы бер эпизод сөйли.

— Вакыт нинди тыгыз, тар булуга карамастан, курсантларга кыска срокка частьтан чыгарга рөхсәт бирәләр иде, — ди ул. — Бервакыт, һич уйламаганда, увольнительныйны Муса белән бергә бирделәр. Кая барырга? Минем өмет шәһәрне күрергә, аннан базарга сугылырга. Ни өчен дисең, авыр занятиедән яки хәрби бурыч үтәп кайткач тамак туйганчы ашамаган чаклар да булгандыр. Аннары җае туры килгәндә сыйланырга да өметләнгәнбездер. Шундый өмет Мусада да бар иде, дип әйтимме, үзара сүз алышмыйча, базарга борылдык. Башта әйрән эчеп сусавыбызны бастык. Аннары икмәк белән атланмайга күзебез төште. Муса белән күзгә-күз караштык та... барлы-юклы акчабызны санап, бер буханка ипи белән бераз атланмай алдык.

Илгә, тыныч халыкка ирексездән тагылган канлы сугыш шагыйрьнең дә, педагогның да язмышын шулай бер иткән. Алар солдат тормышы мәшәкатьләрен бергә кичерәләр. Шатлыклы минутлар да уртак була.

— Почта көтеп алу иң куанычлы чак иде, — дип искә ала Хәй Галимов. — Курска алынган хатларны, занятиеләр якын тирәдә булса, китапханә мөдире Валентина Тарасевич китерә. Ул 25 — 30 яшьләрендәге хатын иде. Матурлыгы, ягымлылыгы теләсә кемне әсир итәрлек. Шундый кешенең почта китерүе үзе бер рәхәт иде.

Курста хәрби өйрәнү һәм укулар җайлы гына барганда, яңа мәшәкатьләр туа. 1941 елның август ахырларында дошман Курскига якынлаша. Төнлә фашист самолетларының үкерүе, бомбалар гөрселдәве ишетелә башлый. Дошман өлкә шәһәрләрен бомбага тота, политработниклар курсы урнашкан Марьино сарай-бакчасы фронт зонасында диярлек кала. Хәй Галимов ул чакны болай искә ала:

— Безне төнлә тревога белән күтәрделәр. Бөтен корал һәм сугыш кирәк-яракларын тагып, кайберләрен җилкәгә алып сафка бастык. Кузгалырга команда бирделәр. Бу — Марьинодан бөтенләйгә китүебез иде... Көзге караңгы төн иде. Юлсыз һәм утсыз барабыз. Иртә белән яңгыр ява башлады, аяк асты пычранды. Монысы бер хәер. Якында гына фронт, дошман самолетлары килеп колоннаны бомбага тотулары ихтимал. Шуңа күрә үзебезне сугышчан хәлдә сизә идек. Без шул көнне үк Щигры шәһәренә килеп җиттек, шактый йончыган идек...

Поход, әйе, беркайчан да җиңел түгел. Муса Җәлил бу кичүне дусларына язган хатында тасвирлаган, шунда ук, үз солдатларының түземлелеге һәм кыюлыгы белән горурланган командир кебек, иптәшләренең яңа урынга имин һәм кәефле барып җитүләрен нигдидер эчке куаныч белән хәбәр иткән.

Щигрыда үзгә шартлар. Курс эшен дәвам иттерә, уку практика белән бергә үрелеп бара, курсантлар «сугышны күреп һәм хис итеп», минуты белән фронтның алгы сызыгына басарга әзерләнеп һәм омтылып баралар.

— Безгә Щигрыда озак торырга туры килмәде, — ди Хәй Галимов. — Вагоннарга төяндек. Безнең взвод бер вагонга урнашты. Ике катлы агач сәкеләр, поход обстановкасы. Без курсларда укуның ахырынача дәвам итәчәген, ә хәзер тылгарак күчерелүен белдек. Безнең Коммунистлар партиясе шундый авыр чакта да армиянең политсоставын әзерләүгә, алар аша киләчәктә сугышчыларга тәрбияви йогынты ясауга шулай зур игътибар бирде. Юлда да вакытны заяга үткәрми идек. Укулар нормаль бара. Вагонда устав һәм наставлениеләр өйрәнәбез, политлекцияләр тыңлыйбыз, яңа алынган газеталар аша фронттагы һәм тылдагы хәлләр белән танышабыз. Монда Муса үзенең югары политик әзерлеген, кешеләр белән эшләү сәләтен аеруча танытты. Без шулай тулы тормыш белән килә торгач, Бөгелмәгә җиттек. Вагоннардан чыгып сафка басарга куштылар. Юл Минзәләгә иде...

Бер взводта хезмәт итүче һәм хәрби-политик чыныгу алучы ике татар егетенең якынлыгына курсларда да тәмам күнеккән булганнар. Кайчак аларны буташтырганнар да әле. Муса Җәлил 1941 елның 6 декабрендә Г. Кашшафка язган хатында бу турыда үзе болай дип искә ала: «...син минем кайтуымны ишетү белән телефонга чакырдың. (Ләкин беренче чакыруыңда «Залилов»ны «Галимов» белән саташтырганнар да, минем урынга икенче кеше барды)» (3 том, 550 бит). Казандагы язучы белән шулай Муса Җәлил урынына Хәй Галимов сөйләшә, әдипнең сәламен дә ала, үзе дә ирештерә.

— Курсларны уңышлы тәмамлагач, без 10 кеше — барыбыз да политик җитәкчеләр — Мәскәү хәрби округында сугышчан частьларга билгеләү көттек. Миңа озак торырга туры килмәде, ротага политрук итеп җибәрделәр. Муса озата килде. «Дус яшәдек, Хәй», — дип фронтта уңышлар теләп калды. Чын дусларча һәм туганнарча үбешеп аерылыштык.

Бөек Ватан сугышы ветераны Әмир Закиров та Муса Җәлилнең курсташы булган. Ул хәзер Актанышта яши. Шагыйрь белән очрашуын Ә. Закиров болай тасвирлый:

«... Муса белән бергә политработниклар курсында укыдык, бергә палаткаларда һәм баракта яшәдек. Минем өчен уку бик авыр иде, миңа бер рус егете белән (исем-фамилиясен хәтерләмим) Муса Җәлил төннәр буена дәрес хәзерләргә ярдәм иттеләр. Ул бик кече күңелле, ифрат ярдәмчел кеше булып чыкты. Ләкин Марьинода озак укырга туры килмәде, немецлар тирә-юньне бомбага тотуны ешайта башлагач, урын алыштыра-алыштыра, Марьинодан Минзәләгә күчтек... Мин Муса Җәлил белән даими аралаштым, хәтта Бөгелмәдән Минзәләгә юлны бергәләп уздык. Мин М. Җәлилне шат күңелле, бик тә гади, шаян сүзле, теләсәң-теләмәсәң дә игътибарны үзенә җәлеп итә торган курсант буларак беләм. Актаныш районы, Наратлы авылыннан Арслан Мадияров та безнең белән бергә Марьинода да, Минзәләдә дә укыды. Ул да нык ихтыярлы коммунист иде (1974 елда туган авылында вафат булды ул). Без 1941 елның декабрендә, курсларны тәмамлагач, төрлебез төрле хәрби частьларга таралыштык. Шунда М. Җәлил белән аерылыштык һәм шул көннән бирле сугышчан дусларым, хәрби политработниклар, командирларым белән очрашып сөйләшү, күрешү насыйп булмаса да, алар минем мәңгелек дусларым булып калды».

Матбугатта чыккан язмаларыбызга авыл хәбәрчесе Әмир Ганиев игътибар иткән. Ул элек Мамадыш районының Түбән Тәкәнеш авылында яшәүче Нәзирҗан Габитовның Марьинода М. Җәлил белән бергә укыганлыгын язып җибәрде. Сугыш ветераны, коммунист, отставкадагы капитан, ике орден кавалеры Н. Габитов белән элемтәгә керү кыйммәтле мәгълүматлар китерде.

«Мин Муса Җәлилне шагыйрь буларак та сугышка кадәр үк ишетеп белә идем, — дип искә ала Н. Габитов. — Аның шигырьләрен дә укып бардым. Шагыйрь белән беренче очрашуым 1939 елда булды. Мин бу чорда Казанда саклык кассалары мөдирләре әзерли торган курсларда укый идем. Муса Җәлил белән мине «Кызыл Татарстан»ның үз хәбәрчесе Абдулла Вәлиев таныштырды. Минем хакта ул Хасан күле буендагы сугышларда катнашучы буларак мәкалә язган иде. Аны фоторәсем белән «Кызыл Татарстан» газетасында бастырып чыгарды[1]. Муса Җәлил белән очрашуым

[1] 1939 елның 16 декабрендә басылган.

Бауман урамындагы 19 нчы йортта, ТАССР Язучылар союзы бүлмәсендә булды. Шагыйрь минем Хасан күле буенда күрсәткән сугышчан батырлыгым, Кызыл Байрак ордены белән ни өчен бүләкләнүем хакында җентекләп сорашты. Үземдә сакланган полк газеталарын да (анда минем турыда язылган мәкаләләр бар иде) сорап алды. Сезнең турыда очерк язам, диде ул. Сәбәбен белмим, ни өчендер Муса Җәлил аны яза алмыйча калды. Бу чорда «Алтынчәч» әсәре белән нык мәшгуль булуын белә идем. Мөгаен, вакыты җитмәгәндер. Шагыйрь белән, — дип дәвам итә Н. Габитов,— яңадан Марьинода очрашырга туры килде. Мин моңа кадәр Бөек Ватан сугышында булырга, яраланырга өлгергән идем. Политработниклар курсына Рязаньда госпитальдә ятканнан соң килдем. Менә бер көнне иртән безне сафка тезделәр. Анда яңа килүчеләр дә бар иде. Карыйм: шулар арасында Муса Җәлил дә басып тора. Сафларны таратуга, мин, аның янына ашыктым. Без бик җылы итеп күрештек, хәлләрне сорашырга керештек. Мин аңардан үзебезнең Татарстан, Казан хәлләрен, ул миннән фронт хәлләрен сорашты. Муса Җәлил шунда миңа үзенең шагыйрь булуы хакында бик шаулап йөрмәскә кушты. Мөгаен, ул үзенә аерым игътибар итүне, курсантлардан аерылып торуны теләмәгәндер. Бик тыйнак кеше иде Муса Җәлил. Аннары шагыйрьнең тизрәк безнең белән фронтка эләгәсе килгәндер. Аңа Казаннан курслардан азат итүләрен сорап үтенеч тә килгән иде. Муса Җәлил, бу хакта белгәч, курслардан китүдән катгый рәвештә баш тартты. Без бер взводта, бер отделениедә булдык. Курсташым Хәй Галимов «Социалистик Татарстан» газетасында басылган истәлегендә «Миннән сул якта Муса койкасы, уңда тагын бер татар егете бар», дип яза. Бу кеше мин идем. Шулай итеп, безнең койкалар рәттән туры килде. Муса Җәлил сугышның авыр буласын дошманны ныклы әзерлек белән генә җиңеп буласын яхшы аңлый иде».

Фронт һаман саен Марьинога якынлаша, артиллерия канонадасы инде бик ачык ишетелеп тора башлый. «Шуңа күрә без,— дип сөйли Н. Габитов.— һәр минутта көтелмәгән хәлләргә әзер булып яшәдек. Чиратлашып постларда тордык. Бер төндә немецлар Марьинодан 10 — 12 чакрымнар тирәсендәге Колонтаевка дигән станцияне бомбага тоттылар. Безне тревога белән күтәрделәр дә тиз генә шунда алып киттеләр. Анда корал алып йөгереп диярлек бардык. Әгәр дошман десант төшерергә исәпләсә, без аны ут белән каршыларга тиеш идек. Десант булмады. Көн яктыргач, без яңадан Марьинога кайттык. Муса Җәлил дә безнең белән булды. Ул юлда арыган иптәшләргә булышырга тырышты, коралларын күтәрешеп барды.

Марьинодан соң Щигрыга, аннан Минзәләгә күчәргә туры килде. Бәхеткә каршы, безнең койкалар Минзәләдә дә рәттән туры килде. Муса Җәлил биредә шигырьләрне ешрак яза башлады. Бер көнне ул миңа «Минзәлә» дигән яңа шигырен укып күрсәтте. Шәһәр урамнарының төзек булмавын, җыештырылмавын тәнкыйтьләп, шагыйрь чәнечкеле юллар да язды һәм аны Минзәлә культура йортында укыды.»

1941 елның ноябрендә язылган «Минзәлә истәлеге (дусларча шаяру)» шигырендә мондый юллар бар:

> **Хуш, Минзәлә,**
> **синдә кунак булдым**
> **Бик аз гына, үтеп барышлый;**
> **Шуңа күрә нәни шаярулы**
> **Бу җырымны сиңа багышлыйм.**
> **Исән калсын миннән урамнарың,**
> **Урам баскан карың, бозларың...**
>
> **(2 том, 35 бит)**

«Муса Җәлил ял көннәрне,— дип яза аннары Н. Габитов,— якын тирәдәге авылларга барып, шигырьләрен укый иде. Бер колхоз председателе аны үзе килеп алып китүе хәтердә калган. Шагыйрь тегендә-монда чыгыш ясарга барасы булса, шигырьләрен матур итеп сөйләргә өйрәнә иде. Ул минем тыңлап торуымны, аңа бәя бирүемне сорый иде. Шагыйрь минем блокнотыма миңа багышлап, «Артиллерист Нәзирҗан» дигән шигырен дә язган иде. Бу шигырь язылган блокнотны, кадерле истәлек

буларак, гел үзем белән йөрттем. Ләкин аны, дошман кулына эләкмәсен дип, бервакыт ирексездән юк итәргә туры килде».

М. Җәлил Хасан күле буендагы сугышларда батырлык күрсәткән Н. Габитовны халык каһарманнарының берсе дип атый һәм аның хакында зуррак әдәби әсәр язарга кирәклеген әйтә. Үзе исә Хасан күле буендагы сугыш вакыйгаларына, япон илбасарларын фаш итеп, «Сабак» исемле шигырен багышлый:

Ул — юлбасар, төнлә керел баса,
Кайда тын һәм кайда караңгы.
Тик артына типкәч итек белән,
Кая керер тишек табалмый.
Хасан күле батыры күкрәгенә
Кызыл орден таккан чагында,
Утыра булыр санап кабыргасын
Ул да тауның теге ягында.

(2 том, 12 бит).

«Мәскәүгә формированиегә барырга боерык килгәч, — ди аннары Габитов, — без җәяүләп Минзәләдән Әгерҗегә киттек. Муса Җәлилне шуннан бер көн элек кенә озаткан идек. Аның белән яңадан Мәскәүдә, үзебезнең резерв пунктында очраштык. Менә шунда ул безне туганнары белән таныштырды. Муса Җәлил минем хәрби гимнастеркамны киеп фотога да төште. Аңа әле нинди дә булса частька билгеләү турында боерык алынмаган, шуңа күрә хәрби форма да бирелмәгән иде. Ә мин аннан алдарак 61 нче армиянең 915 нче артиллерия полкы составындагы дивизион комиссары итеп билгеләндем. Шуңа күрә Муса Җәлилнең һәрберебезгә билгеле фоторәсемдәге гимнастерканы минеке, дип әйтә алам. Мин үз частема аннан алдарак киттем. Тиздән Муса Җәлилдән Мәскәүдән, резерв пунктыннан бер хат алдым. Ул анда озакламый фронтка китәм дип язган иде. Ө соңрак Старая Русса юнәлешеннән аннан тагын ике хат алдым. Бу хатлар теге истәлекле блокнот белән юкка чыктылар».

Чыннан да М. Җәлилнең «Тупчы анты» дигән шигыре армиядә чагында языла һәм ул «Кызыл Татарстан» газетасында (1941 ел, 8 август) басыла. Бәлкем ул шигыре политработниклар курсында бергә укыган артиллерист-офицер Нәзирҗан Габитовка багышлап язылгандыр.

Хаклык сүзе булып, фашист күген
Ярып үтсен ядрәм, ялтырап.
Батарея хәзер, прицел шул ук;
Бир команда, иптәш лейтенант!..
Яшен булып яшьнәр минем ядрәм,
Болыт булып каплар тетене;
Шул тетендә эреп күккә очар
Теткәләнгән фашист көтүе!

Н. Габитовның үзенең сугыштагы хәлләре турында авыл хәбәрчесе, укытучы Әмир Ганиев мондый юллар яза: «Нәзирҗан ага Муса Җәлилнең Мәскәүдән һәм Старая Русса яныннан язган хатларын да ала. Нәкъ шул көннәрдә ул хәрби корреспондент Шәйхи Маннур (ул да Тәкәнеш ягыннан — Ш. Х.) белән очраша. (3 том, 567 бит). Якташларның сөйләшер сүзләре күп була. Икесе өчен дә якын дус булган Муса Җәлил турында озаклап сөйләшеп утыралар. Тик бу көннәрдә авылдашымның Мусадан алган хаты соңгысы була».

Аннары ул авылдашы Н. Габитов белән фронтта булган фаҗига хакында борчылып, мондый хәбәр юллый: «1943 елның җәе. Орел өлкәсенең Медведки авылы янында капитан Н. Габитовның артиллерия подразделениесенә дошманның һөҗүмен тоткарлау һәм безнекеләргә югалтусыз чигенү мөмкинлеге тудыру бурычы йөкләнә. Әледән-әле котырынып һөҗүмгә күчүче дошманны подразделение тәүлек буе

тоткарлап тора. Дошман зур югалтуларга дучар итела. Шул вакыт приказның үтәлүе, подразделениегә дә чигенергә һәм яңа позициягә ныгып урнашырга мөмкин булуы хакында хәбәр алына. Һәм кинәт дөньяның асты өскә килә кебек... Нәзирҗан аңына килгәндә, бу позиция инде дошман кулында була. Дошман гаскәрләре якында ук һаман хәрәкәт итә. Аны күреп алулары мөмкин. Каты яраланган Нәзирҗан, үзендә көч табып, дошман күзеннән читкәрәк шуыша. Үч иткәндәй, якында яшеренер урын да юк. Шуыша торгач, ул бер чишмәгә тап була. Бүтән мөмкинлек юк: ул салкын чишмә суына төшеп утыра. Биредә байтак утырырга туры килә аңа, чөнки дошман гаскәрләре уза тора...

Нәзирҗан ничек кенә булса да үзебезнекеләр ягына чыгу турында уйлана. Документларын, орденын һәм башка истәлекле әйберләрен биредә күмеп калдырырга кирәк дигән нәтиҗәгә килә. Чөнки дошман кулына эләгүләре мөмкин. Һәм менә ул, дүрт елдан соң, кабат шушы якларга әлеге чишмәне эзләп юл тота. Истәлекле урыннар хәтердә нык сеңеп калган. Документлары һәм ордены да яхшы сакланган булып чыга. Үзе өчен изгегә әйләнгән чишмәнең суын эчкәндә, аның күзләреннән мөлдерәп яшь тәгәри. Күңеле белән кабат канлы көрәш елларына әйләнеп кайта... Аның бу тирәләрдәге сугышларда күрсәткән батырлыклары да югалып калмаган икән. СССР Оборона министрлыгының Үзәк архивында аңың Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнүе турында Указ саклана һәм, ниһаять, 1957 елда орден үзенең иясен эзләп таба».

«Мин М. Җәлил турында еш уйлана идем, — ди Н. Габитов. Әсирлектән котылып кайтып байтак еллар узгач кына, чын хәлләр турында белдем. Коммунист Муса Җәлил турында «хәянәтче» дип әйтүчеләргә мин бервакытта да ышанмадым. Аның хакында чынбарлык ачыклангач, үз күңелемдәге ышану һәм уйларның раслануына шатландым».

Муса Җәлил турында эзләнү нәтиҗәле булды: менә тагын бу язмалар авторының хатына җавап итеп Аксубай районы, Иске Ибрай авылында яшәгән, «Татарстан» колхозында бухгалтер булып эшләүче Бөек Ватан сугышы ветераны, отставкадагы подполковник Вәлиҗан Газиз улы Галимовтан да хәбәр килеп төште.

«Мин Муса Җәлил белән булган, үткәргән көннәрне, айларны, — дип яза ул, — үз гомеремнең иң матур, бәхетле көннәре дип саныйм. Бөек Ватан сугышы башлангач, июль ахырларында, мин Марьинога политработниклар хәзерләү курсына җибәрелдем. Безнең арада татарлар да бар иде. Муса Җәлилнең укырга килгән хәбәре бик тиз таралды. Минем хәтеремдә: ул килгәчтен икенче-өченче көннәрендә үк курсантлар арасында чыгышлар ясый башлады. Безнең арада урта белемле иптәшләр дә күп түгел. Күпчелек курсантлар фронтка китәргә ашкыналар иде. Шуның өчен дә Муса Җәлил курсантлар арасында агарту эшләре алып барды, сугыш чорында политработникларның бик кирәклеге турында сөйләде. Бер кичне взвод агитаторы белән Муса Җәлил курсантлар арасында Николай Островскийның «Корыч ничек чыныкты» китабын кычкырып укуны оештырдылар. Шулай бер кичне күл буенда татар курсантлары җыелып туган телләрендә җырлап утырганда, сиздермичә безнең янга Муса Җәлил килеп тыңлап тора икән, — дип яза Вәлиҗан Галимов. — Без барыбыз да аны күргәчтен олылап торып бастык. Ул безнең белән әңгәмә уздырды, сугыш серләрен саклау турында сөйләде».

Вәлиҗан Галимов «Хуш, акыллым» (Әминәгә истәлек) шигыренең язылу тарихын да искә ала. Ул хәрби-политик курсларда укыган Солтан Зарипов үтенүе буенча аның хатыны Бануга М. Җәлилнең шигырь-истәлек язып бирүен хәбәр итә. «Хуш акыллым» шигыре бер «Солтан Зариповта гына калмады, без татарлар барыбыз да кулдан-кулга күчереп «Бану» исеме урынына үзебезнең сөекләләребез исемен язып җибәрдек. Сугыштан соң минем туган сеңлем һәм тормыш иптәшем яхшылап хат та яза белмәгән кеше, ничек шулай матур итеп шигырь яза алдың дип сораштылар. Мин аның Муса Җәлил шигыре булуын аңлаттым», — дип яза Вәлиҗан Галимов.

Аннары В. Галимов политкурсларның Щигры шәһәренә күчүен, Муса Җәлилнең анда булган эшчәнлеге турында сөйли. «Муса Җәлил Щигрыда да курсантлар арасында күп эш алып барды. Политотдел, курс командованиесе Муса Җәлилне ихтирам итәләр иде. Октябрь аенда Щигрыны да каты бомбить итә башладылар, эвакуация

башланды. Хәрби госпитальләрне, шәһәр больницаларын эвакуацияләделәр. Бу эштә без дә ярдәм иттек. Муса Җәлил Щигрыда «Госпитальдән» дигән шигырен язды. Шунда Муса Җәлил үз күзе белән күргән каты яралануларны ул шигырендә тасвирлаган».

Муса Җәлилнең 1941 елның октябрендә язган «Госпитальдән» исемле шигыре Ватанга, халыкка ант булып яңгырый:

**Госпитальдә хәзер мин...**
**Шулай да**
**Син борчылма, тормыш юлдашым!**
**Соңгы тамчы каным тамса тамсын,**
**Тик антыма таплар кунмасын...**
**Ил!**
**Алдыңда синең мин ант итәм,**
**Шаһит булсын кулым ярасы:**
**Гитлер явын тар-мар итми торып,**
**Якты күрмәс күзем карасы!**

**(2 том, 26—28 бит)**

«Щигрыдан китәр алдыннан, — ди аннары В. Галимов, — станциядә безгә Муса Җәлил татар халкының тарихта рус халкы белән бердәмлеге, дуслыгы, туган илне азат итүдә һәм саклауда халкыбызның батырлыгы турында сөйләде. Чөнки самолетлардан ташланган немец листовкаларында ниләр генә язылмый иде».

Әнә шул көннәрдә шагыйрь ил, тугандаш халыклар язмышы турында борчылып болай яза:

**Яраланды ерткыч тырнагыннан**
**Туган илнең бөек йөрәге.**
**Күмерләнеп анда пыскып ята**
**Украина иле өйләре.**

**(2 том, 26 бит)**

«Муса Җәлил бәрлык милләт курсантлары алдында да ихтирам итела иде. Кайда гына очраса да, без Муса Җәлилне олылап сәламләдек... Аны абыебыз кебек күрә идек», — дип горурланып сөйли Вәлиҗан Галимов. Аның:

«Мин пенсиягә подполковник дәрәҗәсендә чыктым. Минем намуслы хезмәт итеп, шушы дәрәҗәгә үсүем Муса Җәлил йогынтысында булды», — дип әйтүе дә моны тагын бер кат раслый.

Белгород шәһәрендә яшәгән, Марьинодагы курсларда взвод командиры булган лейтенант Сергей Яковлевич Дубровин да үзенең бер хатында шуны ук диярлек яза: «Без, командирлар составы, меңләгән курсантлар арасыннан бигрәк тә берсен — Муса Җәлилне яхшы белә идек. Ул иң актив шигырь сөйләүче, курсантларның үзэшчән сәнгать коллективында инициативалы катнашучы һәм бер үк вакытта нәфис сүз тугәрәгенең җитәкчесе иде»[1].

... «Армиядә чын мәгънәсендә политработник — ул үз тирәсенә кешеләр туплап, һәркайсының кәефен, ихтыяҗын, өметен, хыялын тирәнтен белеп, аларны фидакарьлеккә, батырлыкка алып баручы кеше»[2].

Л. И. Брежневның «Кече җир» әсәрендәге әлеге сүзләр патриот шагыйрь, солдат-коммунист, халыклар дуслыгы җырчысы Муса Җәлилгә төбәп әйтелгән кебек. Марьинода: «Ил! Алдыңда синең мин ант итәм, Гитлер явын тар-мар итәргә, — дип дулкынланып язган шагыйрьнең шул анты бик күп сугышчыларның йөрәген чыныктыра, дошманны җиңәргә куәт бирә. Шуңа күрә дә аның фашизмга каршы көрәштәге каһарманлыгы бөтен совет кешеләре күңелендә мәңге саклана.

---

[1] «Социалистик Татарстан», 31 декабрь, 1975 ел.
[2] Л. И. Брежнев. Кече җир. Казан, Татарстан китап нәшрияты. 1979, 57, 49—50 битләр.

## Сибгат Хәким

### Егерме бишенче август

Якты, шатлыклы, борчулы —
Тәрле көн бар язмышта;
Мусаның канлы шәүләсе
Калка һәр ел августта.
Калка офыкта августның
Егерме бише көнне,
Ап-ачык күрәм, тик йөзе
Суынган көл шикелле.

Сүрелеп барган августта
Сагышлы була бит таң...
Еракта Плетцензее,
Еракта Моабитлар.
Карашы аның Иделдә,
Казан өстендә кебек,
Казан да кайгы кичерә,
Газап эчендә кебек.

●

Намус ул кайда да кирәк.
(Онытыла кайвакытта...)
Хәтта бәрәңге бүлүне
Дуслары Моабитта

Тапшырган Мусага. Муса
Тигезләп бәрәңгесен
Бүлгән! Кычкыра алмаган
Үлем дә: «Хәрәмлисең...»

### Нарат

Ржев. Урман. Йокы баскан мине,
Окобыма сузылып,
Черем итәм, узды озын шәүлә
Акылымда сызылып.
Ржев. Урман. Туплар гүләвенә
Яшен яраклашкан...
Күзем ачсам, хатын түгел, янга
Яшел нарат яткан.

Сизмәгәнмен янәшәмдә шаулап
Нарат ауганын да,
Нарат та мин — икәү үлекләрнең
Чиксез аймагында.
Иплап нарат минем өскә салган
Ботак-ылысларны,
Ята җәйрап, көтеп, торып шунда
Минем кул кысканны.

### Фронт хатлары

Төн инде. Кычкыра ялгыз
Урамда калган сарык.

Ятам авылда яңгырның
Тавышына колак салып.

Тукта, бу йортта кем иде?
Яңгыр шыбырдап куя...
Уяна Фатыйма карчык,
Ишек шыгырдап куя,
Чыга яңгырга карамый,
Сизенә минем йөрәк:
Кулында фронт хатлары,
Хатлары төргәк-төргәк...
Суза, укы, ди, чылатма,
Куллары дер-дер килә...
Ә теге йортта кем иде?
Тукта, чү, кемдер килә?
Йөз яшьлек Ибраһим, йөз яшь...
Яңгырлы төннәрдә ул
Йокламый, фронт хатларын
Чүпрәккә төргән дә ул,

Йөри бер йорттан бер йортка,
Сөйрәп иске галошын...
Туктаусыз койган шул яңгыр
Искә төшерә барысын.
Урамда тагын кемнәрдер
Йокламый, йокысызлар.
Аларның йөрәге сызлар,
Нигезе, йорты сызлар.
Төн буе хат укый картлар,
Тузаусез хат, сап-сары,
Һәр өйдә сандык төбендә
Ята фронт хатлары.
Укыйлар картлар. Соң инде,
Зарары бар саулыкка...
Сандыкта фронт хатлары,
Барлык фронт сандыкта.

●

Туган як — мәңгелек моңым,
Һәрнәрсә гади, садә.
Күземне тутырып карыйм
Җирдәге һәрнәрсәгә.
Туган як — мәңгелек моңым,
Омтыла рухым алга,

Күңелне үртәп йөгергән
Мәңгелек дулкыннарга
Күземне тутырып карыйм.
Ул дулкыннар мәңгелек.
Арышлар шул хакта сөйли
Минем биткә бәрелеп.

●

Июнь мине бик бәхетле итте
(Миңа хәзер җитмеш яшь инде...).
Ватан сугышын искә алмаганда,
Булды миңа чиксез рәхимле.
Яшәсен тик кулда каләм, кәгазь,
Болын белән безнең тыкрык,

Әллә каян хисләр килде ташып,
Июньдә мин яздым котырып.
Башка айда, башка чакта ничек?
Я килмәде бәхет, я килде...
Ватан сугышын искә алмаганда,
Июнь миңа булды рәхимле.

## Июнь яңгыры

Өйдән чыккач баскыч, ишек алды,
Капка, аннан безнең өй чаты.
Бүрәнәдә авыл кешеләре,
Авыл бит ул — халык иҗаты.
Сөйли берсе, арада иң карты
(Утыралар кояш батканчы!);
Имеш, патша (безнең патша түгел,
Ни өчендер, төрек патшасы?)
Саклап торып йорты турысыннан
Узган чагын шунда ярлының
Туктаткан ди (ярлы, күккә карап,
Көтеп йөргән июнь яңгырын.):
«Үлчи алсаң, байлыгымны үлчә,
Теләсә ничек үлчә, бел рәтен».

Өйгән, имеш, барлык алтыннарын,
Өйгән җиргә ул мал-мөлкәтен.
Ярлы һаман үз яңгырын көткән,
Күңелендә һаман кайгы-моң!
— Июньнең бер яңгырына синең
Тормый, дигән, бөтен байлыгың...

## Фәрхинур

Әүвәлгечә дулкынлана арыш,
Әүвәлгечә өстә балкый нур.
Әүвәлгечә көлеп син каршыма
Ник чыкмыйсың юлга, Фәрхинур.
Әүвәлгечә дулкынлана арыш,
Әүвәлгечә ата таныш таң.
Тик күренеп китсә дә мин риза
Ал яулыгың синең арыштан.
Туган якның яшел сукмаклары
Очраштырыр безне бәлки бер.
Очрашсак та ләкин көннәр буе
Торырбыз күк сүзсез, Фәрхинур.

## Туй

Әллә нинди гаҗәеп туй иде,
Туй яратмый кемдер тыйганны,
Туй бер килә, күргәнем юк иде
Әлегә кадәр мондый туйларны.
Туй мәҗлесен аягүрә басып,
«Туган тел»не җырлап яптылар.
Бу мәҗлестә хуҗа булып түрдә
Үзе утыра иде Габдуллаң.
«Тел»не җырлап туй урамга чыкты,
«Тел» ил белән бергә тоташты,
Ил каршына кырлар уртасыннан
Озата барды Тукай туташны.
Туйга кинәт илаһилык керде,
Бөтен нәрсә гүя илаһи.
Тукайдан син әгәр өстен булсаң —
Булсаң бөек, булсаң син даһи,
Башка җыр тап, башка җырны җырла.
Туган якның сихри моңнары
Яши миндә, үзем яшәп калам
Онытып шунда бөтен дөньямны.
Туй кырларның уртасыннан бара,
Кайда туктар, белмим, билгесез.
Мин шат бүген, мин бәхетле бүген,
Барыгыз да «Туган тел»ле сез.

## Торам уйланып урамда

Торам уйланып урамда,
Торам карап: тормыш
Үзгәрде, кайда балалар?
Урам тып-тын, тын-буш.
Урам буш, урамда чирәм.
Карлар тынып аккан...
Кайда, дим, теге малайлар,
Кармак тотып чапкан?

Урамда каз бәбкәләре,
Бәбкәләр дә боек.
Кайда, дим, теге әбиләр,
Әбиләр һәм оек?
Кайда ул теге малайлар:
Урам чатыннан ук
«Кайта!» дип ура кычкырган
Уннарча шат оник?

●

Бер карасаң, арыш җәелеп ята
Яшел кием төсле,
Бер карасаң, дулкынлана, уйный
Яхин көе төсле.

●

Уҗым кыры, уҗым аралары
Традицион шигырь юллары кук,
Яки безнең Казан артындагы
Әтнә белән Шимбер юллары кук.

●

Китә язган минем туган ягым
Йошкар-Ола булып,
Хәзер дә мин карыйм кебек шуннан
Яшь карама булып.

## Миңлебай кызы Газизә

Ел тәүлегенә бер тапкыр
Күрешәм әнкәй белән.
Янудан туктамый йөрәк
Күрешәм дип әйткән белән.
Иркәлә яки тиргә дип,
Иңенә куйган сыман,
Салам кайгылы башымны
Зиярат коймасына.
Иям хәсрәтле башымны
Мин туган җир кабренә,
Ваз кичеп бөтен дөньядан,
Икәүдән икәү генә

Сөйләшкән чагым бәхетле,
Күңелдә кабына бер ут,
Аяза күңелем, әйтерсең,
Югала кара болыт.
Яңадан тулыша рухым
Изгелек һәм нур белән,
Ашкынам алга, ниндидер
Якты шигъри үр менәм.
Миңлебай кызы Газизә,
Әнкәйнең — Газизәнең
Кабрендә тополь... Киткәндә
Үрләрдән кул изәдем.

## Инде кич...

Инде кич, барам кыр буйлап,
Кояшка аркам белән,
Картлык ул кояшка туймый,
Көрәшә салкын белән.

Аркамда кояш җылысы,
Кояшның сүрәне дә
Җылыта, кояш сүнгәндә
Картлык та сүнә бергә.

## Шушында минем оям

Минем бала чак эзләрен
Камышлар күмгән күптән.
Әйләнә башым очында
Тиззитлар түмгәклектә.
Тиз кит, тиз кит, диләр алар.
Кушалар тиз китәргә.
Ә минем китәсем килми,
Үпкәлим тиззитларга.
Ничаклы борчу... ничаклы
Тузгыган җан кычкыра,
Ә аста торфлы болын,
Түмгәк тә камыш кына.
Очалар тузгып, очалар,
Елыйлар, чыелдыйлар,
Елыймын мин дә, җыелган
Шушында җыен моңнар.
Шушында авышкан гомер,
Авышкан күптән өйләм,
Әйләнәм мин дә туктаусыз,
Шушында минем оям.

## Нигез исе

Су белән тигезләнде җир,
Калмады тигезлисе.
Кыр чәчәкләрендә күзем,
Күңелдә нигез исе.
Шул авыр нигез исләрен
Тугайдан искән җилләр,
Сталинградтан, Ржевтан,
Дугадан искән җилләр
Бу якка алып килә күк,
Агарып томаннардан,
Тырпаеп утырган мичләр
Калкалар Дугалардан.
Ташланган нигезләр төсе,
Нигезләр салкынлыгы...
Җирнең бертуктаусыз саркый,
Шигырьнең саркый моңы.

# Җәмит Рәхимов

# ТӘВӘККӘЛ ТАШ ЯРА

ПОВЕСТЬ

## I

Кайманов аны өстәле артында аягүрә каршылады. Ул гына да түгел, бер ягы уеп алынган рюмканы хәтерләткән әйләнмәле креслосыннан кубып, ишектән кереп килүче Равилгә каршы атлады.

— Иптәш Закиров?! Ниһаять! — диде ул, күрешергә ике кулын сузып. — Шактый көттерден, дус кеше.

Васил, җитез генә үрелеп, Равилнең беретын салдырды, кулындагы плащын алды һәм ишек катындагы шкафка элеп куйды.

— Без инде көтә-көтә көтек булып беттек, — дип дәвам итте ул, Равилне култыклап. Кайманов кунакны ян тәрәзә буендагы ялтырап торган өстәл янына алып килде, креслоларның берсенә утыртты, икенчесенә үзе урнашты. — Я, ничек килеп җиттегез?

— Кем әйтмешли, аллага шөкер, — диде Равил һәм каршысында утырган Каймановка күтәрелеп карады. Менә нинди икән ул Васил Кайманов. Дүртенче дистәне тутырып килүенә карамастан, яшь чырайлы, башка кайбер начальниклар кебек «тулып ташымаган». Башлангыч класс укучысыныкы сыман кып-кыска чәчен уң як кашы өстенә сыпырып куйган. Кысыграк коңгырт күзләре уйнаклап тора. Җентекләп кырылган чип-чиста бите уртасында кечкенә генә почык борын. Болар бар да аны ничектер малай сыман итеп күрсәтә.

Кайманов, булачак баш инженерының игътибарлы карашын тоеп, уңайсызланып китте һәм шул халәтен яшерү өчен урыныннан кузгалып, зур кәрән өстәле янына узды.

— Менә шулай, Равил Вәлиевич, димәк, ишетүемчә, скважиналар ремонтлау сезнең өчен яңа түгел... — диде ул, сул беләгендәге сәгатен боргалап.

— Таныш эш, — диде Равил сүлпән генә, — ләкин минем аңлавымча...

— Әйе, әйе, — дип бүлдерде аны Кайманов, — яңа идарәнең максаты скважиналарны механик ремонтлау гына түгел. Төп бурыч — катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру. Аларга химик һәм физик тәэсир итүнең моңа кадәр күрелмәгән юлларын табу, скважиналарга килә

торган катлам суларын изоляцияләү өчен яңа материаллар куллану һәм башкалар, һәм башкалар...

Зур өстәлдәге селектор аппараты шытырдап куйды. Карлыккан ир-ат тавышы начальник янына керергә рөхсәт сорый иде. «Унбиш минуттан», — диде Васил һәм трубканы куйды.

— Менә сез шулар белән шөгыльләнерсез дә, Равил Вәлиевич, — диде ул, өзелгән сүзне дәвам итеп. — Дөресрәге, безнең бөтен коллектив шул юнәлештә эшләргә тиеш.

Болар Равил өчен яңалык түгел: әле генә оештырылган идарәнең эше турында берләшмәнең баш инженеры Губерттан ишеткән иде инде ул. Предприятиенең тернәкләнүенә ай ярым вакыт үтсә дә, цехларда эшләр һаман искечә бара диярлек, бригадалар скважиналарга ремонт ясау белән генә мәшгуль. Булачак начальнигы каршында утырган хәлдә, Равил әле һаман Васил сүзләреннән киләчәккә юл күрсәткече итеп алырлык берәр нәрсәнең оеткысын көтте. Ләкин Кайманов купшы сүзләрдән ары китмәде.

— Вообще-то, эшләр зарланырлык түгел, — дип сөйләвендә булды Васил, — узган ай планын йөз дә җиде процентка үтәдек. Әле бер башым килеш ич. Ә икәүләп тотынсак... Дөрес, бу мәсьәләдә мин үзем дилбегәне нык тотам. Тик башкасын да сорый башларлар бит, хөрмәтле Равил Вәлиевич, сорарлар. Менә шул мәшәкатьләрне үз җилкәгезгә алыгыз инде сез. Фән һәм техника яңалыклары, институтлар белән бәйләнешләр һәм башкалар, һәм башкалар... Вообще, сезне өйрәтеп торасы түгел. Юк, юк, мин күләгәгә посарга җыенмыйм, шулай да... Хәер, болары турында иркенләп бер сөйләшербез әле. Руслар әйтмешли, сандугачны җыр белән сыйламыйлар. Каршы булмасагыз, мин сезгә квартирыгызны күрсәтер идем.

Берүзе кварталның яртысын диярлек алып торган биш катлы йорт белән тигезләшкәч, шофер белән янәшә утырып баручы Кайманов артына борылды.

— Менә шушы инде безнең Яшел Түбә, — диде ул әчке бер горурлык белән.

Машина, бәйгедәге чабышкыдай, бер ыргып алды да үзәк мәйданга килеп туктады. Каймановның үзе яшәгән кала белән бераз гына мактанасы килде бугай, Равилнең булачак квартирасына җәяү атларга булдылар.

— Сезнең квартира әнә тегендә, — диде Кайманов, астагы катын буйдан-буйга кибет били торган йортка күрсәтеп, — икенче катта, почмактан беренче тәрәзә.

Ул Равилне култыклап алды һәм әлеге йортның ишек алдына таба алып китте. Баш инженерның күңеленә хуш килсен өчен боларның барына да алдан әзерләнеп куйганмы, үзе шундый кунакчыл, хөрмәтчел кешеме Кайманов — белмәссең. Ни генә булмасын, аның Закировны каршылау церемониясе төгәл, исәпле иде. Икенче катка күтәрелүгә, ул кара дерматин белән тышланган ишекне ачып җибәрде — коридорга мул булып яктылык төште. Бу хәтлесен үк көтмәгән иде Равил: һәркайсында футбол уйнарлык өч бүлмәдән буяу исе аңкып тора. Түшәмнәре күзне чагылдырырлык ап-ак, идәннәре ялтыратып буялган, стеналарга зур-зур фарсы келәмнәре эленгән диярсең — фигуралы көрән сызыклар белән каймалап алынган лимон төсендәге җирлектә купшы бизәкләр. Тәрәзәләр, туй көткән кыз сыман, көлеп торалар төсле. Өстәвенә бүлмәләрнең берсенә йомшак агач карават белән зур тумбочка һәм кием шкафы, уртадагысына төйгән шомырт төсендәге өстәл белән дүрт-биш урындык куелган.

— Яңа урында тормыш башлап җибәрү өчен,— диде Кайманов, мебельгә ишарәләп. — Бөтенләй күченеп, җайланып беткәч, безнең баш

сәүдәгәр Барый Латыйповичка кайтарып бирерсез, яисә бәяләрен түләрсез. Анысы әле ашыгыч түгел.

«Болай ук кирәкмәс иде», — дип уйлады Равил эченнән, ләкин күңелендәге кычкырып әйтмәде, Каймановның хәтерен калдырудан шикләнде. Дәшми калмау өчен генә:

— Рәхмәт, — дип куйды.

— Ярый, мин сезгә комачауламыйм, — диде Кайманов һәм, җиңүле елмаеп, ишек ачкычын Равилгә сузды. — Урнашыгыз, коенып алыгыз, шәһәрне карап әйләнегез. Хатыныгыз күчеп килгәнче, Әлмәткә кайткалап йөрерсез бит әле? Машинагыз көйле, шоферы бар. Мин аны хәзер үк җибәрәм, сезгә кирәгүе мөмкин. Хушыгыз.

Ул, оста биюче сыман житез борылып, ишеккә килде һәм тоткага тотынгач, болай сүз арасында гына әйткән кебек:

— Ике-өч көннән эшкә тотына алырсыз бит?! — дип куйды.

— Мин иртәгә чыгам, — диде Равил ашыгып. Әйтерсең, урынына башка берәүне утыртырга җыеналар.

Кайманов киткәч, бер мәл нишләргә белми аптырап торды ул. Идән уртасына басып сигарет кабызды, аннан өч бүлмәне бер итеп йөрергә тотынды. Кухняга барып керде, ванна бүлмәсенең ишеген ачып карады. Су, газ краннары көйле, плитәсе Польшадан кайтарылган — матур, чыдам.

Шулай бераз уралгач, ул мәйданга караган тәрәзә төбенә менеп утырды, тагы тәмәке кабызды һәм үз мәшәкате белән кайнаган шәһәр урамына күз салды. Үзе дә сизмәстән, уфтанып куйды. Әлфия килмәсә, бу хан сарае нәрсәгә инде аңа? Бәлки хәзергә гостиницадан бер бүлмә генә алыргадыр? Әллә тегә чакны практикада йөргәндәге кебек берәр апага квартирага керергәме? Һай, туры киләме соң инде Саҗидә апа кебек кеше! Нефтьчеләрне яратып бетерми иде бетерүен Саҗидә апа. Юк, иген икмәүләре өчен түгел, урманнарны ботарлаганнары, елга-күлләрне пычратканнары өчен. Коръәнгә тел тидергәндә дә сабырлыгын җуймый торган хатын, табигатьне кыерсыту турында сүз чыкса, чәчрәп торыр иде дә, квартирант егетләрен тетеп ташлар иде: «Дөнья корткычлар!»... Алай да егетләр өчен җанын ярып бирергә әзер иде. Әй, сагынып сөйләргә генә калды шул Саҗидә апасы. Бар иде заманалар, Равилнең эштән кайтуына бер-бер тәмле нәрсә пешереп куяр иде. Ул таралып торган майлы пылау дисеңме, күпереп пешкән бавырсак яисә баллы чәкчәк дисеңме, хуш исле гөбәдия, хәтта тутырган тавык.... Өстәлне күргәч, авызга су килә торган иде. Да-а, Саҗидә апа. Андый бүтән тумас та, булмас та. Урнашып бетүгә, барып кайтырга кирәк янына. Югыйсә, күрмәгәнгә ни гомер бит. Барырга, гафу үтенергә. Ә хәзер нишләргә соң әле? Хатыны килмәсә, төрле сүз, гайбәт китәчәк. Эшкә ныклап җигелгәч, гел кайтып та йөри алмассың. Ихтыярсыздан бүген иртән хатыны белән сөйләшүләре исенә төште.

Әлфия кухняга кергәндә, Равил инде тамагын туйдырган, ачык форточка янында тәмәке төтәтеп тора иде.

— Я, әйт, җаным, ни сүзең бар?

Хатынының кисәк кенә сорап куюы уйларын бүлде, шулай да хатирәләреннән арына алмый байтак торды Равил. Аннан кичә Губерт янында булуы, аның яңа идарәгә күчәргә тәкъдим итүе турында сөйләп бирде.

— Соң үзең ни уйлыйсың?

— Ни уйлыйсың дип... Киңәшик бергәләп.

— Киңәшүеңнең мине юату өчен генә икәнен белми бу дисеңме, Равил? — диде Әлфия тыныч кына. — Синең барыбер үз туксаның туксан.

Гаҗәп, аның үпкәләргә, рәнҗергә исендә дә юк. Берни булмагандай тамагын туйдырды, урыныннан кубып залга чыкты һәм трюмо каршына басып бизәнергә тотынды.

— Миңа барыбер, Равил, — диде ул бераздан битараф бер тавыш белән. — Синең майга катып скважиналарда куныл-төнеп ятуыңа күнеккән инде мин. Әлмәттә торуың ни дә, Яшел Түбәдә яшәвең ни. Тик шуны бел: мин киемгә тагылган бирка түгел. Синңа ияреп моннан да кубар хәлем юк. Күчәм икән, фәкать Мәскәүгә, этиләр янына.

Әлфиянең артык тынычлыгы бик авыр тоелды Равилгә. Һич-югы: «Шайтаныма олак!» — дип кычкырсын, — «Бар чукынып бет!» — дип жикерсен иде. Башка хатыннар кебек ызгыша-талаша гына да белми бит ичмасам, дип өзгәләнде ул. Шулай да эчендәген тышка чыгармады. Башлаган сүзнең ахырына чыкмыйча ук киенде һәм берләшмәгә ашыкты. Бу минутта Губертка җавабы әзер иде инде аның.

Күзе ап-ак якты бүлмәдә «калган» икән. Караңгы коридорда йозак тишеген таба алмый йөдәде, ишекне бер ачып, бер ябып җәфаланды. Тавышка янәшәдәге ишек ачылып китте, коридор яктырды, бусагада бер шәүлә калыкты.

— Кем вата-җимерә дисәм, яңа күрше дип әйтимме?

Тавыш иясе «к» авазын мишәрчәрәк каты итеп әйтүче туташмы, ханыммы шунда. Тавышы көр, яңгырап тора. Ниһаять, Равил йозакның көен тапты, ачкычын алып кесәсенә салды һәм кинәт калкып чыккан күршесенә карады. Яктылыкка арты белән торганлыктан, аның йөзе күренми, ә гәүдәсе зифа, өстендәге халаты тәненә сыланып тора иде.

— Кем өчен шулай тыз-быз килеп ремонтлыйлар икән дисәм, сезгә икән. Таныш булыйк: мин — Фәһимә, — диде ул шул ук мишәр акцентты белән.

Дөресен әйткәндә, Равилнең кәефе хатын-кыз белән сөйләшеп торырлык түгел иде. Тик ачык йөз күрсәткән кешегә ничек җавапсыз каласың инде.

— Мине Равил дип йөртәләр, — диде ул теләр-теләмәс кенә.

— Бик әйбәт, — диде Фәһимә бөтен коридорны яңгыратып. — Узыгыз, минем тормышны да күреп чыгарсыз. Михаил Ивановичлар белән бер семьядай тату яшәдек. Түмәнгә киттеләр. Рабучий класстан җиксенмәсәгез, яхшы күршеләр булырбыз насыйп итсә.

Фәһимә шулай сөйләнә-сөйләнә, бер адым чигенеп, Равилгә юл бирде. Тегесе исә нишләргә белми бер мизгел аптырап торды да, ачык ишеккә акрын гына атлады. Бусаганы үтүгә, иелеп ботинка бауларын чиште.

— Салмагыз, салма, — дип гөрләде Фәһимә, залга узып, — безнең ни, пычранырга келәмнәребез юк... мактап йөрисез дияр идем, — мине белмисез. Бәхетле авыз икәнсез: ашым пешкән, чәем кайнаган.

Шул чак кухняда нидер чыжлады да, Фәһимә, өркетелгән боландай, шунда ташланды. Равил исә һаман да нишләргә белми бүлмә уртасында басып тора иде әле. Ниһаять, ул кинәт кабаланып ишек катына килде, ботинкаларына үрелде, киярга өлгермәде, баш өстендә үк Фәһимәнең үпкәле тавышын ишетте:

— Әч, әч, булмаганны, — диде ул, хәтере калып, — Кем инде пешкән ашны ташлап китә? Әзерләп торучыгыз күренми бит әле.

— Ничево, мин ашханәдә, — дип мыгырданды Равил, уң аягына ботинкасын элеп.

— Сөйләмәгез дә,— дип бүлде аны Фәһимә, — бездән өстен булсагыз да, аштан олы түгелсез. Булмаганны тегеиӘйдәгез!

Фәһимә аны култыклап диярлек кухняга алып керде, өстәл янындагы артсыз урындыкка утыртты. Үзенең йомшаклык күрсәтүеннән кәефе ныграк кырылса да, күндәм малайдай буйсынды Равил.

Эш юктан эш булсын дигәндәй, Равил башта аның кулларына карап утырды. Эре сөякле нык куллар иде алар. Ап-аклар, чисталар. Шулай да, карый торгач, бармак буыннары өстендәге нәни генә ярыкларның

карасу-зәңгәрләнеп торуын күреп алды. Нефтьтә эшләүчеләр кулында күпме генә юсаң да бетми торган үзгә билгеләр иде болар.

Ул, кайда һәм кемдә утыруын онытып, комсызланып ашады, Фәһимәнең гөнаһсыз сүзләрен, вакыт-вакыт үзен кимсетеп маташуларын тыңлый-тыңлый чәй эчте, ләкин сүзгә кушылып китмәде, шулай да:

— Эшче дип, үзеңне кимсетеп сөйләвеңне ташла син, Фәһимә, — диде. — Дөнья эшчеләр кулында. Кстати, кайда һәм ни җимертәсез?

— Әй, безнең ни. Йөрибез инде шунда, майга батып.

Равил инде тамагын туйдырып, нишләргә белми аптырап утыра иде. Кисәк кенә чыгып китсә, Фәһимәне рәнҗетер төсле. Һаман утырса да аптырау. Ире кайтып керсә, әллә ни уйлавы бар. Шул чак стенадагы звонок шалтырады, аның чыңы тынганчы ук, ишек ачылды.

— Фәһимә апа, яңа күршеңнең кая киткәнен белмисеңме? — диде ишектәге кеше нечкә тавыш белән.

— Ә-ә, Габит. Монда ул, монда, — диде Фәһимә, кунакка каршы атлап. — Кер әйдә, чәй эч.

Борын астына кара төкләр дә шытмаган шушы малай Равилнең булачак шоферы, имеш. Ул, Фәһимәгә рәхмәт әйтеп, яңа танышына таба атлады.

## 2

Равилнең күзлеге парланып чыкты. Ул бармакларын электрон-хисаплау машинасы төймәләреннән күтәреп, күзлеген йолкып алды, пыяласын кульъяулыгы белән сөрткәннән соң, кабат борыны өстенә элде. Машина-могҗизаның алсу «күзе»нә, пыяла артындагы кызгылт-сары саннар тезмәсенә карап бераз утырды да, хисаплау машинасын сүндереп куйды, сәгатенә күз төшерде. Киңәшмә башланырга чирек сәгать вакыт бар иде. Бүген ул, объектларда йөрүдән арынып, ремонт бригадаларының узган айдагы эшләренә анализ ясап утырды. Кинәт бик мөһим бер нәрсәнең эшләнми калуын абайлап алды. Ике сәгатьтән Әлмәттә Фәридә белән Ленизаның чыгарылыш кичәсе башлана. Шушы көнгә кызларына истәлек-бүләк алып куярга дип, ничә көн җыенды, һаман эштән арына алмады. Инде бүген һичнигә карамый кибетләргә чыгам, дип йөрсә дә, электрон-хисаплау машинасы янында утыра торгач, дөньясын онытакан икән. Киңәшмәне кыскарак тотарга кирәк, дигән фикергә килде һәм өстәл кырындагы ак төймәгә басты. Ишек артында ялгыз торна тавышы яңгырап киткәндәй булды, ул да түгел бусагада секретарь кыз күренде.

— Әйтегез, керсеннәр! — диде Равил һәм тыңлаусыз житен чәчен артка таба сыпырып куйды.

Кабинет ишеге бер ачылды, бер ябылды, кемнәрдер гөрләтеп сәлам бирде, дөбердәшеп урындыклар күчте. Менә барысы да утырышып бетте, кайсыдыр ут элдерде — бүлмә уртасына эленгән люстрадан мул булып яктылык төште. Закиров тезелешеп утырган инженерларга, геологларга, механикларга күз йөртеп чыкты да:

— Башладык, иптәшләр, — диде.

Шул чак кабинет ишеге ачылып китте һәм бусагада хәвефсезлек бүлеге мөдире Самарин күренде.

— Мөмкинме? — диде ул мескенрәк тавыш чыгарып һәм карашы белән үзенә урын эзләргә тотынды.

— Ишекне ябыгыз! — диде Равил, аңа башы белән ишарәләп. — Әйе, әйе, ябыгыз, тик теге яктан.

Самарин баш инженерның ни әйтергә теләвен аңламыйча, авызын ачып калды. Кемдер пырхылдап көлеп алды, кемдер аңа кул изәде.

Ләкин Самарин аңардан нәрсә таләп ителүенә һаман да төшенеп житмичә, катып торуында булды.

— Чыгасызмы сез, ниһаять, юкмы?! — дип кычкырып җибәрүен сизми дә калды Равил. Билгеләнгән вакытка соңаручыларны җене сөйми иде аның.

Тегесе, эшнең уен түгел икәнен абайлап, акрын гына артка чигенде һәм өнсез генә ишекнө япты. Кемнәрдер тагы пырхылдап җибәрде, кайсыларыдыр шыпыртлап кына бер-беренә сүз катты.

Бөтен кыяфәте белән килкән балыкны хәтерләткән бу инженер идарәдәге күп кенә мәзәкләрнең, төртмә сүзләрнең сәбәпчесе иде. Аның тәнендә карга чукырлык та ит юк, хәтта чалбары да ниндидер могҗиза белән генә эләгеп тора сыман. Бите чебеш томшыгы сыман очлаеп калган, йөзе сап-сары, чырае һәрчак чытык. Гарип-гораба, яисә чирләшкә булса, аңардан көлмәсләр иде, билгеле. Ләкин Самарин үзен-үзе шул хәлгә төшергән кеше. Ул инде байтактан бирле машина сатып алырга хыяллана. Шуңа күрә ашау-эчүгә дә, дөньяның башка рәхәтлекләренә дә расходны соң дәрәҗәдә кыскан. Дөрес, ул үзе дә, хуҗалык бүлеге мөдире булып эшләүче хатыны да моны берәүгә дә сиздермиләр. Шулай да аларның төшке ашны, кечкенә генә бүлмәгә бикләнеп, җиде тиенлек яшелчә консервасы белән коры ипи ашап үткәрүләрен бөтен идарә белә иде. Шунысы гаҗәп: шул рәвешле дәрвишләрчә туклануларына карамастан, аның хатыны чан сыман юан, битләре янып тора. Аларның шулай инә белән кәтүк төсле бер-береннән нык аерылып торулары мәзәк корырга яратучылар өчен яңадан-яңа хикәятләр чыганагы иде.

Киңәшмәнең болай башлануы Равилнең кәефен җибәрде. Әмма ул үзен тиз кулга алды һәм баягыча басынкы, сабыр тавыш белән сүзен дәвам итте:

— Бүгенге сөйләшү безнең үзгәрәк булыр, иптәшләр. Тыңлаучы — мин, докладчылар — сез. Игътибарыгызны бары бер нәрсәгә — скважиналарга килүче су юлларын изоляцияләү эшләренең сыйфатына һәм бу өлкәдә яңа тампонаж материаллары куллануга юнәлтүегезне сорыйм. Дөрес, без бригадаларда булып байтак нәрсәләр белән таныштык. Яңалыкка омтылу фактларына да тап булдык. Ләкин алга таба юлыбызны билгеләү өчен тагы ниләр эшләргә, ниндиерәк юнәлеш алырга? Менә шул хакта сезнең сүзне ишетәсе килә минем. Югыйсә, менә нәрсә килеп чыга...

Ул бүген күп сөйләмәскә, бары тик тыңларга гына җыенган иде дә бит, үзен борчыган нәрсәләрнең тышка бәреп чыгуын сизми дә калды. Узган ай нәтиҗәләренә тукталды, сыйфат мәсьәләсенә кагылды, цех җитәкчеләрен һәм инженерларны кыюсызлыкта, искегә ябышып ятуларында гаепләде.

Туры әйтелгән сүз күңелләренә хуш килмәде бугай, бүлмәдәгеләр кыбырсый башладылар, кыюсыз гына аклану авазлары ишетелде. Ниһаять, түземлекләре төкәнде. Әвәл геология бүлеге начальнигы Петр Шумский күтәрелде. Бәләкәй башлы, какча гәүдәле, озын буйлы бу кеше идарәдә үзенең җитдилеге белән аерылып тора иде. Ул күп укыган, геология-минерология фәннәре кандидаты исеме алуга ирешкән, хәтта җир асты катламнарын тикшерә торган бер-ике приборга авторлык хокукына ия. Шумский юкка-барга сүз тегермәне кормый, коллегалары белән очрашканда да баш кагып кына уза, җыелыш-киңәшмәләрдә исә зур начальниклар, яисә галимнәр катнашканда гына сүз ала. Әйтәсе фикере буталчык, җөмләләренә фәнни терминнар, акыллы гыйбарәләр тыгып тутырган була. Бүген дә шулай килеп чыкты. Ул җир катламнары — фомен, девон, ташкүмер турында сөйләде, ничә ел нефть эшендә чиләнгән Равил булып Равил аңламаган терминнар әйтеп шаккатырырга җыенды, аннары изоляцияләү эшенең әһәмияте хакында вәгазь укырга тотынды.

Аны тыңлаган саен Равилнең йөзе караңгылана барды, чырае сытылды. Башкаларның йөзендә дә — битарафлык чалымнары. Шулай да бүлдермәде аны Закиров, бүтәннәр алдында абруен саклыйсы килде. Тик Шумский урынына утыргач кына:

— Конкрет һәм кыскарак сөйлик әле, — дип куйды.

Ишек катыннан техника бүлеге начальнигы Артомоновның калын тавышы ишетелде:

— Мин дә бер генә сүз әйтим әле, җәмәгать. — Ул авыр гәүдәсе белән килешсез чайкалып торды, гадәтенчә бераз гына бөкересен чыгарып тынып калды, барысының да игътибарын үзенә тарткач, сүзен дәвам итте. — Мәгълүм булганча, немец халкының җилбәзәк даһие Гыйфрид Вильгельм Лейбниц дифференциаль исәпләүләр системасын эшли, ләкин бу турыдагы хезмәтен бастырып чыгарырга лаеклы дип санамый. Математиканың шушы зур бүлеге хакында сүз чыккач, ул: «Минем мондый юк-барларым җитәрлек», — ди. Шуның шикеллерәк килеп чыга. Уйлап карасак, бездә дә «юк-барлар» күп бит. Мин соңгы вакытта скважиналарда су килү юлларын изоляцияләү эшләрендә гипан, сумала, латекс кебек яңа материаллар, аларның цемент белән катнашмаларын куллануны күздә тотам...

Баш инженерның йөзе яктырып китте, башын күтәреп Артомоновка текәлде һәм йотлыгып тыңлый башлады. Константинның нефть промышленносте турында гына түгел, башка фәннәр һәм тармаклар буенча да киң мәгълүматлы кеше булуын, сөйләгәндә атаклы кешеләр тормышыннан мисаллар, аларның акыллы гыйбарәләрен кушарга яратуын белә иде инде ул. Ләкин кинәт үзгәреп китүенең сере моңарда гына түгел иде әле. Артомонов нәкъ ул ишетергә теләгән сүзне башлап җибәрде: гипан, сумала, латекс... «Молодец, Костя», — дип эченнән генә Артомоновны мактап куйды Равил һәм мультфильм караучы бала кебек кызыксынып тыңлавында булды.

Константин исә, киңәшмәгә җентекләп әзерләнгәнме, эше арасында шул кадәр мәгълүмат тупларга өлгергәнме, яңа материаллар белән башкарылган һәр ремонтны нечкәләп анализлады, бу өлкәдәге уңышларга тукталды, хаталарны ачып салды. Инде талчыга башлаган инженер-техниклар, геологлар, механиклар кинәт җанланып, Артомонов туктаганны да көтмичә, сүзгә кушылып киттеләр. Киңәшмә кызды, Равил тагын сәгатенә карап алды. Исенә кабат кызлары, инде ябылырга өлгергән кибетләр калкып чыкты. Шулай да сүзне кыскартырга ашыкмады, алдындагы календарена үзе генә аңларлык сүзләр, тамгалар төшерә-төшерә, тыңлый бирде. Ниһаять, иң аска «Рекомендацияләр эшләргә!» дип язып куйды да, киңәшмәнең ычкынган тезгенен кулына алды.

Алар кабинетта Артомонов һәм яшь инженер Илсур Сәгъдиев белән өчәү генә калганда, тышта төн иде инде.

— Ну, тәэсирләр ничек? —диде Равил, Артомоновка таба күзлеген елтыратып.

— Моңа кадәргеләренә әллә ни өстәлмәде, — диде Константин үкенгән сыманрак итеп, — шулай да кайбер нәтиҗәләр ясарга мөмкин.

Равил, өстәл тартмасын ачып, сигарет белән зажигалка алды, тәмәке кабызды һәм, ел буе тартмаган кешедәй комсызланып, әче төтен йотты.

— Менә, менә, — диде ул, төтенгә чәчәп, — нәтиҗә ясарга һәм бригадалар өчен рекомендацияләр эшләргә. Үзегез генә ерып чыга алырсыз бит?!

— Атаклы орнитолог Альфред Брем: «Әгәр моны эшләмәсәм мин галим түгел», — дип әйткән, ди. Шулай да геологларның ярдәме кирәк булачак.

— Димәк, килештек, — диде Равил, урыныннан кузгалып.

Гаиләсенә ул иртәгесен дә, аннан соң да кайта алмады. Ятканнан соң оеп кына китәргә өлгермәде, ишек катындагы бәләкәй киштәдә телефон шалтырады. Равилнең тынычлыгын бозучы идарә диспетчеры иде.

— Равил Вәлиевич, — диде ул сулышы кабып, — өч йөз илленчедә шартлау!

Равилнең өстенә салкын су койдылар диярсең.

— Кешеләр ни хәлдә, кешеләр? — дип кычкырды ул. — Имгәнүчеләр юкмы?

Бәхеткә каршы, үлүче дә, җәрәхәтләнүче дә юк икән. Эш вакытында мәйданчыкта торучы булмаган. Равил иркен сулап куйды, битенә бәреп чыккан тирне беләге белән сөртеп алды. Ул инде шактый тынычланырга өлгергән, аек акыл йөртерлек хәлгә килгән иде.

— Мачта, җиһазлар ни хәлдә?

Бригада мастеры, кем әйтмешли, анадан ул күлмәк киеп туган күрәсең. Мачтаны һәм башка җиһазларны, бүтән скважинага күчерергә дип, җыеп-җыйнап, читкәрәк тарттырып куйган булганнар.

— Менә нәрсә, — диде Равил диспетчерга, бик тыныч булырга тырышып, — хәзер үк миңа машина җибәрегез.

Дежур автобус скважинага килеп җиткәндә, анда инде янгынчыларның авыр кызыл машинасы барып баскан, бомба воронкасына охшаган чокыр янында пожарниклар белән ремонтчылар кайнаша иде. Бригада членнарын эт итеп сүгеп ташламакчы иде Равил башта, усал-усал сүзләре дә тел очында гына тора иде. Шулай да үзен тыеп калды. Тик тупас итеп:

— Нәрсә сарык көтүе кебек җыелдыгыз?! Газга тончыгып үләсегез киләме? А ну, читкәрәк чигеник, читкә! — дип кычкыру белән чикләнде. Үзе исә чокыр кырыена ук килеп, караңгы бушлыкка күз салды. Нефтьчеләр янгын чыгудан куркып прожекторларны сүндергәннәр иде. «Ярый әле анысына башлары җиткән», — дип уйлады Равил үртәлеп һәм плащ кесәсен капшаштыра башлады. Ыгы-зыгыда ничек башына килеп, ничек салгандыр, кулы кесәсен басып торган фонарьга тиеп киткәч, шатланып куйды. Очкын чыга күрмәсен тагы дип, читкәрәк китте һәм ут кабызды. Аннан яктылык көлтәсе белән төн караңгылыгын сеңгеләп, кабат скважина янына килде, чокырга иелде. Өч метр чамасы тирәнлектә колонна да, насос-компрессор торбасы да кисеп алынгандай өзелгән иде.

Ул пожарникларга скважинаны урап алырга, чит кешеләр җибәрмәскә кушты да, культбудка буенда аптырашып торган нефтьчеләр янына килде.

— Нихәл, бөркетләр?! Ишәк чумарын иштегез алайса, — диде ул мыскыллы итеп. Теленә ямьсезрәк сүзләр дә килгән иде дә, тагы үзен тыеп өлгерде. Мондагыларның берсе дә таныш түгел иде аңа. — Кайсыгыз мастер? Рация эшлиме? Противогазларыгыз бармы?

Каланча гәүдәле берәү — кулындагы кыр сумкасына караганда мастер булса кирәк — төркемнән алгарак чыгып басты, ләкин телен әйләндереп сүз әйтә алмады.

Равил, аның җавабын көтеп тормастан, культбудка ишеген ачты, аяк астына мул булып яктылык төште.

— Бар, диспетчерга әйт: сварка агрегаты белән сварщик җибәрсеннәр, — диде ул мастерга кырыс кына.

Тегесе беравык урыныннан кымшанмый торды, аннан киселгән агачтай бер якка авышты, шулай ук җай гына икенче якка чайкалды. Ниһаять, кузгалып китте.

Авария бригадасы әле килеп җитмәгән, коры кул белән скважина янында буталудан файда юк иде. Равил үлән баскан урман юлы белән әчкәрәк кереп тәмәке кабызды. Күз алдында исә һаман да әлеге мастер хәрәкәтләре. «Каян тапканнар бу бегемотны?» — дигән уй һич кенә дә башыннан китмәде. Туктале, почмакланып торган тупас битле, гөлбадран чәчәгенең сары төймәләредәй шадралары бик таныш ич бу кешенең.

Шундый җитди бер вакытта юк-бар хакында уйланып торуын абайлап, уртәлде, уңайсызланып куйды Равил, исәбен скважинага, аны рәтләүгә бәйле мәсьәләләргә борырга тырышты. Шулай да тегенең авып китәрдәй булып чайкалуын күз алдыннан куа алмады. Кайда һәм кайчан очратты ул шушындый кешене? Ниһаять, сизгер приборның антеннасы әллә кайда, бик ерактагы сигналларны тотып алгандай, аның хәтере дә күптәнге бер вакыйганы калкытып чыгарды.

... Яшь мастер Равил Закировны, әллә сынап карау нияте белән, әллә җае шулай туры килеп, артта калган участокларның берсенә билгеләделәр. Башта ул коллективның аксаклау сәбәбе ачыкларга булды. Аныңча, участокның яман ат алуына моңа кадәр нык куллы хуҗа булмау, шуның аркасында хезмәт дисциплинасының йомшавы сәбәпче иде. Егетләр монда да төшеп калганнардан түгел югыйсә, Равил алар белән берәм-берәм дә, җыеп та сөйләшеп карады. Промыселда яманат йөртүләренә үзләренең дә әчләре поша нефтьчеләрнең. Әмма дәррәү генә күтәрелеп, артталыктан чыга алмыйлар. Беренчедән, оештыручы юк, икенчедән, арада эшкә таяк тыгып, гел тискәрегә сукалап торучылар да бар икән. Шуларның берсе — слесарь Әбүталип иде.

Участокка яңа мастер килгәч, бер ай чамасы вахтага әйбәт кенә чыкты бу. Тик эшләп куандырмады, Равил күз алдыннан югалуга, я тегендә, я монда китеп олага иде. Мастер аңа күз-колак булуны көчәйткән саен, Әбүталип та, яңадан-яңа хәйләләр уйлап чыгара, эшләми генә акча алуның әмәлләрен эзли иде.

Беркөнне Равил аңа нефть җыю резервуарларындагы ачкыч-япкычларны карап чыгарга, агып-тамып торган урыннарны ныгытырга, мазутлы җиһазларны солярка белән юарга кушты. Иртәгесен, участокка килүгә, туп-туры резервуарлар янына ашыкты Равил. Заданиенең тулысынча үтәлмәсен көтсә дә, бу кадәр үк намуссызлык белән очрашырмын дип уйламаган иде ул. Әбүталип, нефтьчеләрчә әйтсәк, Әбел, кушканны үтәмәү генә түгел, резервуарлар янына килеп тә карамаган. Эчем авырта дип, көн буе алмагачлар төбендә аунаган. Бу хәлгә кайнап-кабынырга җитте Равил. Кызгылт күзләре төссезләнеп калды, иреннәре кысылды, ярсып культбудкага атлады.

— Сабиров! — дип кычкырды ул ишектән керә-керешкә. — Сабиров, ни йөзең белән хезмәт хакы аласың! Оятың бармы синең, юкмы?!

— Биргәннең битенә карамыйлар, мастер. — Әбел ат кешнәгәндәй көлеп җибәрде. — Күбрәк бирсәләр, оялып тормас идек әле дә.

Равилнең зур йодрыгы, һавада дуга ясап, дерматины ертылып беткән өстәлгә килеп төште, тегесе шыгырдап бер якка янтайды, бүлмә тынып калды.

— Бар, кит, — дип кычкырды Равил ярсып Әбелнең өстенә ташланырга җиткән хәлдә. — Ычкын! Конторада сорасалар, әйт: мастер куып җибәрде, диген.

— Ярый, ярый, җикермә, — диде Әбел ничектер юашланып. — Китәм. Тик кара аны, үкенергә туры килмәсен.

— Үкенмәбез, — диде Равил, аны карашы белән озатып. — Синең кебек сөрхәнтәй өчен елаучы булмас.

Шул көннән соң участокта айга якын күренмәде Әбел. Инде аның турында онытып бетерә язганнар иде. Җәйге иртәләрнең берсендә культбудкага үзе килеп керде һәм, җиңүле елмаеп, Равилгә кәгазьләр

суңды. Аларның берсенә акка кара белән болай дип язылган иде: «Эшчеләргә карата тупас мөгамәләдә булганы һәм слесарь Ә. Г. Сабировны шактый прогул ясарга мәҗбүр иткәне өчен мастер Закировка каты шелтә белдерергә, хезмәт хакын Сабировка мастер исәбеннән түләргә». Менә сиңа мә! Имзалар бар, печать сугылган. Равил уртлары авыртканчы тешләрен кысты, тик ачуын Әбелгә сиздермәде, кисәк борылып, операторлар белән сөйләшә башлады.

Ул көнне Равил эштән иртәрәк китте, промыселлар идарәсенә ашыкты. Тик анда аның үпкә-зарына игътибар итмәделәр.

— Үзегез гаепле, иптәш Закиров, — диде аңа профсоюз комитеты председателе тыныч кына, — профсоюз оешмасы карарыннан башка кешене эштән куарга ни хакыгыз бар сезнең? Кайнарлангансыз. Ә Сабиров ахмак түгел, сезнең дуамаллыктан бик оста файдаланган.

Мастер белән Әбел арасы бөтенләй бозылса да, Равил эчендәген бирәүгә дә сиздермәде. Сабировка шулай ук һәр көнне эш кушты, үтәлешен тикшерде. Әбел исә бөтенләй азынды, мыек астыннан елмаеп, үз җаена йөри бирде. Аңа җитди генә бер чара күрмәгәндә, кыланышларының башкаларга да тискәре йогынты ясыйсын көт тә тор. Тик нишләтергә Әбелне? Ул шелтә-мазарга төкерми дә, премияне кисүгә күнегеп беткән. Закон нигезендә эштән куарлык сәбәп чыгарганы юк — һәр очракка аклану кәгазе әзерләп куйган була, эчеп-исереп йөргәне күренми. Шулай да бер капты Әбел һәм каты капты.

Күзәтеп йөри торгач, Әбелнең качып йоклый торган урынын белеп алды Равил. Кайчандыр, кем тарафыннандыр салынган кечкенә генә таш бина иде ул. Заманында культбудка-мазармы, төзүчеләрнең конторкасымы булган бу таш келәт участокның иң аулак почмагында, коры елганың текә ярында утыра иде. Тәрәзәләре юк, түшә... тимер-бетон плитәләрдән, калын каен такталардан сугылган ишеге ... тирә-як авыллларда яшәүче җойдыгыш агайлар кулына тими исән к... ган. Әбел анда сәке сыман нәрсә корып, өстенә печән түшәгән.

Әлеге таш келәттән ерак та түгел күп мәшәкат... р чыгармый гына фонтанлый торган юмарт скважина бар иде. Бер ... че юк-бар эш табып, Әбелне шунда җибәрде мастер. Сабировка и... шул гына кирәк тә. Скважина янына барып әйләнде-тулганды да теге таш келәткә таба китеп тә барды.

Сәгать тә үтмәгәндер, скважина янына Равил килеп чыкты. Көткәненчә, Әбел анда юк иде. Мастер таш келәт ягына борылды, ишекне шыпырт кына ачты. Әбел, кулларын як-якка ташлап, гырлап йоклап ята иде. Равил ишекне сак кына япты да алдан әзерләп куйган болт белән бикләп куйды.

Кичке буйда әлеге бина янына бульдозер килеп туктады. Кабинадан башта Равил сикереп төште, аннан машинист күренде. Исәпләүләренчә, Әбел әле һаман йокласа да, мотор тавышына уянырга тиеш. Ишек төбенә җиткәч, тукталдылар. Равил юри тавышын күтәрә төшеп, сөйләргә тотынды:

— Менә шушы почмактан сак кына эттер. Тик кара аны, өстенә ишелмәсен. Ташларны издермәскә тырыш, чокырга тәгәрәмәсеннәр. Яңа резервуар нигезенә кирәк алар.

Бер мәлгә тын калдылар. Тыңлап-тыңлап карасалар да, эчтән тавыш ишетелмәде.

— Ярый, башла, — диде Равил, тагы да кычкырыбрак.

Бульдозерчы тау кадәр машинасын келәт почмагына китереп терәде һәм, газны бар куәтенә ачып, пычакны бер күтәрә бер төшерә башлады. Моторның иләмсез үкерүеннән һәм тимерның ташка ышкылуыннан коточкыч тавыш купты, «таш капчык» селкенгәндәй булды. Кинәт эчтән үзәк өзгеч аваз яңгырады:

— Мастер! Егетләр! Харап итмәгез. Ике бала бар бит, ике бала!

Тыштагылар Әбелнең ялваруын ишетмәмешкә салындылар.

— Умырт давай, умырт! — дип кычкырды Равил.

Бульдозер исә әле ярсып урынында бөтерелде, әле тимер күкрәге белән бинаның таш почмагын кырып, яман авазлар чыгарды. Мастер кул изәүгә, тынып калды.

Шул чак эчтән Әбелнең үксегәне ишетелде. Ул яшенә буыла-буыла бер үк сүзләрне тәкърарлый иде:

— Мастер! Егетләр! Балалар хакына...

Уенның тирәнгә китүен абайлап, Равил ишекне ачып җибәрде. Курку дан калтыранган Әбел, тоткага ябышып, бусагадан тышка авып төште. Аның күзләре урыныннан купкан, чәчләренә әллә аксыл тузан кунган, әллә чаларып чыккан иде.

— Мастер! Рәхмәт, мастер, — диде ул, җиргә тезләнгән килеш балаларча мышкылдап.

Равил бер адым артка чигенде һәм бик гаҗәпләнгән булып:

— Сабиров?! Син ничек монда? — диде.

— Сөйләмә инде, Равил Вәлиевич, — дип мыгырданды Әбел.

Шул көннән соң ул, кулга өйрәтелгән җанвар сыман, ни кушсаң, шуны минутында ук үти торган булып китте. Шулай да промыселда озак эшләмәде, каядыр китеп барды. Әлеге вакыйга исә нефтьчеләргә Әледән-әле тел кашырлык мәзәк, Равилгә «Кислота» дигән гомерлек кушамат калдырды.

Равилнең тоемы, чамасы дөрес, кайчандыр нефть якларында әнә шундый «батырлыклары» белән дан тоткан Сабиров үзе иде бу. Дөрес, ул инде элеккеге кебек үк хөрәсән Әбел түгел, тырыша торгач, техникумның кичке бүлеген бетерде, мастер булуга иреште. Шулай да «Кислота» белән очрашу, житмәсә аның кул астында эшләү Сабиров өчен яхшы фал түгел иде. Шуңа пошынып утырды Әбүталип.

Скважинаны томалап, сварка эшләрен бетергәнче, төн узды, таң атты. Тик Равилгә аннан соң да кайтып ял итү насыйп булмады. Скважинага комиссия арты комиссия килде, промысел башлыклары, идарә, берләшмә инженерлары агылды. Барысы да авария сәбәбен ачыкларга тырыша иде. Әмма аны берәү дә белми, төрле-төрле фаразлар гына әйтелә. Нефть газы белән һава катнашмасының мәгълүм бер пропорциядә шартлавы билгеле нәрсә. Әмма аның өчен нәни генә булса да очкын булуы шарт. Тимергә тимер ышкылган дияр идең, скважинада һава агышыннан башка хәрәкәт булмаган. Шушы табышмак бөтенесен хәйран калдырган иде. Мәсьәләне ачыклау махсус комиссиягә йөкләтелде. Равил кичкә таба гына бушанып, иркенләп тын алды.

## 4

Инде конторга кермәм, туп-туры өйгә узармын, ял итәрмен дип, юл буе уйланып кайтса да, идарә турына җиткәч, Габитка туктарга кушты. Күңелендә шундый тойгы: әйтерсең, бик ашыгыч эш килеп чыккан да, аның кайтуын түземсезлек белән көтәләр. Хәер, ниндидер тынгысыз уй, үз-үзеннән канәгатьсезлек хисе Яшел Түбәгә килгәннән бирле борчып йөри аны. Гүя кемнеңдер бик газиз нәрсәсен тартып алган да, аны үзләштергән. Юк, исраф иткән, аяк астына салып таптаган. Әле менә бүген генә төшенде кебек: ул «нәрсә» — ышаныч дигән изге бер төшенчә. Кисел кенә әйтмәсә дә, яңа идарәгә, димәк ки, аның баш инженерына зур өмет баглавын ачык сиздерде бит Губерт. Равил үзе дә нииндидер бер зур эш, Татарстан промыселларында моңа кадәр күренмәгән

нәрсә дә булса майтарырга исәпләп алынды түгелме соң бу хезмәтенә? Ә ни кырды? Эшли башлаганнан бирле кешеләр, бригадалар белән танышу, аларның башкарган хезмәтенә анализ ясаудан узганы юк.

Шул авыр уйлары идарәгә таба атлаган аякларына ике потлы гер сыман тагылгандай булды. Нигә икәнен уйлап та тормастан, аэродром кадәр хуҗалыкның аргы башына, цехка таба узды. Ләкин монда да юаныр нәрсә, күңелендәген уртаклашыр кеше тапмады.

Рәткә тезелгән таш биналарның иң зурысы ягына җиткәч, ишегенең сыза гына ачык торуын, ярыктан сизелер-сизелмәс кенә төтен саркуын абайлап алды. Шикләнеп, эчкә узды. Ян тәрәзә буендагы верстак сыман нәрсә янында өстенә брезентовка кигән бер кеше утыра иде. Алдында калын торба кисәге сыман нәрсә ята.

Равил сәлам бирде. Карт, кайсы эшсезе буталып йөри тагын дигәндәй, берни аңлатмый торган салкын карашын Равилгә төбәде, ишетелер-ишетелмәс кенә исәнләште һәм тимере өстенә иелде.

Әлеге тимернең скважиналарда өзелеп калган торбаларны аулый торган инструмент икәнен шунда ук төшенде Равил. Ремонт вакытында авариялар булып кына тора һәм алар бер-беренә һич охшамый диярлек. Шуңа күп төрле дә ул аулау кораллары. Байтагы заводларда җитештерелми дә хәтта, цехларда махсус слесарьлар әзерли аларны, кирәк икән, яңасын ясый. Моны инде булды-булмады гына эшчегә тапшырмыйлар.

— Нәрсә, барып чыкмыймы?

Карт дәшмәде, илтифатсыз гына төкереп куйды, торып ут яндырды. Аннан соң гына:

— Чыгып бетми шул, — диде.

— Сызымы бармы соң?

Оста дәшмәде, тартмаларның берсен ачып, актарына башлады. Ул да түгел, тартманы ябып, түш кесәсеннән штангенциркуль чыгарды, тәрәзә төбендәге күзлеген алып, шәмахәләнеп торган борыны өстенә мендереп куйды. Инде бу җавап бирми дигәндә, тагы әйтеп куйды:

— Сызым-мызым белән кайнашмыйбыз. Туй узган — тун тузган.

Һәр хәрәкәте әйтеп тора — сөйләшәсе килми агайның. Тик нишләптер ул төкселәнгән саен, Равилнең оста яныннан китәсе килми, аның телен ачарга дигән әрсез бер уй күңеленә тынгы бирми иде. Ләкин кайсы ягыннан килергә бу тәкәббер кеше янына. Равил верстакта яткан эш бияләен алып киде, булачак инструментка үрелде.

— Яле, нәрсәсе чыгып бетми?

Агайның йөзендә мәсхәрәле елмаю чалынып алды, Равилгә күтәрелеп карап, иң зәһәр сүзен сайлагандай, озак кына дәшми торды.

— Һы, кайсы авыл соң үзең? — дип куйды бераздан.

Равил ихтыярсыз көлеп җибәрде.

— Закиров диләр мине, идарәнең баш инженеры булам.

Бу сүзгә дә әллә ни сикереп төшмәде карт, күзлеген салып, тимер аяклы урындыгына утырды, кесәсеннән «Север» кабы чыгарды, ашыкмый гына папирос кабызды, төтен йотты, ютәлләп алды.

— Һы, минем ташбаш сине йөртә алайса, — диде ул үз алдына сөйләнгәндәй. Аннары тирән утырган төссез күзләрен баш инженерга текәде. — Алайса танышыйк инде: Галиулла атлы мин.

Шуннан ике арадагы боз эрегәндәй булды. Алларында яткан тимерне боргалый-әйләндергәли шактый утырдылар.

— Соң моны ясарга көн җитмимени, Галиулла абзый? Әллә ашыгыч заказмы? — дип сорап куйды Равил.

Карт кабаланмый гына Равилгә таба борылып утырды.

— Ашыгыч түгел дип, кайтып карчык мыжлаганны тыңлап утыраыммы?

— Хатын-кыз бер дә юкка мыжламас, әллә соң теге... төшергәлисеңме?

Моңа кадәр һич нәрсәгә пошынмый утырган Галиулла ага, сварка утына пешкәндәй, сикереп торды, яшенә һич ярашмый торган җитезлек белән идән буйлап йөрергә тотынды.

— Төшергәлисеңме дип, я әйт, кем эчми аны бу дөньяда?! Үзең менә: фәрештәме, изгеме — бер гөнаһың да юкмы? Шалиш, брат, берәү дә мыскалламаган ефәк түгел бу заманда. Безнең Кайманов кына ул теге... фәрештә булып кылана. Беләбез, аның да кем икәнен беләбез... Төшергәлисеңме, имеш. — Ул, суына төшеп, Равил янына килде, шомарып беткән утыргычына утырды. — Бер дә эчмим дип әйтмим анысы, кем, Равил туган. Хикмәт анда түгел. Крестьян каны, мужик каны түгел миндә — менә нәрсәдә сер. Йорт-җир дип исем китмәде гомергә, байлык җыймадым. Монда, шәһәрдә дә үз хуҗалыгым белән яшәгән булам, югыйсә. Өй дисәң хәтере калыр, күрше Сафиулланың мунчасы да зур аңардан. Ә бит күрше-күлән ай-яй таза яши, хан сарае да и түлке. Ул гаражлары, абзар-кура, мунчалары дисеңме. Һәр йөрәктә көнчелек бар. Менә шуңа чәпчи карчык: оясыз күке, ди, картаеп акылга туймаган дивана, ди.

Ул тынып калды, шулай да сүзе бетмәгән икән. Әмма ул инде элеккеге халәтенә кайткан иде.

— Карчыкны көнчелек корты кимерә, мине икенче нәрсә борчый, Равил туган, менә, пример, үземнең малайлар. Кемнән күреп үскәннәр дә, кемнән өлге алганнар диген. Олылары икесе дә кулак мыни. Пачулканың теге башында һәркайсы шушы цех кадәр өй житкерделәр. Аның өстенә аерым кухня. Ул гына да җитмәде, чормаларын кеше яшәрлек итеп җылыттылар. Таштан бер дигән подвал, гараж, тагы әллә нәрсәләр. Ял, йокы белмиләр. Бәләкәен, үзеңне йөртүче Габитны ал: лехковой машина дип тормый, багажнигына әле таш, әле кирпеч төяп кайта. «Урлыйсың», дип сүгәм тегене. «Юк», — ди», — аяк астында аунаганны гына җыям», — ди. Өй салам, машина алам, дип җенләнә. Каян килгән комсызлык бу, нәрсә бу?

Үз йорт-җире белән яшәгәне булмады Равилнең, андый нәрсәләрне күрмәде, ишетмәде. Шуңа да сүзне икенчегә борырга ашыкты. Сөйләшә-сөйләшә тимер игәделәр, чүкеделәр, шомарттылар. Дуслашып та киттеләр шикелле.

Тынчу цехтан чыкканда күңеле белән бөтенләй башка кеше иде инде Равил. Күкрәгендә гайрәт, беләкләрендә куәт арткандай тойды. Кемнәре генә юк бу дөньяның! Җәмгыятьнең уртак мәшәкатьләрен җилкәләренә салып, зарланмый-сукранмый гына заманны алга әйдәүчеләр шушы Галиуллалар түгел мени! Ул, авыр атлап, идарәнең икенче катына күтәрелде, кабинетына таба атлады. Шул чак колагы төбендә үк Фәридәнең яңгыравык тавышы ишетелде:

— Әтием!

Равил аптырап китте. Аягүрә төшләнә башладыммы әллә? Авыраеп торган керфекләрен күтәреп, борылып карады. Артында, бәхет кошы тоткандай балкып, Фәридә басып тора иде. Кызы әтисе кочагына ташланды, аксыл төк баскан тузанлы битеннән үбеп алды.

— Ә без инде сине кайтмый дип торабыз.

— Кем ул «без?»

Кызый кабул итү бүлмәсенең аулак почмагына ишарәләде. Түгәрәк кием элгече янында, гадәтенчә тыенкы гына елмаеп, Лениза тора, өсбашы җыйнак, тик чыгарылыш кичәсеннән соң юньләп йокламаган бугай, йөзендә — талчыгу билгеләре. Равил карашы белән өченче кешене — әниләрен эзләде, ләкин бүлмәдә башка җан иясе күренми иде.

— Нихәл, кызым? — диде Равил нигәдер күңеле нечкәреп, — әйдәгез, бирегә үтегез!

Равил өс-башын салмый гына өстәле артына узды, зиннәтле бүлмәдә аптырашып калган кызларына күз салды. Әниегез кайда соң дип сорамакчы иде дә, никтер тыелып калды, бары:

— Сезнең инде ашыйсыгыз килә, шулаймы? — дип куйды.

— Ә без ашадык, — дип такмакларга тотынды Фәридә, — күрше апа шундый әйбер белән сыйлады, минем әле андый тәмле ашны беркайчан да татып караганым юк иде. Исеме ничек әле, Лениза?

— Салма, — диде тегесе карындашы сыман сикереп чыкмый гына.

— Әйе, әйе, салма! Катык белән — во! — Фәридә баш бармагын югары күтәреп бәхетле чыркылдады. — Прелесть!

— Кем, нинди күрше ул? — дип сорады Равил берни аңламыйча.

— Фәһимә апа.

— Сез инде анда булырга да өлгердегезмени?

— Без бит инде иртүк килгән идек, — дип сүзгә кушылды Лениза,— аптырап йөргәнне күргәч, Фәһимә апа үзе алып керде.

Квартира квартира гына булмады кызларга, алар бүлмәдән бүлмәгә чабышып, аны карый, бүлә башладылар. Бигрәк тә Фәридә очынды:

— Менә монысы безгә, ишетәсеңме, Лениза?! — дип бөтен өч бүлмәгә чырыйлады ул. — Юк, юк, монысы әтием белән әниемә, әнә тегесе, кечерәге безгә.

Балаларның «ах-ух» итеп квартираны мактауларын, сабыйлыкларыннан арына алмый чыркылдашуларын тыңлап, елмаеп басып торды Равил. Менә бит, бәхетле булу өчен кешегә күпме генә кирәк! Әх, әниләре дә килеп шулай очынып йөрсә! Шул уе йөзеннән елмаюын сөртеп алды, исәбен тормыш чынбарлыгына кайтарды. Менә күптән көткән кешеләре килде, тик аларны яткырырга урын-җир дә юк, караваты да берәү генә. Тиз генә кибеткә барып кайтырга кирәк.

Җыйнаулап чыгып барганда, каршыларына Фәһимә тап булды, кочагында тау кадәр урын-җир.

— Кызларны әйтәм, үземдә генә йоклап чыгарлар мәллә дигән идем дә, әтиләре янында кунсыннар инде, — гөрли-гөрли залга үтте, әйберләрен урындыкка куеп, Равилгә таба борылды.— Хәзер раскладушка кертәм.

— Рәхмәт инде, күрше, — диде Равил уңайсызланып.

— Хатын-кызсыз йортта рәт юк инде ул.

Шулай сөйләнә-сөйләнә, ул кабат үзенә чыгып китте. Гаҗәп кешелекле булып чыкты әле бу хатын. Ярый, күршең үзеңнән яхшы булсын, дигәннәр бит. Шулай да сәеррәк бүген Фәһимә. Өстенә рәешкә дигән затлы киемнәрен кигән, чәчен дә кыландырып бетергән. Әллә инде битенә иннек-кершән дә тигән, тагын да яшәреп, чибәрләнеп киткән төсле.

Ул арада Фәһимә раскладушка күтәреп, кереп тә җитте. Кызларга дип, караватка киң итеп урын җәйде, Равилгә тиешле урын-җирне дә раскладушкага иплән салды да, җилләнеп тагын чыгып китте. Бераздан пар бөркеп торган чәйнек белән бер банка варенье күтәреп керде. Равил инде аның болай үз өендәге кебек иркенләп йөрүенә борчыла ук башлаган иде. Кызлар җиткән, әллә ни уйлаулары бар. Әмма андыймондый уй кызларның исләрендә дә юк бугай, чыркылдый-чыркылдый Фәһимә апалары белән чәй эчтеләр, әтиләренә дә бер стакан китереп тоттырдылар.

Шул чак ишек катында телефон шалтырады. Равил урыныннан кузгалганчы, Фәридә трубканы алып өлгергән иде инде.

— Әйе, мин, — дип кычкырды ул, бөтен өйне яңгыратып. — Юк, юк, югалабызмы соң... Без бит записка калдырдык...

Әнисе күп итеп вәгазь укыды бугай, Фәридә, битараф бер кыяфәттә, сүлпән генә: «Э-э», «әһә» дигән авазлар чыгарып торды, сүзне тыңлап та бетерми, трубканы әтисенә сузды.

— Аңлашылды, аңлашылды, — диде Равил хатынының очсыз-кы-

рыйсыз сүзен беравык тыңлап торганнан соң. — Үзең ни хәлдә. Нигә кызлар белән килеп чыкмадың?

— Ә-ә, син мени әле бу? — диде Әлфия тонык тавыш белән. — Кунакка йөрер чакмы соң. Аннан ул җилбәзәкләр миңа әйтми китеп барганнар ич.

— Качканнар алайса, — Равил шаркылдап көлеп җибәрде.

— Син, Равил, көлмә әле, — диде Әлфия кырыс кына. — Үзең беләсең, аларның институтка әзерләнәселәре бар. Иртәгә үк кайтарып куй үзләрен.

Равилнең күңеле нечкәргән чак. Хатыны белән иплэп, тәмләп сөйләшергә ниятләгән иде дә, барып чыкмады — Әлфиянең төксе сүзләре күңелен кайтарды. Салкын гына саубуллаштылар.

## 5

Ул, нарасыйдай, яшь таң нурының иркәләвеннән уянып китте. Кичә тәүлек буе аяк өсте булуына карамастан, йокысы туйган, гәүдәсе җиңелчел, яткан җиреннән талпынып очып китәр төсле. Шулай да кузгалырга ашыкмады. Кичә хатыны белән сөйләшүе, кызларны кайтарып куярга кирәклеге исенә төште. Кызык кына бу Әлфия. Ничек инде ул— әти кеше үзен сагынып килгән балаларына: «Барыгыз, кайтып китегез», — дип әйтсен, ди. Ә кызлар молодцы. Чакырганны да, барып алганны да көтмичә килгәннәр. Үзләрен кем бакканны, кем карап үстергәнне, ниһаять, әтиләренең аларга булган мөнәсәбәтен беләләр, димәк. Беләләр генә түгел, яраталар, үз итәләр әтиләрен. Юк, мондый гаиләнең таркалуы мөмкин түгел. Озакка сузмас, Әлфия үзе дә килеп җитәр әле. Юк инде, килгәннәр икән, күңелләре булганчы торсыннар, күрсеннәр әтиләренең тормышын, карасыннар Яшел Түбәне. Тик ни белән кызыксындырасың аларны? Шәһәр беләнме? Аның нәрсәсен күрсәтәсең инде? Төзелә башлаганына ике дистә ел да тулмаган, байтак йортлары да вакытлы такта бараклар. Әллә соң Ромашкино нефть чыганагында беренче хәзинәне биргән мәшһүр скважинага алып барыргамы? Алай дисәң, җилбәзәк кыз-кыркынга, бигрәк тә Фәридәгә, ни пычагыма инде ул скважина? Шулай ук аларны этеп-төртеп озаткан кебек кайтарып кую да килешми.

Ул урыныннан сикереп торды, саф һавада физзарядка ясарга ниятләп, тәрәзәне ачып җибәрде һәм, иртәнге салкынча һава назына эсәрләнеп, баскан җирендә торып калды. Өстендә сыек кына аксыл томан йөзгән мәйдан тып-тын һәм ничектер сагышлы иде. Равил карашын өскәрәк күчерде. Томан, адашкандай, биек таш йортлар арасында уралып йөри, ә өстәрәк өй кыеклары, дымлы калай түбәләр аермачык күренә, аннан да биектә чалт аяз күк йөзе кояшлы көн вәгъдә итә иде. Карашы ике йорт арасындагы ачыклыкка төбәлеп калды. Шул кечкенә аралыкта кино экранындагы сыман булып урман күренеп тора. Шәһәр өстенә менә-менә авам, яшел дулкын белән күмеп китәм дип торган бу урман Яшел Түбәнең горурлыгы иде. Менә кайда алып барачак ул кызларын бүген.

Тәмам мышнап беткәнче күнегүләр ясап кайнашкач, бил тиңентен салкын су белән юынды, күкрәге кызарып чыкканчы сөртенде һәм өстенә спортчы костюмын киеп алды, аннан кызлар йоклый торган бүлмә ишегенә килде.

— Әй, йокы чүлмәкләре, торыгыз! — диде ул, ишекне ачып. — Торыгыз, тор. Бездә монда төн кыска була.

Кичтән калган чәйне җылытып, тамак ялгагач, кузгалдылар. Алар урамга чыкканда, көн инде тәмам яктырган, йортлар арасында болганып йөргән томан бөтенләй сыекланган иде. Сихри бер тынлыкта үзәк

урам буйлап сузсез генә киттеләр. Ике ягы да кыргый алмагачлар стенасыннан торган урам күркәм, купшы. Кызлар шуңа сокланып баралар иде бугай, күзләре баш очында бөркет канаты булып торган ябалдашларда.

— Күр нинди матур, — дип куйды гадәттә хисләрен сиздерми торган Лениза.

— Яшел җилкән төсле, — дип кушылды Фәридә.

Алмагачларны көязләнеп утырган юкәләр алыштырды, аларның яфракларыннан әллә бал, әллә иртәнге чык тамып тора. Урман аларны кошларның моң авазлы симфониясе белән каршылады. Монда әле караңгылык чокырларга сыенып бетмәгән, агач араларында салкынча һава изрәп ята. Шулай да ул чиркандырмый, сине үзенә дәшә, тел белән әйтеп булмый торган ниндидер бер рәхәтлек белән назлый.

Кызлар, бал кортлары сыман, чәчәктән чәчәккә очындылар, кочакларын тутырып букет җыйдылар. Аларның чырый-бырый ап-ак чык пәрәнҗәсен ярып йөрүләрен карап торуы бик ләззәтле иде әти кешегә. Кызлары артыннан, чык ярып атлый-атлый, Әлфиясен дә үзе белән янәшә итеп хис итте Равил. Шушы хозурлыкта дүртәүләп йөрсәләр ни бәхет булыр иде дә бит... Туктале, ир белән хатын арасында килеп чыккан бәхәсләрдә ни өчен һәрчак аның сүзе аста кала да, Әлфия өстенлек ала бара соң? Либеральлек, хатын-кызга юл кую галәмәте микәнни бу? Ничек хәтерендә калгандыр, студент чагында укыган бер китаптагы сүзләр кинәт кенә калкып чыкты. Борынгы грек философы Эпикур: «Хатыннар куәтләнсә, дәүләтләр юкка чыга», — дигән, имеш. Моңысы инде чиктән тыш. Дәүләтләр юкка чыкмас анысы. Ә менә ир белән хатын бер-берен аңламаса, бер-беренә юл куймаса, семья таркала. Равил ирексездән әтисе белән әнисен исенә төшерде. Нинди кешеләр иде бит! Бер-берең санлап, берсен-берсе ымнарыннан аңлап яшәделәр. Гомерләре генә кыска булды. Кадерләрен белеп яшәделәр дә соң! Берсе әйтсә: «Җитик җир читенә», — дисә, икенчесе кая, нигә баруларын да төпченеп тормастан, аңа иярер иде. Ә Әлфия? Син аны бөтен уңайлыклары булган яңа шәһәргә чакырасың, ә ул... Чыннан да нилектән бу? Юк, юк, бу аның азынуы, ирен санламавы гына түгел, яратмый ул Равилне!

Шушы ямьсез уй Әлфия белән бергә яши башлаганнарыннан бирле беренче тапкыр килде аның башына. Беренче тапкыр. Ләкин ачы хакыйкать булып. Әйе, яратмый бугай аны Әлфия. Кем, нәрсә гаепле аның күңеле сүрелүгә?

— Әтием, арыдыңмы?.. Әллә авырып киттеңме син?

Ленизаның кызганулы соравы әллә нишләтеп җибәрде Равилне, ул кызарып чыкты, сүзен әйтә алмый торды.

— Юк, кызым, юк, — диде, тартынуын сиздермәс өчен сәгатенә карап. — Болай гына... Әллә ниләр төште искә.

Алар урманлы тау-дулкынның икенче ягына барып чыкканда, көн инде тәмам җылыткан, кояш чыгышына алсу җилкән эленгән иде. Урман авызына басып тын калдылар. Табигатьнең серле бер мизгеленә таң калып байтак торгач, кире борылдылар.

— Әтием, карале, — диде Фәридә шыпыртлап һәм юлның караңгы урманга кереп югалган очына ишарәләде.

Равил шикләнеп куйды, кызы ымлаган якка карады. Иске юл буш, тик анда серле күләгәләр генә сузылган иде. Җентекләп карый торгач, томырылып болайга таба килүче җан иясен шәйләп алды. Бераздан аның инде йөгергәнен чамаларга була иде. Юл уртасына басып үзенә карап торучыларны күргәч, теге адымнарын акырынайтты. Өстенә спортчылар трикосы, аягына кеды кигән йөгерүченең Кайманов икәнен шунда гына танып алды Равил. Гадәти булмаган киемнәре, алсуланып янып чыккан йөзе аны тагын да малайсытып, сәер итеп күрсәтә иде.

Тик үзе моңа игътибар итмәде, килеп җитүгә, гадәтенчә көр, күтәренке тавыш белән сәлам бирде:

— Хәерле иртә.

— Хәерле көн, Васил Нигъмәтович, — Равилнең йөзенә сәерсенеп елмаю чыкты. — Ярышка әзерләнәсез дисәм...

Кайманов аның чәнечкеле сүзеннән арынырга тырышып, җавап бирергә ашыкты:

— Болай гына. Картлыкны куркыту өчен. Ялгышмасам, синең кызлар бугай.

— Әйе, Закировлар токымы. — Равилнең тавышында горурлык чалымнары сизелеп китте. — Лениза... Фәридә...

— Бик әйбәт, — диде Васил бөтен йөзен куаныч белән балкытып.— Бергә җыелуыгызга бик шатмын... Нигә туктадыгыз? Кайта торгансыздыр бит?

Шәһәргә таба кузгалдылар. Кайманов та, ялгызы йөгереп китәргә уңайсызланды бугай, аларга иярде.

— Атыбыз бик арык, — диде Равил шаяруга исәп тотып, — безгә карап күнегүләрегезне өзмәгез.

— Анысы башка көнне дә качмый аның. Ә менә баш инженер белән аулакта калу бәхете гел булып тормый. Чын менә. Кайчаннан бирле бергә эшләп, иркенләп бер сөйләшкән дә юк.

Олылар сүзен тыңлап баруны яхшысынмыйча, кызлар адымнарын кызулаттылар, шактый гына аерылып китәргә дә өлгерделәр.

— Мин инде сине бүген юлга чыккансыңдыр дип уйлаган идем.

— Бүген-иртәгә генә булмастыр ахры,— диде Равил командировка хакында сүз чыгуны өнәп бетермичә. — Кызлар килеп чыкты менә... Аннан кисмичә тегә башлау да шәп түгел.

Кайманов йөзеннән куләгә узгандай булды.

— Тел төбеңне аңлап бетермим.

— Кая барырга? Кемнән, нәрсә өйрәнергә?

— Теләгән җиреңә бар: министрлыкка, институтларга, нефть чыгару берләшмәләренә. Җаның теләгән хәтле йөр. Акчадан тормабыз, вакытны кысмыйбыз.

— Анысы шулай. Тик менә әкияттәгечә килеп чыга бит: бар шунда, белмим кая... Оеткысы кая безгә кирәкле яңалыкның?

— Анысын инде, хөрмәтле Равил Вәлиевич, үзең чамалыйсың.

Сүзнең үзен кызыксындырган темага күчүе Равилнең халәтен үзгәртеп җибәрде, мавыгып сөйләргә тотынды:

— Мин инде, дөньяның бер-бер почмагында нинди дә булса яңалык туып, укымый-ишетми калдыммы әллә дип, нефтькә кагылышлы журналларның соңгы елларда чыккан саннарын караштырып, китапханә хезмәткәрләрен туйдырып бетердем. Ни аяныч, моңарчы ишеткән-белгәннәргә өстәрлек нәрсә тапмадым.

Кайманов баш инженерга сәер караш ташлады. Әллә кызыксыну, әллә ачу, әллә мәсхәрә төсмере иде ул караш та.

— Бармаска, эзләнмәскә, дию егез түгелдер бит?

Равил аның сорау катыш кинаясен ишетмәгәндәй, тәмам ачылып, дәртләнеп сөйләвендә булды:

— Дөрес, катламнарга физик һәм химик тәэсир итү буенча кайбер фикерләр, аларны тормышка ашыру юллары кызыклы гына. Нефть районнарының кайберләрендә җир астына газ, күбек кудыру, токымнарга җылылык белән тәэсир итү ысуллары сынала.

— Ну? Ну?

Беркайчан беркемгә сер бирми торган Кайманов «ну-ну»ы белән үзен сатты. Равил аның фән-техника яңалыклары белән кызыксынмавын сизеп алды. Шулай да аны-моны сиздермәде, өзелгән сүзен ялгап китте.

— Нефтьле горизонтларга пар кудырып караучылар, хәтта катламда дары яндырып маташучылар да бар.

Каймановның кызыксынуы ахыр чиккә җиткән иде, ул тукталып калды, балаларча беркатлылык белән Равилгә текәлде.

— Соң, соң?

— Шул, кайбер уңышлар булуга карамастан, көтелгән нәтиҗәгә ирешүче күренми әле. Байтагы эксперимент, әлегә рекомендацияләр бирелми. Кулай дип табылганнары да бик кыйммәт.

Васил көрсенеп куйды. Үзенең сынатуын сизеп алды бугай, борылып ярсып атлап китте.

— Күрше башкорт нефтьчеләренең тәҗрибәсе кызык кына, — дип дәвам итте Равил аның артыннан атлап. — Алар нефтьле токымнарга юдыру сәләте яхшы булган өске-актив матдәләр белән баетылган су кудыралар.

Кайманов адымын акрынайтты, үзенең гадәти иркенлеген, өстенлеген саклаган хәлдә, тынлый бирде.

— Әле Әлмәттә эшләгән чакта ук Туймазыга барып кайттым мин.— Монысы ничек тәэсир итте икән дип, Равил начальнигына карап алды, тегесе, бер дә исе китмәгәндәй, юлын дәвам итте. — Яңалыкны үз күзләрем белән күрдем, сораштым, кирәкле мәгълүматларны язып алдым. Шунысы әйбәт, аны тормышка ашыруның әллә ни кыенлыгы юк: махсус биналар да, яңа җиһазлар да кирәкми.

— Шулай булгач, эш нәрсәдә соң?

— Хикмәт шунда, өске-актив матдәләр дефицит, кыйммәтле. Аларны куллану чыгарылган нефтьнең үзкыйммәтенә сугачак.

Тагын тынып калдылар. Инде шәһәр өстенә ишелергә торган тау маңгаена да якынлаштылар. Васил юл кырыендагы карт имән төбендә туктап калды, ашыгып сорап куйды:

— Теге үзең сөйләгән битум мәсьәләсе ни хәлдә соң? Ничегрәк алмакчы булалар аны?

Равилнең үзен дә нык кызыксындырган иде ул яңалык, кыстатмыйча гына илһамланып сөйләп китте:

— Краснодар нефтьчеләре маташа аның белән. Язуларына караганда, битумны алуы ансат кына икән: мәйданда бер-береннән ерак булмаган берничә скважина тишелә. Шуларның уртадагысыннан җир астына махсус җайланма төшерелә һәм битум яндырып җибәрелә, яхшы янсын өчен һава өрдереп торыла. Катламдагы учак яна-яна алга шуыша, ягъни күчеп йөри, җылылыктан сыегайган продукцияне үз алдыннан этеп бара һәм күрше скважинадан өскә куып чыгара, имеш.

— Шәп, бик шәп, — дип җанланып китте Кайманов. — Бар, өйрән! Бәлки безнең идарәне данга күмәчәк нәрсә шулдыр.

Равил дәшми генә сигаретын тартып бетерде, аны сүндереп җиргә ташлады да ботинка үкчәсе белән изде. Аннан соң гына:

— Миңа калса, битумнарга тотынырга иртәрәк әле безгә, — дип куйды. Ул, әйтерсең, сөйләми, кычкырып фикер йөртә иде. — Хәзерге ысуллар белән эшләгәндә, катламнарда бик күп нефть кала. Алынмый калган җир маен кысрыклап чыгару әмәлләрен әле дөньядагы бер генә акыллы башның да уйлап тапканы юк. Менә кайда хикмәт, менә кайда безнең эш фронты...

— Нәтиҗә?! Шулай кул кушырып утырыргамы синеңчә? Безгә, хөрмәтле Равил Вәлиевич, нидер эшләргә, идарәбезне күккә чөярлек бирәр нәрсәгә ябышырга кирәк...

— Сизенүемчә, Губерт үзе дә нидер әзерли, нидер йөкләмәкче безгә, — диде Равил аклангандай. — Ләкин әйтми, иртәрәк әле ди.

— Бәлки теге... ни ресторанга чакырып карарга дыр? Синең сабакташ түгелме соң ул?

— Губертны алай гына йомшату мөмкин түгел.

— Болай көтеп утырып та булмый, Равил Вәлиевич, — диде Каймарнов шактый кырыс итеп һәм урыныннан кузгалды. — Сөйләшү шушы. Бүгенгә ял ит, Яшел Түбәне күрсәт кызларыңа. Ә иртәгә — юлга.

Васил үңга, агачлар арасындагы тапталган сукмакка кереп китте, Равил алда, кылганлы аланчыкта туктап калган кызларына таба кузгалды.

— Ялыктыгызмы? — диде ул, Фәридә белән Ленизаны култыклап, һәм аларны тау маңгаена алып китте.

6

Алар Бөгелмә аэропортына килеп җиткәндә, самолет кузгалып китәргә сәгать ярымлап вакыт бар иде әле. Равил шоферын көттереп тормаска булды.

— Ягез, сандугач балалары, — диде ул Фәридә белән Ленизаны кочагына алып, — сау булып торыгыз. Әлмәткә кайтып китәргә уйласагыз, ачкычны Фәһимә апагызга калдырырсыз.

— Юк, без Яшел Түбәдә генә әзерләнәбез, — диде Ленизa гадәтенчә җитди итеп. — Тыныч, ял итәргә суы, урманы янәшә. Китапханәсе дә ярлы түгел.

Равил кызларның әллә күп укудан, әллә еш су коенудан суырылыбрак киткән йөзләренә, кояшта янып каралган муен-беләкләренә карап алды, шушы житен башлар өчен кичә генә хатыны белән телгә килүләре хәтеренә төште.

— Сез ул урман тирәсендә чамалабрак, — диде ул ни өчендер Фәридәгә карап. — Болай да әниегездән әлекте инде миңа.

Яшел Түбәгә чат ябыштылар бит кызлар, әниләренең көненә икешәрөчәр шалтыратуына карамастан, теге яки бу сылтау табып, әтиләре янында яши бирделәр. Янында алар булгач, Равилгә дә күңелле: квартирага нур кунды, ятимлек чигенде сыман. Эшләр болайга киткәч, килер, килми калмас дип уйлады ул Әлфия турында. Әмма үпкәсе бик көчле идеме, горурлыгы югалыр дип курыктымы, килеп чыгарга ашыкмады хатыны.

Равил кызларын тагын бер кат кочагына алып маңгайларыннан үпте дә, аларга кызык булсын дип, кулын хәрбиләрчә итеп чигәсенә куйды, аннан посттагы регулировщик-милиционер сыман ишарә ясады. Фәридә белән Лениза, елмаеп, аңа кул болгадылар, ул да түгел, әтиләренең барын-югын да оныткандай, шоферга сырпалана башладылар.

— Габитчик, җилдән тизрәк итеп, ярыймы?!

— Су коенырга тукталабыздыр бит, Габит?!

Кызларның шулай үзе белән илтифатсыз саубуллашулары, кузгалып китмәс борын, Габит белән чыркылдаша башлаулары ничектер күңелен рәнжетте Равилнең. «Менә шулай, һәркемнең үз дөньясы, — дип уйлады ул, аэропорт бинасына таба атлап. — Кызлар кызлар инде — күрше тавыгы, никадәр генә якын итсәләр дә, әтиләре чабуына тотынып йөрмәсләр. Һәркайсы үз мәхәббәтен табар, кияүгә чыгар. Сакалыңны сәлперәйтеп ялгызың торып калырсың. Юк, бөтен таяныч хатында, начармы-яманмы үзең белән тормыш юлын узган кешедә. Аның белән бергә картаюга ни җитә!»

Вокзал халык белән тулы иде. Билетын регистрацияләргә дип сөт сыман аксыл пыялага уеп ясалган тәрәзәгә килде. Сөрмә белән күз төпләренә зәңгәр күләгә ясаган ханымга эндәште:

— Казанга...

— Сезнең рейс өч сәгатькә кичегә, — диде ханым мәрмәр сыман

жансыз битенә бернинди хис билгеләре чыгармыйча. — Казан аэропорты ябык.

Равил, гаҗәеп бер хәбәр ишеткәндәй, аптырап калды. Көн чалт аяз, кояшлы иде, тик көнбатыштан искән җил генә, һаман көчәя барып, вокзал янәшәсендәге каеннарның яшел бөдрәләрен бутарлый. Ул киосктан журналлар сатып алды да, аулаграк урын эзләп, олы залга керде. Анда бер генә дә буш урын юк иде. Кемнәрдер, киерелеп утырган килеш, газета укый, кайберләре аралыктагы чемодан өстенә иелеп шахмат уйный, күбесе башларын күкрәкләренә салып йоклый. Ашыгып урамга чыкты, янәшәдәге туйралыкта үләне тапталмаганрак урын сайлап, плащын җәйде дә, сузылып ятты.

Әллә калгып китте, әллә соңгы көннәрдәге уйларын бер тәртипкә салып дөньясын онытты — торган саен көчәя барган җил тавышын ишетми, аэровокзал артындагы мәйданда, аның кырыендагы бодай басуы өстендә бөтерелгән кара буранны сизми, күзен йомып ятуында булды.

Баш очында гына яңгыраган коточкыч шартлау аның уйларын бүлде. Тамчылар агач яфракларына, тапталган үлән өсләренә, кырыйдагы асфальт сукмакка шыбырдашып коелдылар да, «ә» дигәнче тирә-юньне чылатып та өлгерделәр. Равил, портфелен алды да, башына плащын бөркәнеп, аэропорт бинасына йөгерде.

Биредә инде көтү залы гына түгел, касса, буфет тирәләре дә тәмам тыгынланган, кая гына атлама — анда кеше, чемоданнар өеме. Җитмәсә, ут сүнде, бөтен җирне караңгылык басты, вокзалда ыгы-зыгы көчәйде. Болай булгач, бүген китү хакында уйлама да. Их, юкка җибәрде машинасын. Әллә соң кире чакырыргамы? Шул уй белән автомат телефон будкасын эзләп китте. Тик анда да юлы уңмады: тузгыган чәче эшләпәсенә сыймыйча бүселеп колагы өстенә чыккан берәү ашыкмыйпошмый гына кем беләндер сөйләшә иде. Равилнең дә ашыгасы җире юк, көтәргә булды. Ләкин теге бәндәнең будкадан чыгар исәбе күренми: телефон трубкасын башы белән җилкәсенә кысып тәмәке кабызды, тагы да иркенләп сөйләшә башлады. Шул чак, дөньяны яшькелт нурга күмеп, тагын яшен яшьнәде, бер мизгелгә теге кешенең бите генә түгел, керфекләренә кадәр аермачык күренде. Бер-берсенә ябышырга җиткән яңакларын кара төк баскан, борыны кеше куркыту өчен махсус куелгандай, зур, карчыганыкы сыман. Тукта, күргәне бар ич аны Равилнең.

Ул кабат яшен яшьнәгәнне көтте, тик куәтле яктылык бүтән кабатланмады. Аптырагач, будка тәрәзәсенә якынрак килеп тәмәке кабызды, ләкин соңгарды — теге кеше, трубканы элеп, ишектән чыгып килә иде инде. Нәкъ шул минутта тирә-юньне нурга күмеп тәрәзәләрдә ут балкыды, каядыр өстә прожекторлар кабынды. Пумала чәч, күзләрен кулы белән каплап, алга атлады, Равилгә бәрелә язды.

— Гафу итегез, — дип мыгырданды ул һәм Равилгә күтәрелеп карады.

— Глухов! Син дип әйтимме?

— Рево?! Кая болай?

— Командировкага.

— Мин дә.

Алар, бер-берен култыклап, стена буена — ышыкка килделәр һәм, шуның өчен генә очрашкан кешеләрдәй, сөйләшми генә тәмәке көйрәтә башладылар. Һаман да шул сәер Вениамин икән бу дип фикер йөртте Равил, сабакташына карап ала-ала. Студент чагындагыча ук арык ат сыман озынча битле, үтә ябык, маңгае алга таба чыгып торгангамы, күзләре эчкә баткан төсле, җитмәсә, чегәннеке сыман хәтәр ялтырап торалар. Кара чәчләре дә үзгәрмәгән — гомердә тарак-мазар тимәгән кыл көнҗәләсе сыман чуалган.

Озакка киткән тынлык икесенә дә кыен, газаплы иде. Шулай да электән бер-беренә бик якын булмаган сабакташлар уртак сүз таба алмый йөдәделәр.

— Мин сине Себергә киткән дип ишеткән идем, — диде Равил, болай уңайсызлыктан чыгу өчен генә. Институтны тәмамлагач, мөгез чыгаруын, яңа пешеп өлгергән инженерларны шаккатырып, дипломлы килеш, кайсыдыр экспедициягә бораулаучы ярдәмчесе булып урнашуын тәгаен белә иде югыйсә.

— М-да, тугыз ел изәргә туры килде Себер сазын, — дип куйды Глухов һәм прожекторлар яктысында чайкалучы каеннар очына карап тынып калды.

Кызык, килеш-кыяфәте генә элеккечәме, әллә акылы-фигыле дә һаман шулай сәер микән моның, дип уйлады Равил, аптыраганнан икенче сигарет кабызып. Укуының рәте-башы юк иде бахырның. Студентлар аның китап тотканын да, конспект язып маташканын да күрмәделәр. Лекцияләрдә ул иң алгы партага урнашыр, усал ялтыраган күзләрен, гипнотизер төсле, укытучыга төбәп, сәгатьләр буе селкенми утырыр иде. Төнозын эштә булуына карамастан, ник кенә бер изрәп китсен дә, ник кенә бер дәрес калдырсын. Әнә шулай сәеррәк булганга, аның белән егетләр дә, кызлар да аралашмый, хәтта аның кем булуы, каян килгәнлеген белүче дә юк иде бугай. Шулай да һәр укытучының, һәр студентның йөрәгенә сеңеп калды Вениамин. Нигә дисәң, аның лекция укучыларга тозсыз сораулар биреп, тузга язмаган фикерләр, идеяләр әйтеп, бөтен аудиторияне шаккатыра торган гадәте бар иде. Ул я җиде кат җир астындагы катламнарны әллә ниткән нурлар белән «күреп» буласын исбатлый башлый, я нефтьле токымнарны атом-төш куәте белән ярдырырга тәкъдим итә. Тагын әллә нәрсәләр. Җитмәсә, имтиханнарын гел отличнога биреп, курсташларын хәйран калдыра иде Глухов.

— Инде менә ничә ел биредә, фәнни-тикшеренү институтында.

— Тау-ташлы фән сукмакларыннан киттем дисең алайса, — дип куйды Равил тегеңәргә бераз төрттереп.

— Шулай дим. Кайбер пошмас инженерларны селкеп карарга исәп. Шул хакта Мәскәүгә баруым.

Тагын телсез калдылар. Юлда очрашкан гади танышлар сыман сүзләре ялганмады. Ярый әле сәфәр чыгучыларның гомерлек уртак темалары бар.

— Самолет бүген булмас ахры, — диде Глухов караңгы күккә карап.

— Уйлыйсы да юк. Карале, Веня, гостиницалар тыгындыр инде?

— Ни пычагыма ул гостиница? Миңа кайтабыз.

Вениаминның квартирасы шәһәр уртасындагы биш катлы күркәм генә йортта икән. Тик бусагадан атлауга, баштагы матур тәэсир челпәрәмә килде. Глухов яши торган ике бүлмә дә тәртипсез: бөтен җирдә кием-салым, әллә ниткән чүпрәкләр, кәгазьләр ауный. Алар белән диван да, шкаф та, хәтта тәрәзә төпләре дә тулы. Өстәл өстендә газета-журналлар, китап-брошюралар. Шулар арасында ашалып бетмәгән сыр, колбаса кисәкләре, каткан балык, ипи сыныклары... «Кызлар киткәч, мин дә шушы хәлгә калырмын микәнни?» — дип пошынып куйды Равил.

Глухов, өйдәге тәртипсезлектән уңайсызланды бугай, өстен салып атты да, өстәлен җыештыра башлады. Равил исә, сүз юктан сүз булсынга, әйтеп куйды:

— Өйләнергә исәп юк алайса...

— Фән һәм бала искеләре... Болар янәшә яши алмый торган төшенчәләр, минемчә.

— Шулай да Мәскәүдә ни йомыш?

— Сөйләсәң бик озак, — диде Глухов эшен дәвам итеп. — Беләсеңме нәрсә? Мин кибеткә чыгып керәм, ә син менә бу тәүратны укый тор. Шуннан барын да аңларсың.

Ул ничек чамалап, ничек тапкандыр, өстәлдәге макулатура өеменнән диплом эше кебек каты тышлык белән тышланган бер нәрсә тартып чыгарып Равилгә бирде дә, юеш киемнәренә үрелде.

Равил, дивандагы кием-салымнарны этә-төртә, аның бер кырыена чүмәште, теләр-теләмәс кенә әлеге «диплом эше»н актаргалый башлады. Андагы формулаларга, астына кара сызык сызылган кайбер абзацларга карап-карап алды да, кабат титул битен ачты. Иң өскә баш хәрефләр белән «Катлам физикасы лабораториясе җитәкчесе, фәннәр кандидаты В. И. Глухов» дип язылган иде. Менә сиңа сәер Вениамин! Равилләр ду кубып җир мае чыгарып, ниндидер Әбүталиплар белән ыгы-зыгы килеп йөргән арада, ул диссертация якларга да өлгергән. Туктале, бу язмасында да бер-бер хикмәт юкмы? Равил, кызыксынып, беренче битне ачты һәм укый башлады. Аның сизенүенчә, катлам физикасы лабораториясенең берничә еллык эше хакында язылган иде монда. Менә бит ул эзләгән, ләкин моңа кадәр кайдалыгы башына да килмәгән нәрсә! Бераздан инде Равил, кайда һәм нишләп утыруын онытып, кулъязмада китерелгән мәгълүматлар эченә кереп чумган иде.

Нефтьле катламнарга кудырыла торган суга кайбер химик матдәләр кушканда, аның тәэсир итү көче артканы галимнәргә генә түгел, һәр операторга мәгълүм нәрсә. Татарстан галимнәре күрше Уфа институтындагы коллегаларның тәҗрибәләре белән дә хәбәрдар иканнәр. Тик алар, Равил кебек үк, җир астына өске-актив матдәләр кудыруны кыйммәткә төшә дип саныйлар икән. Лаборатория коллективы арзанлырак һәм тагын да тәэсирлерәк реагент эзләп карарга була. Моның өчен күкерт кислотасы кулайрак булыр сыман тоела. Чөнки ул безнең илдә, аш тозыннан кала, иң күп җитештерелүче матдә.

Ләкин күкерт кислотасына тукталуның сере ул гына түгел, икән. Әле моннан ун ел элек үк институт галимнәре, лаборатория шартларында тәҗрибә ясап, катламнарга су кудыру алдыннан, аңа күп күләмдә күкерт кислотасы кертсәң, нефть алу коэффициентының сизелерлек күтәрелүен беләләр. Тәҗрибәләр тагын һәм тагын кабатлана. Ниһаять, уникенчесеннән соң дөрес юнәлеш алуларына, күкерт кислотасының гаять перспективалы реагент икәненә инаналар. Озак тикшерүләрдән соң шул мәгълүм була: күкерт кислотасы, катламнардагы сыеклык белән реакциягә кереп, үзе үк нефтьне юдыруга сәләтле өске-актив матдәләр барлыкка китерә икән. Бу исә токымнардагы бик нечкә каналларда ятучы җир маен этеп чыгаруда мөһим роль уйный. Өстәвенә, реакция нәтиҗәсендә зур күләмдә җылылык бүленеп чыга, басым күтәрелә. Шулар тәэсирендә нефть тагын да сыеклана, аның агу сәләте арта.

Равил кулъязманы бер читкә куеп, урыныннан кузгалды, тәмәке кабызып, бүлмә уртасындагы мич урыны кадәрле буш җирдә йөренә башлады. Менә бит, аңа кирәк нәрсә үзебезнең Татарстан җирендә үк ята икән. Кызык. Тик нигә соң әле ничә еллардан бирле өстәл тартмасында тузан җыеп ауный бу яңалык? Әллә кайчан чаң сугарга, бөтен нефтьягын аякка бастырырга кирәк иде. Әллә соң берәр хилаф ягы бармы? Ул кулъязманы кабат кулына алды һәм җентекләп укый башлады. Эх, менә нәрсәдә икән эш! Яңалык галимнәр дөньясында яклау тапмаган. Аерым шартларда нефть белән кислота кушылудан сумала сыман матдәләр барлыкка килүе мөмкин икән. Әнә шул матдәләр сыек ягулык юлларын тагын да битәр томалар дип шикләнүчеләр бар икән. Җитмәсә, аларның байтагы зур урыннарда утыручы абруйлы абзыйлар. Менә ни өчен бу хакта шылт та юк әле...

Укый торгач, Равил тагы дәртләнеп китте, йөрәгендә өмет чаткылары артканнан артып, ялкын булып кабынды. Молодцы, егетләр! Әлеге

шикчел агайлар белән килешмәгәннәр, тәҗрибәне производство шартларында ясаганнар һәм сүзләренең дөреслеген раслаганнар. Әйе, әйе, хәтерендә Равилнең, моннан дүрт-биш еллар элек Кама буенда, аннан соң Чирмешән якларында скважиналарга йөзәр тонна кислота кудырылуы колагына чалынган иде. Ул чакта аның нәрсә икәне белән кызыксынмады. Азмыни бездә төрле тәҗрибәләр! Ә бит галимнәрнең ныклы һәм авторитетлы сүзе шул сынаулардан соң әйтелгән. Исәпләүләрдән күренгәнчә, җир астына зур күләмдә кислота кудырып ясалган кайма катламнарның нефть бирүен унбиш процентка арттыра.

Уйларын аяк тавышы бүлде. Күтәрелеп караса, каршында Вениамин басып тора. Капчык-капчык каз башы дигәндәй, бер кочак төргәк күтәргән, плащ кесәсеннән ниндидер эчемлекнең ак чалмасы күренеп тора.

— Хәзер, хәзер без синең белән, хөрмәтле иптәш Рево, симпозиум ачып җибәрәбез, — дип сөйләнде ул, кочагындагы нигъмәтләрне өстәлгә куеп.

Ләкин «симпозиум» табын әзерләнгәнне дә көтмәде.

— Менә син, Вениамин, кислота дисең, перспективалы дисең. Ә аның ничә сум икәнен беләсеңме?

— Төгәл беләм. Тоннасы кырык ике сум.

— Кырык ике?! Чынмы? Хыял дип уйлаган идем аны.

— Хыял түгел, Рево, — диде Глухов, таплы рюмкаларга эчемлек салып. — Менә шуны тот та, аңлатам аннары.

Очрашу хөрмәтенә берәрне күтәрделәр.

— Юк, хыял түгел, — дип дәвам итте Вениамин, сабакташы алдына ап-ак дуңгыз мае, колбаса телемнәре этәреп. — Ә син аша, аша. Студент чакта ач йөргәннәр дә житкән... Безнең өмет, Рево, нефть эшкәртү заводы калдыкларында.

— Аңламыйм, — диде Равил авызында колбаса кисәге әвәләп.

— Хикмәт шунда: заводларда нефть эшкәртүдән соң калган кислотаның хәтта туксан процентлы концентрациясе дә анда кабат куллану өчен яраксызга әйләнә. Хәзер күп кенә предприятиеләр бу куркыныч отходны кая куярга белми интегәләр. Ә андый калдыклар күп, бик күп, ә бу саф кислотага караганда дүрт тапкыр арзанга төшә. Без аны җир астына кудырып карадык. Нәтиҗә — во!

— Алайса, килен дә, кияү дә бар, өйләндерүче генә юк, шулаймы?— диде Равил. Ул Вениаминны үртәп, аны тагы да күбрәк сөйләтергә исәп тота иде. — Хикмәт нәрсәдә соң?

— Куркаклыкта. Менә шул! — диде Вениамин кыза төшеп. Әллә авыз иткән эчемлектән, әллә кызып китүеннән, күзләре аның гадәттәгедән хәтәррәк ялтырый иде. — Бу хакта берләшмәдә белмиләр дисеңмени?!

Димәк, Губерт хәбәрдар. Ә нишләп теге көнне берләшмәдә кислота турында ләм-мим әйтмәде. Ул да шикләнәме? Булмас. Нинди дә булса башка сәбәп бар монда.

Вениаминның ятим квартирасында ут бик соң сүнде. Дөньяларын оныткан ике сабакташ «симпозиум»ы иртәнгәчә сузылды. Тавышлары карлыкканчы бәхәсләштеләр, кислота кудыруга фатиха бирми торучыларның тетмәләрен теттеләр. Шул кайнарлыклары суынмаган килеш, берсе барып караватка сузылды, икенчесе диванга бөкләнде.

## 7

Аксыл төстәге «Волга» соры тасма булып яткан асфальт буйлап үзәнкырларны, урманнарны йөгереп үтте, кылганлы калкулыкка килеп менде һәм дүртесе дүрт якка — нефть тудырган дүрт таш калага бара торган юллар чатында туктап калды.

— Кая барабыз?— Габит күзләрен йомып, йокымсырап барган Равилгә карады.

Тегесе, башын күтәрми генә, кулын алга изәде — Әлмәткә.

Машина, кинәт ыргып, чатны кичте һәм анда зәңгәр рәшә эчендә яткан Зәй үзәненә атылды. Юлдашым йоклый дип, ялгышты Габит. Күзләрен йомып барса да, уяу иде Равил. Көндезен түгел кичә төнен дә йоклый алмады ул. Аны дулкынландырган, йөрәгенә сеңеп калган нәрсә Вениамин белән очрашу, күкерт кислотасы турында ишеткәннәре иде. Дөрес, ул әле һавадагы торна. Кайсы яңалыкның ансат кына юл ярганы бар? Иң әһәмиятлесе — нефтьле катламнарга тәэсир итүнең нәтиҗәле юлы табылган.

Глухов сөйләгәннәр күңеленә шул кадәр сеңеп калган ки, ятса да, торса да, шул хакта уйланды ул.

Ифрат зур табыш вәгъдә итә торган яңалыкның моңа кадәр күләгәдә аунавы аның җанын тетрәтте, шикчел галимнәргә, берләшмә җитәкчеләренә, тагы әллә кемнәргә йөрәгендә үпкә туды. Ул инде кислота белән шул кадәр мавыгып китте, башында аны җир астына кудыру технологиясенең берничә варианты эшләнде дә диярлек. Кайбер нәрсәләрне кабат ачыклап, исәпләүләр ясыйсы, булачак процессның асылын кәгазьгә төшерәсе дә — технологик схема әзер.

Нефтьчеләр кәгъбәсендә юлы уңмады Равилнең, Губерт берләшмәнең генераль директоры кабинетында иде. Шулай да чыгып китәргә ашыкмады Равил. Башта секретарь бүлмәсендә таптанды, аннан киң, иркен коридорга чыгып тәмәке кабызды. Губертны нәкъ менә хәзер, Бөгелмәдә алган тәэсирләре суынганчы, күңеле тынычлый башлаганчы күрәсе килә иде аның. Берничә көннән соң очрашса, әйтәсен әйтә алмас, Губертны күндереп булмас төсле тоелды. Әмма көтү сузылды. Равилнең юлда туып үсә барган үпкә-ачулары яңарды, хәтере калып китәргә җыенды. Бүлеккә, Әлфиясе янына гына кереп чыксын да... Шул ният белән кисәк борылган иде, баш инженер белән йөзгә-йөз очрашты.

— О, Рево, кайтуың белән, — диде Губерт, гадәтенчә бөтен йөзен балкытып. — Әллә юлдан гынамы?

Равил сабакташының купшы өс-башына, ныклап кырынудан зәңгәрләнеп торган яңакларына карап алды, эченнән генә көрсенде: «Черт, тагын сукбайныкыдай өтек киемнәр белән».

— Юлдан... Кайбер нәрсәләр ашыктырды, — диде ул үзенең җыйнаксызлыгыннан гафу үтенгән сыман.

— Алары турында соңыннан, — диде Губерт ничектер үзгәреп. — Министрлыкта син тавышланып йөрдеңме?

Равил дустының караңгыланып калган йөзенә күз төшерде, ләкин сүзнең ни хакта барганын төшенеп җитмәде.

— Мин Мәскәүдә була алмадым.

— Димәк, язып салдың?! — Ул Равилне култыклап алды. — Ярый, ул хакта сөйләшер чак түгел. Син бар, өеңә кайт әле, Алевтина авырып киткән бугай анда.

Губертка ул: «Хәзергә», — дип тә әйтә алмады, кәефе тәмам кырылган иде, йөгереп беренче катка төшеп китте. Каядыр өстә сабакташының:

— Мин үзем шалтыратырмын, — дигән сүзләре генә ишетелеп калды.

Өенә ул ниндидер хәвеф-хәтәр көткән кеше сыман, шомланып тавышсыз гына керде. Гомер булмаганны, Фәриданең тын гына килеп сыенуы, Ленизаның тәрәзә янында боегып утыруы әлеге шомны көчәйтте генә. «Губерт та бик ашыктырды, болары да балталары суга төшкәндәй утыра, әллә соң хәле мөшкелме?» — дип уйлап алды Равил һәм, ботинкаларын да салып тормастан, йокы бүлмәсенә үтте. Юрган астын-

нан Әлфиянең тузгыган кара чәче генә күренеп тора иде. Йөрәге «жу-у-у» итеп китте. Нәүмизләнеп беравык торгач кына:

— Ни булды? Хәлең ничек, Әлфия? — диде.

Тегесе җавап бирмәде. Равил, тәмам куркынып, юрган читен ачты, Әлфиянең йөзенә текәлде — хатыны шактый суырылган, битенә сары суккан, унлап елга картайгандай тоелды аңа.

— Врач чакырыйкмы әллә?

— Кирәкми, үтте инде, — диде Әлфия, басынкы-зәгыйфь тавыш белән. — Чишен син, юын.

Бераздан инде өй эче тәмам җанланып, бүлмәләргә нур кунган иде. Кызлар савыт-саба шалтыратып, чәй кайната, табын әзерли башладылар. Инде Әлфия дә тернәкләнде: торып юынды, өстәл янына килеп утырды. Равилнең дә шик-шөбһәләре таралып, күңеле тынычланды.

Чәйдән соң Әлфия урынына барып ятты, кызлар исә чышын-пышын серләштеләр дә каядыр чыгып киттеләр. Равил нишләргә белми бүлмәдән-бүлмәгә йөренеп, кабат карават янына килде.

— Ничек, әйбәтләнәме?

Әлфия, сабый баладай, бераз турсаеп торды, урын тәкъдим иткәндәй, стена буенарак сыенды һәм күңелендәгеи ярып салды:

— Егылып үлсәң, иренеңә су тидерүче дә булмас. Ярый әле Фәридә белән Ленизаны барып алып кайткан идем.

«Алай икән, үзе барып алган икән кызларны», — дип уйланды Равил һәм хатынына җавап кайтармый гына битәрләүдән котылып калмакчы булды. Ләкин Әлфия турыдан-туры һөҗүмгә күчте:

— Я, әйт инде, карт юләрем минем, тагы күпме йөрергә уйлыйсың болай? — Кабыргасы белән куелган бу сорауга да җавап булмагач, ул тагын да сеңдеребрәк сөйли башлады. — Күр инде, кем синең сыман яшн хәзерге заманда. Кайсын гына алма — үз хәсрәте, үз мәшәкате белән мәж итә. Шул ук Тарабриннарны ал... Фәләховларны... Синең кебек үк инженерлар. Һәркайсы аерым йортта, гаражлары, машиналары дигәндәй...

Равил, аны тыңлаудан бигрәк, телефон шалтыраганны көтте. Губерт шалтыратса, Әлфиянең бу фәлсәфәсеннән котылу җае табылыр иде. Әмма өстәлдәге көрән пластмасса аппарат һаман өнсез. Хатыны исә, ире аның сүзләрен бик бирелеп тыңлый дип, шатланып куйды һәм тагын да йомшаграк, иркә тавыш белән сүзен дәвам итте:

— Ярый, монда яшәп машинасын да, аерым квартирасын да алдың ди. Ә Мәскәүгә, Министырлыкка күчү җае гел булып торыр дисеңме? Эти дә бит мәңге яшисе түгел. Мондый җайны, мондый форсатны кулдан ычкындырамы соң кеше! Акылыңа кил, Равил, төкер Яшел Түбәсенә... Беләм, син сүз булыр дип уңайсызланасың, абруең төшүдән шикләнәсең. Ну, анысына да әмәл бар бит в конце концов. Ну, чирлим диген, исәнлегем юк диген. Һич югы, хатын авырый дип әйт. Мин гинеколог Халидә Галиевна белән сөйләштем, бюллетень белән ярдәм итәргә булды.

Ах, менә нәрсәдә икән эш! Чиренең сере бар икән. Димәк, ул айлар буе корган хәйләсен тормышка ашырырга керешкән. Бүген сүзнең җай гына баруына шатланып торса да, хакыйкатьне аңлагач, кәефе тәмам бозылды Равилнең. Битенә борчак-борчак тир бәреп чыкты, графиннан салып су эчте, урыныннан торып акрын гына йөренергә тотынды. Әлегә хәтле дәшми торса да, зур гауга якынлашып килүен йөрәге белән тоя, шуңа да үзен һаман тыеп торырга тырыша иде Равил.

Менә килеп җитәм дә дөньяның астын-өскә китерәм, дип торган яшенле яңгыр сыман бу минутларның ахыры ни белән тәмамланган булыр иде, анысы билгесез. Шул мизгелдә ишектә звонок шалтырады һәм, рөхсәт сүзен дә көтеп тормый, өйгә Губерт килеп керде, кулында — олы гына букет.

— Рөхсәттер бит, — диде ул тавышы белән берьюлы өч бүлмәне тутырып. — Алевтина ханым ни хәлдә? Менә бу лалә чәчәкләре авыруның кәефен күтәрер бәлки.

— Узыгыз, уз, — диде, кунакны каршылаган Равил һәм букетны да алып кире хатыны янына кереп китте. «Менә бит нинди кеше, — дип уйлады Губерт турында, — эше шундый тыгыз вакытта да хатынкызга игътибарлы. Ә мин авыз күтәреп кайттым. Агач, билләһи агач».

Равил кабат залга чыкканда, кунак трюмо өстәлчегендәге бигудилар белән уйнап утыра иде.

— Я, ниләр күрдең, ниләр майтардың? — диде ул, Равилгә таба борылып.

Тәрәзә буендагы креслоларга килеп утырдылар.

— Командировка кыска, җайлы булып чыкты минем. Үзебезнең Татарстаннан узарга туры килмәде.

— Мәскәүдә булмадың алайса? — дип ничектер шикләнебрәк сорап куйды Губерт.

— Исәп бар иде дә, вакытны кызгандым.

— Димәк Глухов. Ну кайнар баш та соң үзе. Ни әйттем мин аңа, сезнең сәгать сугар дидем. Ә ул...

Бүлмәгә Әлфия килеп керде.

— О-о! Исәнмесез, Алевтина ханым? — диде Губерт, йөзен балкытып. —Күз тия күрмәсен, яшәреп матурланып киткәнсез.

Нәкъ студент чагындагыча таш алиһәдәй басып торган хатынына карап хәйран калды Равил. Кай арада иннек-кершән ягарга, чәчен тәртипкә китерергә өлгергән, зәңгәр ефәк күлмәген киеп алган. Бераз гына ябыгып киткән Әлфия элеккечә яшь, чибәр иде бу минутта.

Ирләрнең эшлекле сүзе бүленде, аңгәмә тормыш прозасына, дөнья ваклыкларына күчте. Әллә үзенең комачаулавын сизенеп, әллә кунакка хөрмәт йөзеннән, Әлфия, китеп, табын әзерләргә тотынды.

— Юк, юк, Алевтина ханым, борчыла күрмәгез, — диде Губерт, урыныннан кузгалып. — Сез ятыгыз, ят. Ә менә Ревоны, сез рөхсәт итсәгез билгеле, ике-өч сәгатькә алып китәр идем.

— Ул инде болай да күкегә әйләнеп бетте.

— Күке! Ха-ха-ха, — дип шаркылдады Губерт бөтен өйне яңгыратып, һәм шунда ук җитдиләнеп калды.— Вакытлы хәл, Алевтина ханым, вакытлы. Менә күчеп барырсыз, бер оя булып җыелырсыз...

— Югинде, — дип үҗәт балаларча кунакның сүзен бүлде Әлфия. — Йөри бирсен шулай күке булып... Үзенә ошатач ни...

Бәхәсне куертудан шикләнеп булса кирәк, Губерт ишеккә таба атлады. Руль артында үзе икән. Янәшәсенә Равил утыруга, житез «Волга», күңелле гөрләп, алга ыргылды. Кая юл тотуларын сорап тормады Равил, кая барсалар да аңа барыбер, тик ялгыз калсыннар да, күңелне кытыклап торган нәрсә турында иркенләп сөйләшсеннәр. Шуңа да вакытны бушка уздырмаска булды, олы юлга чыгуга, Глухов яңалыгы хакында сөйли башлады.

— Беләм, барын да беләм, — дип бүлдерде аны Губерт, — әллә син эшли торган идарәне юкка гына оештырдык дип уйлыйсыңмы? Кем әйтмешли, аллага шөкер, аякка басып киләсез, инде кислота хакында да киерелеп сөйләшергә була.

Машина кисәк кенә сулга борылды, асфальттан төшеп, кыр юлына килеп керде, аз тапталган эздән Зәй буена төшә башлады. Бу хәл тагын да аптыратты Равилне, шулай да ул дәшмәде, серле сәфәрнең ни белән бетәсен көтәргә булды. Әрәмәлеккә килеп керделәр. Ачык тәрәзәдән хуш ис бөркелде, июль чилләсе каядыр асфальт өстендә калгандай булды.

— Менә килеп тә җиттек, — диде Губерт, машинасын өянке күләгәсенә борып. — Җәен бернечә сәгать ял итеп алу безгә дә гөнаһ түгелдер. — Ул багажнигын ачып ниндидер тимер-томырлар, без сыман очлы нәрсәләр алды, капрон кәгазьгә төрелгән төенчекләр чыгарды. — Коры-сары кирәк булачак.

Утын җыярга дип, икесе ике якка кереп киттеләр. Равил ун-унбиш адым атларга өлгермәде, Губертның ничектер дулкынланып кычкырганы ишетелде:

— Рево! Рево дим! Бире кил әле.

Равил, шикләнеп, дусты янына йөгерде.

— Бар бит варварлар, — диде Губерт әвененә ут капкан крестьян агай сыман. — Күрдеңме?

Кемдер, җимешен җыярга булып, зур гына шомырт куагын ерткычларча ботарлаган иде.

— Вәхшилек! — дип куйды Равил көрсенеп.

Байтак кына сүзсез тордылар.

— Ә бит без, нефтьчеләр дә кайчак шушы браконьерга охшап калабыз, Рево, — диде Губерт, мәет күмгәннән соң кабер өстендә әйткән кебек. — Менә бит тагын бер проблема, Рево. Тозлы су! Ә бит соңгы елларда ул артканнан арта. Җир астыннан бер тонна нефть белән шул ук күләмдә тозлы катлам суы күтәрәбез хәзер. Скважиналар ремонтлаганда басуларга күпме агызабыз аны. Катлам суларын җыю һәм аларны кабат җир астына кудыру — алдагы иң зур бурычларның берсе.

— Да, зур мәшәкать, — дип килеште Равил.

— Ә Татарстанның төрле районнарында яткан битум ятмаларын эшкәртү... Шул ук кислота тагы! Алда эшләр тау чаклы, дускай. Боларның барысы да диярлек сезнең идарә җилкәсенә төшә бит...

Тиз генә чыбык-чабык җыеп, учак ягып җибәрделәр. Губерт тимерләре белән кайнашып, учакны кыршаулаган мич сыман нәрсә әмәлләде дә, шампурларга ит кисәкләре тезде дә аларны ут өстенә куйды — әрәмәгә көйгән ит исе таралды.

— Ярый, әнә шул проблемаларны ерып чыгу өчен, — диде Губерт һәм, шаярып, шифалы су тулы стаканын Равилгә сузды.

Бераз капкалап алгач, сүз үзеннән-үзе кислотага күчте. Инде шашлык та ашалып бетте, шешәләр дә бушады, учакта ут та сүрәнләнде, тик инженерларның сүзләре бетмәде. Губерт сәгатенә карап алды да нәтиҗә ясарга ашыкты:

— Ярый, бездән фатиха. Әзерләнә башлагыз. Рәсми күрсәтмәне шушы ике-өч көндә алырсыз. Нәрсә әллә шүрлисеңме?

— Юк, башка нәрсә борчый мине, — диде Равил көрсенеп. — Әлфия белән ботка пешми безнең.

— Сизенеп йөрим инде мин аны. Нишлибез соң? Чыннан да, әллә кире Әлмәткә кайтасыңмы?

— Ул хакта сүз булуы да мөмкин түгел.

Әрәмәгә эңгер төште. Каяндыр җылы сөт исе, мал исе килгәндәй булды, күктә йолдызлар кабынды. Шулай да ике дус һаман да кайтып китә алмады — сүз Равил белән Әлфия мөнәсәбәте турында бара иде.

Тәмам салкынайтты. Губерт сәгатенә карады.

— Ярый, без сабыр итик, Рево. Барыр, бармый калмас. Мин дә әйтеп карармын, — диде ул, урыныннан торып.

Һы, әйтеп карармын, имеш, дип фикер йөртте Равил, автомобильнең йомшак утыргычында җай гына тирбәлгән хәлдә. Ир белән хатын арасын чит кеше рәтли алмый инде аны, Губерт дус. Бозарга мөмкин, ә менә җайга салу... Булсын бик зур начальник, алла үзе булсын, әмма ертыкны җөйсез генә берәү дә ямап куя алмый. Тәмам ертып җибәрсәләр дә, кеше сизмәслек итеп ябыштырып куйсалар да ир белән хатынның

үзләрендә. Габитны кайтарып җибәреп, бүген Әлмәттә калуы да шуның өчен иде ләбаса, җыйнаулап урманга чыгарга, яисә Зәй буена төшәргә иде исәбе. Кичке буйда кибетләрдә йөреп, Әлфиягә дә, кызларга да күңелләренә хуш килерлек бүләкләр алмакчы иде. Ничек кенә булмасын, семьясы белән адәмчә бер ял итү, якыннарының күнелен табу — шулай итеп чатный башлаган гаилә дигән савытны җыгытып кую иде уенда. Ә менә ни килеп чыкты: ярты көн һәм ярты төн буе кислота хакында сөйләшеп утырды. Тагын ни генә уйлап бетермәгәндер дисең Әлфияне!

8

Иртәнге аулакта Кайманов белән киңәшергә дип, идарәгә бер сәгать элдан килүенә карамастан, Васил белән күзгә-күз сөйләшә алмады Равил. Ул килгәндә әле начальник бүлмәсе буш иде. Хуҗа килгәнче дип, эшенә утырды. Кичә ул идарәнең техсовет утырышында кислота хакында доклад укыган иде. Трибунадан төшәргә өлгермәде, Артомонов ябышa калды. Идарәдә башлангыч партоешма секретаре бит.

— Кабатлау — гыйлемнең анкәсе, диләр бездә. Равил Вәлиевич, докладны үзебезнең коммунистларга да укырсыз инде.

Константиннан ансат кына котыла алмыйсың — шул докладны кыскартып, үзгәртеп маташуы.

Утыра торгач, байтак вакыт узган. Равил сискәнеп китте, ашыгып сәгатенә карады — сигез тулып килә иде. Кабаланып селектор трубкасын күтәрде, аппаратта секретарь кызның яңгыравык тавышы ишетелде:

— Тыңлыйм, Равил Вәлиевич. Хәерле иртә.

— Хәерле көн. Кайманов үзе генәме?

— Аның янында ниндидер чит кешеләр: журналистлармы, язучылармы шунда. Әллә инде артистлар тагы.

Равил җавап бирми генә трубканы куйды, урыныннан кубып тәрәзә янына килде, иртәнге салкынча һавада талгын гына чайкалып утырган чаган яфракларына карап, уйлана калды. Әллә нинди генә кеше бу Кайманов. Бер караганда үтә нәзакәтле, начарлыкның ни икәнен дә белми торган кешелекле кеше. Икенче карасаң, шикләнеп куясың — яңа битлеккә төренгән бюрократ, карьерист мәллә? Василнең сәер бер гадәте шундый шик-шөбһәгә урын калдыра иде. Эре предприятие җитәкчесе, эш дигәнең муеннан. Ә аның кабинетында, кайчан ,карама, нефть чыгаруга мөнәсәбәте булмаган кешеләр: бер керүендә журналистлар белән сөйләшеп утырса, икенчесендә — аның янында шәһәрнең һәвәскәр музыкантлары, җырчылары, дөньяда бүтән мәшәкать калмаган сыман, ниндидер җырлар, композиторлар турында гапләшеп утыралар. Инде ничә мәртәбә аның спортчылар белән гөрләшеп утырган чагына туры килде Равил: футбол, волейбол, хоккей, имеш. Тфү! Эш вакытында бит. Әллә соң сәнгатьне, спортны яратуы хакмы? Әллә бер-бер исәп белән элеккеге дворян-меценатлар ролен уйныймы? Алай булуы да ихтимал. Әлеге артистлар, спортчылар газеталарга язып, шәһәр күләмендәге җыелышларда сөйләп кенә торалар: «Иптәш Кайманов җитәкчелегендә...», «Иптәш Каймановның даими кайгыртуы нәтиҗәсендә...», «Иптәш Кайманов кушуы буенча...». Васил исеме төрле сфераларда телдән төшми. Хәзерге заман җитәкчесе өчен нәрсәсе начар моның? Һа, акылсыз түгел.

Равил тагын селектор трубкасын күтәрде:

— Чыкмадылармы?

— Чыктылар. Кабинетта иптәш Борһанов кына.

Аяк урынына тояк дигән уй үтте Равилнең башыннан. Юк, тояк кына түгел — чир, кизү. Бер дә эше юк микәнни соң бу Борһановның: көн

башлануга, Кайманов янына кереп утыра да, шуннан сәгатьләр буе чыкмый. Әллә сүз тыңлап утыра, әллә аңардан башка эш бармас, дип уйлый инде.

Профсоюзларның группа комитеты председателе итеп күптән түгел генә сайланган Мидхәт Борһановның ниндирәк кеше икәнен белеп бетерми әле Равил. Шулай да чамалый: бик сак, төрле конфликтлардан, бигрәк тә начальник белән сүзгә килүдән качарга тырыша бугай Мидхәт — киңәшмәләрдә күбрәк Кайманов сүзен җөпли, һич булмаса, дәшми кала. Бәлки ялгышадыр Равил, ләкин Борһанов турындагы шушы беренче тәэсирләре көннән-көн ныгый, тамыр җәя бара иде.

Футбол тубы сыман түгәрәк, житез бу кеше турында төрле сүзләр йөри идарәдә. Берәүләр аны тыйнак, үтә гадел, принципиаль кеше диләр, икенчеләре исә кирәгеннән артык йомшаклыкта, солдафонлыкта гаеплиләр.

Равилнең сабырлыгы төкәнде, кабинетының ишеген ачып, секретарь кызга эндәште:

— Ничек анда? — диде ул, Кайманов бүлмәсенә ымлап.

— Утыралар.

Юк, чама дигәнне белми икән бу Борһанов.

Ул килеп кергәндә, Васил, уң як терсәгенә таянып, яны белән өстәленә ятылаш ауган, Мидхәт исә стена буендагы утыргычлар рәтенә киерелеп утырган килеш, ни турындадыр акрын гына сөйләшәләр иде. Ишектә Равил күренүгә, Каймановның әйләнмәле креслосы хәрәкәткә килде, хуҗа үзе аягына басты.

— Менә үзе дә, — диде ул балкып. — Гомерле булырсыз әле, профсоюз алласы белән синең кичәге доклад турында фикер алышып утыра идек.

— Алайса барыбызның башында да бер исәп икән, — диде Равил һәм, начальнигының кәефенә яраклашырга тырышып, елмаеп куйды. — Әллә соң партия-профсоюз активын җыеп киңәшикме?!

— Што сез, хөрмәтле Равил Вәлиевич, син утыр әле, утыр... Што син, кислотаны күпләп кудыру уен түгел: әллә барып чыга, әллә юк әле ул. Шулай булгач, ашыгып чаң сукмыйк. Киңәшмәгә барлык цехлардан, димәк, нефть районнарыннан да вәкилләр чакырырга туры киләчәк. Әнә шундый аудитория алдында зурдан кубып, соңыннан көлкегә калсак, ә, иптәш баш инженер?! Шуннан инде цехларда ни уйларлар безнең хакта?

Өчәүләп тынып калдылар. Эшкә тотынмас борын мондый шик-шөбһәгә төшүне көтмәгән иде Равил, аптырап калды. Шулай да үзен тиз кулга алды. Бүген, менә хәзер тиешле җавапны бирмәгәндә, яңалыкның тамыр җәймәс борын сулып-коруы бар иде.

— Барып чыгамы, юкмы дип икеләнүнең булуы мөмкин түгел. — Равил кызып китте, галстугын бушатып, күлмәгенең өске сәдәфен ычкындырды. — Сүз фәкать бер юнәлештә барырга тиеш: эшне кайчан һәм ничек башлыйбыз? Җитәкчелекне кемгә тапшырабыз?

Кайманов бу мөһим эшнең нәкъ менә ул җитәкчелек итә торган идарәгә тапшырылуына шатланган, горурланган төсле күренсә дә, борчылу-шөбһәләнүен дә яшерә алмый, аны ерып чыкмаган тәкъдирдә, авторитетына тап төшәр дип шикләнә иде бугай, һаман да сак булу ягында:

— Ашыкмыйбызмы, Равил Вәлиевич? Ремонт планы да бик киеренке бит. Бәлки, берәр елга кичектерүне сораргадыр, ныгытып аякка басканчы диюем.

Моңа кадәр сүзгә кушылмый гына тыңлап утырган Борһанов идарә начальнигының тел төбен тиз төшенеп алды:

— Камытны кигәнче уйлап бетерәсе иде шул. Ни әйтсәң дә, күпме кешене, техниканы ремонт эшеннән аерырга туры киләчәк бит.

Тагы Васил арбасына утырмакчы, дигән уй үтте Равилнең башыннан һәм ул күзлеген Мидхәткә таба ялтыратып алды. Хәер, Борһановның кислота кудыру мәсьәләсендә икеләнүен, начальник сүзен җөпләү дип кенә карарга да ярамыйдыр, бәлки. Равил үзе дә ул хакта уйланды бит: яңалык кертәсе дип, берәү дә ташлама ясамаячак ич, скважиналар ремонтлау планы өзелә башласа, шул ук Губерт аяк терәп таләп итәчәк. Барын да исәпләде Равил: әнә шундый күңелсезлекләр килеп чыкканда, партия шәһәр комитеты бюросы каршына басачагын да, «портфеле» белән саубуллашу ихтималын да күз алдына китерде. Әмма бу-редән куркып урманга бармый тормыйлар бит. Яңалык гел шулай ул, ансат кына шытып, үсеп китми. Әйе, юлның кыены — башлап узучыга. Аның каравы башкалар ансатрак үтә аннан соң. Өстәвенә, берләшмәдә киңәшелгән, хәл ителгән бит инде мәсьәлә. Ничек инде кирегә сукалыйсың хәзер. Бу бит: «Без көчсез, җәмәгать, бездән булмый», — дию белән бер. Шуңа да Кайманов белән Борһановка икеле-микеле сөйләргә калдырмады Равил:

— Хәрбиләр әйтмешли, артта күпер шарлатылган, чигенү мөмкин түгел, — диде Василнең күзенә карап.

Үзенә бу кадәр кискен каршы килүләренә күнекмәгән иде Кайманов, күзләре ялтырап, бите кызарып чыкты, йөзеннән кара күләгә узды. Шулай да хисен йотты, ирен кырыйларына чытык елмаю чыкты.

— Баш белгечебез катгый карарга килгән икән, мин бик шат, — диде ул, ничектер тантаналырак итеп. — Ерып чыгабыз икән, барыбызга да әйбәт. Данылбыз бөтен Союзга гөрлиячәк, дигән сүз.

Равил исә үз бүлмәсенә чыккач та тынычлана алмады. Фатиха бирү ансат, тик менә ничек хәл итәргә мәсьәләне, әмәлен ничек табарга, кайсы очыннан тотынырга? Ул телефон зыңлавыннан сискәнеп китте, ашыгып трубканы алды. Аппаратта Артомонов тавышы иде:

— Равил Вәлиевич, Кантның һавада йөрергә чыгуына карап шәһәр халкы сәгатьләрен дөресли торган булган.

— Туктале, Костя, мәзәк тыңларга вакыт юк.

— Мәзәк түгел, иптәш Закиров, сүз төгәллек турында бара, — дип тәкърарлады трубкадагы бас. — Сәгать тугыз бит!

— Шуннан ни димәкче буласың?

— Шуннан шул, — дип ярылды тегесе, — тугызда киңәшмә дигән идегез ич.

Кичә шулай дип сөйләшенгән иде бугай шул, барлык бүлекләрнең җитәкчеләрен җыярга, һәркайсына тиешле күрсәтмәләр бирергә иде исәбе. Бөтенләй онытып җибәргән.

— Менә нәрсә, Костя, — диде ул, бераз паузадан соң, — к черту киңәшмәләр, «май, май» дип сөйләнүдән авыз майланмас. Эшләргә кирәк, вот шул. — Ул тагы нидер әйтмәкче булып, авызын ачкан иде, трубкадагы «пип-пип» дигән авазны ишетеп, тынып калды.

Тәк, геологлар бүген генә кисеп бер ни дә әйтә алмаслар. Аларның бурычы — беренче операция өчен скважина сайлауга гына кайтып калса да, бу эш иң четреклеләрнең берсе иде. Чөнки күкерт кислотасы, кайбер тау токымнары белән реакциягә кереп, гипс ясауга сәләтле икән. Орды-бәрде генә тотынып, скважинаның забой яны зонасын таштай катырып куюың бар.

Технологлар янына төшәргә дип урыныннан кузгалган иде, атылабәрелә бүлмәгә Самарин килеп керде. Теге беренче киңәшмәдән соң, баш инженер кабинетына һәрчак иң алдан кереп утыра торган булып китте ул. Керә дә, караңгы почмакка чума. Ул белә: киңәшмәләрдә сүз күбрәк производство турында бара, үзара кычкырыша-кычкырыша арып беткәч, хәвефсезлек мәсьәләсен я бөтенләй онытталар, я беркетмә өчен бер-ике сүз әйтү белән чикләнәләр. Шуңа да Самарин аларга әзерлән-

ми, еш кына керми дә калгалый иде. Бүген исә, сәхнәгә чыккан җырчыдай, ялгызы килеп капты.

— Я, ни җимертәсең? — диде Равил аның каршына басып.

Самарин күзләрен баш инженердан яшерде.

— Менә, Мидхәт Шәриповичка баян-балалайкалар алып кайттым әле, — диде аптырагач.

— Һәр эшсезгә ялчы булып йөрүдән кайчан туктыйсың син, Хәйри Хәйретдинович. Кислота кудыруга әзерлек турында сөйлә син миңа!

— Нәрсәсен сөйлисең инде аның. Безнең бүлек әзер, процесс бүген башланса да... Эш костюмнары, җылы сырмалар, күн һәм резин итекләр бар, плащлар да табарга була. — Самарин безгә чүп тә түгел ул дигәндәй, кулын селтәп, үзе шомартып бетергән урынга утырды, бик зур эштән котылган кешедәй җиңел сулап куйды. Баш инженерның чыгарга җыенганын күргәч, кабат аягына басты. Равил исә аңа карап уйланып калды. Алда торган хәвефле мәшәкать турында бар да шулай җиңел уйласа, ни була инде бу? Юк, Самаринны тыныч калдыру ярамый.

— Хәйри Хәйретдинович, — диде ул, ишекне ачып, — сез менә институтны күптән түгел генә тәмамлаган кеше. Күкерт кислотасы турында укырга, ишетергә туры килгәндер...

Кабул итү бүлмәсендә «пырх» итеп көлеп җибәрделәр. Киңәшмәгә килүчеләр башларын иеп, куллары белән йөзләрен каплаганнар да, шаркылдап җибәрүдән тыелып торалар иде. Равил ялгышуын абайлап алды. Хикмәт шунда иде, Самарин нефть институтының кичке бүлегендә ун ел укып, үткән ел гына диплом алу бәхетенә ирешкән белгеч. Идарәдә шул хакта төрле мәзәкләр йөри, сүз уңаенда Хәйринең үзенә төрттереп алулар да еш була иде. Равилнең сүзен хәвефсезлек бүлеге мөдиреннән көлү дип кабул иттеләр ахрысы. Ул хатасын төзәтергә ашыкты — бусаганы атлап чыкты да, барыннан битәр ачылып, иреннәрен җыеп ала алмый торган баш энергетикка ачулы караш ташлады һәм шул ук төксе тавыш белән сүзен дәвам итте:

— Көлке түгел, егетләр. Кислота үзе тәнгә тигәндә генә димим, аның парыннан ук тере күзәнәкләрнең зарарлануын беләсез. Димәк, һәркем беренче чиратта кешеләр иминлеге хакында кайгыртырга тиеш. Шулай булгач, хөрмәтле Хәйри Хәйретдинович, безгә бүгеннән үк махсус резина костюмнар, резина перчаткалар, киез итекләр өстеннән кию өчен галошлар табу турында уйларга кирәк. Соңгы вакытта матбугатта кислотага каршы торырлык пластмасса итекләр турында язалар — укыгансыздыр шәт. Аннан, процесс зур басым астында барачак — башка кию өчен каскалар кирәк дигән сүз. Ә инде саклык чаралары турында инструкция төзү мәсьәләсенә тукталып та тормыйм. Кайбер нәрсәләрне әнә Глухов язмасыннан алырга мөмкин. Күрәсең, Самарин, эш җитәрлек икән. Ә син иртәгә кудырырга җыенасың... Күрәм, баш энергетик та әзер.

Энергетик сораудан бик асат котылмакчы булды. Яшел Түбәдәге предприятиеләрнең берсе скважиналар ремонтлаганда территорияне һәм эш мәйданчыгын яктырту өчен махсус установкалар ясап чыгара башлаган икән. Яктылык тәэмин ителгән дигән сүз. Ләкин баш инженер аңардан тирәнрәк уйлаган икән.

— Ә элемтә, элемтә мәсьәләсе ничек? — диде ул, баш энергетикның яшьлек бөркеп торган йөзенә текәлеп.

— Гадәттәгечә рация инде, — диде тегесе, дулкынланып торган чәчен бармаклары белән тарап.

— Шулаен шулай, — Равил күзлеген салды да аны керләнгән кульяулыгына сөрткәли башлады. — Тик безгә Татарстанның төрле район-

нарында эшләргә туры киләчәк бит. Рациянең мөмкинлеге исә илле-алтмыш километр гына. Димәк, арадаш рация хакында уйларга туры килә. Монысы бер булса, икенчесе — процесс вакытында эшчеләрнең үзара элемтәсе мәсьәләсе. Анда дистәләгән агрегат гөрләп торачак. Гади рупор, мегофон гына коткарырмы безне. Бәлки, танкистлар элемтәсен үрнәк итеп алыргадыр?

Баш инженер чыкканчы, кабул итү бүлмәсендә таптанып, шаярып көлеп торган инженерлар, эшнең уен-муен түгеллеген чамалап, тынып калдылар. Равил дә аягүрә генә вәгазь укуына уңайсызланып, сүзен очларга ашыкты:

— Алда торган мәшәкатьтән барыбызга да өлеш чыга, егетләр: механикларга да, тәэминатчыларга да, автотранспортчыларга да. Кызлар да читтә калмый, — Равил түр буйда җыелышып торган хатын-кызларга таба борылды. — План-экономика, хезмәтне оештыру һәм аңа түләү бүлекләренә дә эш җитәрлек. Кислотаны ерак җирләрдән ташу, бу эштә катнашучыларны материаль кызыксындыру мәсьәләләре дә мөһимнәрдән. Барыгыз, уйлагыз. Әйбәт, якты фикерләр туу белән миңа хәбәр итегез.

Ул, инженерларның таралуын да көтмичә, астагы катка — технологлар янына төшеп китте.

Ишектә баш инженер күренүгә, Артомонов авыр гәүдәсе белән чайкалып басты, ләкин бер сүз дә әйтмәде. Равил дә, дәшми-тынмый гына түргә узып, өстәл янындагы урындыкка утырды.

— Ничек, Костя, булдыра алырбызмы?

Ни турыда сүз барганын сорап тормады Константин, баш инженерның бу арада кислота белән җенләнеп йөргәнен белә иде ул.

— Сез менә, Равил Вәлиевич, булдыра алырбызмы, дисез, — дип башлады ул салмак кына. — Ә бит Рудольф Дизель узган гасырда ук: «Инженер эшләмәгән нәрсә юк», — дигән. Без исә идарәдә генә күпме инженер утырабыз, цехларда тагы... Һәр бүлеккә конкрет задание бирергә кирәктер, мөгаен. Тик, минемчә, иң элек кислота кудыруның технологик схемасын эшлисе бар. Ышанып тапшырсагыз, безнең бүлек схеманы эшләүгә алыныр иде.

— Рәхмәт, Костя, схема эшләү бүлеккә йөкләтелде, дип сана. Үзем мин аны менә болайрак күз алдына китерәм...

Киңәшеп, бәхәсләшеп күпме утырганнардыр, Артомонов яныннан чыккач, шактый арганын тоеп алды Равил. Иртән уйлаганча, Әлмәткә — семьясы янына гына китеп барасы иде дә бит, һаман эчен бер нәрсә тырнап тора, бая киңәшмәгә дип килүчеләр арасында нишләптер тәэминат бүлеге начальнигы Кавиев күренмәде. Баш инженерны санламавымы, әллә өйдә юкмы? Равил түбәнге катның аргы башына — тәэминатчылар ягына атлады.

Кара дерматин белән тышланган ишекне ачып, кечкенә генә бүлмәгә килеп керде Равил. Монда берәү дә юк, шулай да бер-беренә терәп үк куелган дүрт-биш өстәл аны тагын да кысан итеп күрсәтә иде. Бик тыгында интегәләр икән егетләр. Авыр драп пәрдә белән капланган эчке ишеккә узды, шакымый-нитми генә ачып җибәрде һәм кадакланган дай туктап калды. Аның алдында бөтен җиһазлары белән ремонт бригадасы кереп урнашырлык зур бүлмә иде. Анысы бер хәл, мондагы җиһазны әйт тагын: бусагадан түргә кадәр затлы келәмнән юл, аңа аркылы итеп зур көрән өстәл куелган. Биш-алты телефон аппараты сыйдырган махсус урын, тагын әллә нәрсәләр. Өстәл артында бик затлы йомшак кресло, ләкин ул буш иде. Равил уңга борылды: түр буй почмакны тутырып төсле телевизор тора, аның янәшәсендә кирәк булганда карават итеп җәйлашлы зур кәнәфи, стена буйлап йомшак утыр-

ғычлар тезелгән, алар өстендә, бөтен стенаны алган купшы рамда, Шишкинның мәгълүм нарат урманы. Равил, качып-посып кына чиркәүгә кергән малайдай ничектер бөрешеп, сулга карады. Иң элек күзенә икесе ике тумбочка өстенә куелган радиола белән магнитофон ташланды. Соңгысы өстендәге транзисторлы нәфис радиоалгычтан тагын булып музыка агыла. Биредәрәк ике ягыннан ике кресло кысып торган җыйнак кына журнал өстәле, аның өстендәге вазада печенье-конфетише тәм-том, алар кырыендагы бәләкәй генә электр самаварыннан пар бөркелеп тора. Шул яктагы зур-зур өч тәрәзәгә Равил исемнәрен дә белми торган затлы материалдан пәрдәләр асылган. Алар шундый мул, опера театры сәхнәсен хәтерләтеп тора. Ишек артындагы тәрәзә буенда гөлләргә су сибеп торучы Кавиевны шунда гына күреп алды Равил.

Кавиев, кабинетына рөхсәт белән генә керүләренә гадәтләнгән кеше, ишек тавышын ишетсә дә, борылып карамады. Шакымый-нитми генә керә икән, ул инде җыештыручы Җамал апа. Ничә әйтте шул томана хатынга, минем бүлмәдә әллә кемнәр, алла үзе дә булуы мөмкин, рөхсәтсез кереп йөрмә, диде. Әллә оныта, әллә юри шулай итә — мебельнең тузанын сөртергә дип, туп итеп килә дә керә.

— Син тагы шакымый-нитми, ә? — Кавиев артына борылды һәм елмаеп торган баш инженерны күреп кызарды. — Гафу итегез, мин техничка дип торам... Узыгыз, утырыгыз. Традиция буенча, кадерле кунакка һинд чәе бездә. — Ул шулай сөйләнә-сөйләнә, бәләкәй өстәл янына килде, чәй ясарга тотынды.

Нефть районнарында ничә еллар эшләп, зур-зур начальниклар кабинетында да бу кадәр зиннәтне күргәне юк иде Равилнең. Гаҗәпләнде, ләкин бүлмә хуҗаына сиздермәде. Креслоларның берсен читкәрәк тартып утырды һәм астан гына Кавиевка карап алды. Хуҗа үзе дә кабинетына иш икән. Мәһабәт гәүдәсендә чем-кара костюм, хәзер генә тегүче кулыннан алып кигәндәй. Күз явын алырлык ак күлмәк, муенында әллә Эйфель манарасы, әллә башка бер әкәмәт сурәт төшерелгән чуар галстук. Артка кайтарып салган куе кара чәче, пөхтә итеп кырылган яңаклары аңа дипломатлар кыяфәте бирә иде.

Беравык сүзсез утырдылар. Кавиевның сәүдә, алыш-биреш эшендә азау ярган кеше икәнен ишеткән иде Равил. Сөйләүләренә караганда, ул эзләгән нәрсәсен тапмый калмый, әмма эшне зурдан йөртә. Алдына Кавиев куйган чәйне бер йотты да, Равил сүз башлады:

— Булитлар кирәк, Кавиев.

Тегесе бер мизгел уйланып торды да чәйгә үрелде.

— Ни белән ашыйлар соң ул «булит» дигән нәрсәне?

— Ничек аңлатырга сиңа?— Равил кесәсеннән куен дәфтәре, каләм алды, чиста битләрнең берсен ачып, рәсем ясый башлады. — Менә шушындый зур кыярга охшаган озын тәбәнәк чаннар. Тик теләсә нинди түгел. Корычның сыйфатын күрсәткән сертификат бирермен мин сиңа.

— Ничәү кирәк инде?

— Башлап җибәрү өчен һич югы өч-дүрт.

— Ха-ха-ха, — Кавиевның күзләреннән яшь чыкты хәтта. — Иллеалтмыш диегез ичмасам.

— Ничә булса да булыр, тиз кирәк. Аңладыңмы?

Кавиев дәшмәде, тәмләп кенә чәен эчеп бетерде, киерелеп утырды.

— Өр-яңа анекдот, иптәш Закиров. Бер хатын...

Равил креслосын дөбердәтеп урыныннан кузгалды.

— Башка чакны, эш беткәч, Кавиев, — диде дә, ашыгып бүлмәдән чыкты, йөгереп диярлек коридорны үтте һәм машинасына таба китеп барды.

Кайтуына бикле ишек каршылады Равилне. Ачып керүгә, гаҗәпкә калды: кием-салымнар туздырып ташланган, өй үлек чыккан йортка охшап калган иде. Бу хәлне нәрсәгә юрарга белми торганда, кухня өстәлендә газета почмагына язылган язуга тап булды: «Безне эзләмә — без Мәскәүдә». Кара эчле булса да булыр икән кеше. Юньләп язып калдырса, яисә шалтыратып әйтсә ни булыр иде. Инде әниләре тешләклә нә икән, кызлар шалтыратырга тиеш иде ләбаса! Ах, әйе, кичә кырда — скважиналарда иде бит ул. Равилнең йөрәге кысып куйды. Ниндидер серле, күңелне хафага сала торган хәл иде бу.

Ул, ябылудагы киек җәнлек сыман, өч бүлмәне бер итеп йөрергә тотынды, әлеге табышмакка җавап эзләде. Ләкин өйдәге бөтен нәрсә өнсез, Равилнең болай да каткан башын гаҗизләндереп, төрлесе төрле яры таралып ята иде. Һич югы кырынып алырга исәпләп, өстәл тартмасын ачты һәм пәке өстендә кәгазь кисәген күреп алды. Тыгыз итеп түбәндәге сүзләр язылган иде анда: «Әтием, Тарабриннар үзләренең машиналарында Мәскәүгә баралар. Әнием шулар белән сөйләште. Китәбез, сынауларга шунда әзерләнәбез. Сине үбеп: Фәридә—Лениза». Кисәк бик нык арганын тоеп, тәрәзә буендагы креслога чүкте Равил.

Боегып, фани дөньядан ваз кичеп күпме утыргандыр, кинәт аңына килеп, урыныннан кузгалды, ишекле-түрле йөренә башлады. Юк, болай мәлҗерәп төшәргә ярамый, нидер эшләргә кирәк. Хәзер үк шалтыратып, Мәскәү белән сөйләшергәдер, мөгаен. Ул, кабаланып, кесәсеннән куен дәфтәрен чыгарды, Сафагәрәевләрнең телефон номерын эзләп тапты һәм трюмо өстәлендәге аппаратның трубкасын күтәрде. Гаҗәп, анда «шылт» иткән аваз да ишетелми иде. Өзгәннәр, дигән уй үтте башыннан. Бу хәл тагын кәефен бозып җибәрде, кайчандыр гөрләп, күңелне тартып торган квартирасы ташландык бер мазар булып тоелды аңа.

Ярсуын баса алмый йөренә торгач, бераз тынычланды, сигарет кабызды һәм трюмо каршына килеп басты. Көзге пыяласыннан аңа боек чырайлы, яңа гына әнисе кыйнаган малайныкыдай салынкы иренле кеше карап тора иде. Кыяфәтен юньләп карарга өлгермәде, көзге пыяласы беркетелгән фанера арасына кыстырылган зәңгәр конвертны күреп алды. Равил конвертның читен ертып ачты. Һәм каты кәгазьдәге таныш эре хәрефләргә текәлде. Әлфия кулы! Юкка өзгәләнгән, юкка тиргәгән икән хатынын — менә ич язып калдырганы. Ул җиңел сулап куйды, җайлап утырды да, хаттагы сүзләргә йотлыгып күз салды:

«Ниночка!»

Равил, үз күзләренә ышанмыйча, кәгазьне күзлегенә якынрак китерде, хат башын тагы бер кабатлады: «Ниночка!» Ул корт чаккандай кабаланып, хатның конвертын эзли башлады, аны кресло артыннан табып алды. Хат чыннан да Куйбышевта яшәүче ниндидер Нина Кравцовага адресланган иде. Почта ящигына салырга онытка курәсең Әлфия. Их, юкка гына ашыгып ертты. Хәер, башка конвертка салып җибәрергә дә мөмкин ич. Тик ачкан инде, укып чыгарга кирәк, дәшмитынмый гына юкка чыгуының сере шундадыр, бәлки. Ул тагын хатка иелде, дөньясын онытып укырга кереште:

*«Ниночка!*

*Хәтереңдәме, җаным, мин Равилгә тормышка чыгып, без ир белән хатын булып яши башлагач, син еш кына: «Көнләшәм бәхетеңнән, Алевтина!» — дия торган идең. Яшермим, үзем дә чын бәхеткә ирештем, дип уйлый идем башта. Ни әйтсәң дә, Равил төскә-биткә күркәм генә, акыл-фигыль ягыннан да төшеп калганнардан түгел, белемле, кеше арасында абруе бар...*

Менә сиңа ачыш! Кичә үлгән булсам, Әлфиянең мине мактавын белми дөньядан китеп барачак икәнмен.

*...Гайбәтенә кирә алмыйм, ул минем өчен кулыннан килгәннең барын да эшләде: авыр күтәртмәде, йорт эшләре белән күммәде, акчага, кием-салымга интектермәде. Юмарт, мәрхәмәтле, кешелекле булды Равил: тиеннәр санап бәгыремне телгәләмәде, көнләшеп аптыратмады, башка хатыннар артыннан сөйрәлмәде, эчеп тәмсезләнмәде. Бер уйлаганда, шуннан да яхшы кешенең булуы мөмкин түгел, идеаль ир эталоны инде, тот та музейга куй!..»*

Әүлия икәнмен ләбаса. Ничек белми йөргәнмен моңа кадәр. Ә шаяртмый фикер йөрткәндә, барын да дөрес язган, «Бозау» диярга генә оныткан.

*Шулай да аның белән уздырган гомерем кызганыч миңа.*

Менә сиңа мә! Менә сиңа иске авыздан яңа сүз!

*Шушы яшемә җитеп, мин үземне ир белән яшәдем, дип әйтә алмыйм. Җанлы ир булудан бигрәк, акыллы бер механизм, робот иде ул...*

«Иде?» Туктале, мине күмгән булып чыга түгелме соң бу?

*Танышкан көннән башлап бүгенгә кадәр мин аңардан: «Яратам», дигән сүз ишетмәдем, назлану-сөелүнең ни икәнен белмәдем...*

Соң яратуны тел белән генә әйтеп аңлаталар микәнни? Чын сөю һәр мизгелдә, һәр хәрәкәттә күренеп тора ич ул.

*Ул мине сагышлы чагымда назламады, кәефем югында иркәләмәде, күңелем тулганда юатмады, кайгым булганда уртаклашмады — гомумән, гомерем буе назга, иркәләүгә, татлы сүзгә мохтаҗ булып яшәдем мин...*

Кара син, чыннан да шулай бугай бит, әй...

*Күңелендә сөю, наз бөтенләй булмаган дип әйтә алмыйм анысы. Булгандыр. Ләкин ул аларның барын да тимер-машиналарга, майга каткан нефтьчеләренә өләште, миңа тамчысын да калдырмады...*

Калды ла инде, Әлфия. Әле хәзер дә житәрлек ул, күңел читлегеннән чыгарып, ирек куйсаң, ялкынланып китәрлек. Буш өйгә кайтып кергәннән бирле, юкка гына чәнчи дисең мени бу йөрәкне?

*Менә шул хәл бәгыремне ташка әйләндерде, Ниночка. Дөрес, үзем мин аңа һәрчак игътибарлы, тасма телле, юмакай булырга тырыштым, шуны күреп-тоеп үзгәрмәсме, дидем. Әчемдәген тышка чыгармадым. Ә йөрәгемдәге боз тавы һаман үсә барды, инде килеп, бөтен җанымны туңдырды...*

Шулай ук булды мыни соң, Әлфия? Кайгырма, бергә булсак, эретеп, парга әйләндереп бетерәчәкбез ул бозны.

*Күңелсез язмышым белән килешкән идем инде мин. Нигә дисәң, балалар бар, кеше сүзе бар, әхлак-мораль дигән нәрсә бар, ниһаять. Тик чыгырыннан чыккач, әнә шул тыюлар да авызлыклый алмый икән йөрәкне. Ул үзенекен дәгъвалап тыпырчына, ярсый, дуамалланa. Алай да түздем, уртак оя хакына, уртак байлыгыбыз — балалар хакына дип чыдадым. Тормышыбыз һаман шулай бер җайга барса, тагы да түзәр, әчемдәген кабергә кадәр берәүгә дә сиздермәгән булыр идем, бәлки.*

*Аның Яшел Түбәгә эшкә китүе сабыр савытын ташытып чыгаручы соңгы тамчы булды. Инде китәм. Әчемдәге таудай сагышымны, салкын айсбергымны алып, яшьлек эзләремә кайтам. Ул чактагы сукмакларның берсен — үзем иң күп узганын үлән каплап бетермәгән төсле. Соң булса да, бәлки, башка берәр юлга чыгарыр ул мине.*

Туктале, нинди яшьлек эзләре, нинди сукмак, нинди юл ул? Тел төбендә нәрсә моның? Әллә...

*Менә шулай, дустым. Инде мин синең тормыштан, Сережа белән икегезнең бәхетегездән көнләшәм. Дөресрәге, күптән көнләшә идем.*

*Коры көнчелекнең берни бирмәвен дә аңладым. Шуңа да кул кушырып утырмаска булдым. Бу минем Әлмәттән соңгы хәбәрем сиңа, хатларыңны безнең Мәскәү адресына сал.*

*Каты итеп үбәм: Әлфия».*

Кисәк йөрәге сулкылдап, бик каты чәнчеп куйды Равилнең. Бу хатка ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Үпкә-ачулары ирена килеп ирешсен дип, аның да йөрәге телгәләнсен дип, ниндидер Нинага юри язып калдырганмы? Булмас, эчен бушатырга уйласа, Равилнең үзенә адреслап калдырыр иде ләбаса. Алайса нигә почта ящигына салмаган? Онытканмы?

Уй ташкыныннан башы катты Равилнең. Бүген монда калып йоклау турында уйлыйсы да юк. Бу өй инде аңа кеше аяк басмаган салкын бер планета булып тоела башлады. Почтага барып Мәскәүгә шалтыратса, Әлфиясенең тавышын гына ишетсә дә, бераз тынычланыр, күңелендәге давыл басылыр сыман булды. Шул исәп белән урамга чыкты, элемтә үзәге урнашкан мәйданга борылды. Барып җиттем дигәндә, эчендәге теге шайтан тагын баш калкытты. Шул үҗәтлеге аның юлын үзгәртеп, автовокзалга таба алып китте. Тагы бер сәгатьтән ул инде автобуста Яшел Түбәгә таба бара иде.

## 10

Кичтәнге акыл иртәнгә ярамый. Теге көнне, сәгать ярым буе селкенеп автобуста кайтканда: Әлфия янына кичекмәстән Мәскәүгә барырга, берни яшерми-нитми, тартынмый-тайчанмый, ачыктан-ачык сөйләшергә, бата башлаган гаилә корабын саклап калырга дип уйлаган иде Равил. Ул көннән бирле инде ничә тәүлек үтте, тик барып кайтумы соң, хатынына шалтырата да алмады. Вакыты булмады түгел, тели икән эш арасында кабинетыннан да сөйләшә алыр иде. Шулай дип берничә тапкыр талпынып та куйды. Әмма соңгы чиктә генә, эчендә ниндидер җен кузгалып, теләгән ахырына кадәр башкарып чыгудан тыеп тора иде. Аннан эше дә бик куерып китте бу арада, кислота кудыруга әзерлек мәшәкате арткан-артып, тәмам шәһәргә кайтып кермәс булды.

Технологик схема нинди генә камил, даһиларча хәл кылынмасын, эшне башлап җибәрү өчен иң элек тимер чаннар, нефтьчеләр теле белән әйткәндә, булитлар кирәк иде. Теге көнне Кавиевнын һаваланауына караганда, алар ансат кына табылыр төсле тоелган иде. Шуңа да Равил ул мәсьәләгә әллә ни әһәмият бирмәде, эшне тәэминатчыларга тапшырды да, тынычланды. Тегеләр исә анда барып төртелгәннәр, монда килеп сугылганнар, ләкин булитларның эзенә төшә алмаганнар. Һаман да нәтиҗә күренмәгәч, Равил бүлек начальнигын кабинетына чакырды.

— Синең бер мәкаль ишеткәнең бармы икән, Кавиев? — дип каршылады ул баш тәэминатчыны.

— Нинди мәкаль икән ул? — Кавиев мескен генә булып, утырырга да утырмаска да белми ишек катында басып калды.

— Сугалмаган зур күтәрә, диләр. Менә синең кебекләргә әйтәләр инде аны. Соң, кулыңнан пычагым да килми икән, һич югы мактанмаска иде. Булмый иптәш Закиров, җибегән мин диясең калган. Минем эш зиннәтле бүлмәдә бөртек чәй белән кунаклар сыйлау, диярләр булмаса.

Кавиевнын, чыннан да, булитлар хакында үзе эш йөрткәне юк иде әле, һаман ярдәмчеләрен куды. Гаебе булгач, дәшмәде, баскан җирендә башын иеп тора бирде. Равил исә инде тәмам кызган, өстәл артыннан чыгып, Кавиев каршына баскан, очып өстенә кунар чиккә җиткән иде.

— Бар, тап, йөрмә селкетеп. Өч көн срок сиңа!

Баш инженер белән аулакта йөзгә-йөз сөйләшүнең ни икәнен бел-

милəр иде əле идарəдə. Шулай итеп, беренче мəртəбə Кавиевка татырга туры килде аны. Закировка ни өчен «Кислота» кушаматы яреп килгəнен шуннан соң аңлады. Ярсыган чагында, чыннан да, бик хəтəргə əйлəнə иде шул Равил.

Кабинеттан янып-кызарып чыкты Кавиев, гарьлəнде, кичкə кадəр зиһенен җыя алмый йөрде. Аннан бар осталыгын эшкə җигеп булитлар эзлəргə тотынды: таныш тəэминатчыларын берəм-берəм ресторанга чакырды, дефицит товарлар вəгъдə итеп кызыктырды, тирə-як шəһəрлəрне айкады. Булдырмады түгел, тапты булитларны Кавиев, тик аларның берсе-дə максатка яраклы булып чыкмады: я стенасы нечкə, я корычның сыйфаты шəп түгел. Шул кадəр изаланып та нəтиҗə чыгара алмагач, Закиров янына үзе керде, тагын да яманрак сүзлəр көтте. Тик кычкырмады, янамады бу юлы баш инженер, ялынып, йөрəге белəн сорады гына:

— Үтенеп сорыйм: тап əмəлен, Кавиев, сине бит бу якларның иң зирəк сəүдəгəре, дилəр.

Кавиев ташкүмер кисəге кебек җете кара күзлəрен тутырып Равилгə карады, аннан карашын идəнгə төбəде дə, үз алдына сөйлəнгəндəй итеп тезеп китте:

— Келəм дигез — телəсə ни зурлыктагысын, кара икра, дигез, ниһаять, күгəрчен сөте, дигез — барын да табам. Тик бу булит дигəн нəрсə белəн генə аптыратмагыз.

Бу эшнең чын-чынлап бер афəт булуын шуннан соң гына аңлады Равил һəм шул көнне үк, машинасына утырып, Яшел Түбəдəн чыгып китте. Атна дигəндə бөтен нефть районнарын айкап кайтты. Шулай да эзлəгəнен таба алмады, тəмам аптырагач, берлəшмəгə килде. Башына нинди генə бəла төшкəндə дə моң-зар чəчəргə, зарланырга яратмый иде Равил. Бу юлы гадəтенə хыянəт итте, Губертка бар зарын селкеп чəчте. Тегесе исə ахырына кадəр тыңлап та тормады:

— Нигə башта ук миңа килмəдегез? — дип бүлдерде.

— Юк-бар белəн борчыйсым килмəде, — диде Равил никтер кызарып.

— Юк-бар, имеш, — Губерт, урыныннан кубып, бүлмəсен урап килде, аннан сабакташы каршына басып, күптəн таныш күзлəргə текəлде. — Менə нəрсə, Рево, булитлар мəшəкатен миңа калдыр. Үзең икенче көнгə Мəскəүгə барып кайт: ял ит, Əлфия белəн иплəп сөйлəш, болай ярамый, — диде.

Нəрсəдəн чыгып əйткəндер ул бу сүзлəрне — төбенə төтен салып тормады Равил. Җитмəсə, шул мизгелдə Губертны берлəшмə директоры чакырып алды. Ни генə булмасын, аның тел төбендə генə түгел, йөзендə үк нидидер шом бар сыман. Əлфия хат язып җибəргəнме, əллə болай гына борчыламы Губерт?

Икенче көнне кабинетын ачып керүе булды — берлəшмəдəн Губерт шалтыратты. Газ эшкəртү заводында искерəк булса да булитлар бар икəн. Шуларны карап кайту өчен кеше җибəрергə кушты. Равилгə хəерле юл телəде дə, трубкасын элде. Шуннан беравык уйланып утырды Равил, аннары Артомонов белəн баш механикны чакырып заводка озатмакчы булды. Инде телефон номерын җыйгач, трубканы кире куйды. Юк, бу эшне берəүгə дə ышандыра алмый иде ул.

Əле шуннан кайтып килеше Равилнең. Көнозын шул хакта ыгы-зыгы килеп йөрүенə карамастан, күңеле күтəренке, кəефе шəп аның. Ниһаять, күптəн эзлəгəн нəрсə табылды. Дөрес, аларны əле кайтарасы, янсə турыдан-туры процесс булачак скважинага илтəсе, парлыйсы, чистартасы, кислота кудыруда яраклы итеп җиһазлыйсы бар. Хəер, болары инде үзлəреннəн тора, каядыр барып, кемнəргəдер ялынып йөрисе түгел. Тик менə технологик схеманың өлгереп җитмəве генə...

Кабул итү бүлмәсенә килеп керүгә, кабинетында сузып-сузып телефон шалтыраганын ишетте.

— Равил Вәлиевич, Фарадей турында укыганыгыз бармы сезнең?

Сүз иясенең Артомонов икәнен белеп алгач, Равилнең йөзенә елмаю чыкты. Нарасыйдай кече күңелле, беркатлы Константинга ачулы дәшә алмый иде ул. Шуңа да шаяртыбрак сөйләшергә тырышты:

— Ни булган ул Фарадей дигән бәндәгә?

— Бик тә хәтерсез, таркау булган ул «физиклар патшасы», — дип сөйләвендә булды Константин,— хәтта еш кына үз исемен хәтеренә төшерә алмый интеккән.

— Шуннан?

— Шуннан шул. Сез Фарадей, без Прометей түгел. Ачтан үләбез ич.

Эшнең нәрсәдә икәнен шунда гына төшенеп алды Равил һәм шаркылдап көлеп җибәрде.

— Гафу ит, Костя, — диде, аннан, кинәт җитдиләнеп һәм трубканы куеп, түбәнге катка йөгерде.

Технологик схеманы эшләп бетерү өчен Ильсур белән Константинга бер атна вакыт биргән иде Равил. Билгеләнгән вакыт үтте, егетләр исә схеманың очына чыга алмадылар. Көндезләрен технология бүлегенә кереп-чыгып йөрүче өзелми, кичләрен күпме генә эшләргә була. Шуннан инженерларны иртән иртүк бүлмәләренә биклəп куя торган булды Равил. Башка көннәрне, анда-монда киткәндә, ачкычны секретарьга калдыра торган иде, бүген бөтенләй исеннән чыгарган.

Механика, гидравлика кебек фәннәргә тешләре үткән егетләрнең башлары тәрәзәдән чыгып йөрергә генә җиткән икән. Ашаганнар да, эчкәннәр дә. Баш инженерны технологик схема белән танышырга дип чакырулары булып чыкты.

— Үзебезчә тәмамлагандай иттек, Равил Вәлиевич, — дип каршылады аны Артомонов.— Тик әлегә каралама хәлендә.

— Менә монысы инде күңелле хәбәр, — диде Равил, кулларын угалап һәм онытылып ватман кәгазе өстенә иелде.— Ну-ка, ну-ка, ни майтардыгыз икән?

Ул сызымга текәлде. Шул хәлендә, «так-так» дия-дия байтак утырды. Бераздан авыр сулап куйды, арган күзләрен Артомоновка төбәде.

— Принципта сүз әйтерлек түгел төсле. Иң шәбе — системаның ябык, герметик булуы. Иминлек мәсьәләсен беренче планга куеп дөрес эшләгәнсез. Ләкин катлаулы, бик катлаулы килеп чыккан. Аякны юрганга карабрак сузарга кирәк иде. Аннан соң...

Фикерен әйтеп бетерергә бирмичә, Константин дөбердәтеп урыныдын этеп җибәрде, чайкала-чайкала аягына басты.

— Бу карашың белән килешмим, Равил Вәлиевич. Без инженерлар һәм һәммә нәрсәне белгечләрчә хәл итәргә тиеш. Мөмкинлек мәсьәләсенә килгәндә, кем әйтер безне хәерче диеп. Материал ягы кыенрак кыенрагын, әмма табып булмый, димәс идем. Христос булгач, тәре баганасына кадакланмый мөмкин түгел. Аннан килеп, тау-техника инспекциясендә раслатасы барын да онытырга ярамый.

— Кызма, Костя, утыр, — диде Равил дустанә елмаеп.— Ярый, ышандырдың. Шулай да гадиләштерергә туры килер. Ә менә кислота җибәрү алдыннан һәм аның артыннан кудыру өчен су кулланырга җыенуың монысы инде, гафу ит, инженерларча түгел. Күкерт кислотасы су белән кушылганда ни буласын онытып җибәргәнсең. Бер-беренә дошман бу ике сыеклык нефтьле катламда гына очрашырга тиеш. Димәк, суны башка сыеклык, әйтик, солярка белән алыштырсак? Аннан компрессорларны да башкачарак тоташтырырга кирәктер, минемчә. Әйтик, менә монда...— Ул, кулына карандаш алып, сызымга төзәтмә кертә башлады. Егетләр дә аның белән килешкәләр бугай, өстәлгә якынрак елышып, сызым өстенә иелделәр.

Шул рәвешчә ничә сәгать узгандыр, тәмам йончып, тәмәке төтененә тончыга башлагач кына урыныннан кузгалды Равил.

— Ярый, чистага төшергәч, җыйнаулап тагы бер карап чыгарбыз. Ә хәзер... — Ул, күлмәк җиңен кайтарып, сәгатенә карады. — Уһу, ун тулып килә.

Өстенә киенергә дип, кабинетына менгәч, телефоны баягыча таләпчән шалтырый башлады. Кабаланып трубкага үрелде, шомлана-шикләнә аны колагына китерде.

— Мин тыңлыйм, — диде дулкынланып.

— Әтием, кайтасыңмы инде?! — аппаратта Ләниза тавышы иде.

— Ләниза, синме бу?!

— Мин, әтием.

— Каян шалтыратасың болай?

— Өйдән.

— Ничек өйдән? — Равил шөбһәләнә төште, маңгаена тир бәреп чыкты. — Әлмәттәнме?

— Биредә мин — Яшел Түбәдә.

Равил тәмам аптырап:

— Ярый, хәзер кайтып җитәм, — диде.

Шәһәр белән контора арасын әллә атлап, әллә йөгереп узды. Ләниза аны урам чатында көтә иде. Кыяфәтенә караганда чирләп-нитеп киткәнгә охшамый. Равил аны кулыннан алды, йөзенә текәлде.

— Ни булды? Кайсы фәндә абындың?

— Абынмадым, әтием. Математиканы «биш»кә бирдем, — диде ул, тыныч тавыш белән. — Башкаларын да җиңеп чыга идем.

— Шулай булгач... Фу-у, берни аңламыйм, — Равил кулъяулыгы белән битен, маңгаен сөртеп алды.

— Әни бит... — Ләниза сулкылдап куйды, йөзен читкә борды. — Институтка иярә дә килә... Җитмәсә, имтихан биргәндә аудиториягә кереп утыра.

— Утырса, утыра бирсен.

— Утырып кына тормый шул. Укытучы янына килә дә: «Министерстводан Сафагәрәев кызы», — ди. Ә миңа иптәшләрдән оят. Физикадан билетны ташлап чыгып киттем.

«Әтисенең кызы», — дип уйлап алды Равил. Үзе дә түзеп тормас иде андый хәлдән. Тик беткә ачу итеп, тунны утка ташлау кебегрәк булып чыга түгелме соң бу?

— Инде нишләргә уйлыйсың?

— Эшкә керәм. Яшел Түбәдә минем көч җитәрлек берәр эш табылмый калмас әле.

— Ярый, анысы турында соңыннан сөйләшербез, — диде Равил, тәмам тынычлап. — Ресторан ябылганчы, тамак ялгап алыйк әйдә. Фәридә ничек анда?

— Фәридә үтәчәк, гел «отлично»га биреп бара, — диде кыз әтисе белән янәшә атлап.

— Әниең ни хәлдә соң?

Ләниза авыр сулап куйды, ачык ишектән эчкә узды. •

— Әни квартира ордеры артыннан йөри, — Ләниза күзләрен әтисеннән яшерергә тырышып, келәм җәйгән киң баскычтан өскә атлады. — Әлмәткә бүтән кайтмыйбыз, ди ул.

Шуннан сүзсез калдылар. Өстәл артында Ләниза бу сүзләрне әтисенә әйтүенә үкенеп утырды, Равилнең башында исә мең төрле исәп иде. Теге көнге шик-шөбһәләре калкып чыкты. Алай... Соң Яшел Түбәгә күчәсе килми икән, күчмәсен, яши бирсен Әлмәттә. Үзе кайтып йөрер иде Равил. Сирәк-мирәк ялгызы куна икән, күтәреп китмәсләр иде әле. Яшиләр бит кешеләр шулай аерым-суырым. Әти-әнисе янында яшисе килүме бу, әллә чыннан да башкала тартамы күңелен? Туктале, нишләп

һаман Әлфияне генә гаепли соң әле ул? Хатын-кыз хатын-кыз инде. Назланырга, бераз гына ялындырырга ярата торган халык. Үзең соң ир башың белән семьяны саклау өчен ни кырдың? Бармак та селкетмәдең бит, көйсез кияү шикелле турсаеп йөрүдән узмадың. Эш дигән булдың, вакыт җитмәүгә сылтадың...

Ашы аш булмады Равилнең. Башына аллы-артлы килеп торган четрекле сорауларына уралып, алдындагы нигъмәтләрне эткәләп-төрткәләп утырды да, моңаеп калган Ленизага:

— Киттек, кызым, — диде.

## 11

Бөтен өстәлен тутырып яткан сызым өстенә иелеп күпме утыргандыр, Равил аркасының тактадай катып китүен, җилкәләренең авыртуын тоеп, башын күтәрде, озак итеп, тәмләп киерелде. Тәрәзәне ачып җибәрим дип борылуы булды, утка пешкәндәй артка тайчынды — тәрәзә каршындагы чаганны ялкын ураган иде. Күр инде, тышта көз хакимлек итә башлаган. Һай, гомерләр!

Ә баш инженерның күңелендә яз, бәйрәм иде бу арада. Әнә бит ярты кабинетын алып технологик схема ята. Булачак процессның һәр вaклыгына хәтле исәпләнгән, бар нечкәлекләренә кадәр төшерелгән анда, һәр нәрсә үлчәнгән, кат-кат саналган. Ул гына да түгел, өстәге уң як почмагына «Идарәнең техсоветында расланды» дип язылган, тиешле имзалар куелган. Молодцы егетләр, зур эш майтардылар. Теге чакны өчәүләп карап чыкканнан соң, Константин белән Илсур схеманың тагын ике-өч вариантын эшләделәр.

Артомонов җитәкчелегендәге махсус группаның скважинада уңышлы гына эш башлап җибәрүе дә күңеленә хуш килде Равилнең. Менә шуңа да көне кояшлы бүген. Алай да эчен бер нәрсә тырнап тора. Технологик схеманың сул почмагына «Килешенде» дигән сүз төшерелгән. Язылуын язылган, тик менә иң кирәге — район тау-техника инспекциясе начальнигының имзасы юк. Техсоветта, ни әйтсәң дә, үз кешеләр, яңалыкны тормышка ашыру дәрте белән йөрүчеләр җыелган иде шул. Ә менә «сират күпере»н кичүләре ай-һай кыенга килер. Нефтьчеләр телендә «сират күпере» дип йөртелгәне — РГТИ — район тау-техника инспекциясе. Андагыларның һәр нәрсәгә үз үлчәүләре. Башкарыласы эштән саф алтын ишелеп чыгачак булса да, табыш дигән нәрсәгә исләре китми. Алар аршины — кешеләр иминлеге, урман-кырларны, җир-суларны саклау, табигый байлыкларны исраф итмәү. Бөтен нәрсәне иң элек шул аршин белән үлчиләр. Ансат кына ботка пешерермен димә.

Әле бүген таң белән килеп утыруы да шулар аркасында. Күзгә күренмичә чиле-пешле җире калмаганмы дип, схеманы баштан-аяк карап чыкты. Хилафлык күренми, бар да уйланып, фәнни нигездә эшләнгән. Тәгәрмәчкә таяк тыга алмаслар! Әй, аларныкын белмәссең. Уһу, ун тулып килә, РГТИ начальнигын көттерү ярамас.

Инспекция начальнигы бик төгәл кеше икән, билгеләнгән сәгатькә эшләреннән арынган, Равилне көтеп тора иде.

— Рәхим итегез, утырыгыз, — диде ул ишектә Равил күренүгә. — Сезнең хакта күп ишеттем, ләкин күрешкән юк иде. Менә нинди икәнсез.

— Мин дә, — диде Равил елмаеп һәм кулындагы сызым төргәген өстәлгә куйды. — Болай булгач шәп танышлар икәнбез.

Икәүләп көлешеп алдылар.

— Ярый, товарыгызны чыгарыгыз, — дип, инспекция начальнигы сызымны җәеп җибәрде һәм сүзсез калды, әйтерсең, пәрәвез җепләрен хәтерләтүче сызыклар арасына кереп чумды. Байтак вакыт үткәч кенә

башын күтәреп, Равил каршына басты. — Менә нәрсә, күкерт кислотасының ни икәнен сез дә, без дә яхшы беләбез. Аннары бу кадәр катлаулы сызымны бер карауда өйрәнеп бетерү мөмкин эш түгел. Шулай булгач, ашыкмыйк әле без. Схема биредә калсын, кем әйтмешли, бераз тузлансын...

— Бөтенләй тузланып кала күрмәсен, — диде Равил аны бүлдереп.

— Хәтәр, бик хәтәр эшкә алынгансыз, иптәш Закиров. Процесс вакытында килеп чыгачак һәм без вак-төяк дип атарга гадәтләнгән кимчелекләр турында сөйләп тормастан, кислотага чыдам махсус киемнәр, җайланмалар җитешмәү, эшне башкаручыларның бер-бере белән элемтәләре булмау, ниһаять, агрегатларның кислота кудыруга яраклаштырылмаган булуларын искә алганда гына да, схемага хәзер үк «тәре» куярга кирәк... Ләкин без дә бит кешеләр. Сезнең теләкне, изге ниятне аңлыйбыз һәм кулдан килгәнчә ярдәм итәчәкбез. РГТИ инспекторларының ярдәмен беләсез инде — ул сезгә, производство кешеләренә, хәвефсезлек таләпләрен һәм табигатьне саклау тәртибен бозуга юл куймау. Һәрхәлдә, схема аяк астына салып таптамас, дип ышандыра алам. Хәзергә исә хушлашып торыйк.

Идарәгә кайтканчы авызын җыеп алалмады Равил, куанычы йөзендә уйнады. Шулай булмыйни, «сират күпере»н ансат кына кичте диярлек ич. Кайтып җитүгә, шул шатлыклы шаукым белән, АТК начальнигына шалтыратты, кислотовозларны иртәгә нефтьчеләрнең Кама буендагы базасына хәтәр йөк алырга җибәрергә кушты.

Соңгы көннәрдәге күңел күтәренкелеге, бөтен нәрсә ансат кына хәл ителгән төсле күренү давыл алды тынлыгы булган икән. Иртән эшенә килеп кабинетына керергә өлгермәде, юлда кислотовозларның берсе шартлавын әйттеләр. Хәбәр шомлы иде, бөтен эшен ташлап, ерак юлга үзе чыгып китте. Барса, кислотовоз куркыныч кыяфәттә юл уртасында тора: цистернасы як-якка каерып ташланган, машина үзе, мең ел күл төбендә яткан таштай шомлы кара төскә кергән, тирә-як, юл буе канаулары әшәке исле сыекча белән тулган. Узгынчы машиналар, үләттән качкандай, бу турыны әйләнеп үтәләр, шофер исә, ике кулы белән башын тотып, бер читтә таш өстендә утыра иде.

Автоинспектор, кислотовозга якынаерга курка-курка, шул тирәдә уралды, аракы исе килмиме дип, авызына керердәй булып, шофер белән сөйләште дә, мәсьәлә монда техник яктан каралырга тиеш дип, китеп барды.

Гаеп исә нәкъ менә шоферда һәм машинаны кабул иткән комиссиядә иде. Хикмәт шунда, тимер савытларга үзе генә тутырылганда «шылт» та итми ул кислота дигәнең, шунда еллар буе саклыйсыңмы, меңәр чакрымга күчерәсеңме, тыныч кына ята бирә. Инде кайбер матдәләр, бигрәк тә су белән кушылганда, ул баш бирмәс аждаһага әверелә, ярсып дулый башлый. Шуңа да кислотовозларны юлга әзерләүгә көч күп куелган иде. Моңа кадәр скважиналарга төрле химик реагентлар, катлам суы ташыган машиналарның цистерналары төбендә ни генә булмас дисең. Алар кат-кат юылды, киптерелде. Бу шофер я юарга иренгән, я юньләп киптермәгән. Дөрес, үзе әйтмәсә, аны исбатлавы кыен хәзер. Ләкин логик фикер йөртү аның эшенә салкын каравын күрсәтә иде. Кислота төяп, кайту юлына чыккач, реагент төптә калган сыеклык белән реакциягә керә башлаган, ябык цистернада басым күтәрелгән һәм дуамал шул көч аның стеналарын як-якка аерып ташлаган.

Машинаның моторына пычагым да булмаган, аны сафка бастыру өчен әллә ни зур чыгым кирәкми иде. АТК җитәкчеләре шуңа шатланыштылар. Равил исә үртәлде, борчылды — бу мәрәкәнең гауга, шаушу чыгарачагын шунда ук сизенде ул.

Шулай булып чыкты да, әйтерсең, юлда кислотовоз түгел, тау-тех-

ника инспекциясе өстендә бомба шартлады: инспектор шул ук көнне скважинага барып, булитларны бикләп, пломба салып куйды.

Кичке якта скважинадан Артомонов кайтып төште һәм, киемнәреннән юл тузанын да кагып тормастан, атыла-бәрелә баш инженер кабинетына килеп керде. Ул суырылып калган, битен сакал-мыел баскан иде.

— Нәрсә, Равил Вәлиевич, җикмәс борын туарабыз да мыни? — диде ул, исәнләшергә дә онытып, — егетләр урын-җирләрен төенләп, коралларын әрҗәгә тутырып куйдылар анда.

Равил бу хәтлесен үк көтмәгән иде, шулай да сабырын җуймады. Килеш-кыяфәте белән илгизәр дәрвишне хәтерләтүче Константинга эчке бер хөрмәт белән карап торды да:

— Тукта, сабырсызланма, Костя, кил, кешечә исәнләшик бер, — дип Артомоновка каршы кузгалды, аның кулын кысты һәм тартып диярлек стена буендагы урындыкка утыртты. — Утыр һәм тыңла. Бернинди паникага юл куймаска. Синең группа, бернигә карамый, план буенча эшләргә тиеш. Тагын да яхшырак, тагын да нәтиҗәлерәк итеп. Эшләр болайга киткәч, кунакларның олыракларын көт. Аңладыңмы шуны?

— Аңлавын аңлыйм. Тик комнан бау ишү булмасмы?

Баш инженер Артомонов каршына килеп туктады, бөтен гаеп шушы йончыган кешедән чыккандай, кычкырып җибәрде:

— Булмас! Яңалык утының сүнеп калуы мөмкин түгел. Юл куймабыз!

Константин, бүлмә хуҗасының «кабына» башлавын сизеп, урыныннан кузгалды:

— Алайса киттем мин.

Равил дә, юкка кычкыруын абайлап, оялып куйды, битенә кызыллык йөгерде. Күңелсезлекне йомшартырга теләп, Артомоновның юлына аркылы төште.

— Кайткан кайткан, коенып, бер кич булса да ял итеп кит.

— Юк, ярамый. Паниканың көчәюе, эшнең бөтенләй таркалуы бар. Аннан җыеп та ала алмассың.

— Тукта, кыбырҗама, — диде аңа Равил каты итеп. — Фәрманыңны рация аша бирерсең әнә. Хәзер исә Кайманов янына керәбез. Киңәшәсе нәрсәләр бар.

Начальник кабинетының ишеген ачкач, узарга да, узмаска да белми туктап калды Равил, артыннан кереп килүче Константин исә аңа килеп төртелде. Шул килеш бусагада катып калдылар. Идарәдә эшли башлаганнан бирле Кайманов бүлмәсендә әллә кемнәрне очратты Равил, әмма мондый картинага тап булганы юк иде әле. Идән уртасында дүрт подшипник-тәгәрмәчле арбада ике аяксыз ябык бер кеше утыра, Васил исә аның каршына чүгәләгән, тегене кызгану хисе йөзенә чыккан — менә-менә елап җибәрер төсле. Равил, чигенеп, Артомоновны кабул итү бүлмәсенә кысрыклады, ишекне япты, колагына Каймановның: «Була, була ул, ярдәм итәрбез», — дигән сүзләре генә ишетелеп калды.

— Монысы тагын нинди әкәмәт? — дип сорады Равил, кабат үз бүлмәсенә узгач.

Константин, сорауны ишетмәгәндәй, байтак кына дәшми торды, Равил, шуннан файдаланып, тәмәке кабызды, төтенгә чәчәп Артомоновка ябырылды:

— Монысы тагы нинди прием, дип сорыйм мин синнән.

— Ә-әй, Хәйбуш ла ул. Үз кәсебе белән йөри.

— Соң, соң?

— Кайчандыр кышкы салкында эчеп-исереп урамда егылган, шуннан ике аяксыз калган Хәйбуш. Ничек булса булган, кеше гарипләнгән,

пенсиягә генә яши икән. Тик шушы хәл дә сабак булмаган Хәйбушка, кайчан карама, дүрт тәгәрмәчле арбасына утырып, кибет тирәсендә, сыра саткан җирдә чуалыр. Пенсиясе атна-ун көн эчендә юкка чыга. Элегрәк базар чатында чыгып, соранып та йөргән, диләр аны. Хәзерге заманда хәерче югын кем белми, сорый икән — эчәргә. Шуңа да нәфесен тыйганнар Хәйбушның. Тик аның да башы эшли, сорашуның өр-яңа ысулын таба. Дүрт тәгәрмәчле арбасында зур-зур начальникларның ишеге төбенә килеп утыра да, үзенә игътибар иткәннәрең көтә. Эндәшүче булдымы, сүзен таба инде ул. Имеш, кыйбат даруга акчасы җитми, фәлән дә төгән. Ишеге төбендә тере гарип утырганда, кайсы гына начальникның йөрәге түзәр икән. Тегеләй-болай итәләр, егерме-утыз сум табып, көйләп-җайлап озаталар тегене. Кайманов янына да ешлады әнә, — дип бетерде ул үзенең бу хикәя-белешмәсен. — Васил исә, ул килсә, каяндыр, ничектер табып бирә.

— Димәк, кызгана, димәк, кешеләрне ярата начальнигыбыз.

— Василме?! — Артомоновның күзләре зурайды, сакал-мыек баскан йөзе ниндидер куркыныч төс алды. — Син белмисең әле аны, Равил Вәлиевич, җилкәңдә татымадың. Цех начальнигы булып эшләгәндә, беләсеңме күпме кеше куды? Күбесе кадровый эшчеләр, житмәсә, иң принципиаль, иң гаделләрен.

— Ай-һай, Костя, арттырмыйсыңмы? — диде Равил һәм сөзеп Артомоновка карады. — Василнең тупаслыгына, явызлыгына ышанмыйм, ышана алмыйм.

— Ә ул тупасланмый, усаллыгын йөзенә дә чыгармый, хәтта, кычкырмый, җикерми. Тик үзенә аркылы килгән кешегә дип йөрткән ташы һәрвакыт куенында була: премиясен кисә, кесәгә сугуның башка юлларын таба. Ызгыш-гаугасыз гына үзе китәргә мәҗбүр була теге кеше.

— Ал-лай.

Гайбәткә керен китүләреннән уңайсызланып, тынып калдылар. Ул арада бөтен идарәдә аякка басты: ачык ишектән секретарь кызның йөгерә-йөгерә кереп чыгып йөргәне күренде, пеләшен ялтыратып баш бухгалтер ашыга-ашыга Кайманов бүлмәсенә узды, аның артыннан ук Борһанов кереп китте — барысы да, эшләрен ташлап, Хәйбушка акча юллый иде.

— Шулай да мин китим әле, — диде Артомонов һәм аңа хас булмаган җитезлек белән ишеккә таба кузгалды.

## 12

Начар хәбәр әшәке ис кебек: күз ачып йомганчы таралып, тиешлесенә дә, тиешсезенә дә барып җитә. Яңалыкның тау-техника инспекциясендә терәлеп калуы бөтен идарәгә җәелеп өлгерде. Инженерларның бер ишесе сыкранып кабул итте моны, икенчеләре пошынмады да. Кайберәүләр исә башкаларга сиздерми шатланды гына — күпме мәшәкатьтән котылачаклар ич.

Артомонов каршында гайрәтләнсә дә, Равил үзе дә аптырап калды башта, яраткан уенчыгын югалткан баладай, кая барып бәрелергә белмәде, күңеле төште, кулы эшкә ятмый йөдәде. Хәер, җиде юл чатында басып калган кеше нишләргә тиеш соң? Уңга барыргамы, сулгамы? Әллә борылып китәргәме? Озак баш ватты Равил, ләкин төпле генә бер фикергә дә килә алмады. Тәмам гаҗизләнгәч, берләшмәгә Губерт янына китеп барды.

Теге исә сабакташын тыңлап та тормады.

— Кайт, тыныч кына көтүеңне бел. Сабыр төбе сары алтын, — диде дә, селектор аша кем беләндер сөйләшә башлады. Әйтерсең, бүлмәдә

Равил юк иде аның өчен. Губертның мондый кыланышына хәтере калып, урыныннан кузгалды Закиров. Ишеккә таба ике-өч адым ясарга өлгермәде, артында дустының боерулы тавышын ишетте:

— Син кая кузгалдың әле, утыр. Ай-һай эшем иясе булып киттең,— ул өстәле артыннан чыгып, сабакташы янына килде, аны терсәгеннән алып, тәрәзәгә таба әйдәде. — Менә нәрсә, Рево, — диде. ул бөтенләй икенче дустанә тонга күчеп, — син кислота белән җенләнеп йөрисең йөрүен дә... Гаиләң иминлеген кем кайгыртыр дисең? Минме, әллә Пушкинмы? Кичерешләреңне аңлыйм мин. Шулай да турсаеп йөрмә, бар Мәскәүгә, алып кайт Әлфияңне. Үпкәләп йөрү егетлек түгел...

Берләшмәдән тагы боегып, кара көеп кайтты Равил. Бер-ике көн исәр кешедәй әйле-шәйле йөрде, хезмәттәшләре белән орды-бәрде сөйләште. Ниһаять, мондый халәтнең кислотага гына бәйле түгел икәнен аңлап алды. Һич уйламаганда гаиләсенең зил-зибәр килеп бетүе бигрәк тә талкый иде шул күңелен. Губерт дөрес әйтә, үпкәләп йөрү эш түгел. Әлфиясе янына барып кына кайтыр иде дә бит, кырык эш кырык яры таралып ятканда кая кузгаласың. Шулай җанын кая куярга белми йөргәндә, Мәскәүдән телеграмма килеп төште. Тик ул Фәридәдән иде. Кызда әле башка кайгы юк, үз шатлыгы шатлык — университетка кабул ителүен хәбәр иткән. Фәридәне котлау сылтавы белән Равил Мәскәүгә шалтыратты, ләкин трубканы кайнанасы алды. Кыз укуында икән, Әлфия өйдә юк, имеш. Карчыкның иренеп кенә салкын сөйләшүеннән үк сизенеп алды — хатыны шунда, сөйләшкәннәрен тыңлап тора, тик трубканы алырга теләми иде.

Әлфиянең болай үҗәтләнүе җен ачуларын чыгарды Равилнең, шулай да түзде: хат язып салмады, юлга чыкмады. Ябыкты, тешләкләнде, кешеләрдән кача башлады.

Шундый күңелсез көннәрнең берендә кабинетына Губерт килеп керде: һәрвакыттагыча пөхтә, чиста, саф, күңеле күтәренке. Әйтерсең, аның белән бергә бүлмәгә яз керде.

— Ну, варвар, җыен,— диде исәнләшеп тә тормыйча һәм Равилне ашыктыра башлады. — Чыгып машинаңа утырырга бер минут сиңа. Безнең арттан калма.

Кая баралар, нигә? Аларын сорап тормады Равил. Губертның нинди дә булса зур эш чыгарып йөрүенә иманы камил иде аның. Йөрәге урыныннан купты, ешрак тибә башлады. Идарә ишеге төбендә туктап торган биш-алты машинаны күргәч, тагын да алгысый төшеп, Габит янәшәсеннән урын алды. Шофер да эшнең җитди икәнен төшенгән, моторын кабызып куйган иде. Равил утыруга, машинасын олы юлга борды, алдан баручы колоннага иярде.

— Ну эшләр була бүген, — дип куйды Габит никтер елмаеп.

Шофер халкының житезлеген, өлгерлеген белә инде Равил. Аларның бар нәрсәне әллә кай арада ишетеп алуларына хәйран кала. Әллә соң начальство йөртүчеләре генә шундый әрсез алабайлармы? Әнә бит нидер ишетеп, белеп тә алган.

— Я, сөйләп җибәр, — диде ул шоферына коры гына. — Әйтәсе сүзең авызыңнан чыгам дип пытпылдап тора ич.

— Һә-әй, дөнья купкан анда! — Габит сабан туена баручы чабышкы җайдагыдай дәртләнеп-дәртләнеп сөйли. — РГТИның бөтен инспекторлары, хәтта Казандагы начальниклары да килгән. Институт галимнәре, инженерлар, әллә нинди чуртлар тагы...

Комиссия чыннан да, зурдан иде. Скважинага килеп төшүгә, мамонтка һөҗүм итүче борынгы кешеләрдәй, булитларга ташландылар. Кислота хакында житди һәм соңгы сөйләшү буласын аңлап, Равил дә аларга иярде, ләкин сүзгә кушылмады, әйтелгән фикерләрне, күрсәтелгән кимчелекләрне куен дәфтәренә яза барды. Хәер, төпле генә фикер әйтүче булмады да диярлек. Чөнки әле монтаж эшләре тәмамланмаган, жи-

һазлар төрлесе төрле яры таралып ята. Сүз кислотаны кудыру-кудырмау турында иде. Ниһаять, читкәрәк чыгып, утрау булып торган туйралык янына тукталдылар.

— Ягез, тәэсирләр ничек? — диде Губерт, барысы да жыелып беткәч.

Сөйләргә сүзләре калмагандай беравык тын тордылар. Инспекциянең округ комитеты председателе — киң җилкәле йомры кеше, барысының да аның ни дә булса әйткәнне көтүләрен төшенеп, уртагарак атлады.

— Дөресен әйткәндә, тәэсир бака йоткандагы кебек, — диде ул, ни өчендер башындагы эшләпәсен салып. — Теге кырык тонна кислота салган булитыгызның исе генә дә дөнья корытырлык. Район тау-техника инспекциясе бик дөрес карарга килгән, дип уйлыйм мин.

Өлкән начальникларының мактавы күңелләренә хуш килде бугай, инспекторлар берсен-берсе бүлә-бүлә аның сүзен җөпли башладылар. Яңалыкны башлап йөрүчеләр исә, гаепле малайлардай, сүзсез торалар иде. Губерт, инспекторларның шау-шуын бер селтәнүдә бетерергә исәпләгәндәй, кулы белән кискен хәрәкәт ясап куйды.

— Туктагыз әле, иптәшләр. — Аның тавышы тыныч, шулай да дулкынлануы сизелеп тора иде. — Безнең илдә күкерт кислотасы, аш тозыннан кала, иң күп җитештерелә торган әйбер. Димәк, аны эшләп чыгаруда, саклауда, транспортлауда меңнәрчә кеше катнаша. Бәхетсезлек очраклары да булгалыйдыр. Саклану чараларына төкереп караган кайсы гына предприятиедә, колхоз-совхозда булмый ул бәхетсезлек?! Ваемсызрак кешеләр ашаганда авызын да пешерәләр... Кислота дисез, куркыныч дисез. Ә бит аннан саклану өчен менә диган резин киемнәр, итек, перчаткалар, противогазлар бар. Аннан бит су белән кушылмаганда алай ук куркыныч та түгел ул...

Китте, китте шуннан сөйләп. Губертның белеменә, эрудициясенә, инандыру көченә сокланып туймады Равил. «Шулай, шулай, дускай, бир кирәкләрен», — дип, эчтән генә аңа куәт өстәп торды. Әмма Губерт никтер туктап калды, кем нәрсә әйтер дигәндәй, янындагыларга карапкарап алгалады. Сүзгә кушылучы күренми иде. Шулай да округ инспекциясе начальнигы алга таба бер адым ясап куйды. Аның бәхәскә керәсен сизенгән Губерт шул ук ышанычлы, нык тавышы белән сүзен дәвам итте:

— Эзләп табу өчен бик күп чыгымнар һәм материаль ресурслар тотылган барлык нефть запасының яртысы җир астында калуы безне борчымыймы? Әгәр туган илебездә нефтьнең нибары унбиш-егерме проценты гына алынган һәм инде өметсез дип саналган ятмаларның күп икәнен искә алсак, нинди резервларыбыз бары аңлашыла булыр. Болар минем сүзләр түгел, егетләр. Бу хакыйкать съезд трибунасыннан яңгырады. Аны кабатлап ни димәкче булам мин?

Губерт тагын тынып калды. Сүзләрнең мәгънәсе барына да барып җитсен әле дигәндәй, бераз торды да, кабат сөйләп китте:

— Шуны басым ясап әйтсем килә: күп кенә кешеләр, хәтта кесәләрендә диплом йөртүчеләр дә, табигатьне саклауны күз алларына бер төрле генә китерәләр. Аларга урманнар шаулап, чишмәләр чылтырап торсын, сандугачлар сайрасын. Бик шәп теләк. Кем генә каршы икән моңа?! Мин дә, Глухов та, башкалар да шуны телибез... Ә бит медальнең икенче ягы да бар, иптәшләр, җирнең асты, аның куенындагы казылма байлыклар: нефть, газ, ташкүмер, металл бар. Менә шуларны эффектлы файдалану, сак тоту турында бара сүз... Шуны аңлагыз, аерым шәхесләр генә фәнни-техник революцияне тоткарлап тора алмый. Безнең җәмгыять, дөньядагы иң алдынгы җәмгыять, шундый зур хәзинәнең яртылашы җир астында калуына юл куя аламы? Юк. Катламнарга тагын да куәтлерәк нәрсәләр белән дә, әйтик, атом-төш кодрәте

белән тәэсир итәргә туры килер, бәлки. Анда инде тәэсирләр бака йоткан кебек кенә булмас... Гомумән, кислотаны кудырмау турында сүз булуы мөмкин түгел. Аның белән ничек сак эш итәргә, кешеләрне, табигатьне саклауның тагы нинди юлларын табарга? Менә нәрсә хакында баш ватарга кирәк... Мин Мәскәү белән сөйләштем. Андагы иптәшләр, хәтта сезнең коллегалар да, шул фикердә. Бетте, Закиров, иртәгедән монда өстәмә көчләр җибәрегез. Кислотовозларны — Кама буена!

Көтелмәгән финалдан җыелган халыкның авызлары ачылып калган иде.

## 13

Шул көннән соң скважина тирәсендә ыгы-зыгы артканнан артты. Һәр кичне рация аша сөйләшеп, андагы хәлләрне сорашып торса да, күз өстендә каш булып киткән бу төбәккә ешлый алмады Равил. Берничә көн тау-техника инспекциясе кешеләре белән кайнады. Инде технологик схемага кул куйдыруга ирешкәч, вак-төяк мәшәкатьләргә чумды. Кислотага бирешми торган эш киемнәре эзләп, техснабка, Уфага барып кайтты, автотранспорт конторасы инженерлары белән процесста катнашачак агрегатларның техник хәлен тикшерде, шоферлар юлда тагы ул-бу чыгармасыннар дип, Кама буендагы базаны әйләнде, автоинспектор сыман чатта басып торгалады. Бүген, ниһаять, шулардан бераз арынгандай булды һәм, тагы берәр нәрсә килеп чыкканчы дип, кислота кудыруга әзерләнә торган скважинага китеп барды.

Автомобиль, кисәк акрынаеп, уңга борылды, ал тәгәрмәчләре ниндидер чокырга төште, ул да түгел, дулкын өстеннән үткәндәй, тирбәлеп алды. Равил уйларыннан айнып, башын күтәрде. Алда, яп-якты каен урманы буенда, ремонт мачтасы калкып чыкты, аның янында сураеп торган булитлар, шул тирәдә кайнашып йөргән кешеләр күренде, сварка уты җемелдәде.

Баш инженер машинасын танып үзе каршы чыкканмы, бер-бер эш белән йөрүе идеме, беренче очраган кеше Артомонов булды. Аның турына җиткәч, Равил ишекне ачты һәм, машина, туктар-туктамас, җиргә сикерде.

— Я ничек, Костя? — диде ул, күрешергә кулын сузып. — Барамы?

Константин ерак тайгада эшләп йөрүче геологка охшап калган иде: җиңелчә сырма өстеннән арзанлы яшел плащ киеп алган, аягында резин итекләр, чигәсеннән алып муенына кадәр кара сакал баскан. Шулай да күзләре шатлыклы елтырый, күңеле күтәренке икәне әллә каян сизелеп тора.

— Инглиз сәяхәтчесе Роберт Скотт: «Соңгы сохари беткәнче көрәшергә!» — дигән, — дип, гадәтенчә олы авторитетларны телгә алып башлады ул сүзен. — Безнең исә сохари гына түгел, колбаса, ит ише нәрсәләр дә тагын ике-өч көнгә җитәрлек, ә эш бетеп тә килә.

Артомоновның «доклады» бик оптимистик булса да, Равилнең йөзе үзгәрмәде.

— Күрсәт хуҗалыгыңны!

Булит янында аларны Галиулла абзый каршылады. Ул, күрешергә исәпләп булса кирәк, баш инженерга таба борылды, ләкин кулына тоткан озын пыяла көпшәне кая куярга белми аптырады.

— Эшләр гөрлиме, Галиулла абзый? — диде Равил, аның беләгеннән кысып. — Бирешмим дисең алайса?

— Исәп гел бирешмәскә дә, кем, Равил апаем, — Галиулла көпшәне сак кына торбалар өстенә куйды, — картлык үзенекен итә икән шул. Менә урвнәмирне ялгыш монтажлап куйганмын бит әле, карт алаша, булит белән тоташкан җиренә винтель куймаганмын.

Равил Артомоновка таба борылды:

— Карале, Костя, рационаллаштыру тәкъдимен рәсмиләштергәндә Галиулла абзыйны, гомумән группадагы барлык кешене авторлар рәтенә кертергә онытма.

— Што сез, Равил Вәлиевич, Галиулла абзый, Гафурова кебек эшчеләребез булмаса, без нәрсә — армиясез генераллар гына. — Артомонов булитның теге очына ишарә ясады. — Күрдегезме, ничек асат хәл иттеләр.

Галиулла кеше сөйләгәнне тыңлаган булып вакытын бушка уздыручылардан түгел, әлеге пыяла көпшәне алып булит тирәсендә кайнаша башлады. Артомонов исә пинжәгенең эчке кесәсеннән бер төргәк кәгазь чыгарды.

— Тәкъдим менә ул, Равил Вәлиевич. Идарәгә алып китсәгез дә була. Бар да әзер.

Равил документларны кулына алды, салмак кына актара башлады. Иң өстә Кайманов фамилиясе ярылып ята иде. Равил карашы белән исемлекнең азагына кадәр үтте. Схеманы иҗат итүчеләр дә, аны тормышка ашыручылар да — барысы да бар, хәвефсезлек бүлеге начальнигы Самаринныкы гына күренми иде. Равил күзлеген кабат исемлекнең башына төбәде, каләмен алып Васил фамилиясен сызып атты һәм «Самарин Х. Х.» дип язып куйды.

Бу хәлне күреп торган Артомонов бер мәлгә өнсез калды, аннан кисәк кенә кычкырып җибәрде:

— Харап иттең, Равил Вәлиевич, бөздың!

Закиров күтәрелеп Константинның борчулы йөзенә карады, тыныч кына әйтеп куйды:

— Ничево, исемлекне яңадан басарлар. Менә шушы төзәтү белән...

Артомонов, тәмәке тартмаса да, Равил кулындагы пачкадан сигарет алды, аны угалый башлады.

— Болай ярамый, Равил Вәлиевич!

— Ничек инде ярамый? Кайманов кислота хакында бармакка бармак та сукмады.

— Шулай да ансыз булмый. Сезнең белән бездән генә калмаган: башка предприятиеләрдә дә шулай итәләр, саллырак тәкъдимнәр булганда, начальник соавтор итеп кертелә.

— Соавтор булмаса дамы?

— Бала-чага булмагыз, Равил Вәлиевич, авторлар исемлегендә начальник үзе булгач, тәкъдим асат кабул ителә, акчасын алу да тоткарлыксыз. Бу инде гадәткә кергән.

— Димәк, начар гадәт.

Сөйләшә-сөйләшә янәшәдәге чирәмлеккә килеп чыктылар. Биредә әле үлән тапталырга, җир өсте актарылып ташланырга өлгермәгән — хәтфәдәй бәпкә үләне кызыктырып, үзенә тартып тора иде.

— Я, тагы ниләрең бар? — диде Равил кырыенда җилле көндәге буровой сыман чайкалып торган Константинга карап.

Артомоновны алыштырып куйганнар диярсең: күзе-башы җимерелгән, гадәттәгедән ныграк чайкала — кәефе кырылганы әллә каян күренеп тора. Гомер булмаганны, сигарет кабызып җибәрде, кесәсеннән дүрткә бөкләгән кәгазь чыгарып, аннан дәшми-тынмый гына Равил алдына чирәмгә ыргытты.

Кәгазьгә кагылмады Закиров, күзлек пыялаларын елтыратып, Артомоновка озак кына карап торды да:

— Тыңлыйм, — диде.

Аның сүзен ишетмәгәндәй, сигареты белән байтак кына маташты Константин, аннан үз алдына сөйләнгән кебек кенә әйтеп куйды:

— Һәр тигезлекнең тау буласы килә — менә шунда трагедия.
— Юньләп кенә сөйлә әле, Костя?!
— Әнә, укы.

Закиров чирәмдә яткан кәгазьне алды, аны ачып карауга, идарәдән цехка күчәргә сорап язган гариза икәнен аңлап алды, тагы сүзсез калды. Мондый вакытта кешене юату, үгетләү файдасыз, ул үҗәтләнә генә бара, корырак торырга кирәктер, мөгаен.

— Ә бу петицияне нигә дип миңа бирәсең?

— Синең резолюциядән башка кул куймый Кайманов, сызгалап бир инде?!

Равил ни әйтергә белми аптырап калды, кәгазьне кулында угалап-угалап торды да:

— Дурак син, Костя, — диде. — Шуның өстенә дизертер икәнсең әле. Нинди кызыклы эксперимент әзерләнә, ә ул... эштән китә, имеш.

— Юк, эштән китмим мин. Киресенчә, цехка күчеп, аңа якыная төшәм.

— Ярый, әйдә, кешечә генә сөйләшик әле. Нинди чебен тешләде сине?

— Беләсезме нәрсә, Равил Вәлиевич. Минем хакта нәрсә уйласалар да күтәрә алам, бары бер нәрсәне — ахмак дип исәпләүләрен генә ишетү авыр...

— Кем шулай әйткән инде?

— Әйтүен Рудольф Дизель әйткән. Тик аны бүген минем сүзләр дип исәплә.

— Ә кем ахмакка саный сине?

— Җанны телгәләмә, Равил Вәлиевич, куй имзаңны... Баш геолог Шумскийның ни белән шөгыльләнгәнен беләсең инде син?!

— Менә сиңа, иске авыздан яңа сүз. Геологның ни белән мәшгуль булуын кем белми инде. Геология белән, әлбәттә.

— Анысын аның юл уңаенда гына башкарды Шумский. Мин аның төп эшен күздә тотам, — диде Константин, һаман да тупас, орды-бәрде итеп.

— Гафу ит, Костя, кызыксынганым булмады, — диде Равил, аптырагач.

Артомонов кызып ук китте.

— Хәер эстәп йөрде ул, беләсең килсә!
— Аңламыйм, берни аңламыйм.
— Беркатлыланма, Равил Вәлиевич.
— Ихлас менә.
— Скважиналар ремонтлау планының асат кына үтәлүе нәрсәдән дип беләсең? Шумский үтәде аны.
— Шумский? Ничек?
— «Таяклар» теләнеп.

Таяклар? Ах, әнә нәрсә хакында бара икән сүз. Промыселларда скважиналар санап бетергесез күп булган кебек, аларны ремонтлау ысуллары да күп төрле. Кайсыларын сафка бастыру өчен айлар, хәтта еллар кирәк. Кайбер ремонт исә бер-ике атнага гына сузыла. Арада бер көнлек, хәтта берничә сәгатьлек ремонтлар да очрый. Андыйларын «таяклар» дип йөртәләр ремонтчылар. Чөнки техник-экономик күрсәткечләрнең беренчесе — ремонтланган скважиналар саны. Бер көндә сафка бастырылганмы ул, бер елдамы — барыбер. Бер ремонт — бер таяк. Шуңа да скважиналар ремонтлау цехларында «таяклар» белән маҗыгучылар бар, дип ишеткәләгән иде Равил. Ә менә яңа идарәдә җиңел юлга басучылар бардыр дип башына да китермәде. Баксаң, монда да бар икән «таяк» эзләп йөрүчеләр.

— Теләнсен дә, ди. Сиңа ни катнашы бар аның?

Константин бөтенләй кабынып китте:

— Аңламыйм мин сине, Равил Вәлиевич. Үзең баш инженер, үзең чит кеше кебек сөйләшәсең... Инде айга якын Шумский тубдиспансерда ята — үпкәсендә кара таплар тапканнар. Ә идарә буенча план үтәлеше ике сарылы. Байтактан тынгы бирми миңа Қайманов, Шумский камытын кияргә куша. Мин исә булдыра алмыйм, ишетәсеңме, теләнә белмим мин!!!

Равил гаризаны кулында әйләндергәләде дә, ерткалап җилкәсе аша сипте. Кәгазь кисәкләре җиргә төшеп җитмәде, җил аларны урманга таба куып алып китте.

— Бар, Костя, эшләреңне кара, — диде Равил тыныч кына. — Қайманов белән үзем сөйләшермен. Аннан, беләсең килсә, гаделсезлек белән болай көрәшмиләр. Қстати, син бит партоешма секретаре. Оят түгелме?

— Оят, бик оят, Равил Вәлиевич, — диде Константин өзгәләнеп, — әмма бер тарыдан ботка пешми.

— Ә нигә бер тары? Без — коммунистлар кая? Киңәштеңме партия членнары белән, аңлаттыңмы хәлне аларга? Дәүләт планы хәйлә белән үтәлә икән, нигә җыелышка куймаска мәсьәләне?

— Уйладым, барын да уйладым, Равил Вәлиевич, — Артомонов кисәк кенә басылып, юашланып калды, көчле зур кулларын кая куярга белми йөдәде.— Җыелышка куйдык та ди. Ә коммунистлар мине якламасалар? Ул чакта ни буласын чамалыйсыңдыр. Үзенә каршы чыгучылар белән сөйләшә белә Васил. Тавыш-гауга кубармыйча гына, Каймановча итеп... Безнең дуслык исә болай да чамалы. Аннан, үзең беләсең, минем бит партия эшендә тәҗрибәм юк, башлангыч партоешма начальник кадәр начальникны тикшерә аламы? Менә тиздән идарәдә партком оештырылачак, ул чагында инде...

— Димәк, утлы күмерне кеше кулы белән тотарга уйлыйсың? Их, Костя, Костя, синнән моны көтмәгән идем. Егет булсаң, башкалар артына ышыкланма син!

## 14

Эш мәйданчыгы тып-тын, әйтерсең, куәтле техника монда бер бизәк өчен генә куелган. Равил атылып таза каен такталардан ясалган мәйданчыкка килеп менде, скважина тамагына якынлашты: үзәк япкыч ачык, колонна эчендә торбалар күренми иде. Равил, ярдәм эзләгәндәй, як-ягына каранды, карашы торбалар әрдәнәсе өстендә яткан пакерга тап булды. Нефтьле катламнан өстәрәк колонна белән торба арасын бөке сыман томалап куярга тиешле җиһазның резин боҗралары кыршылып, теткәләнеп беткән иде.

Бригада членнары шуннан ерак та түгел чирәм өстендә ял итеп, тәмәке пыскытып яталар икән. Эш мәйданчыгында чит кеше күренүгә, урыннарыннан кузгалып, скважинага таба атладылар. Мазутлы брезент чалбарын, төшеп йөдәтмәсен дип, шпагат белән бәйләп куйган, башына көрән төстәге каска кигән табак битле таза гәүдәле нефтьче башкалардан алгарак чыкты, Равилгә кычкырды:

— Карагыз әле, иптәш, тали блогы астында йөрергә ярамый бит!

— Хәвефсезлек кагыйдәләрен беләсез икән. Анысы шәп. Тик менә нишләп пакер күперчектә чайрап ята?

— Төшергән иек, иптәш начальник, утырткан да иек,— диде бурильщик, үкенечле тавыш белән. — Кичә скважинага су кудырып караган иек, тотмавы мәгълүм булды.

— Соң, өскәрәк күтәреп утыртырга иде.

— Карадык ла... Тотмый тек тотмый, паразит. Күрәсең бит, резины теткәләнеп беткән...

— Инде нишләргә уйлыйсыз? — диде Равил, нефтьчеләргә борылып.

— Нишләргә дип... Бозжраларын алыштырыр иек тә, яңалары юк. Башка пакер алып киләм дип, мастер калган ие базада. Никтер күренми.

Равил төкереп куйды, ашыгып мәйданчыктан төште һәм культбудкага таба атлады. Булит яныннан узганда кинәт, чиләкләп койдылармыни, өстән бер көлтә чаткы чәчрәде. Күтәрелеп караган иде, яшькелт ялкынга күзе чагылды. Шул мизгелдә ниндидер бер әчке тоем белән югарыдан нидер шуып төшүен сиздә һәм, тимер-мазар булмагае дип, алга ыргылды, ул да түгел, «дык» иткән тавышка сискәнеп, артына борылды. Аңардан ике адымда гына, җирдә, тупас брезент киемле кеше ята иде. Йөрәге «жу-у-у» итеп китте Равилнең, бер сикерүдә сварщик янына барып җитеп, аны күтәреп алды һәм культбудкага таба йөгерде.

— Ишекне, ишекне ачыгыз! — дип кычкырды ул егетләргә.

Инде күптән авыр нәрсә күтәргәне булмаса да, булит белән будка арасын бик ансат үтте ул. Шунысы гаҗәп, сварщикның гәүдәсе җиңел һәм шушы тупас киеме аша да тәненнән җылылык бәреп тора сыман тоелды аңа.

— Баш очына берәр нәрсә бирегез, — диде Равил үзе артыннан кергәннәргә һәм бәлагә тарган кешене топчанга сак кына салды. Ильсур кулындагы майлы сырманы алып, сварщикның баш астына кыстырды, йөзенә иелде. — Кай җирегез?

Ул, кинәт ток суккандай, коелып төште, аның күзлек пыялаларыннан бер чиректә генә күршесе Фәһимә йөзе иде. «Менә кем икән ул Гафурова», — дигән уй үтте башыннан, ашыгып соравын кабатлады:

— Кай җирегез авырта?

Фәһимә күзләрен ачты, уңайсыз гына елмаеп куйды, аннан битенә бик килешле булып кызыллык йөгерде.

— Юк, юк, бер җирем дә авыртмый, курыктым гына, — диде ул, кабаланып һәм, бер төркем ир-ат алдында ятуына тартынып, урыныннан кузгалды.

— Ятыгыз, ят,— диде Равил,— без хәзер чыгабыз. Бәлки больницага илтергәдер?

— Булмаганны, — Фәһимә торып утырды. — Биек түгел ич. Мин аннан гел шуып төшә торган идем. Бу юлы нишләптер аягым каймыгып китте дә...

— Ярый, бәхетегез, — диде Равил, Артомоновка борылып һәм беренче булып ишеккә таба атлады. Баскычтан төшеп, егетләрне көтеп алды, алар артыннан ишек ябылгач, кабат Константинны шелтәләргә тотынды. — Әйттем мин сиңа группага хатын-кыз алма дип.

Һай, бу кешеләр! Нигә бер-берләренә шулай гамьсезләр икән? Күршесендә яшәүче, җитмәсә, бер буйдан квартирасына кереп-чыгып йөрүче тол хатын йөрәгендәниләр кайнавын белсә, Константинны түгел, үзен гаепләр иде Равил. Баш инженер янына килмәгәнгә, аның эшен күреп сокланмаганга үртәлеп, булит буйлап шуып төшәргә һәм туп итеп аның алдына басарга уйлаган иде бит Фәһимә. Булмады.

Булып алган күңелсезлектән бераз кәефе китсә дә, бик үк аптырашта түгел иде Равил. Группа йөзне кызартмады, әзерлек эше тәгәлләнеп килә. Өстәвенә бая брезентовка аша тоелгандай булган җылылык күкрәгенә рәхәтлек биреп тора сыман. Әллә шушы гади хатынның көннән-көн үз була баруын искәртүче хисме соң бу? Бүгенге кадәр дә аның турында уйланганлады түгелме? Юктыр, гел кереп-чыгып йөргәнгә, Ленизага тормыш әлифбасын өйрәтеп торганга гына шулай тоеладыр. Ни генә булмасын, күңеле якты иде аның. Болай булгач, тагын бер-ике көннән... Ах, әйе, пакер... Ул, җилләнеп, кабат культбудкага керде, тә-

рәзәгә карап сагышланып утырган Фәһимәгә игътибар итмәгән булып, рация өстенә иелде:

— Кристалл! Кристалл!

Тик юкка кыбырҗыган икән, мастер Сабировның инде күптән пакер алып чыгып китүен хәбәр иттеләр.

Гомер булмаганны, Габит, урыныннан акрын гына кузгалып, сөргән җир өстеннән салынган юлны көймәдә баргандай җай гына тирбәлдереп узды да, «Волга»сын олы юлга алып чыкты. Әмма анда да кумады машинасын. Җәй уртасындагыдай чалт аяз бөркү көн булуга карамастан, моңланып-сагышланып калган урман-кырлар йөрәгендә нечкә хисләр уяткан бугай, юлдан битәр тирә-юньне карап бара. Соңгы көннәрдә әллә нишләде әле бу малай. Әллә гашыйк булган, сәер-сәер хәлләр чыгарып куйгалый. Күз керүгә карамастан, машинасын чәчәк белән тутырган. Равил үзе дә, ихтыярсыз, тәрәздән башын чыгарды, табигать хозурлыгыннан әсәрләнеп калды. Асфальт юлның сул ягындагы Зәй тугае, чыннан да, искиткеч иде бүген.

Алда зур түгәрәк күзгә булып су өслеге ачылды. Сусаклагыч, чын диңгез булып, ерак-еракка сузыла. Аның өстендә кояш нурлары уйный, акчарлак канаты булып вак дулкыннар йөгерешә, сирәк-мирәк көймәләр тирбәлә. Аларда бөршәеп утырган балыкчылар, йокыга талгандай, калкавычларга төбәлгәннәр. Суга карап мөкиббән киткән кешеләр яр буенда да күренгәли иде. Шул вакыт кырыйда иләмсез КРАЗ машинасы күренде. Нигәдер бик таныш сыман тоелды бу машина, Равил Габитның беләгеннән тотып алды.

— Тукта, ашыкма!

Шофер кисәк тормозга басты,— зур тизлектә барган машина, салулый төшеп, юл кырыена, корып-кипшенеп барган чирәмгә чыкты һәм туктап калды.

— Нәрсә, су кирәбезме? — диде Габит, күзләрен очкынландырып.— Әллә балык каптырып карыйбызмы?

— Юк ла, — Равил, машинадан чыгып, әлеге КРАЗга карап басты.— Яле, синең күзләр үткеррәк, номерын күрәсеңме?

Габит аның янәшәсенә килде, кулын кашлары өстенә куйды.

— Аерып бетерә алмыйм. Шулай да таныйм — безнең кислотовоз бу!

Равил, юл үреннән төшеп, су буйлап китеп барды.

КРАЗ, чыннан да, кислота ташырга билгеләнгән машиналарның берсе иде. Шоферы утыргычын алып, машина күләгәсенә куйган да, чалып ташлаган үгездәй хырлап, шуның өстендә йоклап ята. Ачуыннан ни диярга дә белмәде Равил, бөтен тәненә кайнар кан йөгергәнен тоеп алды, күзләре кызышты, уч төпләре кычытып куйгандай булды. Кылә-килешкә утыргычның бер ягын күтәрде һәм җиргә шуып төшкән шоферның өстенә каплады.

Тегесе кайда һәм нишләп ятуын оныткан бугай, борчуларына ризасызлык күрсәтеп, әче итеп сүгенеп алды, бер селтәнүдә утыргычны читкә атты һәм, күзләрен уа-уа, аягына басты.

— Сез... сез нишләп биредә?! — диде Равил, үзен көчкә тыеп. — Болай йоклап, ике рейсны ничек ясарсың?

Инде шофер да ни булуын аңлап, алдында кем торуын белеп алган иде — тотлыга-тотлыга акланырга тотынды:

— Без... без ни... Кушканны үтәүче генә... Мастер әйтте... Мин килдем...

— Кая, нинди мастер ул?

— Анау... Сабиров, — диде шофер, яр буенда кармак салып утырган кеше ягына ишарәләп, үзе, утыргычын алып, кабинасына күтәрелде.

Равил атылып яр буена килде, калкавычка карап мәрткә киткән балыкчы артына туктап, беравык аптырап калды. Каланча гәүдәле бу кеше, чыннан да, Әкрен Сабиров иде. Беренче теләге шушы пошмас бәндәне ярдан тибеп төшерү булса да, ачуын тыеп, мәсхәрәле шаян тонга күчте:

— Нәрсә, чиертәме?

Сабиров, алачыкта җир идәнгә күмелгән сандал бүкәнедәй, селкенмәде дә, тик бераздан гына кулын күтәрде, елан ыслагандай:

— Тес-с-с! — диде.

Башкача чыдарлыгы калмады Равилнең, күзләре зурайды, кызарып чыкты, аннан бар куәтенә:

— Вста-а-ать! — дип кычкырып җибәрде. Тавышы киң су өстенә генә сыеша алмыйча, каршы ярдагы тау араларына, алар өстендәге урманнарга барып сугылды, аннан кире кайтып бөтен Зәй буена яңгырады: «А-а-ать!»

Тик Сабиров кына селкенмәде. Шул мизгелдә су өстендәге калкавыч биеп алды, мастер, һич көтелмәгән җитезлек белән, кармак сабына ябышты, аны читкәрәк тайпылдырды, ул да түгел, кисәк кенә кармагын тартып алды, һавада тал яфрагы кадәр генә шыртлака кыймылдап ялтырады.

— Эләкте бит, эләкте, наный, — дип такмаклый-такмаклый, табышына үрелде Сабиров.— Ә сез кычкырмагыз, гражданин, балыкны куркытасыз. Балык ул...

Мастер авызы колагына җиткән йөзен Равилгә таба борды. Һәм, балык кылчыгына кадалгандай, туктап калды.

Бу хәтле үк сансызлыкны көтмәгән иде Равил. Кинәт каны кайнап чыккандай булды, үзен-үзе онытып, бар куәтенә кизәнеп Сабировка йодрыгын тиз генә бер кундырып алмыйча, тәки түзмәде бит... Тегесе артка таба шуышкандай булды һәм гөбердәп суга барып төште. Бераздан суынгандай булды Равил, нишләгәнен аңлап алды, аркасына салкын тир бәреп чыкты. Өс-башы үтәли чыланган Сабиров акрын гына ярга күтәрелеп килә иде.

— Сык киемнәреңне, хафа! — диде Равил, инде дустанә итеп.

Алар, Сабировны утыртып, кабат скважинага килгәндә, кислотовоз шоферы пакерны калдырып каядыр китеп югалган, бригада тирә-юньгә тимер чыңы, мотор гөрелтесе таратып эшләп ята иде.

Шәһәргә, кыска көн үтеп, биек таш пулатлар өстенә инде эңгер иңгәндә кайтып төштеләр. Идарәгә кереп тору исендә дә юк иде Равилнең. Шулай да, Кайманов бүлмәсендә ут күргәч, яхшысынмады, туктарга кушты. Җитди эксперимент алдыннан начальник белән күзгә-күз сөйләшү, киңәшү кирәк иде.

Һәрвакыт план үтәлеше, хуҗалык эшләре белән генә мәшгуль төсле тоелса да, кислота кудыруга әзерлек мәсьәләсендә Равил уйлаганнан хәбәрдаррак булып чыкты Кайманов. Аныклыйсы нәрсәләр байтак булып чыкты. Икесенең дә кәефләре яхшы: сөйләштеләр, киңәштеләр, көлешеп тә алдылар.

Кайтырга дип урыннарыннан кузгалгач, Васил өстәленнән ниндидер кәгазьләр актарып чыгарды.

— Мин сиңа бер сюрприз әзерләп куйдым бит әле, Равил Вәлиевич,— диде ул Закировка орден тапшырырга җыенгандай тантаналы итеп. — Бик кызыклы сәфәр чыгып тора монда сиңа.

Равил, сәерсенеп, Каймановка таба борылды.

— Сәфәрләр калып тора, Васил Нигъмәтович, — диде ул битараф кына. — Эксперимент узмый торып, башка берни белән дә шөгыльләнә алмыйм.

Васил мондый җавапны көткән иде ахры, кабат сөйләшүнең рәсми

төс алуын белдерергә теләп булса кирәк, Равилгә өстәл кырыеннан урын тәкъдим итте.

— Экспериментны башкарып чыктык дип исәплә. Тырыштыгыз, рәхмәт. Эш кудыруга гына калгач, Артомонов та булдырыр. Аннан соң без дә бар бит әле монда. Ә менә Бакуга баруны кичектерергә ярамый.

— Бакуга?!

— Әйе, әйе, берләшмәдә, министрлыкта йөдәтә торгач, фатиха алуга ирештем.

— Тәгаен Закиров барырга тиеш дип әйтмәгәннәрдер ич?

— Әйтүен әйтмәделәр. Тик галимнәр арасына теләсә кемне җибәрә алмыйм. Губерт та шул фикердә. Аннан... Аннан без сиңа, Равил Вәлиевич, кичекмәстән, Мәскәүдә, семьяң янында булырга кирәк, дигән карарга да килдек. Юл уңаенда анда сугылып чыгарсың.

Авырткан җиренә басуларына кәефе кырылып, Равил беравык дәшми утырды, угалап утырган кәгазь кисәген чүп савытына ташлады да урыныннан кузгалды.

— Кайгыртуыгыз өчен рәхмәт, Васил Нигъмәтович, эксперимент узгач та китәрмен.

— Юк, юк, — Кайманов ашыгып урыныннан торды, йөзеннән ниндидер шәүлә узгандай булды. — Командировка кәгазе язылган, институтка телеграмма бирелгән — иртәгә юлга чыгарга кирәк.

— Аңламыйм, Васил Нигъмәтович, — диде Равил, ишектән кабат борылып. — Бу кадәр ашыгу нәрсәгә? Алдан бардың ни дә, соңардың ни — бер-ике көн мәсьәләне хәл итми.

Кайманов та торып басты, өстенә киенә-киенә, үзенекен исбатлый башлады:

— Үзең беләсең, безнең эш бер кислотага гына кайтып калмый бит, Равил Вәлиевич. Болай да син аның белән артыграк мавыгып киттең бугай. Йөкне тигез тартыр вакыт җитте төсле, югыйсә, минем камыт кыса башлады. Бу айда планның яну куркынычы бар. Кислота әле һавадагы торна, кулдагы чыпчыкны ычкындырмаска кирәк. Ә ялгызыма кыен, һай кыен аны ычкындырмау. Я, Бакуга да мин чыгып йөгеримме инде? Үз вазифаңны онытырга ярамый, хөрмәтлем... Аннан... семьягыз белән мондый хәл, Анысына да битараф була алмыйбыз без. Синең хакта төрле гайбәтләр йөри. Яхшы түгел. Сөйләшү шушы, кушкан бу нәрсә өстәл төешмичә дә үтәлер, дип уйлыйм.

Равил дәшмәде, Каймановның киенеп беткәнен дә көтми, баскычтан төшеп китте.

## 15

Поезд тәмам акрынайды, ләкин тукталмады, кисәк тартылып, яңадан тизлеген арттырды. Равил, ятагыннан башын күтәреп, тәрәзәгә карады. Әле яктырып җитмәгән, шулай да юл буенданиләр барын шәйләргә мөмкин: инде өтәләнергә өлгергән яфраклары, көзге алмалары белән моңаеп утырган бакчалар эчендә зиннәтле гүрничәләр — дача поселоклары. Менә вак кисенте уртасында утырып калган биек ак каен булып тугыз катлы йорт күренде, икенчесе, өченчесе... Поезд башкалага якынлашып килә иде.

Мәскәү әле тулысынча уянмаган, эшлекле башкала яңа көнгә көч туплап, иртәнге сәгатьтә назлана. Алай да вокзал тирәсе җанлы: чиксез зур илнең әллә кай почмакларыннан җыелган мосафирлар, шәүлә булып кына, вокзалга керә-чыга, кечкенә арбаларын тарткан носильщиклар — әрсез мишәр агайлар, берсен-берсе бүлә-бүлә, юлчыларны үгетли, аларның ризалыгын да көтмичә чемоданнарына ябышып, кыюсыз пассажирларны үзләренә ияртәләр иде.

Кая баруы турында уйланып тормастан, Равил такси тукталышына килде һәм сыңар яшел күзен елтыратып торган машиналарның берсенә утырды.

— Кызыл мәйданга! — диде ул аның боерыгын көтеп калган шоферга.

Күпме сынаганы бар: башкалага килеп төшүгә, аны ниндидер бер серле көч Кызыл мәйданга алып китә. Шунда барып, Ленин Мавзолеена баш ию, чал Кремльгә карап соклану, мәйданның нәкъ уртасына басып, туган илнең пульсын тыңлагандай, берничә минут тын тору аның өчен йолага әверелгән иде инде. Бу юлы да шулай булды, әлеге сихри көч аны тарихи мәйданга әйдәде.

Шәһәр үзенең олы мәшәкате белән ыгы-зыгы кылә башламаган иртәнге мәлдә мәйдан аеруча моңсу-тантаналы. Үз гомерләрендә бик күпне күргән таш диварлар, мәһабәт Спасс манарасы, Рәсәй тарихының күптәнге шаһиты — күп гөмбәзле купшы чиркәү, хәтта аяк астындагы ташлар ниндидер бер героик дастан сөйлиләр төсле. Равил, дымлы ташларга басып, ашыкмый гына Мавзолейга таба атлады. Бу минутта аңа дөньяның бар мәшәкатьләре, ыгы-зыгылары, хафа-борчулары каядыр адашып калгандай тоелды. Изге урын күңелдә изге хисләр генә уята иде. Ул, мәрмәр булып катыккан Мәңгелеккә карап, бер мизгелгә бу фани дөньядан югалып торды сыман. Аннан шундый ук сак адымнар белән мәйдан уртасына барып басты, чал тарих кайтавазын тыңлап, оеп калды. Кинәт ул үзен ничектер җиңеләеп, чистарып, сафланып киткәндәй тойды.

Бераздан инде ул Ленин тауларында, мәшһүр университет бинасы янында басып тора иде. Башкаланың шушы төбәгендәге иркенлек, илаһи матурлык, янынан әледән-әле узып торган шат егетләр һәм кызлар аны тәмам тынычландырды. Равил, саташулы гашыйктай, үзенә якынайган бер төркемне җентекләп карый-карый, университет бинасына якынлашты. Ләкин бу төркемдә кызы Фәридә күренмәде. Алай дисәң, кызы әллә каян үзе танып алыр иде аны. Ул кеше күп йөри торган скверларның берсендә утыргычка утырды да, сигарет кабызып җибәрде, уку йортына таба килүче һәр кешене күзәтә башлады. Фәридәнең яшь болан кебек ыргып килүен, коеп куйгандай сынын әллә каян танып алыр төсле иде ул.

Тик күпме генә утырмасын, җанына якын сын күренмәде. Җитмәсә, инде кояш күтәрелеп, көн тулысынча хакимлек итә башлады, скверда, үтеп-сүтеп йөрүчеләр азайды. «Булмады, күрми калдым», — дип өзгәләнде Равил һәм ашыгып университетка кереп китте.

Дөньяда иң зурлардан саналган бу фән сараенда кирәкле кешене табу салам эскертеннән инә эзләүгә тиң икәнен аңлый иде ул. Өстәвенә, кулында Фәридәнең төгәл адресы да юк. Шулай да кызы укый торган факультетны белүе йөрәгендә өмет чаткысы уята иде. Сораша торгач, филология факультетын, аның Фәридә укый торган бүлеген эзләп тапты. Ләкин беренче курснкылар совхозга бәрәнге алырга киткәннәр икән.

Университеттан боегып, күңелсезләнеп чыкты Равил, кая таба һәм ни өчен баруын абайламастан, урам буйлап китте. Кинәт йөрәге сулкылдап куйды, бөтен тәненә ниндидер чәнчү йөгергәндәй булды — үзен зур җинаять эшләгән кешедәй хис итте. Тагы берничә сәгатьтән тегендә, Зәй буенда гаҗәеп эксперимент башлана, ә ул — шул эш өчен җан атып йөргән кеше ыргым вакытында хезмәттәш дусларын ташлап киткән, башкала урамында гамьсез генә йөрсен, имеш. Моннан да артык сансызлыкның булуы мөмкинме соң? Ялгышты, ах, ялгышты Равил. Ничек тыңлыйсы итте соң ул Каймановны? Ә, әйе, эшсезлектә гаепләве белән чыгырыннан чыгарды аны Васил. Әллә соң кайтып кына китәргәме? Юк инде, Мәскәү хәтле Мәскәүгә килгәч, сөйкемле кызы — Фә-

ридәсен, татлы сызлануы — Әлфиясен күрми, сөйләшми китү мөмкин түгел. Кайтам, процессның ахырына булса да өлгерәм, ди икән, соңгы козыре бар әле аның — Бөгелмәгә соңгы самолет кичке якта гына китә.

Менә күңелгә якын урыннар, урамы, галәмәт зур өе таныш, подъезды, тәрәзә каршындагы яшь карагайлары таныш, тик йөрәгендәге хисләр генә ят иде аңа. Хәер, алары да белгән, кайчандыр кичергән хисләр түгелме соң? Әйе, теге чакны, беренче тапкыр Сафагәрәевләр өенә килгәндәге сыман тартынып тора бугай бит. Менә син, әй, нинди бер бетмәгән малайлык бу?! Тартынсаң, тартынмасаң да, кирәргә, ничә айдан бирле чуалып, төенләнеп килгән киләпне яңадан чорнарга, бер тәртипкә китерергә кирәк ич.

Ишек ачканнан соң, ярым караңгы коридорда басып калган карчыкны танымый торды Равил. Күзе нияләшә төшкәч кенә аның үзен еш кына төче коймак һәм сәйлүн чәе белән сыйлаган мәрхәмәтле ана икәнен абайлап алды, «Исәнме, әби», — дип ике кулын сузды. Юк икән, коридорның караңгырак булуында гына түгел икән хикмәт, Әлфиянең әнисе алар күрешми торган вакыт эчендә нык бирешкән, бөтен килешкилбәте картлыкка тарткан, җилкәсенә салган кара мамык шәле чал чәченең аклыгын тагы да ача төшкән. Җитмәсә, ничектер салкын күреште, элеккечә «кияү» дип өзелеп торырга тырышса да, нидер тыя иде аны.

— Уз, кияү, чишен, — диде ул, коридорны тутырып торган шкафны ачып. — Әлфия үз бүлмәсендә әнә...

Ул, ирләрдән тел яшерә торган борынгы карчыктай, артыгын сөйләми генә кухняга — гомерлек вахтасына үтте. Күзләрен кияүеннән яшерергә тырышуын гына абайлап калды Равил. Шулай да әби кешенең салкын каршылавына әллә ни игътибар бирмәде, олыларныкын белмәссең, бәлки, чирлидер, кәефе китеп торадыр, дип уйлана-уйлана ботинкаларын салды, плащы белән портфелен шкаф башына үрелеп куйды да, эчкә узды. Бөтен идәненә яшел йомшак келәм түшәлгән зал буш иде. Һаман да шул кыюсызлык хисе кичергән хәлдә, сак кына басып, залны үтте, кайчандыр үзе еш кына кунгалап чыккан бүлмә ишегенә килде. Шул мизгелдә халәте кинәт үзгәрде аның, тартыну-тыелуы юкка чыкты, үзен һәрвакыттагыча иркен хис итә башлады, шакымыйнитми генә ишекне ачып җибәрде.

Бусаганы атлауга, битумга ябышкандай, кинәт туктап, шаккатып калды. Урамга караган киң тәрәзә янында моннан егерме ел элеккеге Әлфия басып тора иде. Теге чакта Җигулида кигән су коену костюмы сыман ачык зәңгәр затлы күлмәк гәүдәсенә шул кадәр килешле утырган ки, сөлектәй буен, биленең әле дә булса нечкәлеген сиздереп тора. Башкала парикмахерлары, иннек-кершән аның йөзендәге еллар шәүләсен дә, борчу-мәшәкать эзләрен дә яшергәннәр. Әйтерсең, студентка Әлфия басып тора алдында. Бар да шул ук: матурлыгы да, салкынлыгы да...

Әллә нишләп китте Равил. Шушы таш сын каршына басып башын иясе, юк ла, аны кочагына алып сөясе, берсеннән-берсе татлы сүзләр белән назлыйсы, әллә ниләр кыландырып бетергән әнә шул кара чәчләрен туздыргалап иркәлисе килде. Әмма алай нечкәләнүне күтәрмәгән йөрәге, агач теле бу юлы да хыянәт итте аңа.

— Куян тиреләре базарда очраша, диләр,— дип башлады ул, булган үпкә-зарларын җорлану белән капларга тырышып. — Безгә ярминкәдә очрашу насыйп булган икән.

Равилнең хәбәр-хәтерсез килеп керүеннән өнсез калган Әлфия анымоны әйтергә өлгермәде, кулына чәйнек тотып әнисе килеп керде, кире чыкты, өстәлгә тәм-том китереп куйды. Аннан, шулай ук күләгә булып, тагы китеп югалды. Әллә эчәсе килгәнгә, кайнанасының төлке каны кебек кызыл чәенең тәмен авызында тойгандай булды Равил, ымсынып

куйды. Ләкин Әлфия чәй ясарга ашыкмады, катып калгандай урынында тора бирде. Эре бизәкле чынаякка үзе чәй агызды Равил, өстәл кырыендагы урындыкларның берсенә утырды да шикәрсез-нисез генә чәй йотып куйды, батыраеп сүзен дәвам итте:

— Ярар, шаярмадык түгел, Әлфия, җитте. Җыен да, үзебезнең өйгә кайтыйк.

Әлфия, аны ишетмәгәндәй, байтак торгач кына телгә килде:

— Соң шул, Равил.

Хатынының һаман шулай салкын булуын өнәп бетермәсә дә, сүзнең асат кына бәйләнеп китүенә күңеле булып, очынып сөйләргә тотынды Равил:

— Бүген дип әйтмим. Берәр атнадан, мин Бакудан әйләнеп кайткач. Җыенырга да, аласын алырга да вакыт җитәрлек.

— Мин гомумән соңгару турында сөйлим, — диде Әлфия һәм, ире килеп кергәннән бирле беренче мәртәбә хәрәкәткә килеп, тәрәзәгә борылды, йөзен Равилдән яшерде. — Мин... мин кияүгә чыгам, Равил.

Таудай үпкәләр, рәнҗү катыш усал сүзләр көткән иде Равил, тик мондый тупас шаяруны башына да китермәде. Алай да сүзнең уенга күчүе аны канатландырып җибәргәндәй булды.

— Я, бер-беребезнең бәгырьләрен телгәләми генә, тыныч кына бетерик бу мәрәкәне, — дип дәвам итте ул, сүзен кыскартырга исәп тотып. Тик әйткәненең үтеменә ышанып җитмәде бугай, төплерәк дәлил китерергә булды. — Лениза да бик сагынды үзеңне...

— Лениза?! — Әлфия, кинәт борылып, Равил каршына килде.— Лениза синең сыман сансыз булмас, хатасын аңлагандыр ук әле, кабат килеп җитәр Мәскәүгә. Мин аңа урын сөйләштем инде... Ә мәсьәләне тыныч хәл итүгә килгәндә, син хаклы. Элегрәк күп сөйләшенде бит инде, сүзсез генә бетсен әйдә!

Мондый нәтиҗәдән бөтенләй исереп, хатынын кочып алырга, теге елларда кызчыклары белән уйнаган шикелле чырыйлатып әйләндерергә дип, Равил урыныннан кузгалган гына иде, ишектә звонок шалтырады, Әлфия, өркетелгән боландай, шунда атылды.

Менә хәзер кайнатасы Рәхмәт Сафагәрәев белән күрешәсен күз алдына китереп, Равил суына башлаган чәенә үрелде, берне йоткач, чәйнектән кайнарын агызды һәм комсызланып эчә башлады. Тик шул чак залдан ишетелгән сүзләрдән сискәнеп, чынаягын төшереп җибәрә язды.

— О-о! Син бүген Рафаэль мадоннасыннан мең тапкыр чибәррәк, җаным, — диде бераз гына карлыккан, шулай да гаҗәеп ягымлы ир-ат тавышы. — Әйтәм аны аккош булып төшемә кереп йөдәттең... Менә йөзекләр алдым, гүзәлем. Бөтен Мәскәүдә иң кыйммәтлеләре...

Әлфия нидер әйттеме, ишарә ясадымы, тавышы киселеп калды. Аның каравы Равил йөрәгендә янартау аткандай булып дуамал бер көч дулый башлады. Ул, елан чаккандай, сикереп торды, кинәт атылып, күкрәге белән ишеккә килеп бәрелде. Ябылыр-ябылмас торган пыяла ишек гөрселдәп ике якка ачылып китте. Зал уртасында басып торган Әлфия һәм аның каршындагы зур букет тоткан купшы ир кеше ялт итеп аңа таба борылдылар. Күзләрендә шом, курку иде аларның. Шулай да кунакның елтыр кара күзле, киң кара кашлы, дулкын чәчле чибәр кеше икәнен чамалап алды Равил, ярсуыннан буылып, кызарып янып чыккан күзләрен хатынына төбәде.

— Син... Синең баягы сүзең дөрес мени?

Әлфия керфекләрен идәнгә текәде:

— Дөрес, Равил.

Башына суккандай миңрәп калды Закиров, зиһенен җыя алмый йөдәде. Аннан кинәт кенә тынычлана башлавын тойды, ашыгып сәгатенә карады. Бөгелмәгә оча торган самолет кузгалырга сәгать ярымлап вакыт калган иде.

— Бу синең соңгы сүзеңме? — диде ул ничектер юашланып, битарафланып калган тавыш белән.

— Башка сүзем юк минем, Равил.

Закиров, шашкан кешедәй, коридорга ташланды, юл киемнәре салынган портфелен, плащын элэктерде дә, тышка атылды. Икенче каттан яшен ташыдай төшеп, такси тукталышына йөгерде. Бу минутта аның йөрәгендә Әлфиягә ачу-үпкә дә, рәнҗү дә юк, студентлар белән бергә совхозга киткән Фәридәне күрми калуы өчен өзгәләнү генә иде.

## 16

«Өч нарат арасында адашып үлгән кеше хәленә калуың бар», дигән уй үтте Константинның башыннан һәм күтәрелергә теләп мүкәли башлады. Ләкин тупас резин киеме кул-аякларын богаулый, торып китәргә ирек бирми иде. Шул чак ул җилкәсенә көчле куллар орынганын тоеп алды. Аннары куллар аның биленә төштеләр һәм күтәреп аягына бастырдылар.

Шул ук куәтле кул Артомоновның битеннән маскасын сыдырып алды, әллә чүпрәк, әллә кулъяулык белән яңак-борыннарын сөртергә тотынды.

— Хәлең ничек, Костя?

— Мин фикер йөртәм, димәк, мин бар, — диде Константин, Франциянең милли горурлыгы Рене Декарт сүзләре белән. Күзләрен ачты һәм житен чәчләре тузгыган Закировны күреп алды. Баш инженерның өстендә рәешкә кия торган зәңгәрсу-кара костюм, плащының изүен чишеп җибәргән, яланбаш иде. — Сез... сез нишләп биредә?! Махсус киемнәрсез... Во-он! Вон моннан!

Константин үпкәсенә саф һава керүдән буылып-буылып ютәлли башлады.

— Зарар юк, Костя, зарар юк, — дип акланды Равил. — Мин җил ягында идем, барын күреп тордым. Кием эзләп торыргамы соң... Я, ничек монда?

— Күрәсең ич... Җәһәннәм, — Артомонов инде шактый тынычланган, ютәле басылган иде. — Нишлибез, Равил Вәлиевич, эш харап бит.

— Берни эшләр хәл юк, бу булитны шулай бетерәбез. — Равил инде баягы мескен хәлдән чыккан, тавышы ныгыган иде. — Түбән якка — әрәмә буена чокыр казырга иде. Хәзер үк.

— Амбар әзер. Мин эшнең шулайрак булачагын сизенгән идем.

Равил нидер әйтмәкче иде дә, төчкереп җибәрде.

— Молодец, Костя! Кешеләрне... ках-ках... — инде ул ютәлләргә тотынды. — Кешеләрне чакырасы иде.

Артомонов, авыр чайкала-чайкала, аксыл томан оешып торган җирне урап, машиналар ягына китеп барды. Бераздан инде кайсы кармаланып, кайберләре берсен-берсе җитәкләп, эшчеләр җил уңаена җыелдылар. Килгән бере шыксыз битлеген салып, иңбашына элгән сумкасына тыга торды.

— Мөхсиновтан башка пешүче юкмы? — Константин һәркайсын, бары тик бүген күргәндәй, текәп карады — пешкән-шешкән битләләр күренми иде. Үз яңакларының, кояшны беренче күргән кызлар тәне кебек, кызарып чыкканын сизми иде әле Артомонов.

— Менә нәрсә, егетләр, агрегатлар шул килеш әйләнсен, үзегез шушында гына торыгыз.

Инде механизаторларның да телләре ачылды:

— Тәмуг бу, егетләр, билләһи тәмуг!

— Пары да пары, себерке генә алып киләсе.

— Мөхсинов! Кая олакты әле? Местком председателеннән ул родон ваннасы сорап йөри иде бугай.

— Алды инде ул ваннаны.

Шул рәвешле тел кашыштырсалар да, көлүче булмады. Бу исә хәлнең житдилеген күрсәтә торган барометр иде. Мондый чакта кешеләрнең күңелен күтәреп, рухына азык бирмәденме, эшләрнең чуалачагын көт тә тор.

— Ничево, егетләр, зарланырлык түгел, — дип сүзгә кушылды Равил күңеллерәк булырга тырышып. — Мин әле моннан да хәтәррәк хәлгә тап булырмын, дип кайткан идем. Болай икән, процесс чагыштырмача уңышлы бара дигән сүз. Мин диспетчерга тагы өч агрегат җибәрергә куштым. Без бу булитны бушатып, ашап-эчеп алганчы, килеп тә житәрләр.

— Менә монысы — да!

— Башта ук шулай итәргә иде аны.

— Чистый, нигә тимер кызганырга. Уралда күп ич ул.

Башта ук дублер агрегатлар планлаштырылуын, ләкин аңа Кайманов каршы чыгуын сөйләп тормады Равил. Бирелә сүз куертуның кирәге юк иде. «Процесстан соң җыелырбыз, шунда әйтербез барысын да», дип уйлады ул һәм башлаган сүзен очларга ашыкты:

— Димәк, болай: кичке аштан соң яңа агрегатларны эшкә кушабыз. Ә сезгә, егетләр, үз агрегатларыгызны юып, яңа сальниклар тутырасы булыр. Аннан — алмашу сәгате сукканчы ял.

Шул чак булитлар ягында Илсурның нечкә тавышын калынайтып, карлыктырып мегофон «телгә килде»:

— Машинистлар! По места-ам!

Егетләрне куч сара башладымыни, ашыга-кабалана маскаларын киделәр һәм, калын киемнәре белән алпан-тилпән килеп, машиналары янына йөгерделәр. Илсур исә, көнозын сөйләшми торганның ачуын чыгарырга теләгәндәй, һаман кычкырынуында:

— Беренче, солярка куч! Башкалар моторларын сүндерә. Галиулла абзый, яп булитны!..

Куәтле гөрелте кисәк кенә сүрелде, аннан акрын-акрын тына барып, инде бердәнбер мотор тавышы гына ишетелә иде.

Бәхетләренә, кичке буйда тынып калган җил, караңгы төшү белән тагы күтәрелде — мәйдандагы парны, сөремне, кислота исен каядыр әрәмәгә таба куып китте. Ул арада тирә-юнь бөтенләй тынып калды. Бу вакыт инде булитларның иң зурысы хәтәр йөгеннән арынган иде.

Тәне, әгъзалары сау-сәламәт, башына ишелеп төшкән кайгы килмәгәндә, кешегә бәхетле булу өчен күп кирәкмени? Вагоннар янында уенкөлке ишетелде, кемнәрдер шаркылдап көлде. Эшчеләрне зарыгып көткән пешекчеләр исә, тәмле телләнеп, егетләрне ашарга кыстый иделәр. Константин белән Закиров кына прожекторлар яктысында ничектер серле булып калган җиһазлар арасында, чаптыр-чоптыр пычрак изеп йөриләр иде әле.

— Сизденме, Костя,— диде Равил никтер елмаеп, әйтерсең, бәхет кошы тоткан,— димәк, бөтен сисетмада иң йомшак урын — сальниклар. Бу исә сезнең бүлеккә тагы мәшәкать дигән сүз. Аларны кислотага каршы торырлык материалдан ясарга кирәк: агачмы ул, резинамы, пластмассамы, әллә башка берәр нәрсәме? Эзләргә, әнә Глухов белән дә киңәшергә, табарга кирәк.

— Сөйләве асат, — дип мыгырданды баш инженер алдыннан атлаучы Артомонов. Тик тегесе әллә ишетмәде, әллә ишетмәмешкә салынды:

— Мин бит авиаторлар белән бер нәрсә хакында сөйләшеп кайттым, Костя. Башыңа да килмиме?.. Авиациядә тиешле сәгатен эшләп, яраксызга чыгарылган самолет тәгәрмәчләре. Зур басымга чыдый торган-

нар. Во! Булитлар өчен бер диган көпчәкләр! Бу «ракеталарны» Татарстанның бер почмагыннан икенчесенә күчереп йөртәсе дә була бит әле.

— Монысыннан ничек котылырга диген, Равил Вәлиевич.

— Чү! Дәшмә! Барысы да бик әйбәт. Инженер икәнсең, хәзер үк барын да язып куй кимчелекләрнең: противогаз күзлекләре тирләүне дә, яктылык житешмәвен дә, элемтә мәсьәләсен дә өстә. Барына да чарасы табылыр. Үзең әйткәндәй, инженер эшләмәгән нәрсә юк.

— Мин түгел, Дизель әйткән аны.

— Барыбер, шәп әйткән.

Сөйләшә-сөйләшә мәйданның түбән ягына, яткын жиргә аркылы казылган амбар янына килеп життеләр. Биредә караңгы, шулай да чокырга байтак кына кислота җыелганын шәйләргә мөмкин — астан аксыл пар, тынны буып кислота исе күтәрелә иде.

— Карале, Костя, өстенә су агызырга кирәк моның, нейтральләшсен бу нәмәрсә,— диде Равил.— Иртүк киртәләп кую да зыян итмәс, мал-туарны, белмәссең, төшеп тә чумарлар.

Артомонов җавап бирмәде, шактый тын торганнан соң гына маңгаена сугып куйды.

— Ахмаклар без, Равил Вәлиевич, ахмаклар! Су түгел, известь, сүндерелмәгән известь китерергә кирәк иде монда. Китерергә дә аяк астына түшәргә.

Күр инде, күкерт кислотасының известь белән реакциягә керүе, нейтральләшүе башларына да килмәгән. Һәрнәрсә эштә, тәҗрибәдә ачыклана шул.

— Ну баш та үзеңдә, — диде Равил шаяртуга исәп тотып. — Пожардан соң булса да, уйлый үзе тагын.

Ләкин шаярту барып чыкмады.

— Нишлисең бит... Акыллы башлар качып беткәч ни... — диде Константин хәтере калып. — Әллә уйларга, әллә эшләргә монда... Әнә агрегатлар килде. Кстати, нишләп бик тиз кайттың әле?

Равил авыр сулап куйды, чирле кешедәй йөзен чытты.

— Бармадым мин, Костя, Мәскәүдән борылып кайттым... Син бар, аша да ял ит. Мин үзем, — диде дә, юеш жирдә тая-тая, куәтле машиналар каршына китеп барды.

Чирек сәгать узганнан соң, ярсып-ярсып жир астына реагент кудыручы агрегатлар тавышын тыңлап, «капитан күперчеге»ндә басып торган кеше бөтенләй башка Закиров иде инде. Аның өстендә тупас резин киемнәр, противогаз маскасы кигән башы балаларның яраткан дусты Чиполленога охшап калган, муенына бинокль аскан, кулында мегофон. Шушы сәер киемнәр, әйтерсең, күңелен дә бүтән иткән иде аның.

## 17

Янәшәдәге каен урманы өстендә таң талпынып килгәндә аны Артомонов алыштырды. Константинның әйбәт ял итүе әллә каян күренеп тора: кырынганнан соң яктырып, чистарып калган битендә ниндидер алгысу, яшькелт-зәңгәр күзләрендә мутлык бар сыман.

— Кислота фронтында ни яңалык? — диде ул Равил янына килеп житүгә. — Ага-тамамы?

— Тамгалый башлады, — диде Равил, дымлы һавадан авыраеп калгандай керфекләрен көчкә күтәреп. — Яктырып бетүгә, агрегатларның тегеләрен җик.

Җилкәсен басып торган биноклен, кулын күшектергән мегофонын Константинга бирде дә, нәни генә шәһәрчек булып торган вагоннар ягына китеп барды. Куәтле прожекторлар яктысында, иләмсез гүләгән дизельләр тавышы астында таптанып төн уздыра торгач, сизми дә калган: һава болытлардан арынып, иртәнге салкын төшкән, аяк асты чирап

кипшенгән. Каенлык артыннан күтәрелергә җыенган кояшның нлчеләре булып уйнаган нурлар аяз көн вәгъдә итә иде.

Үз гомерендә мондый нурлы иртәләрне күп күрде Равил. Нинди генә кыен, газаплы төн уздырмасын, яңа туган сабыйдай җиһанга яшәү яме, өмет һәм бәхет алып килүче көн йокыны, ару-талуны, мәлҗүне, таң чыгы белән юып алгандай әллә кая алып китә иде. Ни гаҗәп, бүген алай түгел. Җилкәләр талган, озак басып торудан бите сызлый, аяклары телеграф баганасыдай гүләп тора сыман. Күз кабаклары бер-беренә җилемләгәндәй ябыша, җитмәсә, чатнап башы авырта иде. Аулаграк урынга авып, тәгәрәп-тәгәрәп йоклыйсы, дөньяның бөтен мәшәкатьләрен, ыгы-зыгыларын, йөрәкне туктаусыз тырнап торган ямьсез якларын онытып торасы килә иде.

Шул ният белән юлында очраган беренче вагон ишеген ачты — борынына спирт исе, әллә нинди дарулар исе килеп бәрелде. Ишек башындагы бердәнбер лампочка гына янганга, бүлмә ярым караңгы, шулай да мондагы һәр әйбер, һәр җан иясе аермачык күренә. Яныи торган электр миче кырыенда бирегә каяндыр килеп хуҗа булып алган ала-кола песи «юынып» утыра, медсестра кыз утырган җиреннән өстәлгә капланып йоклап киткән. Уң як стена буендагы сәкедә битен ниндидер май белән буяган Мөхсинов хырлап ята.

Боларны уятмагаем дип, сак кына ишекне япты да, күрше вагонга таба китеп барды Равил. Биредә, бөтен идәнне тутырып, башларын кая туры килсә шунда куеп, агрегатчылар йоклый иде.

Әле монда килгәндә үк вагоннарның икесен — капма-каршы куеп күпер белән тоташтырылганнарын — җитәкчеләр һәм килгән-киткән кунаклар өчендер, дип уйлап алган иде. Шунда таба атлады. Тик анда да юлы уңмады. Берсендә чәчен-башын туздырган Глухов белән ничектер уңайсыз бөкшәеп яткан Илсур хакимлек итсәләр, икенчесендә пан булып, ниндидер сырмалар, запаска алып килгән эш киемнәре арасына чумган Самарин һәм биредә нишләп йөрүләре, ни өчен килүләре бераүгә дә билгеле булмаган тагы биш-алты кеше хуҗа булган иде.

Ашханәгә сугыласы да юк, анда, мөгаен, хатын-кызлар ял итә, аннан бу киемнәрдән ризык тирәсендә уралуы да яхшы түгел. Шулай аптырап йөргәндә бер читтә ничектер боегып, әллә ничә еллык сөремнәре белән каралып утырган ремонт бригадасы культбудкасын күреп алды. Булса, шунда инде тыныч урын: ремонтчылар вахта машинасында кайтып-китеп йөриләр, ә төннең икенче яртысында, гадәттә, эшләмиләр.

Тәрәзәдән үрелеп карауга, өмете аклануына шатланып куйды Равил — культбудка буш иде. Ләкин ул йозакта булып чыкты. Монысы инде Закиров өчен проблема түгел. Ул, капшана торгач, кәкре тимер кисәге табып алды һәм, егетләр үзләре ясаган «хәйләле» йозакны ачып, эчкә узды. Нефтьчеләр китәр алдыннан гына тимер мичне нык кыздырганнар күрәсең, монда җылы, солярка исе аңкып тора иде.

Равил бөтен тәнен буып торган салкын резин киемнәрен салып атты, сөякләре шытырдаганчы сузылды һәм, беркемгә карамый йокларга булып, стенага таба борылды. Тик миендәге ниндидер «сак» изрәп китәргә бирмәде. Йокысызлыкка каршы бик шәп «даруы» бар иде аның. Шушылай гаҗизләнеп урында ауный башладымы, үзе укыган китаплардан иң гыйбрәтлесен, күңелне дулкынландырганын исенә төшерә, андагы вакыйгаларны кино экранындагы кебек күз алдына китерә һәм, шундагы кешеләрнең язмышлары белән хыялланып ята торгач, калгып китә торган иде. Шул әмәле хәтеренә төшеп, күңеленә сеңгән китапларны «барларга» тотынды, әмма бер генә дә рәтле нәрсә тапмады. Ба, кайчаннан бирле кулга китап тоткан юк шул соңгы айларда, дигән уй үтте башыннан, кино-театр дип тә авыз сирәк ачыла... Менә син, әй, чистый Робинзонга әйләнер икән кеше. Ярый әле Ленизасы янында, югыйсә,

саташып уларсең, билләһи. Шунысы бер куаныч, Яшел Түбәдә төпләнде кебек кызый: нефть әзерләү цехына лаборант булып урнашты, институтның кечке бүлегендә укый башлады. Шулай да кыз бала кыз бала инде ул, әнисе әйтмешли — күрше тавыгы, үзенә насыйбы табылуга, китәр дә барыр. Менә шунда башланачак инде чын ялгызлык. Китәр сүз... Хәер, хәзер үк болгана бугай инде ул. Йөзенә бәреп әйтмәсәләр дә, сизеп тора Равил, идарәдә аның турында төрле гайбәтләр йөри, кемнәрдер ни өчендер юри ныграк куертмыйлар да микән әле аны. Өстәвенә Фәһимә белән буталуда гаеплиләр бугай. Анысына да нигез юк түгел шул. Җитәр, нинди генә кешелекле, ярдәмчел булмасын, ул ханымның квартирага кереп-чыгып йөрүенә чик куярга кирәк. Алай кырт киссәң дә аптырау — Лениза бигрәк дөньяның рәтен-чиратын белми шул. Балага, бигрәк тә кыз кешегә, тормыш тәҗрибәсен ана сеңдерергә тиеш иде дә бит, нишлисең, Әлфиянең үзендә юк иде шул ул «тормыш арифметикасы».

Фәһимә дигәннән, беркөн ул ятып торган сәкедә ауный түгелме соң Равил? Күз алдына бөтен ваклыгы белән шул вакыйга килеп басты. Менә тупас брезент киемле Фәһимә булит янында тәгәрәп ята, Равил йөгереп барып аны кулларына күтәрә, ашыга-кабалана культбудкага алып бара. Фәһимәнең тән җылысы киеме аша да сизелеп тора сыман. Шул тойгы Равилгә гаҗәеп бер рәхәтлек бирә, ниндидер шатлыклы бер хис күкрәгe буйлап үрмәләгәндәй була. Менә ул сварщикның тулы, йомры гәүдәсен сәкегә китереп сак кына сала, аның йөзенә иелә. Фәһимәнең тыйнак кына елмаюын, битенә җиңелчә кызыллык йөгерүен әйт син. Равилнең шул алсу йөзне куллары белән сыйпап иркәлисе, хатынның тузгыган чәчләрен рәтләштерәсе килгәндәй булды, мазутлы кием кигән шул ханымга күңеле тартылды.

Кинәт культбудка ишеге ачылды һәм бусагада кулына кечкенә чемодан тоткан хатын-кыз күренде. Ул ике адым ясауга, тимер мич янына килеп җитте һәм, тагын атларгамы, юкмы дигәндәй, туктап калды. Өстенә зәңгәрсу йон костюм кигән ханымның йөзенә карауга, сварка утына эләккәндәй булды Равил — ачык зәңгәр күзләре белән томырылып елмаеп торучы кеше Әлфия иде.

— Менә мин кайттым, акыллым, — диде ул яңгыравык тавыш белән. — Булдыра алсаң, кичер мин тилене. Инде ачуың ташкан икән, сук, орыш, кычкыр. Алай гына да җаның тынмаса, мә сук. Нишләтсәң дә риза, тик кума гына.

Равилнең бәхете тулып ташыды, шулай да сер бирергә, дәшәргә ашыкмады. Җитмәсә, әле генә чит хатын турында уйлавыннан оялып кызарганын тойды.

Әлфия дә башка сүз катмады, башын килешле генә салып, елмаеп торуында. Шулай да сабырлыгы озакка бармады, пышылдап:

— Хөкемеңне көтәм, Равилем, — диде.

Равил атылып торды да, кочагын җәеп, Әлфиягә ташланды. Кинәт тез башы чатнаудан туктап калды. Караса, алдында сөремле тимер мич, будкада исә берәү дә юк иде...

— Фу, черт, — дип сүгенде ул, тезен уып, — кешегә сөйләсәң, кеше ышанмас бит. Уяу килеш саташып ят, имеш... Тәки йоклап булмас күрәсең. — Ул кабат сәкегә үрмәләде, чалкан ятты да, үзен йокысызлык хөкеменә биреп, тынып калды.

Кайчан оеп киткәндер дә, тәмам онытылып күпме йоклагандыр. Бервакыт үткән көннәр хатирәсе миендә кайный башлады. Әле генә су коенып чыкканнар, имеш. Су шундый назлы — йөгерек дулкыннар шыбырдашып килләләр дә, шәрә аякны рәхәт итеп кытыклыйлар. Ә тирәюнь, Идел өсте, бөтен Җигули ниндидер сихри нурга коена, гүя җиһанга бәхет ява. Шуңамы тәндә әйтеп аңлаталмаслык җиңеллек, ниндидер шатлык йөрәкне кыса, алгысыта: каядыр йөгерәсе, дөнья ярып кычкы-

расы килә. Әлфия дә шундый ук хисләр кичерә бугай — ул яшәреп киткән, кыз чагындагыдай бар матурлыгы белән балкый. Әйтерсең сөлек кебек ике кыз үстермәгән дә, замана җилләре аңа кагылмаган. Әллә соң теге чактагы сыман зәңгәрсу коену костюмы киеп алгангамы, әллә инде артык сагынгангамы?

Туктале, бу бит Әлфия түгел, әллә кем. Ничек инде әллә кем булсын, Фәһимә ич! Толымнары, йомры гәүдәсе — барысы да аныкы. Әнә, судан чыгуына карамастан, тәненнән җылы бәреп тора.

Өсләренә киенделәрме, юкмы, әллә инде Иделдән чыккан килеш, балаларча житәкләшеп, үргә, шәһәр үзәгенә таба киттеләр. Зур таш кала урамында икәүдән-икәүләр генә, имеш. Берни сөйләшмиләр, әйтәсе сүзләрен бер-береннең кул җылысыннан аңлыйлар. Юк икән шул, ялгызлары түгел икән. Каршыга килгән трамвайдагылар, аларны күреп, нидер кычкыралар, көлешәләр, туктаусыз кыңгырау шалтыраталар. Берсе узып китеп, тирә-як тынып калуга, икенчесе килә, тагы шау-шу, тагы шалтырау. Менә ул инде тоташ бер зыңгылдауга әверелде, ул да түгел, кайдадыр набат суга башладылар: «Даң-доң, даң-доң». Нәрсә бар, җиһанга ут капканмы, сугыш чыкканмы әллә? Соравына җавап эзләп як-ягына каранырга өлгермәде, каршысына халык дулкыны килгәнне күреп алды. Нәкъ Херосима трагедиясен күрсәткән кинодагы кебек шашынып, берсен-берсе таптап, бәлагә тарган киек-җәнлекләрдәй чинашып килә иде төркем. Ни булганын йөрәге белән тоеп алды Равил: булитлар ярылып, каланы кислота ташкыны баскан! Йөрәге чәнчеп, ыңгырашып куйды һәм... уянып, башын күтәрде. Кемдер тәрәзә рамын төя иде.

— Торыгыз, граф, сезне бөек эшләр көтә!

Артомонов! Шул булмый кем булсын. Ниндидер бер бөек кешегә хезмәтчесе әйткән сүзләрне кабатлый. Мәзәк өчен уятыр микәнни?

Ул арада Константин үзе культбудкага килеп керде.

— Ну, йоклыйсыз, иптәш баш инженер, ә?! Уятыр хәл юк, — дип гөрләде ул. Тавышыннан тәрәзә пыялалары зыңгылдап куйды. — Әйдәгез, кунаклар көтә анда.

— Нинди кунаклар? — дип сорады Равил сүлпән генә һәм, бөтен тәнендә авырту тоеп, кабат урынына ятты.

— Күрше республика нефтьчеләре... Процесс белән танышырга килгәннәр...

Равил сикереп торды, шулай да Константинның сүзләренә ышанмады. Нишләп йөрсеннәр ди алар? Каян ишетсеннәр дә, каян белсеннәр әле монда ни кырганны?

— Менә министр ичмасам. Барын аякка бастырып, төнгә каршы юлга чыгарган бит.

Равил берни аңламый аңа карап торды, йөзенә чытык елмаю чыкты:

— Бөек кешеләрнең сүзләрен такмаклап йөри торгач, саташа башладың бугай син, егеткәй. Нинди министр ул? Сөйләсәң, рәтләп сөйлә!

Константин аның янына утырды.

— Чыннан да, син берни белмисеңме, Равил Вәлиевич?

— Ни белергә тиеш инде мин?

— Кичә бит скважинага министр үзе килде. Әлмәттән үк телеграмма бирдереп, бөтен тирә-күршеләрне күтәргән әнә.

Равил инде бөтенләй аптырап, кызгылт күзләрен мелт-мелт китереп Константинга карап торды.

— Туктале, Костя, саташасыңмы, шаяртасыңмы син? Аңламыйм.

— Менә инде, мин бит бала-чага түгел.

Равил урыныннан купты.

— Менә рәхмәт, менә барып житте хәзер, — диде ул, йокысыннан тәмам айнып. — Менә ни өчен кирәк булган икән минем командировка. Ашыктыруыннан ук шикләнгән идем... Тагын кемнәр бар иде?

— Берләшмә житәкчеләре, Кайманов... Башкаларын сорап та тор-

мадым, процесс башланган иде, — дип, Константин ишектән тышка атлады.

Равил дә, аның артыннан чыгып, өс-башын бераз тәртипкә китерде дә, вагоннар янында җыелып торган кунакларга таба китеп барды.

18

Кунакларны озаткач, ничектер җиңеләеп, тынып калгандай булды Равил. Болай бушанып калу тойгысын соңгы көннәрдә кичергәне юк иде әле аның: һаман каядыр ашыкты, кабаланды, нәрсәдер эшләп бетермәде, ятса да, торса да җилкәсен нидер басып тора сыман иде. Бүген, төш аугач исә, шул халәте үзгәрде, әйтерсең, иңенә күтәреп торган тау кадәр йөкне дәрьяга ташлады. Нилектән болай икәненә эш мәйданын урап, вагоннар тирәсен әйләнгәннән соң төшенде. Скважина тирәсе аулакланып калган икән: артык-портык кешеләр кайтып беткән, хәтта ничә көннәрдән бирле шушында кунып-төнеп яткан Глухов та каядыр китеп олаккан иде. Баксаң, процесс беткәнче монда булырга тиешлеләр дә кайсы кая таралып беткән. Көне бик матур шул: берәүләр әрәмәдә йөрсә, икенчеләре урман һавасы сулый булыр. Димәк, башкалада да шундый ук халәт, дип исәп йөртте Равил. Шулай булуы да табигый: процесс күптән тигез бер ритм белән бара, агрегатлар инде хәтәр йөкнең соңгы тонналарын җир астына куалар.

Дөресен әйткәндә, биредә инде баш инженерның үзенә дә эш калмаган иде. Вак-төяк кимчелекләрне, кайберәүләрнең битләре кызарып чыгуын исәпкә алмаганда эксперимент уңышлы башкарылды дип санарга була. Шулай да китә алмый Равил, ниндидер сихри көч аны процесс беткәнчегә кадәр скважинага бәйләп куйган иде. Җитмәсә, Габит-ташбаш күренми бит әле. Төш аугач килерсең, дип әйткән иде, югыйсә.

Чирәмгә чыгарып куелган аш өстәле янында аптырап-йөдәп бераз утырды да, сәгатенә карап алды. Исәпләве буенча, процесс тәмамланырга сәгать ярымлап вакыт бар иде әле. Ятсаң, йоклар ара калмаган, болай тик утыру да газап кына. Ниндидер бер моң, ашкыну белән эшләп утырган агрегатлар ягына карап алды да, янәшәдәге каен урманына таба кузгалды. Язымга таем дигәндәй, такыр гына сукмакка туры килде. Уң ягында сирәк кенә эре урман — кочакка сыймастай каен агачлары. Сул якта исә скважиналар рәте. Биредә бораулау эшләре күптән булып узган бугай, трассаны яшь усак, вак каен баскан, чикләвек куаклары иркенләп үсеп киткән.

Табигатьнең кодрәтенә сокланып, мондагы тынлыкка табынып, күпме баргандыр, трассадагы юлдан, җиңел генә гүләп, автомобиль узгандай булды. Әллә шул кадәр җитез үтеп китте, әллә туктады, минут эчендә тавышы ишетелмәс булды. Моңа әһәмият бирмәстән, сукмак буйлап ун-унбиш адым китмәде, чикләвек куагы артындагы ачыклыкта «үз» машинасын күреп алды — Габитның аны эзләп йөрүе микәнни?

Әмма егеттә начальнигы кайгысы түгел икән. Ул урыныннан җитез генә сикереп төште дә, машинасын әйләнеп үтте һәм, шомарып беткән таксист кебек, ялтырап торган ишекне ачты. Машинадан, очынып-канатланып, Лениза килеп чыкты. Кызын күп еллардан соң беренче күргәндәй ымсынып куйды Равил. Бар икән чибәрлек тә, гел әнисе, дигән уй үтте башыннан.

Ә кызый, чыннан да, гадәттәгедән матур иде бүген. Матур гына да түгел, ничектер үзгә. Һәрвакыт җитди, уйчан йөзендә нур, елмаю тантана итә. Ул кирәксә дә, кирәкмәсә дә, чыркылдап көлә, шуклана. Килеш-кыяфәте дә бүтән бүген Ленизаның. Сабын күбеге булып күпергән аксыл чәчен үтә күренмәле шәмәхә кыекча белән буган. Өстендәге ак кремплин күлмәге дә бик килешле, кызның өзелергә торган билен, тый-

нак кына төртеп торган күкрәген аерып күрсәтү өчен тегелгән төсле. Габитын әйт тагы, элек һәрвакыт изүен ярып төшергән «олимпейка», салкынрак көннәрдә чыштырдап торган таплы куртка киеп йөргәнгә йолкыш кына бер шофер булып күренгән үсмер кызлар күзе төшәрлек егет икән ләбаса. Затлы костюм белән ак нейлон күлмәге һәм күпертмә бизәкле саргылт галстугы шулай күрсәтәме, җилкәсенә төшеп торган кыл кебек җиту чәче, атналар буе пәке тидерми саклаган мыек сыман нәрсәсе мәһабәтлек бирәме, һәрхәлдә, ул инде малай Габит түгел иде.

Көтмәгәндә бик кыен хәлгә калуын абайлап, нишләргә белмәде Равил. Борылып китәр генә иде, аяк тавышын ишетеп, күреп алачаклар. Болай чекрәеп, кызыңның егет белән сөйләшүен карап тору да шәп түгел. Башка чарасы булмагач, куак төбенә, корышып килгән абагалар арасына чүкте.

Яшьләрнең исә тирә-юньдә гамьнәре юк, үз дөньялары дөнья — тукталу, машинадан төшү мәшәкате белән бүленеп калган бәхәсләрен дәвам итәләр иде.

— Нигә? Шушы урман-кырларга, үзән-болыннарга хуҗа сыман, аларны барлагандай, көнгә берничә урау бәхете тагын кемгә тия?

Шоферның шулай илһамланып, бераз гына артистланып сөйләвен беренче тапкыр ишетүе Равилнең. Лениза исә, тыштан үзгәрсә дә, Лениза булып калган. Әнә бит ничек төпле сөйләшә.

— Димәк, син язмышыңнан канәгать?

— Зарланмыйм.

— Ал-лай.

Ярый әле мәхәббәт турында сөйләшмиләр дип үз алдына куанып утырды Равил. Күз алдында чуп-чуп үбешә башласалар да, берни эшләр хәлең юк.

— Күз алдыңа китер, Лениза! Каршыңда ерак-еракларга сузылган Зәй үзәне, өсләрендә рәшә тирбәлгән әрәмәләр, басулар, зәңгәрләнеп торган урманнар. Үзгә табигатьле, машиналы, шау-шулы туган ягым— менә шул инде минем бәхетем, Лениза!

Кыз шактый гына дәшми торды, аннан үкенүле тавыш белән әйтеп куйды:

— Шунысы аяныч, Габит, бу якларның йөзен без түгел, безнең этиләр үзгәрткән.

— Ә без?

— Ә без хәзергә җиңел машинада утырып йөрибез. Бары шул.

— Бөтен кешегә дә йөк машинасына утырырга димәгән.

— Өрлектәй егетләрнең начальниклар ташып йөрүенә йөрәгем әрни минем. Ничектер кимсенүле күрәм мин сезнең эшне.

— Менә ничек!

— Инженер дипломы алырга башы җиткән кеше машина йөртә белмәс идеме? Йөртерләр иде — теләкләре юк. Менә синең кебек егетләр гарьләнә белмәгәнгә шулай ул, Габит. Укырга кирәк безгә.

— Укырга дисең...

Шулчак, тирә-юньне дер селкетеп, трассага куәтле машина килеп керде, яшьләрнең бәхәсе өзелде. Тавыштан файдаланып, Равил урман арасына шылды. «Их, Лениза, Лениза, — дип сөйләнде ул үз алдына,— егетләр белән шулай сөйләшәләрме? Әтиең кебек агач тел, туң йөрәк булырсың микәнни?»

— Әч-әч... әллә күрше? Сиңа да эш калмадымыни соң, бахыр?

Тавыш килгән якка борылган иде, үлән арасында чекрәеп утырган ап-ак чәчәкләр күреп алды. «Җиләк кабат чәчәк аткан — көз озын киләчәк быел», — дигән уй үтте башыннан. Ул да түгел, өянке булып утырган шомырт куагы төбендә чирәмгә җәелгән сырма өстендә утыручы Фәһимәне күреп алды. Ул, әйтерсең, монда ялга килгән: җылы

киемнәрен салып сузылып яткан, акка зәңгәр чәчәкләр төшерелгән кыска җиңле күлмәктән, яланбаш, кулында китап иде.

— Сез... син бирелә мени? — диде Равил башка сүзе булмаганнан гына. — Күзгә-башка күренмәгәч, кайтып киткәнсең дип торам.

Ир-ат алдында җәелеп ятуны яхшысынмады бугай, Фәһимә торып басты, күкрәгенә төшеп торган толымнарын артка чөйде дә туфлиен кия башлады.

— Китеп барсаң да аптырау, сезнең ул зәхмәтнең агып беткәнен көтеп утыруы да кыен, — диде Фәһимә көйләбрәк. — Вакыт үткәреп йөрим шулай.

— Шәһәргә кайтасың калган.

— Сварка кирәк булыр, диделәр бит.

— Анысы да хак. Процесс бетүгә, су линиясен ялгыйбыз.

— Әле шөкер, вагонда синең сыман аунамадым, — дип тезеп китте Фәһимә, сердәше белән серләшкәндәй иркенләп. — Ә-әнә тегендә, урман буенда бер авыл кисәге бар икән, ун-унбиш кенә өйле. Кырый йортта гына ялгыз карчык тора. Инде дә кешелекле, инде дә юмарт әби. Кислотагызны гына өнәп бетерми, «Дөнья корыткычлар», — ди. Шунда яшәп яткан көн.

— Үзең тагы бер дә алдатмыйсың, — диде Равил һәм, күзлеген сөртергә исәпләп, кесәсеннән кульяулыгын чыгарды. Әмма уйлаганын эшләргә өлгермәде, Фәһимә бөтен урманны ярып кычкырып җибәрде:

— Әнекәем, кульяулыгың! Кит инде, инженер кеше шул кадәр керле яулык йөртәме? Китер, хәзер үк чайкап элим әле мин аны. — Ул Равил кулындагы өтек чүпрәкне тартып алды да, чирәмдә яткан сумкасына иелде, аннан күбектәй ак нәфис яулык тартып алды. — Мә, шуны йөртә тор ичмасам.

Равил гарьлегеннән кызарды, тирләп чыкты, шулай да кульяулыктан баш тартмады.

— Уф, үләм, якаларың тагы! — дип дәвам итте Фәһимә, Равилнең нейлон күлмәге якасын кайтарып. — Пычак үткерләрлек булган ич. Ул костюмыңның өтеклеге. Болары шушындый икән, эчке киемнәрең нәрсә инде анда? Их, иптәш инженер, иптәш инженер! Йөрмә болай, иртәрәк кайт бүген, һәйбәтләп кенә юып куярбыз.

Кызык, Фәһимәнең шулай сөйләнүе аны инде һич кенә дә гарьләндерми, киресенчә, иркәләнүгәме, назлануга охшаш хис уята иде. Алай гынамы, Фәһимәнең шулай такмаклавын бик озак тыңлап торасы килә иде аның. Тик һич көтмәгән тавыш — Лениза тавышы аны сискәндереп җибәрде.

— Фәһимә апа?! Менә кайда икәнсең син! Үзең бәлеш ясарга өйрәтәм дидең, үзең кайтып та кермисең, — дип такмаклый-такмаклый, кыз Фәһимәне кочаклап алды, шулчак күзе әтисенә төште. — Әти?! Нигә инде өйгә кереп тә чыкмадың? Мәскәүдә булдыңмы? Безнекеләр нихәл анда?

Зур җинаять өстендә тоттылармыни, Равилнең колакларына кадәр кызышты, ни дип җавап бирергә дә белмәде, ярдәм эзләгәндәй артына борылды, анда исә үзе кебек үк кызарып, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп, Габит басып тора иде.

— Өйгә кереп тора алмадым шул, кызым, — диде ул телен көчкә әйләндереп. — Ни... Мәскәүдә булырга да туры килмәде... Әйдәгез, процесс тәмамлангандыр инде.

Ул килеп җиткәндә скважина тирәсе тып-тын, тик каралып, ничектер боеккандай калган җиһазлар гына тирә-якка яман ис чәчеп утыралар иде. Культбудка яныннан узганда ачык тәрәзәдән Артомонов тавышын ишетеп алды. Рация өстенә иелеп, бөтен көченә кычкыра иде Константин:

— Аяклары пеште дим! А-як-лары!

Равилнең йөрәге «жу-у» итеп куйды. Ни өчендер, культбудкага түгел, скважина янына ташланды. Будканың икенче ягына чыгута, чегән таборына юлыккандай булды: эшчеләр тупас резин киемнәрен, аякны тирләтә торган итекләрен салып атканнар да, үлән өстенә тәгәрәшкәннәр. Кайсы тәмәке көйрәтә, кайсы, төнозын йокламавына карамастан, мәзәк корып маташа, кайсы, кулын баш астына куеп, изрәп ята иде. Мондагы ваемсызлыкны күрүгә Равил бераз тынычлангандай булды, шулай да шөбһәсе кимемәде. Ашыгып төркем янына килде һәм берәүгә дә төбәми генә:

— Ни булды? — диде.

Кайтарып җавап бирүче булмады, аның килүен сизмәделәр дә диярсең. Житмәсә, Мөхсинов иләмсез авызын җыеп алалмый утыра. Тынлык эчендә узган берничә секунд ел булып тоелды Равилгә. Ниһаять, Мөхсиновның кабартма иреннәре җыелды, үзе, урыныннан кузгалып, майлы сырмасына тезләнде.

— Закуска бар, иптәш инженер, калганы сездән, — диде ул, кош тоткандай балкып.

Кызык булмаса да, гөр итеп көлешеп алдылар. Аннан барысы бердәм нидер сөйләргә тотынды. Бу бака туеннан берни аңламаган Равил, ярдәм эзләгәндәй, артына борылды, культбудка баскычыннан төшеп килүче Константинны күреп алды.

— Аңлатып бир әле, Костя, ни булды сезнең монда? — диде ул, Артомонов каршына басып.

— Менә син, ай, — диде Константин аклангандай. — Бәла аяк астында диюләре хак икән... Кем уйлаган...

Равилнең сабырлыгы бетте, кызарып чыкты.

— Адәм рәтле сүз сөйләрлегең калмады мәллә? Нәрсә бар в конце концов?

— Кот очарлык нәрсә юк, — дип сөйләп китте Артомонов, — әбинең казы, дөресрәге, аяклары пешкән әнә.

Будка буенда авызын чәчәкле шәлъяулык почмагы белән каплап, өнсез генә торган карчыкны һәм аның аягы очында чирәмдә утырган ала-кола казны шунда гына күреп алды Равил. Тәмам тынычлап, кесәсеннән сигарет чыгарды, аны кабызып, ничек болай килеп чыгуын сораштыра башлады.

Ә вакыйга менә болай булган икән. Кислотаны кудырып бетергәч, мәйданга бала-чага, мал-туар килеп кермәсен дип, күз-колак булырга Хәйри Хәйретдиновичны калдырганнар да, үзләре чирәмгә чыгып ял итәргә утырганнар икән. Авыл скважинага бик якын булмагач, ул-бу килеп чыгудан шикләнмәгәннәр дә. Самарин да, хәтәр йөктән исән-имин котылуларына шатланып, ваемсызланыбрак калган. Житмәсә, бик кысталган чагы икән, таллыкка ук кереп киткән. Язымга-таем ничек чыгып тора диген, шул чак авыл ягыннан шушы дуадак каз килеп чыккан һәм, гомер су күрмәгәндәй, мәйдандагы күлдәвекләргә ташланган. Казына тагылып ук диярлек атлаcorrect да, әби ала-коласын коткара алмый калган икән.

Бер караганда мәзәк сыман гына булса да, күңелле хәл түгел иде бу.

— Менә нәрсә, Костя,— диде Равил борсаланып,— хәзер үк диспетчер белән сөйләш, нишләп известь китермиләр һаман.

Ул хакта сөйләшенгән булса да, Артомонов культбудкага кереп китте. Равил исә карчык янынарак килде, нәзакатьле генә исәнләште. Әби дә зур начальник килүен аңлап алды бугай, битен тагы да каплый төшеп, зар-моңын сөйләргә әзерләнде, тик нәрсәдән башларга белми аптырап калды. Равил үзе ярдәмгә килде.

— Казың кыйммәт торамы, әбекәй?

Үз телендә әйтелгән җылы сүз җитә калды әбигә, бердәнбер казы

бәлагә тарган вакыт эчендә башына килгән уйларын такмакларга тотынды:

— Кыйбатмы диеп, сатарга үстергән мал мыни соң ул, апаем. Ишек алдында каңгылдап йөргән бердәнберем не бит җанкисәгем. Күкәйләре буш булып, дуадак калгач та уйлаган ием аны, хәерлегә түгел бу, дигән ием. И шулай булып чыкты да. Шушы исле нәмәгезне авыл кырыена китереп түкмәсәгез, урын беткән иеме соң? И аллам, замана ахырлары шулдыр инде.

Гәпнең озакка китүен сизеп, Равил сүзне кыскартырга, әбине юатырга булды:

— Ә син борчылма, әбекәй. Бәясен генә әйт, хәзер үк түләрбез. Ну, унбиш... егерме сум.

Акча сүзен ишеткәч, карчык тынычлар, шуның белән сүз дә бетәр, дип көткән иде Равил. Әмма әбинең үз туксаны туксан иде.

— И олан, акча кирәкмени миңа. Улым сезнең кебек үк нифтедә, җир-су бозып йөри. Килен дә шул нифте дип акайган. Рәхмәт мине ташламыйлар үзләре тагы: әле берсе, әле икенчесе кайтара акчаны. Утынын да китерәләр, кием-салымын да алып кына торалар. Әле үзләре, зурысын алгач, иске телевизорларына хәтле китереп куйдылар. Нишлим ди мин ул акча белән. Акча бит ул ишек алдында ошбу җанкисәгем кебек сүләшеп йөрми.

«Арзанга бирәсе килми үзе», — дип уйлады Равил эченнән, аның сүзләрен сатулашуга санап. Нишлисең, гаеп бездә булгач, акчасында торырга ярамый. Тавыш кына чыкмасын, эшне шунда бетерергә кирәк. Ул, куен кесәсенә тыгылып, бер уч бишлек чыгарды.

— Ярый алайса, егерме биш, ну, утыз сум, әбекәй. Килештекме?!

Карчык шактый гына дәшми торды, әмма акчага үрелмәде.

— И-и, олан, шушы наныйның ишек алдында бер каңгылдавы бер гомер ич миңа.

Сатулашу Равилне туйдыра башлаган иде инде, ун бишлек санап алды да, каз хуҗасына сузды:

— Илле сум, әбекәй. Әйдә, бәхилләшик.

Тик карчык бу юлы да акчага сузылмады, алъяпкыч кесәсеннән бер телем икмәк чыгарды да, аны ваклаштырып, казы алдына чирәмгә салды.

— Әйттем ич, акча кирәкми диеп.

Ниһаять, карчыкның ниятен аңлады Равил, бүтән баш каз сорый булып чыга бу. Башыңа төшкәч, башмакчы буласың дигәндәй, каз эзләп йөрергә кала инде, күрәсең.

— Ярый, Костя, идарә исеменнән йөкләмә сыман нәрсә язып бирик әбигә, — дип янына чыгып баскан Артомоновка борылды.

Ярдәмгә Мөхсинов килеп җиткән икән.

— Кәнишне, шулай итәргә, — диде ул бик җитди чырай белән. — Каз беткәнмени дөньяда. Бер дә кайгырма, әби, өеңә үк китереп куярлар. Бу имгәгең калсын шунда.

— Кит, кит, булмаганны. Каз өчен кешедән кәгазь аламмы соң. Нишлисең, хак язганы шулдыр. Инде ниятегез чын икән, китереп бирерсез бер. Анау йорттан Сажидә мин. — Ул авыл ягына ишарәләде. Аннан иелеп казының аркасыннан сыйпады, ул да түгел, кисәк кенә күзләрен каплап, китеп барды. Культбудка янын авыр тынлык басты.

Шунда гына аңына килде Равил. Сажидә?! Сажидә дидеме? Тукта, бу аның Сажидә апасы түгелме соң? Теге елларда җир җимертеп йөргән хатын шулай картайганмы? Шул! Әйтәм аны тавышы таныш төсле. Күр инде, Сафчишмә янында ук эшләп яталар икән лә. Үзгәргән, нык үзгәргән бу тирәләр. Саклыйбыз, саклыйбыз дия-дия дә, шактый кыерсытыла икән шул табигать. Әнә бит урманны ярып, ничә җирдән скважиналар рәте үткән, авыл кырыена ук нефть җыю пункты салынган.

«Дөнья корыткычлар», дип юкка гына тиргәми икән шул Сажидә апа. Чү, китеп үк бара бит. Рәнжеп, үпкәләп китә. Равил шашкан кешедәй кычкырып җибәрде:

— Сажидә апа!

Ике-өч сикерүдә карчыкны куып җитте. Тегесе исә аның шөкәтсез тавышыннан курыктымы, аяк тавышына сискәнепме, артына борылды.

— Сажидә апа! — диде Равил, тынына капланып. — Сажидә апа! Танышсыңмы мине? Равил бит мин!

Карчык, аңа яшьле күзләрен төбәп, гаҗәпләнгәндәй, озак карап торды. Алдыннан Равил шәүләсе югалып, томан пәрдәсе генә калгач, сыкранып, шулай да каты тавыш белән әйтеп куйды:

— Юк, мин сине белмим, олан!

Равилгә бик авыр булып китте, гаебен йоларга теләп, карчыкны җитәкләп алды.

— Алай димә, Сажидә апа. Хәзер барын да аңлатам... Әйдә, озатып куйыйм... Ә казны... казны табабыз аны. Менә дигәнен.

Культбудка янындагылар, баш инженерның болай кисәк кенә исәрләнүен нәрсәгә дә юрарга белмичә озак карап тордылар. Ниһаять, Самарин телгә килде:

— Бу имгәкне нишләтәбез инде? Илтеп бирик әбинең үзенә.

— Дөньяда ничә ел яшәп, зыянлаган малны нишләтүләрен белмисеңме? — диде Мөхсинов, кесәсеннән пәке чыгарып. Аннан казны күтәреп алды да, култыгына кыстырып, бер читкә атлады.

Тынып калдылар. Шулай күпме ятканнардыр, арадан берсе көрсенде һәм әйтеп куйды:

— Урман-кырларны харап итәбез бит, егетләр.

Самарин да шундый уй белән утырган, шул турыда гәп корырга теле кычытып торган, күрәсең, сүзне күтәреп алды:

— Күрәлэтә кеше үтермәгәек диген.

— Сиңа-то берни булма, Хәйри Хәйретдинович, — дип кычкырды кемдер, арткы рәтләрдән. — Кислота алырлык нәрсәң калмаган инде синең.

Шаркылдап көлешеп алдылар, тик күңеллелек озакка бармады.

— Табигать тә жалко, Самарин, — диде бая сүз башлаган машинист, — скважина турындагы талларны күрдеңме соң? Яфраклары кырау суккандай шиңеп төшкән мескеннәрнең.

Кайберәүләр торып ук утырды.

— Үләннәр дә янып-көйгән.

Сикерешеп тордылар, кулларын бутый-бутый, шаулашырга тотындылар:

— Җитәр! Кислота белән шаяруга юл куймаска кирәк.

— Бүтән бармыйбыз процессларына. Күрәлэтә үлемгә кереп булмый инде!

— Мәскәүгә язарга кирәк.

Барысының тавышын күмеп, Артомонов кычкырды:

— Туктагыз әле! Нинди бака туе бу?! Бу ниткән бунт? Башыгыз белән уйлап карагыз әлек.

Машинистлар тынып калды да, әйдә, сайра инде дигәндәй, илтифатсыз гына урыннарына утырдылар.

— Сезнеңчә җирнең өсте ал да гөл булсын, ә астындагы байлыклары шул килеш ятып калсын. Шулаймы?! — дип дәвам итте Константин, гадәттәге басынкы тавышы белән. — Юу-у-ук, алай батмый, егетләр. Менә хәзер, шушы минутта дөньяга бер грамм да нефть калмаган итеп күз алдына китерегез әле. Ни килеп чыгар икән?

— Анысы да бар, — дип килеште бәхәсне үзе башлаган машинист. — Ул чакта агрегатларыңны шушында калдыр да, җәяүләп кайтып кит инде. Да, кызык хәл булыр иде ул: бер генә машина да йөрмәс,

самолетлар очмас, поезд-теплоходлар туктар, тракторлар җир сөрмәс...

— Алай гына да түгел, — дип аңа таба борылды Константин. — Аяк киемнәре, синтетик сүс, ислемай һәм башка меңләгән төр товарлар эшләп чыгаручы фабрикалар тынып калыр, әнә шул син санаган машиналарны йөртү, галәмгә очыру өчен яңа төр ягулык эзләргә, үзебезнең авыздан өзеп, фабрикаларга бөртек, бәрәңге озатырга туры килер, санап очына чыга алмаслык мәшәкать туар иде.

— Шулаен шулай инде, — диештеләр нефтьчеләр.

Артомонов, сөйләгән кадәресен сеңдерсеннәр әле дигәндәй, бераз туктап торды да, кабат тезеп китте:

— Урман кискәндә, йомычка чәчрәми калмый, ди безнең рус халкы. Көрәш корбансыз булмаган кебек, нефть чыгару да югалтусыз булмый. Хәтерегездәме, баштагы елларда күпме нефть түктек, күпме җир-су пычраттык. Аннан килеп, тозлы суларны җыя алмый күпме изаландык. Хәзер бөтенләй башка картина бит. Безнең Яшел Түбә нефтьчеләре генә колхозларга йөзләрчә гектар җир кайтарып бирде. Бирде генә түгел, аларны, ташлардан, тимер-томырдан чистартып, ашладылар, уңдырышлы иттеләр. Зәй, Шушма елгаларында балык тота башладык. Хуҗаларча эш иткәндә, бүре дә тук, сарык та исән икән ләбаса! Хикмәт шунда, егетләр, нефтьне дә алырга, табигатьне дә сакларга кирәк. Аны ничек эшләү исә бездән тора. Без лучше кислота кудырудагы кимчелекләрне бетерү, яңа сальниклар булдыру хакында сөйләшик. Анысы егетләрчә булыр...

Сүзнең ахырын Мөхсинов та тыңлап торган икән.

— Ташлагыз әле, юк белән баш ватуны, — диде ул ялтырап киткән кып-кызыл йөзенә борчылу галәмәте чыгарып. — Казны пешерергә кирәк, казны. Моталлап, бар, утынга йөгер!

Равил скважинага әйләнеп кайтканда, җиһазлар җыелган, агрегатлар әрәмә буена тезеп куелган, Илсур белән Самарин кислота түгелгән урыннарга известь түшәтеп йөри, ә Артомонов группасы белән ремонтчылар бригадасы су кудыру линиясен ялгап маташалар иде. Машинистлар исә ялгыз өянке төбендәге учак янына җыелганнар да мәзәк корып утыралар. Һавага җиңелчә генә таралган тәмле истән аларның каз пешүен көтүләрен аңышып алды Равил.

— Закуска әзер, — дип каршылады аны авызы колагына җиткән Мөхсинов. — Соңгы сүз сездән, Равил Вәлиевич.

— Соңгы сүз икән, соңгы сүз, — Равил кесәсеннән бер уч акча алып түгәрәк уртасына, җиргә ташлады. — Тик исерештән түгел.

Кай арада кибеткә барып кайтканнар диген, корымлы чиләктән каз алынганда, газета кисәкләре җыелган табында ак чалмаларын елтыратып берничә шешә утыра иде. Стаканнарын да тапканнар. Чисталыклары әллә нидән түгел түгелен — кайсы майдан бушаган, кайсы катык салып эчкән килеш. Хәер, аракыга пычрак тия мени?

Бүген пешекче дә, табынчы да Мөхсинов иде. Ул, мулла булып кылана-кылана, һич уйламаганда мондый нигъмәт белән сыйлаучы әбигә рәхмәт укырга, куллары белән казны ботарларга тотынды. Стаканнарга кайсыдыр аракы сала башлады. Арадагы бердәнбер кружканы Равилгә китереп тоттырдылар. Ул башта малайлар сыман мавыгып китүенә үзен-үзе битәрләп утырса да, эшләр болайга киткәч, мәҗлескә рәсми тон бирергә булды.

— Ягез, барыгызны да җиңү белән котлыйм, — диде ул, кружкасын күтәреп.

Салган аракыларын эчеп бетермәделәр, скважиналар рәте буйлап йөгереп килүче кешене күреп алдылар. Чәчләре тузгып, башы-күзе тонган бу кеше Глухов иде. Ул төркем янына якынлашуга кулларын бутарга, кычкырырга тотынды:

— Егетләр! Равил Вәлиевич!.. Җиңү! Җиңү!..

Равил, аның килеп җиткәнен көтеп алды да, тыныч кына сорап куйды:

— Туктале, Вениамин, иплэп кенә. Ни бар?

— Без нефтьче-операторлар белән тирә-күрше скважиналарны урап чыктык, — диде Глухов тынына капланып, — алардан нефть алу сизелерлек арткан. Су бармы, су?

Равил аңа аракылы стакан сузды.

— Миңа монсы баса төшә сусынны.

Вениамин кулын гына селтәде.

— Скважинага кудыра торган су хакында мин.

— Озакламый водоводны ачалар, — диде Равил елмаеп. — Җиңү тек җиңү. Котлыйм, Вениамин. Мәле шуны тотып җибәр.

Глухов стакандагыны голт-голт итеп эчеп тә куйды. Аннан, үзенә сузылган ит кисәген дә алмыйча, чирәмгә чүкте. Бу минутта аның кыяфәте бик мескен иде — күзләре утырып калган, битен сакал-мыек баскан, киемнәре өтек.

— Кайтып ял итәр идең, Веня, — диде Равил, аңа кызганулы карап. — Хәзер әйтәм: илтеп куярлар үзеңне.

— Што син, што син, Рево. Бер тәүлек су кудыргач, күрше скважиналарны дебитен үлчибез әле без.

## 19

— Равил Вәлиевич?! Син?.. Син ничек биредә?!

Авызы тулы каз итен чәйнәүдән туктап калды Равил, ләкин әйләнеп карамады. Яңагын бүлтәйтем торган ризыкны, аннан-моннан гына әвеләп, йотып җибәрде дә, артына борылды. Аңардан бер адымда гына сөмсере коелган Кайманов, аның янәшәсендә гөнаһсыз Санчо-Панса кыяфәтендә Борһанов басып торалар иде. Идарә начальнигының бу кадәр дә кара янып дәһшәтен йөзенә чыгарган чагын күргәне юк иде әле Равилнең.

— Әә без — беркатлылар Бакудан телеграмма көтәбез тагы,— диде Васил ачуына буылып һәм, кисәк борылып, капма-каршы куелган будкаларга таба китеп барды. Мидхәт исә, инәгә тагылган җеп кебек, аның артыннан атлады.

Күңелле генә барган мәҗлеснең бозылуына кәефләре кырылып, мондагыларның кайсы торып китте, кайсы урыныннан кузгалып та тормый чирәмгә тәгәрәде. Бер Мөхсинов кына ашалмый калган каз канатларын ялманып, шешә төпләрендә калган эчемлекне бер стаканга җыеп маташа иде.

— Ташласана, мәңге ач торган кебек кыланасың, — диде аңа Равил үртәлеп. Аннан, карашын тирәкнең бүртеп торган калын тамырына башын куеп яткан Вениаминга текәп, уйланып калды. Әнә шулай чирәмгә авып, дөньяның бөтен мәшәкатьләрен, ыгы-зыгыларын онытып, ял итәргә иде дә бит исәбе. Булмады. Начальство алдында туарылып ята алмыйсың шул. Туктале, ни җимертеп йөрүләре боларның?

Ул, урыныннан акырын гына кузгалып, өстен-башын какты, якаларын рәтләде, бушайтып җибәргән галстугын тартып куйды да Каймановлар эзеннән китеп барды. Ләкин әлеге капма-каршы куелган будкаларга килеп җитмәде, эчтән Василнең кайнарланып нидер сөйләвен ишетеп, туктап калды. Тавышның еракта ук ишетелүе будка ишегенең ачык икәнен әйтеп торса да, Василнең сүзләре аңлашылмый иде. Инде керим дип талпынган иде, кинәт әрсез-ачык булып Фәһимә тавышы яңгырады:

— Мондый сүз сөйләгән кеше әшәке... ну, түбән җан вуупшем...

Гөрселдәп ишек ябылды, тәрәзә пыялалары зыңлап куйды, будка стеналары селкенгәндәй булды — Фәһимә, бозавын дошманнан сакларга ыргылган пошидай ыргып, басмаларга да басып тормый, җиргә сикерде, Равилне таптардай булып, җилеп узып китте. Аның күз төпләрендә җемелдәгән ике бөртек яшь тамчысы гына күреп калды Равил.

Бу хәлгә ни дияргә дә белмәде Закиров, шулай да эчтә бик күңелсез темага сүз баруын аңлап алды һәм, мондый минутта Кайманов күзенә чалынмаска исәпләп, скважинага таба борылды. Тик барып җитә алмады, каршысына Артомонов очрады.

— Ну, сезнең ничек анда, Костя?

— Бетте. Амин! — диде куанган Константин.— Скважина су кабул итә башлады. Тик миңа начальство чакырта никтер.

Икәүләп тагы будкага таба киттеләр. Ишек һаман да ачык, тик моннан Кайманов та, Борһанов та күренми, урталыкта бөтен будканы тутырып, боларга арты белән мастер Сабиров басып тора һәм нидер сөйли иде. Аның тавышы, әйтерсең, өстән — матчадан ишетелә:

— Мин әйтәсен әйттем, иптәш Кайманов: миңа берәү дә сукмады. Эш вакытында балык каптырып утырган өчен язмыш үзе җәзалады мине — яр ишелеп суга төштем. Вәт шул.

Сүзен бетерде дә, карга оясы хәтле беретын башына киде, янәшәсендәге эскәмиядән майланып беткән сумкасын алды һәм ишеккә юнәлде. Аралыкта торучы Равил белән Константинга аны-моны дәшмәстән, аю гәүдәсе белән аларны култыксага кысып узды да, чыгып ук китте. Артомонов эчкә үтте, Равил исә, будкада сүзнең үзе хакында баруын тәмам төшенеп, култыксага сөялгән килеш бераз торды да Константин артыннан атлады.

Алар белән исәнләшүче дә, «Узыгыз»,— дип әйтүче дә булмады. Кайманов будкадагы бердәнбер өстәл артында кара янып утыра, ә каршы як стена буендагы эскәмиягә урнашкан Мидхәт бер ноктага карап каткан иде. Будканы дәһшәтле тынлык басты. Бер-беренә күтәрелеп карарга тартынып, шактый утыргач кына, Васил телгә килде:

— Баш инженерыбызның эше беткән, димәк. Эшчеләр белән җыелып эчүдән башка шөгыле калмаган.

— Бүгенгә шулай,— диде Равил көрсенеп.— Иртәгә, дөресрәге, дүшәмбе көн Бакуга китәргә, дип торам.

— Кирәкмәс, мәшәкатьләнмәгез,— дип кырт кисте аны Кайманов.— Бакуга баш механик барыр. Сезгә инде, хөрмәтле Равил Вәлиевич, юлда туздырган акчаларыгызны кайтарып бирергә туры килер...

— Аларында эш тормас.

Беразга тынып калдылар. Будка өстеннән бозлы өермә узгандай булды, дүртесенең дә йөзендә аптырау, йөдәү, гасабилану иде. Тынлыкны Кайманов бозды:

— Сез, инде, Равил Вәлиевич, кырасын кырдыгыз — җитәр! План үтәлеше өзеләчәк бу айда.

Равил мондый гаепләүгә ни дип җавап бирәсен уйлап өлгермәде, Артомонов телгә килде:

— Ә аның идарә яралганнан бирле үтәлгәне булды микән?

Кайманов ялт итеп аңа таба борылды, аскы иренен чәйнәп, сүз таба алмый торды.

— Уч тутырып премия алуларыгызны оныттыгыз мәллә? — диде, ниһаять.

— Әйе, без дә гөнаһлылар,— дип сүзгә кушылды Равил. — Ул премияләрнең ничек ясалганын белсәк, алмас та идек, бәлки.

— Күктән төшмәделәр алар, Равил Вәлиевич,— диде Васил, кулын чигәсенә куеп,— менә шушы баш булдырды аларны.

Артомонов, урынынннан кузгалып, алга таба нелде. Каймановның күзләренә текәлде.

— Алдашасыз, Васил Нигъмәтович. Планны Шумский утәп килде... Таяклар теләнеп...

Васил, башына суккандай, миңрәп калды, шулай да үзен сырты белән саддырмаска тырышты.

— Димәк, исәнәсез?!

— Юк, исәнмибез,— дип тыныч кына сүзен дәвам итте Константин.— Без ул мәсьәләне партоешмада тикшерергә булдык.

— Кем инде ул «без»? Закиров белән икегезме?

— Без — коммунистлар.

— Димәк, провакация?—дип чәчрәп урынынннан торды Каймалов.— Юк инде, йомыркадан җөй эзләмәгез, баш инженер белән шөгыльләнегез әнә.

— Ни булган Равил Вәлиевичкә?

— Күрмәмешкә салышабызмы? — Васил өстәл артындагы тар аралыкта йөренә башлады.— Ярый, әйтеп бирим алайса: беренчедән, еш кына тупас, культурасыз кылана. Үз кулы астындагы инженер-техникларга, әйтик, Кавиев кебек эрудитларга гына түгел, материаль байлыкларны тудыручы эшчеләргә дә кычкыра, җикерә, хәтта телгә алырга чирканыч сүзләр әйтә...

«Бу сүзләрдә дөреслек юк түгел»,— дип уйлап куйды Равил, бер бармагын бөкләп. Нишлисең, шундыйрак гадәте бар аның. Эштә таркаулык, оешмаганлык, сүлпәнлек күрсә, кайнап чыга, кайчак катырак әйткәнен дә сизми кала. Ә менә кәгазь күтәрмәслекләре... Кызыбрак киткәндә, ычкынгалыйдыр, бәлки. Һәрхәлдә коллективта, җәмәгать урыннарында кулланганы булмады бугай.

Каймалов исә, хөкем карары укыган судья сыман, Равилгә гаеп өстенә гаеп өя торды. Башта әйткәне баласы гына булган икән әле. Тагын да саллырагы—хулиган икән әле ул Закиров. Равил икенче бармагын бөкләде. Сабиров үзе расламаса да, сусаклагыч янындагы вакыйганы кире кага алмый иде ул. Дөрес, кайнарланды, үзен-үзе тыеп кала алмады. Шуңа да тиешле җәзасын алырга әзер.

Ничек кенә булмасын, моңа хәтлеләре белән килеште әле Равил, үзенең гаебен танымады. Ә менә шуннан соңгылары... Аларын ишетүгә, чәчләре үрә торгандай булды, йодрыклары кысылды, чәчрәп торып: «Гайбәт бу!» — дип кычкырырга җитте. Шулай да үзен тыеп калды, тешләрен кысып, Василне ахырына кадәр тыңларга булды.

Аның җен ачуларын чыгарганы — үзен эчкечелектә гаепләү иде. Дөрес, монысы коры сүз генә. Алай да машинистлар белән бер табында утыруны кая куясың?

Монысына да түзде әле Равил, утыра торгач, көләсе килеп куйды хәтта. Әмма Василнең чираттагы һөҗүме йөрәгенә агулы ук булып кадалды, бәгырен телгәләде. Имеш, ул гаиләсен җәберли, хатынын, балаларын ташлап, аларны ятим итә. Ул гына да түгел, Яшел Түбәдә ялгызы сәер-шикле юлдан йөри, алдынгы эшче Гафурованы аздыра, аны сөяркәсе итеп тота, ялчысы урынына эшләтә...

Юк, башкача чыдарлыгы калмады Равилнең. Ничек кенә авыр булмасын, дөрес сүзгә түзәр иде әле, кара гайбәткә, бөһтанга чыдап булмый менә. Ул, тешләрен шыгырдатып, урынынннан кузгалды, коры кул белән аюга каршы барган һунарчыдай, акны-караны күрми өстәлгә ыргылды.

— Ниһаять, ниһаять... Мин сине аңладым, Каймалов! — дип кычкырды ул ярсып.— Юха еланлык бу!

Васил, эшнең хәтәрлеген шәйләп, чәчрәп урынынннан кузгалды, акрын-акрын гына ишеккә таба чигенде... Моңа кадәр сүзгә кушылмый утырган Мидхәт өтәләнеп торды, Равилнең юлына аркылы басты.

— Җитәрегез!.. Зинһар җитәрегез! — диде ул янау катыш ялвару белән.— Кеше ишетсә, кешедән оят бит, честное слово. Мәртәбәле ике белгеч... базар хатыннары кебек кычкырышасыз бит. Утырыгыз, Равил Вәлиевич, тынычланыгыз. Сез дә, Васил Нигъмәтович... Баш ярылып, күз чыкмаган ләбаса! Кичә без берләшмәдә булдык, киңәшмәдә. Эксперментның эш күләме план үтәлешенә керәчәк. Димәк, бу айда да премиясез калмассыз, иптәш Кайманов. Шулай да җыелыш җыярга кирәк булыр. Артамонов хаклы: дәүләт планының хәйлә белән үтәлүенә юл куя алмыйбыз без. Бәлки, Кайманов сүзләрендә дә дөреслек бардыр, сезгә дә коммунистлар каршына басарга туры килер, иптәш Закиров.

Борһанов, кабат урынына утырды да, уйга талды. Их, ялгышты бәйдәге эт кебек йөреп. Һәр эшен, һәр адымын Васил белән киңәште моңа кадәр, ул нәрсә әйтсә, шуны тыңлады. Ә бит аның урынындагы кеше принципиаль булырга, һәр нәрсәгә аек карарга тиеш. Ул исә һаман Кайманов җырын җырлады. «Әч» дигәнгә, «түч» дип тормаса, мондый хәлләр килеп тә чыкмаган булыр иде шат. Якын көннәрдә идарә эшчеләренең гомуми җыелышын җыярга, дәүләт планын үтәүдә яшәп килгән халтура турында уртага салып сөйләшергә кирәк.

Булып алган давылдан соң тынып, сабырланып калган Равил исә, тәрәзә буенда үз-үзе белән сөйләшеп, бәхәсләшеп тора иде. Тикшерсәләр, тикшерсеннәр әйдә. Кызып, онытылып киткәндә, ярамаган эшләр эшләнмәде түгел. Орышсыннар, кисәтсеннәр. Сабак бу. Алда чамалабрак эшлисе булыр. Ансат кына котылмакчы булгансың икән, иптәш Кайманов. Ашыкмый тор! Безгә эш җитәрлек әле монда: нефтьле катламнарга химик тәэсир итү этабы башлана гына диярлек. Аның яңаданяңа юлларын табасы, сынап карыйсы бар. Татарстанның бөтен битум ятмалары кул тимәгән килеш ята бит әле. Күпме кызыклы эзләнүләр, хәл ителмәгән проблемалар көтә алда! Юк, Васил дус, тиз генә китмим әле мин. Яшел Түбәгә кендек беректе инде хәзер.

Аралык култыксасына таянган Василнең уйлары исә барыныкыннан да күңелсез иде. Ничек болай килеп чыкты соң әле, дип өзгәләнде ул. Кешегә казыган базга үзе дә төшәр, көлкегә калыр микәнни? Мидхәте дә җебегән нәрсә булып чыкты, начальнигын яклап бер сүз әйтми утыруын кара. Аны профсоюзларның группа комитеты председателе итеп сайлату өчен күпме көч түктем. Ул исә бозау булып чыкты. Юу-ук, монда эшләр катлауланды хәзер. Планны айлар буе алдап-юлдап үтәп килгән өчен партҗыелышта җавап бирергә туры килер микәнни? Бөтенләй үк буялып беткәнче, китәргәдер, ахры, моннан. Бораулау идарәсенең хәвефсезлек бүлегендә бер урын буш бугай...

Будкадагылар шулай һәркайсы, катлаулы комбинация өстендә утырган шахматчыдай, тирән уйга талып, үз хәле, үз мәнфәгате турында фикер йөртә, бер Константин гына үзе өчен хафаланмый иде. Аның миендә кешелекнең уртак мәшәкатьләре турында ниндидер фәлсәфи фикерләр бөреләнә, шыта, үсә: шулай, бик гадел корылган бу дөнья җинаять эшләдеңме, замана кануннарын боздыңмы — җавап бир. Капитализм чорында да, урта гасырда да, борынгы Римдә дә, хәтта, дәүләтләр юк чагында, кешеләр ыруг, кабилә хәлендә яшәгәндә дә шулай булган бу. Хәзер дә шулай: кешелек кабул иткән законнарга хыянәт иттеңме — рәхим ит, җәзасын ал. Дәүләт милкенә, иясә кеше малына кул сузучыга да, башкаларга кизәнүчеләргә дә, тәмсез телле кешегә дә, хәтта авыз күтәреп урамда эчеп йөрүчеләргә дә тиешле чарасы бар. Тик менә мәкергә, кара эчле кешеләргә, йөрәкләргә җөйсез җәрәхәт ясаучыларга юк җәза. Нигә алай икән? Ә кирәк, бик кирәк югыйсә.

*1974—1978.*

## Әхсән Баянов

### Ак канатлар

Тәрәзәмне ак канатлар кага —
Әкиятләрдән килгән коштыр ул.
Улаулары, елаулары белән
Кош түгелдер, дәшә кыштыр ул.

Әй, аккошлар, кичәгемә инде
Сез күптән бит киткән, югалган.
Куыш ясап кардан, сезнең күлдә
Дулкын терелтүче булалмам.

Еллар буе өйгән өй катыннан —
Чарлагымнан карап торам да,
Офыкларда күрәм: еллар анда
Бөтерелә кушылып буранга.

Ак бушлыкта мин калдырган эздә
Кар эремәс, үсмәс яшь үлән.
Мин өзәсе гөлне салкын инде
Күренмәслек итеп яшергән.

Үзем генә белгән чәчәкләрне
Үзем генә белгән аккошка
Бүләк итә алмам. Җир буйлап бит
Чал бураннар чыккан чабышка.

Төшендерер тиздән тигез аклык
Сөюләрнең нәрсә икәнен.
Тиз әйтермен: «Сөйгән булып йөреп
Күпме вакыт әрәм иткәнмен!»

Юкка чыккан буш ашкыну белән
Югалгандыр күпме уңышлар!..
Ак канатка төяп, шундый ачыш
Китерделәр миңа бу кышлар.

Мин — әүлия, инде башкаларны
Өйрәтермен сафлык-тәүфыйкка.
Бу да акыл булыр. Чарлактан тик
Җилпенә җан бүтән аклыкка.

## Ялангач ай

Бүлмә тулган тыныч уйлар белән,
Сөт дәрьясы кебек — ап - ак, ап - ак.
Күктән карый миңа ялангач ай,
Мәңгелек сер, илаһи төс саклап.

Мин ялангач айга текәлгәнмен.
Сузылмыйча сыйпый бармакларым
Кытыршылык рәхәтлеген тоеп
Әллә мәрмәр тәннең, әллә айның.

Айга кулы җитә кемнең, генә?
Минем генә бугай, минем генә.
Бәхәсләшмәк кеше табылыр дип,
Шик-күләгә, төшмә күңелемә.

Кытыршы ай каты була белә,
Ә бүген ул шундый нәфис, затлы.
Ялангач ай шундый изге һәм саф,
Аның нуры — инсаф, бәхет, якты.

Бу инсафны, бу сафлыкны бәлки
Миннән башка һичкем тапмас, тапмас.
Каршы өйнең бозлы өлгесеннән
Көлә ләкин адәм атлы картлач.

Ләкин, ләкин... Таңда чыкса буран,
Айны коткарырга мин бар:
Сакта торам!

●

Шуның өченмени көттем сине,
Шуның өченмени эзләдем.
Җирнең, күкнең бар төсләрен сирпеп,
Юккамыни көлде күзләрең?

Шуның өченмени без табыштык,
Хушлашырга дипме кавыштык?
Бер гомерлек дәреслекне җиңде
Сәгатьләргә сыйган ялгышлык.

Гомер буе нигә кирәк эзләү —
Бер мәгънәсез кинәт җуярга?
Сораулар тик минутларда туса,
Җаваплары кала елларга.

●

Эшләрем күп, йөди, арый идем,
Арсам да бар эшкә ярый идем.

Җан да, тән дә — ялда, калды бер эш:
Элеккечә мин сөяргә тиеш.

Җыйганда да элек бар хәсрәтне,
Читен булмый иде шушы хәтле.
Мәхәббәтме шушы авыр хезмәт —
Җиңеләйтим ничек? Дустым, өйрәт.

Мең бәйрәмне алмаштырып килгән,
Җир-күкләрне чыңлатырлык көлгән,
Чая көннәр, уйсыз тиле шуклык
Кая китте — кая килеп чыктык?

Яратуың авырлыгын әле
Гел күтәреп йөрү авыр, авыр.
Алда яратмавың авырлыгы бардыр...
Анда йөрәк ничек исән калыр?

Икебезгә бары бер мәхәббәт.
Тик күз яшьсез түзеп булмый рәтләп.
Кайтсын мең бәйрәмне җыйган хезмәт,
Син бәхеткә мине өйрәт.
Өйрәт тизрәк!

●

Мәхәббәтне уйнау
Әле мөмкин икән.
Тик бу уен авыр
Барча авыр эштән.

Мәхәббәтнең үзенә
Җегәр бармы тамчы?
Ят диванга, кайт та,
Уйла, җилкә кашы.

Гәзит укыган булып,
Ауна шунда, әйлән.
Оеп китсә гәүдәң,
Торып су эч, әйрән.

Күз яшьләрең килә
Әллә бөек хистән,
Әллә чыга саркып
Бары көчсезлектән?

Чөмер татлы диеп,
Тозлы тәмнәр сизсәң.
Ела сөенечтән:
Шул да, шул да җиткән!

## Чалма чәчәк

Чалма чәчәк — Маргаритка
Аллы-гөлле, ак та, күк тә.
Өмет бии җем-җем төстә,
Күрсәм сәхрә балкып китә,
Чалма чәчәк — Маргаритка.

Үзенчә бит һәр гөл күркәм.
Ямь тапмыйсың әллә күктән —
Син гел җирне сөяр кебек,
Башың җиргә тияр кебек,
Чалма чәчәк — Маргаритка.

Изгелекләр җирдә ятмый,
Ятканнарын табан таплый.
Матурлыкны түбән йөртмә,
Үзеңне дә син рәнҗетмә,
Чалма чәчәк — Маргаритка.

Үлән — ишле, үрләп китә,
Аларны син үрнәк итмә.
Син бит — сирәк, нәфис, нечкә,
Үс гел өскә, өскә, өскә,
Чалма чәчәк — Маргаритка.

## Салкын кояш

Әй, минем салкын кояшым,
Син исән икән һаман.
Күрендең кабат, күзләрем
Күгәреп беткәч тәмам.

Юеш болытлар артына
Яшеренеп озак-озак,
Нишләп йөрдең кача-кача
Җинаять кылган сымак?

Оныттыңмы үз эшеңне
Син минем яктыртучым?
Үпкәләп әллә йөрдеңме,
Булдымы котыртучың?

Мондый гына үпкә, рәнҗеш
Сине таплый димени.
Сине миңа, мине сиңа
Ятлар мактый димени.

Тик көлмәсәң, мин-җиреңне
Мәңге боз куммәс димә.
Гел кайнар була белмәсәң,
Бул син гел көләч кенә.

Көләчлеккә көч тапмасаң,
Җуйма кызыл төсеңне.
Тукта, китмә, тагын китсәң,
Инде чыкмас өчендер.

Юеш кичтә кар яуганда
Туңмыйм тик, түзәм икән.
Ап-ак булыр дөнья иртән,
Яңгыр үткән, җир кипкән.

## Зәңгәр томан

1

Әллә болыт, әллә рәшә —
Аръякта — зәңгәр томан.
Күк дәрья дәшә үткәнгә,
Көн дә бер барып чыгам.

Дала җиле ерак төннән
Эңгер ташый кичләргә.
Тик күнегә алмый күзләр
Күктән башка төсләргә.

Аръяктан кәккүк кычкыра:
«Сез бергәме, ничек?» — ди.
Шатлык кара төскә керә,
Кәккүк мине ишетми...

Аръякта гына икәү без
Күгелҗем моңга чумган.
Көн дә бер барып адашам,
Көн дә бер исән чыгам.

Аръякта — зәңгәр томан.

2

Аръякта кабат терелә
Яшь көннәр озынлыгы.
Киртәләргә уттай куна
Кикрикләр кызыллыгы.

Тавыкбикә җырлый: «Бәхетем
Түгәрәк!» — диеп кенә.
Яшел сөенеч чемчи казлар,
Саф тәмнәр сизеп кенә.

Хөрлеккә чыдый алмыйча,
Бәрәннәр сикерешә.
Карлыгачлар черки куа
Күк төсне тишә-тишә.

Барысы да инде аръякта,
Барысы да булды кичә...
Бүгенгенең кадерен күр дип,
Җил исә сизелмичә.

## Азак

Үз уемда минем караш — нык.
Үз уеңда синең караш — нык.
Мин дә орыштым татарча,
Син дә тырыштың татарча —
Аңлаша алмадык.

Үз уемда минем караш бикле,
Үз уеңда синең караш ипле.
Син дә орышмадың бер телдә дә,
Мин дә тырышмадым бер телдә дә,
Күзләр белән генә караштык.

Һәм безгә ни җитү-җитмәвен дә,
Һәм нәрсәнең артык икәнен дә —
Бер ялгышсыз күреп аңлаштык.
Белдек:
Без тик бер нәрсәдә ялгышканбыз —
Табышканбыз.

## Ак төшләр

Күләгә өстенә күләгә эленсә,
Күләгә сәбәбе — ботаклар, кәүсәләр
Яфракка, чәчәккә күмелсә,
Төсләрдән карашлар камаша,
Сәбәпләр чалынмый карашка.

Сәбәпкә бәрелеп күз төбең күгәрсә,
Күзләрең учласаң син гәрчә,
Күрәсең: тумыштан бүгенге көнгәчә
Тимгелләр астына тимгелләр күмелгән.

Хәтерлә тагын бер: тел белән
Сәбәпсез син ялап карагач,
Һәм озак куптара алмагач,
Бәсләнеп агарган туң тимер
Ачкан бит дөньяның серендер?
Син моны онытачак түгелдер.

Һәм мин дә... Тәрәздән карасам,
Җемелдәп яктыра сагышлар.
Торбалы төтеннәр, төтенсез торбалар
Бәйрәмнән кайткандай, чалышлар,
Чалышлар...

Яфраклар, чәчәкләр — ак кына.
Җыям да, салам да мендәргә тыңгычлап,
Баш куеп шуларга, талам мин йокыга.
Сәбәпләр кирәкми, сәбәпләр онытыла.
Дөньяда җилпенә, талпына
Саф төсләр,
Ак төшләр.

## Төштәге диңгез

Бәләкәйдә, күрмәс борын өндә,
Диңгезне мин күрдем төшемдә.
Сурәт иттем яшьләй шигыремдә,
Хәзер моң ул — чыңлый хисемдә.

Диңгез эзләп кошлар киткән чакта,
Ияреп мин китәр идем лә.
Алар сагынып кайткан үзәннәрдә
Гөрләп ага минем сүзем дә.

Минем сүзне кабатлыйлар кошлар.
Күпме генә вакыт кичсә дә,
Адашмыйча кайта инешемә,
Нинди җилләр каян иссә дә.

Кошлар белә минем нәселемнең
Кайчан кайда гомер сөргәнен.
Ил җырында кипми калган диңгез
Әүвәлгечә киң ул, тирән ул.

Бүген мин баш куеп яткан сулар
Диңгез түгел — чишмә, инешләр.
Диңгез гомере өчен ул инешләр
Саекмаска ләкин тиешләр.

Мин колачлап йөзгән дәрья — Идел,
Аны да эчә вакыт кояшы.
Ярый әле инешләрем, дим мин,
Иделемә коя, коясы...

Ерак дөнья — кошлар хәтерендә,
Ерак диңгез — минем хисемдә.
Минем ми һәм күзләр белән нәселем
Шул диңгезне күрә төшендә.

## Болгарга сәяхәт

Килгән идем шәһәр чаклы җирдә
Калгандыр дип тау-тау хәрабәләр.
Калган — утрау: пар аякның берсе
Урын тапмас, ныклап бассаң әгәр.

Мин гыйбадәт кылмак булган идем
Карт тарихка, даулы соры төскә.
Тик юлыктым яшел чиксезлектә
Оеп яткан телсез үкенечкә.

Дәрбәләрдә зыңлый яшь исемнәр,
Ялгыз тора читтә карт манара.
Ул ракета гүя — атыласы
Юклык дигән соңгы, аргы ярга.

Манараның менеп михрабына,
Көлә яшьлек, көлә тешсез сакал.
Уйсыз яткан чал ташларны ялап,
Яшел диңгез килә тирә-яктан.

Бүгенгe шат тормыш, вәгъдә, уңыш
Соры төсне килә ашап, җимереп,
Балык-җимеш, тавык-чебешләрне
Көлешә-көлешә без кимергән кебек.

Килә диңгез, улап, үкереп түгел,
Килә назлы каен шавы белән.
Куәт, киңәш алып кояш, җилдән,
Кыштыр-кыштыр: сөю, яфрак, үлән...

Ак каендай чуклы сорау үсә,
Ышыгында — тыныч, тәмле йокы.
«Барлы-юклы соңгы сорылыкны
Әллә бәйрәм, бака туе йотты?..»

Тик айныйсы килә, тиз айныйсы,
Тиз күрәсе килә: ике төсне —
Ике бөек көчне килештерер илче,
Ерак дөнья сине көтә, коткар,
Җирнең җиде катламыннан чыгар,
Коткар аны, Кеше!

## Килдем синең янга

ПУШКИНО ИСТӘЛЕГЕ

Туган җирем — ерак, синең янга
Мин Иделдән килгән бер кунак.
Үзем татар. Синең заманнарда
Яңгыраган бу сүз яманрак.

Мин алгебра китермәдем сиңа,
Алып килдем бодай исен тик.
Чал Иделдә шәүләләре калган
Манаралар сынын кабул ит.

Алып килдем тагын гөслә чыңын,
Иң элек бит безгә таныш ул.
Соңрак күмгән һәм таптаган аны
Ят аваз һәм тояк тавышы.

Тояклар һәм уклар белән килгән
Яман хисләр һич тә юк миндә.
Нәселем минем төзеп кала, илләр,
Җыр тараткан Идел өстендә.

Урман-кырда Дубровскийны мин
Күпме эзләп малай чакларда,
Аның белән яклап гаделлекне,
Күпме чапкан тулпар атларда!

Син чакырсаң тагы шул дауларга,
Мин ияреп китәр малай бит.
Ничә генә яшькә жителсә дә,
Син барыбер миңа агай бит.

Куаклыклар, ахры, селкенделәр
Җилдән түгел, синең килүдән.
Тиңдер үзеңә: я, ал, мин китердем
Бөек сөю уртак Иделдән.

## Аерылышу

ПОЭМАДАН

Поезд китте. Күзнең күрешеннән
Ара инде киңрәк, ераграк.
Караңгылык: «Аерылдылар!» — диде.
Аңладым мин моны соңлабрак...

Күпме йөрәк эзли берсен берсе,
Күпме йөрәк читкә атыла.
Кемдер тирги ераклыкны. Кемдер
Җәфа чигә ара якынга.
Бер бүлмәдә — тойгы тантанасы,
Бер бүлмәдә корый теңкәләр.
Юллар аерып бәхет китерәләр,
Я бәхетне урлап китәләр.
Ак йолдызга сәфәр китә кеше,
Барып чыга кара йолдызга.
Ак һәм Кара, Сак белән Сок йөри.
Аерылулар була юлсыз да,
Аерылгач та була кавышулар...

Уйланырга бар җай, бар сәбәп.
Ачыш көтә дуслык! Һәм үзенең
Эйнштейнын көтә мәхәббәт!

## Гомәр Бәширов

# САРУТ

озын хикәя

## I

Ак чырайлы, какча гәүдәле трибунал рәисе шактый искергән френч кесәсеннән ашыкмыйча гына пенснәсен алып киде. Ялангач өстәлдән берничә бит кәгазь алып аны караштырып чыкты. Башын күтәрер-күтәрмәс, ишек янындагы коралллы сакчыларга дәште:

— Якынрак китерегез!

Сакчылар ике араларында басып торган түгәрәк кара тут йөзле, төптән юан чыккан базык, йомры гәүдәле егетне өстәл янына китереп үзләре ишек катына чигенделәр. Рәис, ике ягына утырган хәрби киемдәге трибунал членнарына иелеп, киңәшкәннән соң, каршысында торган әлеге яшь кешедән җавап ала башлады:

— Исем, фамилиягез ничек?

Егет, кашларын җимергән килеш түбән карап, теләр-теләмәс кенә җавап бирде:

— Мифтах... Шәмгунов...

— Ничә яшь?

— Унтугыз.

— Өегездә тагын кемнәр бар?

— Үги ана.

— Атагыз?

— Сугышта үлде.

— Кайсында?

— Гирманскидә.

Тәрәзә янындагы аркылы өстәлдә язып утырган секретарь туташка нидер әйткәч, рәис ян сәкедәге кешеләргә борылды:

— Шаһитлар кемнәр?

Стена буеннан торып баскан коңгырт сакаллы авыл кешесе, янындагы таяклы бабайга ишарә итеп:

— Менә без, — диде.

Ул кулындагы яшел солдат капчыгыннан киң йөзле кынысыз бер хәнҗәр, тагын лимоннан зуррак сырлы-сырлы кара граната чыгарып өстәлгә куйды. Мифтах ягына башы белән ымлап:

— Өеннән алдык, тентү вакытында, — диде.

Ул арада, бүреге эченнән алган кәләпүшен чал башына кия-кия, әлеге бабай да өстәл каршысына килеп баскан иде.

— Дөрес, хак сүз. Мин пүнәтәй булып кердем, — диде. Рәис бабайга утырырга кушты, алдындагы кәгазьләрне әйләндергәләп, әлеге агайга сорау бирде:

— Приговорда нигә пичәт юк?

— Патша пичәте чуттан чыкты, ә сәвитский пичәт каладан кайтып житмәде әле, — диде агай.

Таяклы бабай башын игәләп ул әйткәннәрне беркетеп куйды. Рәис тагын сорау бирде:

— Монда язылганнар барысы да дөресме?

Агай, гаепле авылдашына карап алганнан соң, аның өчен үкенгәндәй, авыр сулап алды:

— Дөрес ләбаса шул, иптәш кем... Дизиртил булып кайтканнан бирле авылда ниләр кыланган, бөтенесе ничек булса, шулай теркәлгән.

— Сөйләп бирегез!

Агай күзләрен ачалак-йомалак китереп гаҗәпләнә калды.

— Кәгазьгә язылган булса дамы?

— Әйе!

— Алайса, шулай... — Ул, баскан урынында таптанып, тагын авылдашына карап куйды. Шәмгунов өстендәге өр-яңа гимнастеркасы, «бутылкалы» кызыл галифесе, көзге шикелле ялтырап торган күн итеге белән масайган сыман, ике кулын аркасына куйган хәлдә, киерелебрәк басып тора иде. Агай кырысрак итеп тамагын кырып куйды да, бүреген ян сәкегә ыргытып, тураебрак басты. — Алайса иң әүвәл шул хакта: ник пригавар җыйды халык? Түзәр әмәле калмаганга! Әгәренки үзәк бәгырьләренә үтми икән, халык дигәнең үз баласы өстеннән беркайчан да мондый пригавар җыймый! Рәнҗү ташып аккан, түземлеге төкәнгән! Менә бит афәт — башка төшкән бәла!

Рәис ябык, озын бармаклары белән өстәл шакып, агайны туктатты:

— Буш сүз кирәкми! Атап әйтегез, ачык итеп: кайчан, кайда, нәрсә, ничек? Иң башта кем ул? Игенченең ниндие? Батракмы, ярлымы, уртамы, кулак нәселеннәнме?

Агай Корбангалигә карап «Ишеттеңме?» дигәндәй көлемсерәп алды.

— Һы! Юк ла инде! Каян килеп игенче булсын ди ул? Рәҗе игенченең мондыйга кулы бара? Юк! Гомеренә бер ат җикмәде, сыер саумады. Йөрде шунда шәләй-вәләй, тудыйм-судыйм кагылып, сугылып. Ни ултара, ни пултара дигәндәй. — Агай, авылдашына шелтәле караш ташлап, башын чайкады. — Элек-электән бизбашка булып үсте инде ул. Умарта басып та тотылды, базларда сөт-каймактан авыз иткәндә дә эләккәләде, кыен да ашады.

— Судта булганы бармы? — диде рәис.

Агай кулларын җәеп җибәрде.

— Менә анысы юк! Булмаганны әйтә алмыйм. Алай зурга җибәрмәде халык. Менә төзәлер, менә акыл керер дип көтте. Ну соңгы айларда бөтенләй дә чыдар әмәл калмады, гүпчи дә азынды, кызыл әрмегә ихтыйярыйлар җыя башлагач бигрәк тә.

— Ачыграк: нәрсә, ничек?

— Барып теркәлә дәген, өр-яңа салдат киеме киеп кайта бу. Анысын сатып эчә дәген, яңадан барып теркәлә бу! Алып кайта дагын, сата бу, сата дагын, эчә бу, яңадан барып теркәлә бу!

Трибунал членнарының берсе:

— Ничә тапкыр шулай киенеп кайтты? — дип сорады.

Агай кулын гына селтәде:

— Биччут!

Ул, дулкынланып, янә авылдашына ачу белән карап алды. Ә тегесенең исендә дә юк. Шәмгуновның йөзе бакырдан коелган сынныкы кебек хәрәкәтсез, ул һаман элеккечә бүксәсен киереп тора иде. Агайның моңа кәефе кырылып бот чабып куйды:

— Булса дагын булыр икән таш бәгырь! Тора лабаса бизнигам![1] Мәрткә киткәнмени?

Рәис очлаеп төшкән ябык ияге белән ымлап:

— Тагын? — диде.

— Тагын дакта, анда Гөлҗиһан мәрәкәсе теркәлгәндер...

— Анысы кем?

— Гөлҗиһанмы? Кем дип әйтеп... соң, авылның бердәнбер чибәре, иң уңган кызыбыз инде ул безнең.

— Ярый, аңа нәрсә булды?

— Шөкер, булып ук җитмәде анысы, мишәйтләделәр! Мөгаллимебез Гайфигә рәхмәт инде, бичарага, ул коткарып калды. Аннары Сәләй. Күрше авыл егете.

— Ничек, кайчан?

— Кайчан дип... — агай ян сәкедәге картка таба борылды. — Хәтерем ялгыштырмаса, узган чишәмбедә бит әле, Корбангали абзый?

Карт, тамагын кырып селкенгәләп алганнан соң, төзәтмә кертергә кирәк тапты:

— Юк, кем, Хәйретдин, хаталанма. Базар көн булды бу хәл, әйе, базардан кайткач, кичкырын!

— Ә шулайдыр алайсам... Менә шул Гөлҗиһанны ата-анасы кулыннан йолкып дигәндәй йөгертеп алып чыкканда...

Рәис өстәл шакып тагын туктатты:

— Ничек аңларга ул «йөгертеп» дигәнегезне? Нигә йөгертә ул аны?

Хәйретдин иңбашларын җыергалап, бераз түбәтәй астын кашып торды, Корбангалигә дә карап алды.

— Соң, «йөгертеп» дигәнебез... ни инде ул, аны ябыштырып чыгару дип тә әйтәләр. Почти урлаган шикелле! Яучы җибәрмичә, кызның ата-анасыннан рөхсәт сорамыйча, токтомалга кызны качырып алып китү була инде бу!

Рәис моның белән аеруча кызыксынды.

— Кыз үзе риза булмаса дамы?

Хәйретдин икеләнебрәк башын чайкап торды:

— Төрлечәрәк була дип әйтерием...

Шунда Шәмгунов телгә килеп секретарь туташка борылды, аның яза торган кәгазенә бармагы белән күрсәтеп:

— «Урлаган» дип язмагыз! Гөлҗиһан миңа урларга үзе кушты!— диде.

Башкалар аптырабрак торганда ян сәкедән Корбангали карт жилкенеп торып басты:

— Ялган! Син аны көчләп әйттергәнең!

Трибунал рәисе боларны тынычландырып Хәйретдингә дәвам итәргә боерды.

— Әлеге дә баягы шул Гөлҗиһанны урлап алып киткәндә, ындыр артына парат килеп җиткәнне көтеп, мунчага алып кергән бу моны... Мунчага алып кергәченнән... — Хәйретдин секретарь кызга таба кыяркыймас кына карап, тамагын кыргалап тора башлады.

— Әйтегез, әйт! — диде рәис.

— Әйе, мунчага алып кергәченнән көчли башлаган бу моны. Шунда аның кычкырган тавышына килеп кереп, Гөлҗиһаныбызны хәрәп булудан Сәләй белән Гайфи мөгаллим коткарып калды. Әйе! Бичара!

---

[1] Бизнигам — гамьсез, ваемсыз дию.

— Нигә «бичара»? — диде рәис.

— Бичара дими нң дисең? — Хәйретдин кулларын күкрәгендә кушырып башын селкеп торды. — Гомергә бойлыксыз итте бит бу эзвир аны!..

— Аңлашылмый. Ничек? — диде рәис.

Корбангали таягы белән Шәмгунов ягына күрсәтеп кычкырып җибәрде:

— Әйт, Хәйретдин, анысын да әйт, бөтенесен ярып сал! — диде.

— Әйтмичә соң, әйтәм! — дип җилкенде Хәйретдин. — Бу кансыз, Гайфине аулакта саклап торып, оча башы белән «дыңк» иттереп бусага катысына утырткан. Әллә ничә тапкыр. Әзмәвер бит ул, аңа кем чыдасын!?

Боларын ук лыгырдар бу әләкче дип һич уйламаган иде Мифтах. Зәһәрләнеп теш уртларын уйнатып куйды. Хәйретдин аңа атасы ягыннан чыбык очы гына булса да туган тиешлерәк тә бит әле. Ә ул... Төнлә Мифтах исереп йоклагач, пүнәтәйләр белән кереп, аның әрбирләрен алып чыгучы да шушы бит әле! Аңа гына бик күп кирәк! Ул гына йөри бөтенесенә кысылып... Шәмгунов үзен күп булса, биш-алты айга төрмәгә ябырлар, я булмаса сугышка җибәрерләр дип уйлый иде. «Туган итеп» арт сабагын укытачак әле ул аның!..

Трибунал рәисе, щетка сыман тырпаеп торган кыска чәчен сыйпаштырып, Шәмгуновка карап бераз уйланып торды да янә сорау бирде:

— Нигә шулай рәхимсез кыландыгыз?

Шәмгунов рәискә ачу белән карап үзе сорап куйды:

— Ә нишкә минем белән Гөлҗиһан арасына кысыла? Ул кем дә мин кем?

Трибунал рәисе тыныч кына:

— Сез кем соң? — дип сорады.

Шәмгунов гимнастерка изүен шатырдатып аерып ташлады да иңбашындагы яра эзен күрсәтеп:

— Менә мин кем, менә! Сугышта кан койган кеше! Ә ул тыл күсесе, сугыштан качып калган!

Хәйретдин сикереп торып:

— Ялганлама! — дип әйтеп куйды. — Аның кәгазе бар! Мөгаллим булган өчен алмадылар аны!

Трибунал члennары Мифтахның ярасына күз салганнан соң, рәис Хәйретдингә дәвам итәргә кушты.

— Үзе турында пригавар чыгарганны ишеткәч, бөтенләй котырды бу. Бомба ташлап авыл сәвите кәнсәсен шартлатты. Ике кеше яраланды, алар бүлнистә ята, кәнсә җимерелде, яңаны салмыйча булмый.

— Тагын нәрсә өсти аласыз?

— Тагын шуны өстисе килә: шундаен да авыр сугышларны баштан кичереп, патшаны төшереп, җирле-сулы булып аз гына иркен сулыш ала башлаганда, менә сиңа, мә! Аяк астыннан чыккан афәт! Ул кайтканнан бирле халык кан калтырап тора. Илнең асыл егетләре яңа хөкүмәтне яклап сугышып йөргәндә ул менә нишли! Қояш баюга капкасын бикли дә халык тизрәк утын сүндерә. Монда озатканда халык әйтте: безгә мондый эзвир кирәкми, гадел хөкемгә тапшырабыз, диде.

Трибунал рәисе Хәйретдингә утырырга кушып, Шәмгуновка сорау бирде:

— Армиядән ник качтыгыз?

Шәмгунов аның күзенә туп-туры карап:

— Качмадым, өйләнергә кайттым, — диде.

Рәис аңа кулын сузды:

— Увольнительниегезне бирегез!

— Югалттым.

Рәис, секретарьнең монысын язып бетерүен көтеп торды да, гаепләнүчегә:

— Сөйләгез! — диде.

Бу арык шайтанга Мифтахның башта ук жене каткан иде. Ул ялт кына аның артындагы ачык тәрәзәгә күз атты, куллары йодрыкка төйнәлде. Әнә шул очлы иягенә берне тондырып сынын катырырга да урамга сикерергә... Тик, ике арада менә бу өстәл, аннары ике якта ике фараон мишәйтли... Ул киреләнеп читкә карады.

— Сөйләмим! — диде.

— Сәбәп?

— Дөрес түгел!

— Нәрсә дөрес түгел?

— Суд! Болай суд итмиләр! Сизмисезмени? Бөтенесе көнчелектән! Галифәдән көнләштеләрме? Көнләштеләр! Әфисәрски итектән әпәйттәки шартларга житештеләр. Пытамушты алар миндә генә!

— Ә Гөлжиһан?

— Нәрсә Гөлжиһан? Аннан да көнләштеләр! Ә мин кемгә телим, шуңарга өйләнәм! Бетте китте! Хәзер хөррият!

— Урлап алып чыкмакчы булгансыз, көчләргә тотынгансыз!

— Түгел инде. Ул миңа йөгереп чыгарга үзе риза булды.

Корбангали сикереп торып аңа каршы төште:

— Ялганлама! Син аны көчләп әйттергәнең, үтерәм дигәнең! Үз теле белән жылый-жылый әйтте. Халык алдында!

Шәмгунов бүртенеп картка теш арасыннан ысылдады:

— Син! Житте сиңа! Бер аягың гүрдә! Ни пети-патый!

Корбангали рәискә сөйләвен дәвам итте:

— Менә шулай инде ул. Әйтергә дә оят! Исерек башы белән айгыржанаш булып бөтен авылның котын алып йөрде. Ничек әйтергә, кызлы йортлар дер калтырап тордылар. Көчләргә тотынуы да дөрес!

Мифтах аңа тагын очып кунарлык булып ярсыды.

— Житте диләр. Һаман шуны чәйнисең! Бер сәгатьтән үзеңнең хатының буласы кызны кочаклап ятуы ниткән көчләү булсын?!

Трибунал членнары берсенә-берсе карашып алдылар. Аннары берәве:

— Нигә совет йортына граната ыргыттыгыз? — диде.

Шәмгунов борынын пошкыртып:

— Нигә, нигә? — дип үчекләде. — Каян белим мин аны? Белмим тек белмим!

— Ничек белмисез?

— Ничек, ничек! Нәрсә һаман бер сүзне чәйнәргә? Исерелгән и бетте-китте!

— Исерек булуыгыз гаебегезне жиңеләйтми. Киресенчә!

— Ә нигә ул тыл күселәре, кеше котыртып, өй борынча тамга жыеп йөриләр? Бөтен дөньяны сасытып!

Хәйретдин түзмәде, урыныннан торып бераз кызып алды:

— Бу тикле дә булыр икән, кире беткән! Юньсез! Үз куначаннан торып кына кытаклама! Сиңа бит ике чабата бер кием, ике дөнья бер тиен! Кетеки генә як-ягыңа да күз сал!

— Знайт низнай! Законный суд түгел бу! — диде Шәмгунов.

Рәиснең йөзендә бер генә хәрәкәт тә күренмәде. Ул башта ничек булса, хәзер дә шулай ук тыныч иде. Рәис, озын ябык бармаклары белән кыска чәчен сыйпаштыргалап, Шәмгуновка карап утыра, нидер аңларга, нәрсәнедер ачыкларга тырыша иде шикелле. Шулай озак кына карап утырды да Шәмгуновка соңгы сүз бирде.

— Гаепләрегезне жиңеләйтердәй дәлилләрегез булса, әйтегез!

Шәмгунов киреләнеп «Әһә? Артык нык түгелме?» дип уйлап алды

Ул рәис йөзенә күзләре белән көйдереп алырдай итеп, усалланып карады да бөтен торышы белән үҗәтлеген белдереп:

— Гөлҗиһан, Гөлҗиһан! Нәрсә булган Гөлҗиһанга? Укасы·уңганмыни? — диде.

Трибунал члены белән секретарьның нәрсәдер язып бетерүләрен көткәндә, рәис Шәмгуновка күзен тутырып, сүзсез генә озак карап утырды. Күптән тарак күрмәгән бу каты кара чәчне бәлки кемдер иркәләп сыйпар, бәлки бу кара күзләр кемнедер мәхәббәт нуры белән сихерли алыр иде. Чуеннан коелгандай бу таза, кыска муен, бу нык җилкәләр озын гомер эчендә бик зур авырлыклар күтәрә алган булыр иде. Әйе, булыр иде, әгәр эш узмаган булса... Хәер...

Карарга кул куяр алдыннан трибунал рәисе Шәмгуновка тагын бер сүз салып карады:

— Бәлки сезнең берәр әйтәсе сүзегез исегезгә төшкәндер, бәлки сез боларны, ничек әйтергә, ялгышлык белән генә эшләгәнсез дә хәзер үкенә торгансыздыр? Әйтегез, әле соң түгел!

Шәмгуновның беркайчан да әйткән сүзен кире алганы юк, кылган гамәленә ул һич үкенми иде. «Бер ай артык, бер ай ким! Төкерим бер танауларына!» дип уйлады. Баскан урынында кукраеп үз кирелеген кабатлады:

— Әйттем ич инде, дөрес түгел! Тыл күселәре белән бер булып, сугышта страдайт иткән кешене... — дип кычкырды.

*
* *

Трибуналның карары кыска гына иде:

«Яшь Советлар дәүләтенә контрреволюция көчләре тыштан һәм эчке яктан котырынып һөҗүм иткән бер вакытта, Көнчыгыштан Колчак армиясе якынлашып килгән аеруча хәвефле көннәрдә Казан өязе, Ямбыз авылы гражданы Мифтах Шәмгуновның дезертирлыкта йөрүе һәм Совет органнарында эшләүчеләргә карата террор актлары эшләве, хатын-кызны көчләргә һөҗүм итүе революцион законнарга катгый рәвештә хилаф килә, дәүләт иминлегенә һәм халыкның тынычлыгына зур куркыныч тудыра. Шул югарыда саналганнарны һәм Ямбыз авылы халкының аны зарарсызландыруны үтенүен искә алып, Мифтах Шәмгуновны атып үтерергә хөкем итәргә. Трибуналның карары катгый, шикаять бирелми. Фронт якынлашып килүен истә тотып, карарны кичекмәстән гамәлгә ашырырга».

Авылдан килгән ике шаһит, көтелмәгәнчәрәк килеп чыгуга тетрәнеп, баскан урыннарында катып калдылар. Мифтах сискәнеп уянгандай бөтен гәүдәсе белән калкынып куйды, маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Ул трибунал өстәленә таба ыргылып буылган сулышы белән гыжылдады:

— Ә?! Атарга? Минеме? Ничек атарга? Ә?

Җан-фарманга өстәлгә китереп сукты, әлеге арык шайтанның якасыннан эләктереп алмакчы булып өстәлне тибеп аударды. Ләкин ике сакчы, аңа сулыш алырга да ирек бирмичә, ишек янына илтеп бастырдылар. Ул сакчылар кулыннан ычкынмакчы булып маташканда өстәл яңадан үз урынында иде инде. Трибунал члennары берни булмагандай тыныч кына аңа текәлеп торалар. Трибунал рәисе нидер аңлатып кулындагы кәгазьне секретарь кызга сузды. Туташ аягүрә басып карарны яңадан укып чыкты. Ләкин Мифтах аны барыбер аңламады. Ул үзен албасты баскандай, уяна алмыйча азаплый торган нindидер газаплы төш күргәндәй хис итә иде.

Секретарь кыз, курка-курка гына, карарның күчермәсен Мифтахка сузды. Шәмгунов аны йолкып алды да, үзен-үзе белештермичә ярсып, әллә ничәгә ерткалагач рәиснең битенә ыргытмакчы булып өстәлгә таба борылды. Әмма өстәл арты буп-буш иде. Нишләргә белмичә таштай катып калганда, аны сакчылар аңына китерде. Аларның берсе Мифтахның иңенә кагылып:

— Давай, брат, жыен! — диде.

«Кая?» дип сорамады Мифтах. Кая барасын ул әле һаман да аңламый иде, алай булыр дип уйлый алмый, ул аның башына сыймый иде. Әйтерсең аны каядыр эш белән барырга мәҗбүр итәләр. Шуңа җене чыккандай, усал бер кирелек белән нигәдер чишенергә кереште.

Хәйретдин күзен челт-челт йомгалап, мескенләнгән кыяфәттә Мифтахның каршысына килеп басты. Бәхилләшергә дип кул суза башлагач, сүзен әйтә алмыйча, каушап калды. Бөтен авыл халкының котын алып, дер калтыратып торган шушы кансызга, шушы баш кисәргә хәзер ниндидер җылы сүз әйтәсе, аны аз гына булса да, ничек кенә булса да юатасы килә иде. Хәйретдиннең күңеле тулды, тавышы калтырап китте, ул башын иеп Мифтахка кулын сузды:

— Бәхил бул инде, Мифтахетдин энем. Зинһар, рәнҗеп китә күрмә инде. Үзең беләсең, дошманлыктан түгел, төзәлмәссең микән диген өмет белән... Каян беләсең? Дөньялыкныкы дөньялыкта калсын.

Мифтахның йөрәге таш булып каткан иде. Хәйретдин аның ачуын гына кабартты. Аннан тизрәк котыласы килгәндәй, ул, идәнгә утырып, ялтыравыклы итеген кабалана-кабалана салды да тавышы тыгылсын дигәндәй, ачуланып аны Хәйретдингә ыргытты. Фуражкасы белән шинеле дә, яшел капчыгы да итеге артыннан очты. Гимнастеркасын да салмакчы иде дә ничектер кире уйлады. Ул Хәйретдингә күзенең агы белән генә карап алды да утырган урынында башын учлап тынып калды.

Корбангали карт идәнгә тезләнеп кыйблага юнәлгән хәлдә дога кылырга керешкән иде. «Аллаһ әкбәрен» әйтеп битен сыйпар алдыннан, борылып Мифтахка сүз кушты;

— Син инде, улым, туры әйткәнне гаеп итмә. Нишләмәк кирәк, ләүхелмәхфүздә шулай язылган булыр күрәсең. — Ул бераз тотлыгып тамагын кыргалап алды. — Мин инде үзебезчә, картларча дигәндәй, әз генә нитмәкчеием... ата-бабаң рухы рәхим-шәфкать белән каршы алсын димәкчием. Менә белмичә торам: догамны кемгә багышлыйм? Атаңны беләм, Галләметдин исемле иде, мәрхүм. Бабаң исемен дә әйтсәнче?

Мифтах идән уртасында яланаяк, яланбаш утыра иде. Борчыганга ачуы килгәндәй, Корбангалигә борылып та карамыйча иңбашы аша гына әйтеп куйды.

— Белмим!

Карт чын-чыннан борчылып телен чыртлатты.

— Ай, улым, ай яшьлек, ай холкың! Соң, рәхмәт төшкере, үзеңнең нәсел-нәсәбеңне, иң якын бабаңны да танымыйча, аларның кадерен белмичә ничек яшәмәк, ничек тормышлар итмәк кирәк?

Мифтахта ул ваем түгел иде инде. Сакчылар аны урамга караган ачык ишек янына китереп бастырдылар. Ишек янына тышкы яктан атка атланган карабинлы, кылычлы ике гаскәри килеп туктады. Шәмгунов янындагы сакчыларның берсе алардан:

— Ничек? Икегез генәмени? — дип сорады.

Атлы гаскәри:

— Син нәрсә? Бер кеше өчен бөтен эскадронны аякка бастырыргамы әллә? — диде.

Сакчы тагын сорап куйды:

— Кая, тегеләр нигә дип көттерә?

— Хәзер чыгалар. Анда инструктаж...

Мифтах сакчыдан алып икенче мәртәбә тәмәке төреп тартканда, теге сакчы түземсезләнеп тагын кычкырды:

— Чыгалармы, юкмы тизрәк? Ансатмы әллә монда!..

Тәмәке төпчеге Мифтахның иренен пешерә, әмма ул һаман суыра иде. Әллә нинди авыр төш күргән шикелле. Кылычлы, мылтыклы ике җайдак та аны озата чыккан. Сакчы серле итеп телгә алган «тегеләр»-дә «шунда» барыргадыр. «Инструктаж» дигәне аны кайда, ничек итеп... Мифтах боларның һәммәсен күзе белән күреп, колагы белән ишетеп тора. Тик бу кешеләрнең кылачак гамәле аның аңына чын булып кереп житә алмый, дөресрәге, акылы ул турыда уйларга теләми, уйлый алмый. Ул «хәлне» Мифтах, бүтән кеше язмышы турында сүз баргандай читләтеп, әмма шомланып күзәтә иде.

Атлылар янына иңнәренә көрәк салган кара киемле ике кеше килеп кушылгач, Мифтах, гүя эченә бозлы су коелгандай тетрәнеп куйды. Ул нишләргә белмичә ашкынып, ярсып, упкынга ташлангандай ниндидер башсыз тәвәккәллек белән, ике сакчыны як-якка этеп җибәреп, урамга атылды.

## II

Мифтах гимнастерка изүе аерылып төшкән килеш, ялангач күкрәген кояшка куеп, урамның нәкъ уртасыннан атлый. Ул үзенә төбәлгән ике мылтык көпшәсен аркасының, муен тамырының һәр күзәнәге белән сизеп бара. Алар артыннан килгән ике җайдак кулында кынысыз кылыч ялтырый. Ул әле исән-сау, ә иң арттагы көрәкле кешеләр аны инде күмәргә баралар... Каршыга килүчеләр боларны күргәч, атларын чажчож чыбыркылап, урамның кырыена бәреп чыгалар. Капкадан чыгарга җыенган хатын-кызлар, тузанлы юл уртасыннан атлаучы шул кара тут йөзле, камыт аяклы яланбаш егетне, аңа төбәлгән мылтыкларны, арттагы көрәкләрне күрәләр дә, котлары чыгып капкаларын ябып куялар. Мифтах аларга карап та тормый, аның ирен кырыйлары гына селкенеп куя, күзләре генә кысыла. Шулай!.. Ул узганда бүтәннәр дер калтырап торсын, җаннары табан астына төшсен! Ник дигәндә, ул Мифтах, ул алар шикелле селәгәй түгел, ул бер генә!..

Урам уртасыннан яланаяклары белән җылы тузан ерып баручының йөзендә бер генә тамыры да селкенми, ашкынуы, йөрәк ярсуы да тышка бәреп тормый. Ул эчтән генә яна. Аның йөрәгендә чиге-чамасы булмаган зәһәр ачу кайный. Аны атарга эшләгән баягы өрәккә дә, аның өстеннән әләкләп, аның башына җитеп үзләре исән калырга маташучы әнә ул тавык йөрәкле бәндәләргә дә ачуы чиктән ашкан. Аны трибуналга биреп үзе бүген кич Гөлҗиһанга кияү булып керәсе теге Бигәнәй селәгәен дә, Гөлҗиһанның үзен дә ул бугазларын чәйнәп, өзгәләп ыргытыр иде. Ул әнә шуларның һәммәсен дә күзләре белән ерактан көйдереп алырдай булып, зәһәрләнеп атлый, шуларга үч итеп башын ими!

Менә сул яктагы почта йортын да уздылар. Әнә тимер рәшәткә белән әйләндереп алынган больница да артта калды. Инде шәһәрчекнең читенә якынлашып киләләр. Бераз гына алдарак ямь-яшел каеннары белән зур гына зират җәелеп ята. Шуңа җитәрәк, тау кырыеннан сөзәкләп болынга таба төшкәндә... шәрә урында...

Тик Мифтах моңа бөтен җаны-тәне белән каршы, шулай булуы мөмкинлеген ул башына да кертеп чыгармый. Ничек инде ул? Тиктомалга кешене аттыр да ул өйләнәсе кызга үзең хуҗа булып кал, имеш! Тот капчыгыңны!

Зират янындагы каравылчы йортының кече капкасы ачык иде. Аңа биш, алты, сигез адым булыр... Ике-өч кенә сикерәсе. Кергәч эчке яктан

капканың биген төшереп өлгерсәң... Арт ягы бакча, аннары болын, әрәмәлек...

Башын аз гына, шикләнмәслек итеп кенә борып Мифтах сакчыларны шәйләде. Аралары ун адым чамасы, артык булмас. Мылтыклары корылган булса... «Бик якын» дип уйлап алды. Башына ниндидер яңа уй төшеп, Мифтах сиздермичә генә киерелебрәк атлый башлады. Ара ераграк булганда ничек тә...

Зираттан узып ачыклыкка чыккач, сакчыларның берсе:

— Әй, сулга! — дип кычкырды.

Юл уңга таба китте, болар сөзәк тау кырыйлатып аска таба төшә башладылар. Мифтах каш астыннан гына алга таба күз салды. Тау астында тар гына болын бар икән. Аның аргы кырыенда тирән буа, аның да теге ягында куе әрәмәлек, аннан да арырак тимер юл станциясе...

Якын-тирә буп-буш, кеше-кара, мал-туар юк, шушындадыр... Мифтахның бөтен гәүдәсе, барлык мускуллары актык чигенә кадәр киерелеп килде. Ул артындагы сакчыларның һәр хәрәкәтен, һәр кыштырдауларын колаклары белән генә түгел, бөтен тәне белән сизә башлады. Менә, менә... «Затворлары боевойга куелдымы икән? Әллә юкмы?» дип уйлап алды. Әгәр куелмаган булса, затвор ачылып ябылган арада... Аның җаны әнә шул бер сулыш эчендә я тегеләй, я болай...

Арттан килүчеләрдә дә ниндидер дулкынлану, каушау билгеләре сизелде. Алар берсенә-берсе ашыгып кына, өзеп-өзеп кенә нидер әйтеп алдылар. Иң кырын урынга килеп җитүгә, кинәт, берьюлы ике-өч затвор чыйкылдап куйды. Мифтах баскан урыныннан кинәт пружинадай аска сикерде, мылтык гөрселдәп өлгергәнче капыл гына түбәнгә тәгәрәп китте. Артта кайсыдыр бик яман кычкырып җибәрде, гөрселдәп мылтык атылды. Мифтахның ботын нәрсәдер кыздырып алды. Тагын затвор тавышы ишетелде, Мифтах торуга тагын аттылар. Ләкин ул бер уңга, бер сулга ташланды, егылды, туп кебек түбәнгә тәгәрәп китте. Бу урында тау кырые текә иде. Мылтыклыларның берсе егылды, икенчесе каушап тидерә алмады. Атлылар бу тирәдән аска төшә алмыйча сөзәгрәк урынга чаптылар.

Шушы ыгы-зыгыдан файдаланып, Мифтах, җан көче белән бер яктан икенче якка атыла, сикерә, уйнаклый торгач, шапырдап суга килеп чумды. Су астыннан җан-фарманга аргы якка йөзеп китте. Тончыга башлагач судан башын гына калкыткан иде, колак яныннан гына узган пуляларның берсе аның иңбашына килеп тиде. Мифтах ничектер үзеннән-үзе җан өшеткеч елак тавыш белән ачыргаланып акырып җибәрде:

— А-а-а-а-й...

Ул да түгел яңадан башын суга яшерде. Су астыннан берничә тилпенүдә борылышның икенче ягына барып чыкты. Түмгәк артына ышыкланып, камышлар арасыннан, Мифтах аргы якка күз салды. Ике сакчы яр буена тезләнеп утырган килеш, мылтыкларын бу якка төзәп, моның я үле, я тере килеш судан калкып чыгуын көтәләр. Атлылар, станция ягына чыкмакчы булып, өстәге күпергә таба чабалар иде.

Менә ул, менә әрәмәлек! Менә ул кайда котыла! Тизрәк, тизрәк! Мифтах куаклар арасына кача-поса тимер юлга таба йөгерде. Бер күзе белән генә атлыларның күпергә якынлашып килүләрен күреп алды. Әгәр аның каршысына килеп чыксалар, аны бит котырган эт урынына атып егачаклар. Шул гына җитмәгән!

Мифтах яраларыннан кан агуын сизә башлады. Алар ачытып авырталар, юеш галифесе балтырларына сыланып йөгерергә уңайсызлый иде. Сулыш кабып гыж-гыж килде, йөгерә торгач, хәле бетеп, тәгәрәп китте. Нәкъ шул вакыт борылыштан товар поезды күренде. Мифтах куанычыннан кычкырып җибәрә язды. Яраларының ачытуын тоймас булды, ашкынып, гыжылдап алга ыргылды. Биш-алты адым гына атла-

вы булды, үч иткәндәй, өстен кычыткан каплаган тирән чокыр эченә мәтәлде. Табанына шырпы кадалды, балтырларына эт эчәгеләре, билчәннәр уралды, битен, муеннарын зәһәрләнеп карт кычыткан өтте. Ул ыңгырашты, уһылдады, шулай да туктамады, мүкәләде, егылды, тагын торды, тагын йөгерде. Инде котылдым дигәндә, кинәт биек коймага килеп төртелде. Әйләнеп узарга вакыты юк. Шул арада атлылар куып җитүе, поездның узып китүе мөмкин. Әгәр дә суның аргы ягында һаман да сагалап торган булсалар, аны койма өстеннән көртлек урынына атып төшерәчәкләр! Ул тешләрен шыкырдатып куйды. Мылтык астыннан исән чыккач, котылдым дигәндә генә! Каһәр генә суккырысы! Мифтах Газраил бугазына ябышкандай җан ачуы белән койма өстенә ыргылды. Ни тере, ни үле... Менә, менә, дип җанын уч төбендә генә тотканда койманың аргы ягына егылып төште. Ату тавышы ишетелмәде. Мифтахның «Котылдым, котылдым!» дип кычкырасы килде. Аны су астында тончыккандыр дип ышанганнар иде, күрәсең.

Ул тимер юл кырыена килеп җиткәндә озын товар поезды станциядан кузгалып кына тора иде. Менә черек шпаллар, менә утын әрдәнәләре, менә аның аяклары астында ком, таш кыштырдады. Мифтах, актык көчен җыеп, арттагы вагоннардан берсенең баскычына ябышты.

### III

Кызыл вагоннар тек тә тек килеп бер көйгә чаба бирделәр. Озын платформа идәнендә балык мичкәләре, патрон әрҗәләре, «максим» пулеметлары, чиләктер, фәләндер берсенә-берсе ышкылып, төрле тавышлар чыгара. Шулар арасында кулын-аягын як-якка ташлап, берни белештермичә яткан камыт аяклы кеше дә Көнчыгыш ягына чаба, җанын сорап колак төбендә сызгырышып очкан үлемнән һаман ераклаша бара иде.

Аның кулбашы турысында гимнастеркасына биялэй кадәр кан саркыган, балтырындагы ярасы тирәсенә көтүе белән чебен җыелган иде. Ләкин ул үзе боларның берсен дә сизәрлек хәлдә түгел, вагоннар җөй турысында сикереп киткәндә ул да сузып салган утын яркасыдай арлыбирле чайкала иде. Менә тимер юлны аркылы кисеп узучы кара-соры болыт поезд өстенә кинәт кенә шыбырдатып салкын яңгыр койды, платформа идәнендә, мичкәләр өстендә эре тамчылар биеште. Мифтах, яралары авыртканга түзә алмыйча, күзен ачты. Кинәт ул яшен тизлеге белән мичкәләр, әрҗәләр арасына кереп посты. Ләкин платформада бер кем дә күренми, поезд акрын гына урманга таба кереп бара иде.

Яңадан кояш кыздыра башлауга карамастан, ул бик яман туңа, тешләре тешкә тими, бөтен гәүдәсе дерелди иде. Ул күп уйлап тормастан, пулеметка япкан брезентларны тартып алды да, баштанаяк төреп, эчкәрәк кереп ятты. Бераздан азрак җылынса да, яраларының үтереп сызлавына чыдар әмәл юк. Мифтах эчке күлмәген ертып балтырын бәйләде, иңбашындагы ярасына чүпрәк ябыштырды. Бара торгач, үзеннән-үзе ялкынланып торып утырды. Үлемнән котылды бит ул! Атлысын, җәяүлесен дуракка калдырып качып китте бит ул! Аның сикереп торасы, бөтен дөньяны шаккатырып: «Күрдегезме? Мин шулай утырттым бит аларны! Мин, мин!» дип кычкырасы килде.

Тик шунда ул тешләрен шыкырдатып куйды, аның күзләре кысылды. «Бүген төнлә үк эшләрен бетерергә, бүген үк!» дип уйлап алды. «Бетерергә дә, кая да булса олагырга! Хет җәһәннәмгә, хет Колчак ягына!» Мифтах ничек итеп үч аласын әле үзе дә белми иде. Шул вакыт аның күз алдына Гөлҗиһан килеп басты, аның янына бүген кич Мифтах өстеннән әләкләгән Бигәнәй Сәләенең кияү булып керәсе исенә төште. Мифтах ачуына чыдый алмыйча катлы-катлы итеп сүгенеп ташлады. Кем аркасында атарга эшләделәр аны? Шул кәнтәй белән аның

селәгәе аркасында! Кинәт аның башына шәп уй килде: бүген үк кайтып житәргә дә кияү кергәнче Гөлжиһанның эшен бетереп чыгарга! Мифтах үрле-кырлы сикертеп аның арт санын каеш белән ярачак. Ул аннан: «Мифтах абый, жаным, мин риза, мин синеке!» дип әйттерәчәк. Шуннан соң ул аны эт тә өйләнмәслек итеп эшен бетереп китәчәк. Мифтахның иреннәре үзеннән-үзе ерылып китте. Тик утырсын аннары жылыйжылый Мифтахтан калган кара чутыр малайны тирбәтеп...

Кайнарлыгы бераз сүрелә башлагач, аның күңеленә шик төште, ничек кулга төшерергә Гөлжиһанны? Урлап чыгаргамы? Аны бит саклыйлар! Корал кирәк иде, корал...

Поездның акрын кыймылдавы Мифтахка ошамый иде. Аның чамалавына караганда, менә бу урманны чыкканнан соң да ул төшәсе разъездга шактый ара бар әле. Поездцан төшкәч, байтак кына жәяү кайтасы да бар. Ә аңа, Ямбызга кичен кияү кергәнче кайтып эшен бетерергә дә, ярты төннәрдән дә калмыйча яңадан чыгып югалырга кирәк.

Шунда паровоз моржасыннан чыккан көлтә-көлтә очкынга күзе төште. Утын яга икән ләбаса бу жәһәннәм арбасы! Шуңадыр алайса арт санын жыя алмаган карт сыер шикелле кыймылдый!

Поезд ниндидер разъездга килеп туктады. Ул да түгел, Мифтах ышеренгән платформа баскычына мылтыклы кызылармеец менеп басмасынмы? Мифтах тагын да эчкәрәк елышты. Аның суга батып үлүенә ышандылармы, әллә юкмы? Әгәр аны эзләсәләр, теге шәһәрчектән бирегә хәбәр салырга тиешләр. Бу кызылармеец ул хакта берәр нәрсә беләме, әллә юкмы?

Мылтыклы як-ягына каранырга да өлгермәде, төрле яктан йөгерешеп килгән капчыклылар өере баскычны сарып та алдылар. Сакчы мылтык түтәсе белән кизәнә-кизәнә аларны куаларга тотынды.

— Ярамый монда! Әйткән бит, ярамый! Ваянный поезд! Төшегез, төш!

Бер төркемен куып жибәрүгә бүтәннәре килеп сарыла, бөтен разъездда кычкырышу, елашу шау-шуы гөрләп тора иде.

Мифтах сакчыдан бер генә сулышка да күзен алмады. Яңа гына мыек чыга башлаган чандыр гына бер нәрсә икән. Буе Мифтахтан чүт кенә калкурак булыр. Ә гәүдә саллыгы ягыннан ул моңа караганда чыра гына. Мифтахка мондыйны бөтереп ыргыту — ике тиен бер акча! Глауный — кием-салымы. Алары Мифтахка мач кына килеп торыр шикелле. Менә бит мәрәкә! Пулеметларның өсте ачылуын күрә калса, бу кибәк баш капларга килгән булыр. Ә поезд разъездда чагында Мифтахның бу малай белән пычранасы килми иде...

Капчыклылар белән ыгы-зыгы килгән арада поезд кузгалып та китте. Сакчы мылтыгын аяклары арасына бастырып куйды да иркенләп тәмәке тартырга тотынды. Брезент арасындагы ярыклардан күзен елтыратып Мифтах аны сагалап ятты. Сакчының гамендә дә юк, ул, юри моны үчекләгәндәй, бу якка борылып та карамый, юл кырыеннан сузылып барган урманнан күзен дә алмыйча тәмләп кенә тарта бирә иде. Ул яктан килгән тәмәке төтене Мифтахның үзәгенә үтеп тартасын китерде, ул түземсезләнеп төкеренеп куйды.

Мылтыклының үзен бик тыныч тотуына караганда, бер төрле дә ыгы-зыгы купмаган, Мифтахны эзләмиләр, аның су төбенә китеп дөмегүенә ышанганнар иде булса кирәк. Шул кирәк ул дуракларга!

Ни арада күзе йомылып өлгергәндер, Мифтах үзе дә сизми калган. Ул өстеннән брезентны тартып алганга уянып китте. Сакчы аңа иелеп:

— Әй! Ну-ка! Нишләп син монда? Кем син? — дип кычкырды.

Мифтах тезләрен иягенә кадәр жыерып кечкенә генә булып калды. Нечкә генә тавыш белән:

— Беспризорни-и-к... — диде.

— Какой-такой беспризорник? Ә галифе? Бактың исә дезер...

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады. Корыч куллар аны кинәт кенә бугазыннан буып алып карабины-ние белән идәнгә китереп ордылар. Егетнең буденновкасы читкә тәгәрәде.

Поезд, ара-тирә урманны яңгыратып кычкырта-кычкырта, һаман чаба бирде. Кызыл фуражкалы дежурныйлар, вокзал каршысына чыгып, аны тыныч кына озатып калалар. Платформаларның берсендә, көн җылы булуга карамастан, шинель якасын күтәреп, буденновкасын күзенә кадәр үк төшереп кырыйга посып утырган кызылармеец турында «Бизгәк чире эләккән, ахрысы, бичарага» дип уйлыйлар иде.

Ә ул комсызланып шинель кесәсеннән чыккан сохарины кимерә, кулаягын як-якка ташлап күлмәкчән генә идәндә аунап яткан әлеге егеткә ара-тирә күз дә салгалый иде. Егетнең кесәсендә актарына торгач, аның бармаклары шырпы кабына килеп төртелде. Кинәт аның башына яңа уй килде. Әһә! Пригавар җыйдыгызмы? Аттырырга булдыгызмы? Каһәр төшкән бу авылга ул гомердә онытылмаслык кара тамга салачак, аяз көндә яшен суккандай итәчәк! Менә аның күз алдында төнге авыл өстендә чын шикелле булып утлы ялкын өермәсе дулый, урамнарында кая барып бәрелергә белмичә, акырышып шашынган кешеләр чабыша иде. Мифтахның башына җитеп үзләре генә рәхәт яшәмәкче! Юк, алай булмый торсын әле!..

Ул йөрәк януын басар өчен тартып алырга булды. Тик поездның ул төшәсе разъездга якынлашып килүен чамалап, егетнең тәмәке янчыгын кире кесәсенә салды.

Соңгы бер ел эчендә Мифтахка бу разъездда бик еш булгаларга туры килде. Өс-баш әйберсенә кытлык заман. Казаннан киеп кайткан солдат киемен кулың белән йолкып алырга торалар. Кайсын күмүшкәгә алмашып, кайсын өч-дүрт кич тол хатыннарда типтереп пыран-заран китергәннән соң — яңадан Казан. Аягында оек-чабата, өстендә иске бишмәт... Бу юлы Мифтах поездның разъездга барып җит ен көтмәскә булды. Бәладән башаяк... Төшәр алдыннан һаман да ан..на килә алмыйча яткан әлеге җебегәнгә карап башын чайкап куйды. Мифтах котылды, бу малай тотылды. Менә моны аталар да аталар инде, шартлатып кына аталар! Бар кеше дә Мифтах була алмый шул! Мифтах булу өчен ат башы тикле йөрәк кирәк!..

Ничектер исенә төшеп, Мифтах үзе кигән гимнастерка кесәсеннән кат-кат гәзит кәгазенә төргән кызылармеец кенәгәсен тартып чыгарды. Битал исемле икән, Басуркин фамилияле. Ямбыз авылының Мифтах Шәмгунов тончыгып су төбендә дөмегеп калды, аның урынына Битал калкып чыкты. Мифтах аның кай яктан, нинди кеше булуы белән кызыксынмады. Нинди генә битлек кисәң дә барыбер түгелмени?

Поезд акрынлый башлауга, карабинның штыгын аска таба каратып китерде дә Мифтах вокзалның каршы ягына сикерде. Башта әремнәр арасына посты, аннары утын әрдәнәләренә ышыкланды. Еэгелә-сыгыла атлый торгач, як-ягында куаклар үсеп утырган озын чокыр эченә барып төште. Разъездан шактый ук ерагайганнан соң, чокыр кырыена утырып, иңендәге карабинының патронын санады. Бер обойма икән. Күп түгел түгеллеген. Шулай да хәзергә җитеп торыр дигән уйга килде. Көпшәнең очыннан ике чирек чамасы кисеп ташларга булды. Шулай иткәндә кием эченнән тагып йөрерлек менә дигән обрез чыгачак.

## IV

Бу тирәдәге юлларны, сукмакларны Мифтах биш бармагы кебек белә иде. Озак та бармады, җир башларыннан турыга кистереп үзе кайтасы юлга килеп чыкты. Ләкин теге Битал дигән малайның ботинкасы

бераз баргач ук кыса башлады. Аякчуларын юка китереп аягын яңадан киеңеп утырганда, аны колынлы җирән ат җиккән мыеклы бер агай куып җитте. Ат туктап кына өлгерде, анасы төсле үк җирән колын, тәртә арасыннан суэылып, бияне имәргә үк тотынды.

Агай ачык чырайлы, сүзчән кеше булып чыкты.

— Әй, иптәш! Кайларга юл тотасың болай? — диде.

Мифтах башын күтәрмичә астыртын гына күз сирпеп алды. Юк, күргән-белгән бәндә түгел икән. Тел очыннан төшәм-төшәм дип кенә торса да, үз авылын әйтмәде.

— Кибәхуҗа, — дип алдады. Кибәхуҗалар өчәү. Башлары катсын әзләп!

Теге кеше үзенә юлдаш чыгуга чын-чынлап куанды.

— Шулаймыни!? Кара, бәхет басты синең! Бер якка кайтабыз икән ләбаса! Әйдә, утыр юл чатына тикле. Аннан сиңа әллә ни ерак калмый.

Мифтах шундук чамалап алды. Олы юл чатыннан аның авылына дүрт-биш чакрым чамасы гына кала. Караңгы төшүгә шәт кайтып җитәр. Гөлҗиһаннарның йорты зират очында. Күренмичә генә кереп булса... Аның эшен бетереп чыккач, авылның бер башыннан ут төртсә...

Яңа юлдаш кузгалырга ашыкмый иде. Ул, колынга имәргә җайлырак булсын өчен, атның аркалыгын төшерде, дилбегәне атның аркасына салды.

— Ә мин Түлешкәнең Сәхәби булам, — дип әйтеп куйды. — Беләсеңдер тугыз өйле Түлешкәне? Шүрәле каргаган авыл, шуңа күрә тугыз өйдән артмый ул.

Мифтах дәшми генә уздырды. Сәхәби аның өс-башына, тезенә салган карабинына күз төшерде.

— Берәр ваянный перказ белән кайтумы? — диде.

— Шул чама. Продотрәт булып кайтам.

— Ә-ә-ә! Икмәк җыярга алай булгачыннан.

— Байлардан.

— Шулай инде! Мондый халыкта каян булсын икмәк? Иске беткән, яңа җитмәгән. Бура төпләре тап-такыр, тычкан башы ярылырлык. Эштән чыгарды сугыш, бетерде... Менә мин дә..,

Әмма Мифтах аны бүлдерде.

— Карале, мин озак көтә алмыйм. Үзең беләсең, ваянный вриме. Давай кузгалыйк!

Сәхәби аңа сәерсенебрәк карап алды. Бу кешенең шулай төрпә сөйләшүе, япь-яшь булуына карамастан, бер генә тапкыр да «абзый» дип дәшмәве аңа ошамый иде. Шуның өстенә, колын, йомшак иреннәрен кәмит кенә кыймылдатып, шундый тәмле итеп имә, анасы шул тикле рәхәтләнеп, күзләрен йомар-йоммас шундый киләнеп тора, сабыйның шундый тәмле ризыгын өзәргә Сәхәбинең һич тә кулы бармый иде. Шулай да ул мылтыклының аңа төбәлгән боздай салкын, җансыз күзләре белән очрашты да тиз генә арбасына утырып, атын кузгатып җибәрде.

— Шулайдыр. Ваянный эш булгачыннан... На, на рәхмәт яугыры, әйдә атла әле! Колыныңны өйгә кайткач туйдырырсың, алла боерса. Яңа ат булганлыктан, холкын-фигылен, йөрешләрен дә белгән юк әле...

Ул мылтыклы «яңа ат» дигән белән кызыксынып, сораштыра башлар дип көткән иде. Алай булмады, мылтыклы һаман карасына батып, кашларын җимереп утыруында булды. Агайның куанычы шулкадәр зур иде, ул аны сөйләмичә түзә алмады.

— Аны әйт тә, моны куй, дигәндәй, энекәш, мин атлы булдым бит әле?

— Мм... ничек алай ансат кына?

— Шулай. Волостка җәяү барып менә атлы булып кайтам! Менәтерәк нинди ат әләкте миңа!

Шундый зур гәүдәле, колынлы атка дөрес юл белән тиешүенә ышанасы килмичә, Мифтах башын чайкап кашларын сикертеп куйды.

— Белмим. Каян алай? Кем кулыннан алдың?

— Яңа влач бирде, үз кулы белән!

— Бер тиенсезме? Кит аннан! Әле җитмәсә, колыны белән!

Сәхәби кесәсеннән пичәтле кәгазь чыгарды.

— Менә ышанмасаң! Панаука алпавытының ат көтүе барын ишеткәнеңдер? Ярлы-ябагайларга сәвит влачы әнә шуның атларын өләште. Ышандыңмы инде?

Мылтыклы җирән биягә теләр-теләмәс кенә карап алды да, һич тә исе китмичә генә авыз эченнән «мм...» дип кенә куйды. Сәхәбине бу да бик гаҗәпләндерде. Җаны бармы моның аз гына, әллә юкмы? Атлытунлы булу ярлы-ябагайның гомерлек хыялы бит инде ул! Төшеңдә ат күрсәң дә хәерлегә юрап куанып йөрисең. Менә бит ул гомер буе көткән бәхет, менә! Сәхәби тагын да кайнарланыбрак дәвам итте:

— Син я бәлкем яшьлегең белән аңлап җиткермисең булыр. Тик атсыз нинди игенче инде син?! Атсыз ни дә, кулсыз ни — икесе дә бер! Ни юк синең кадерең, ни үтмидер сүзең! Йөрисең шунда күзле багана булып!

Сәхәби иреннәрен кызык кына чөмәкәйләндереп, әмма шуннан үзенә бер тәм табып атына чөңгереп куйды.

— На, на, игелегең белән килгере! Нәрсә син онытканда бер атлыйсың? Әнә, абыең ашыгам дир анда... Шуннан ары килеп, энекәш, ходаның нинди хикмәтедер, малай булмады минем. Биш кызга бер малай юк! Бер имана җир белән җиде тамак туйдырып кара әле син. Үзең атсыз! Аннары килеп, бишесенә биш күлмәк-күнчек, биш бирнә! — Сәхәби шатланып тезләренә сугып алды. — Менә хәзер кызларга да кияү чыгар, алла боерса! Чүтеки атлы-тунлылар чутына кердек бит.!

Мылтыклының Сәхәби сөйләгәннәргә эче пошып кайта иде. Бертуктаусыз лыгырдый, ә атына дилбегә кагып та карамый. Баюга таба юнәлгән кояшка ымлап, кырыс кына:

— Соңга калам! — дип әйтеп куйды.

Мифтахның бу кырыслыгы, каядыр ашыккан, нәрсәгәдер ашкынган шикелле гел кыбырсып, кара янып кайтуы Сәхәбине борчый башлады. Моның белән төнгә калсаң, алла сакласын! Бәлки атны куа төшеп, бу бәндәдән якты күздә үк котылырга кирәктер. Алай дисәң, колын бик арган. Башын салындырып, хәлсез аяклары белән чалыш-чолыш атлап көчкә генә сөйрәлә бит, мескенкәй! Колынга күзе төшүгә Сәхәбинең йөрәге сызлап куя иде. Атны кусаң, колын бөтенләй дә егылмагае...

Сәхәби үзенчә хәйләгә керешкән булды. Ул дилбегәсен каккалап, атын орышкан, аны ашыктырган булып кыланды, ә мылтыклыны теле белән юарга тотынды:

— Бик изге юлда йөрисең икән, сәвит влачын сакларга барганың бугай. Өйдәгеләрең ничек соң? Атаң-анаң дигәндәй тигезме соң? Икесе дә саулармы?

Мифтахның сөйләшәсе килми иде, ул ваемсыз гына:

— Бар белән юк арасында, — диде.

— Бәлеш, ничек була инде ул алай?

— Шулай! Әни булган кеше мине бала чагында ук ташлап яшь иргә кияүгә чыккан. Әти булганы мине үги анага таларга калдырып үзе сугышта үлде. Менә шулай!

Сәхәби егетнең бу хәленә борчылып, аңа карый-карый уйланып барды.

— Алай. Сынык җан икәнсең... Әйтсәм әйтим, энекәш, чүтеки атаана хакын онытмаска кирәгие сиңа. Яхшымы, яманмы, тапкан, үстергән дигәндәй.

Мифтах ачу белән төкереп куйды.

— Тапкан, тапкан! Тапкан икән, нигә үзе үстермәгән, нигә эт авызына ыргыткандай шундый зобаныйга ташлап киткән?! Давай сөйләшмик ул турыда!

Кояш түбәнәеп бара иде, Мифтах, болай атлар-атламас кайтканда, кияү кергәнче Гөлҗиһан белән исәп-хисапны өзүгә ышанмый башлаган иде инде. Ул түземлеген җуеп:

— Мин бер әйткән инде! Юырттырырга исәбең бармы, юкмы? — диде.

Аның куанычын шулай мыскыллап, моның олы кеше белән болай тупас сөйләшүенә Сәхәби чын күңелдән рәнҗеде. Әмма мылтыклыдан шүрләп, дилбегәләрен тарткаларга, атын яман да орышырга кереште.

— Ярар, алайсам, ярар. На, диләр сиңа, на! Кара син аның кыланышын, кара атлауларын! Һи, үшән, салпы колак, изелеп аккан нәрсә! Бер аягыңны атлаганчы икенче аягыңны эт ашый! Менә мин сиңе!..

Җирән кашка, колакларын алмаш-тилмәш уйнатып, орышканны ишетеп бара иде. Хуҗаның күңеле булсын өчен генә хәтта ул юри генә юыртып та алган булды. Әмма тиздән үк адымга күчеп артта калган колынына күз салмыйча булдыра алмады. Аның бит җиленәнә мул булып сөт тулган, колынын ашатыр вакыт әллә кайчан житкән ләбаса! Ул бәбиенен йомшак, җылы иреннәре белән ими суыра башлавын, үзенең шуңа рәхәтләнеп оеп тору вакытларын түземсезлек белән көтә, аның җилен тирәләре шул рәхәтне көтеп, баядан бирле сулкылдый иде инде. Җирән кашка борчылып, тынгысызланып барды-барды да кешнәп җибәрде. Нечкә генә тавыш белән шактый ук артта калган колын да җавап бирде. Җирән кашка теләр-теләмәс кенә артына карый-карый атлый башлады.

Сәхәби ике ут арасында калды. Биясенең нигә борчылуын ул җанытәне белән сизеп, шуңа нишләргә белмичә ачынып бара, бер яктан биядә адәм акыллары булуына чын күңелдән куана иде. Тик менә яхшылык кадерен белмәгән бу кансыз бәндә белән нишләргә? Юл чатына ерак калмаган иде инде. Аңа кадәр генә ничек тә тегеләй болай уздырып, колынны ташлап чапмаска булды. Ул атына кычкырып, дилбегәсен тарткалаган булып:

— Дөрес, синеке дә дөрес, энекәш, бик җилле кайтып булмый бит, анасын эт ялагыры, колын бик арыды, ашыйсы да килгән. Аннары менә биянең дә үшәне туры килде. Гәүдә бар да бит! Коры гәүдә нәрсә ул үзе үшән булгач! Ә менә колын анасына бөртек тә охшамаган! Юк, колын бөтенләй башка, колын пирвый сорт!..

Тик Сәхәби сүзен әйтеп бетерә алмыйча калды. Әлеге карасына кабынып, үзеннән-үзе бусарынып кайткан төнтек, кинәт кенә дилбегәне Сәхәбидән йолкып алды.

— Атың түгел, үзең дә үшән син! Күп лыгырдыйсың! Атны алай тотмыйлар, менә болай тоталар! — диде дә, арбага аягүрә басып, атны чаж да чож кыйнарга керешге. Авызын каеруга, дилбегә очы белән үзәгенә үткәреп сугуга чыдый алмыйча җирән бия ыңгырашып куйды, баскан урынында сикергәләп торды да кинәт кенә алып-биреп кушаяклап чабарга тотынды. Арба әле бер якка, әле икенче якка атылды, арба төбендәге салам тузгып җилгә очты, ат хуҗасы эчен тотып арба эчендә үрле-кырлы сикерде.

Тузан туздырып, дөбердәп инеш күперен дә уздылар, тауны да тын алмыйча кушаяклап чабып менделәр. Җирән бия ак күбеккә батып калкулыкка күтәрелде дә уңга борылып әрәмәлек буеннан чаба башлады. Колын әллә кайларда аерылып калды.

Сәхәби, ачынып, Мифтахның кулына ябышты.

— Әй, туктат, туктат! — дип кычкырды, калтыранган куллары белән дилбегәгә үрелде. — Котырдыңмы әллә?! Колын калды бит, колынны хәрәп итәсең бит! Өч атналык кына ич әле ул!

Мифтах чыннан да туктады. Лəкин ул кирегə борылып колынына каршы барасы урында, кояшка күз генə төшереп алды да, ашыга-ашыга атны тугарырга ябышты. Сəхəби юлдашының бу кыланышына ни дип тə əйтə алмыйча ат белəн Мифтах арасына килеп керде.

— Туктале, нишлəвең бу? Башта колынны барып алырга кирəк!

Мифтах аны төртеп кенə җибəрде дə, дуганы бер якка, камытны икенче якка алып ыргытты. Кояшка башы белəн ымлап:

— Күрмисеңмени?! — дип кычкырды. — Əйттем ич мин сиңа, соңга калам дип!

Күңеленə килгəн шөбһəнең дөрес булып чыгуыннан куркып Сəхəби эсселе-суыклы булып китте. Ул нишлəргə белмичə арлы-бирле сугылды да атның тезгененə барып ябышты.

— Соң бит, ничек инде ул болай?! Башыңа тай типмəгəндер лəбаса! Бу бит минем ат, минеке! Законный үз җирəнем! Сəвит үзе бирде, үзе!

Мифтах терсəген җиңел генə бер тилпендерде дə:

— Ягылма! — дип Сəхəбине əллə кая чөеп җибəрде. — Хəзер синеке-минеке юк, пынимаеш! Хəзер хөрьят! Байларныкы-сəвитнеке. Ə сəвитнеке — синеке дə, минеке дə, Мөхəммəт-Дəминнеке дə! Пынимаеш!

Сəхəби нишлəргə белмичə, еларга житешеп, Мифтахның күңелен йомшартмакчы булып карады:

— Соң, рəхмəт төшкере, син ваянный бит, кирəк булса, сиңа телəсə кайсы авылда ат бирəлəр. Əнə генə бит авыл, əнə генə!

— Ə миңа монысы да ярый!..

Сəхəби юлдашының җиңеннəн тотты.

— Карале, туган, үзебезнең кеше бит син, аз гына гөнаһсыннан курык! Минем бөтен өметем шунда бит! Атсыз мин нишлим? Балаларымны ничек туйдырыйм? Алла хакы өчен кара җаяу калдырма! Ичмасам, биш баламны кызган! Зинһар дип əйтəм!

Мифтах нигəдер дилбегəне биленə урап маташа иде, бу əйткəннəргə ачуы чыгып күзен акайтып кычкырды:

— Ə мине, мине кызгандыларммы соң, мине!?

Сəхəби атның əле бер ягына, əле икенче ягына чыгып аның муенын сыйпады, ялларын сыпырды, Мифтахның күзенə карарга тырышып каршысына килеп басты.

— Зинһар өчен хур итмə! «Атың кая?» дип каршыма чыккан балаларыма нəрсə əйтерем, аларга ни йөзем белəн күренерем? Əйдə җигик атны! Телəсəң кая илтəм, авылыңа ук!..

Мифтах кырыс кына:

— Мин үзем дə кайта белəм! — диде.

— Əллə кызлар янына ашыгасыңмы? Үзем илтеп куям! Билләһи илтəм! Беркемгə бер жалу итмим! Зинһар өчен!

Мифтах атны арбага якын ук китереп яралы аягын кузгата алмыйча озак азаплана торгач, көч-хəл белəн җирəннең өстенə менеп утырды. Бу бəндə аны тəмам туйдырган иде инде. Аның күпердəн кыенлык белəн генə аягын сөйрəп акрын гына менеп килүче колынга да җене чыкты.

Сəхəбигə күзен акайтып:

— Бар, газраилнең үзенə жалу бир! — дип кычкырды. — Əйт, мине Ямбызның дизиртир Митак талады, атымны шул алып китте диген! Бар, сыптыр моннан!

— Чү! Телеңə тилчə! Əстəгъфирулла — тəүбə! Андый белəн шаярмыйлар! Аллаң орыр!

— Орасын орган инде! Əйт, шул Митак явыз диген, шул гына хəрəп итте диген! Ə мин дөньяда юк, мине трибунал атып үтерде, пынимаеш! Мин атылган, үлгəн, дөмеккəн кеше, пынимаеш! — ул кинəт җенлəнеп, котырынып чалбар балагын аерып ташлады, коточкыч булып шешенгəн

балтырын, канга баткан җилкәсен ачып күрсәтте. — Менә, менә, күр, рәхәтлән!..

Сәхәбинең күзләре шар булды, ул ышанырга да, ышанмаска да белмичә телсез калды. Арты белән чигенә-чигенә арбасына барып төртелде.

— Ләхәүле, ләхәүле!..

Ләкин аның йөрәге барыбер түзмәде. Әле генә килеп житеп әнисенең имиенә ябышкан колынга аз гына да имәргә ирек бирмичә, атны куа башлагач, Сәхәби йодрыкларын йомарлап Мифтах артыннан ташланды.

— Кансыз! Ерткыч! — дип кычкырды ул. — Тукта! Хәрәп итмә сабыйны, имез! Ишетәсеңме, ичмасам, үлмәслек кенә булса да имез!

Мифтах кинәт кенә борылып аркасындагы карабинын суырып алды да Сәхәбигә төзәде. Әллә нинди котсыз кыргый тавыш белән:

— Атам! Каласыңмы, юкмы?! Кабер такталарыңны... Атам! — дип акырды. Аның йөзе кыйшайган, күзләре атылып чыгарга житешкән, тешләре шыкырдый иде.

Рәхимсез кара түгәрәкнең нәкъ маңгаена төбәлүен күрүгә, Сәхәби хәле бетеп җиргә тезләнде. Тик шундук йодрыкларын айкый-айкый җан ачуы белән илереп кычкырырга тотынды:

— Ат, разбойнек! Ат, зобаный! Җаның җәһәннәмгә дөмексен! — Аннары кулларын күтәреп алласына ялварырга, мылтык шартлаганчы әйтеп бетерергә ашыккандай, кабаланып каргарга тотынды. — Ярабби, күреп торасың, балаларымны ятим калдыра бу имансыз! Ходаем, оланнарымны ач-ялангач итә күрмә! Ярабби! Бу явызны ятимнәрнең күз яше тотсын! Нахакка рәнҗеткән өчен бу бәндәнең муены астына килеп, кәкрәеп катсын!.. Ярабби-и-и!

Мифтахның бу кычкырганнарга һич исе китми, ул аларны юньләп тыңламый да иде. Әмма Сәхәбигә мылтык төзәп торганда аның әллә кәләпүшен әнә шулай кырынрак киүе, әллә өстендәге кара казакие Мифтахның атасын хәтерләтте. Ул үзенә-үзе ачуыннан төкеренде дә карабинын җилкәсенә элде.

Мылтык гөрселдәмәүгә сәерсенеп Сәхәби бераздан күтәрелеп карады. Теге явыз, җирән кашканы юырттырып, Ямбыз юлына таба кереп бара иде.

## V

Җирән кашканың җылак хуҗасыннан котылганнан соң, Мифтах урманга керер алдыннан кояшка тагын бер күз салды. Салды да, кабер такталарын искә алып, тагын сүгенеп ташлады. Теге җылакның әкиятен тыңлап кайта торгач, соңга кала бит! Кая инде олай булгач! Гөлҗиһанның арт сабагын укытырга өлгерәме, өлгермиме? Чәнчелеп кенә киткере! Приговорга бөтен авыл кул куйган булса да аның йөрәк-бәгырьләренә кадалган кешеләр Гөлҗиһан белән Сәләй иде. Шулар сүзе белән аны атарга эшләделәр! Шул кәнтәй башына житте Мифтахның! Авылга ут төртү белән генә Мифтахның ачуы басыласы түгел, юк! Аннан үч алмыйча торып җаны тынычланмаячак!

Кайта торгач, башына яңа уй килеп, Мифтах үзенә-үзе ым какты. Әһә! Теге дошман бүген кич Гөлҗиһанга кияү булып керәсе! Әйе, нәкъ бүген, җомга көн кич, ясту тирәләрендә! Мифтах моны авылдан ук ишетеп киткән иде. Аның колагына шыпыртлап кына әле шунысын да әйттеләр: «Теге башкисәр, теге явыз кулга эләккән арада төенне төйнәп, эшне ныгытып калырга кирәк. Кайтып килсә, алла сакласын!» дигәннәр.

Жирәнне куа биреп Мифтах ирен кырыйлары белән генә көлемсерәп куйды. Саклады пычагым, аллагыз! Мифтах менә атып үтергәннән соң да кияү каршыларга кайтып килә. Сөекле кияүне йоласына җиткереп «сый-хөрмәт» белән каршы алырга кирәк бит! Кирәк!

Кияү кисәге Ямбызга орынып кына торган урман почмагыннан, андагы күпердән узарга тиеш. Менә аны каршыларга иң шәп урын! Шундый уйга килгәннән соң, Мифтах, авылларына кереп тормыйча, кайда җәяүле сукмактан, кайда су буйлатып әнә шул күпергә турылап кайтты. Монысына да соңга калмас өчен ул җирән кашканы аяусыз куды. Теге бәндәгә җене чыкканда, үзен-үзе белештермичәрәк, кайсы авылныкы икәнлеген ычкындырганнан соң бигрәк тә ашыгырга кирәк иде.

Гөлҗиһан юл буе аның күз алдыннан китмәде. Ничек каның катмасын, ничек хурланмыйсың? Кайчаннан бирле ул Мифтахның башын әйләндереп йөрде! Әле күз кыскан була, әле каш сикертә. Бигрәк тә кызыл галифе белән ялтыравыклы эфисәр итеге киеп кайтканнан соң гел генә Мифтах тирәсендә бөтерелә башлады. Нихәтле канфит, нихәтле ситсы-тавар ташыды аңа Мифтах каладан! Ә ул, кәнтәй, юмалый да юмалый. Янәсе, белмәссең, чәчләре бәйләнгән булса, ходай язган булса, фәлән дә фәсмәтән. Менә сугышлар туктасын янәсе, исән-сау әйләнеп кайтсын... Ә үзе, бу югалып торган арада тегенең белән иснәшеп куймасынмы! Йөргән кызыңны ятлар чәлдереп киткәнне авыз ачып карап торыргамы? Сәләйгә тикле өлгерсәне Мифтах. Их, чукынып кына киткересе, үзе махы бирде, үзе! Кыз урлар алдыннан күмүшкәне ул тикле күп чөмермәскәе аңа! Ул чагында шул урланган сәгатендә үк Мифтахның хатыны булып каласые Гөлҗиһаның!

Куа торгач, Мифтах якты күздә үк кайтып җитте. Җирән кашканы өстәге аланга дилбегә белән арканлап җибәрде дә аксый-аксый түбәнгәрәк төшеп куаклар арасына кереп посты. Кияү узасы күпер монда якын гына иде. Агачлар арасыннан авылның түбән очын да күреп була икән. Күзе белән эзли торгач, Гөлҗиһаннар йортын да тапты. Ул очта бүтән андый такта түбәле, тимер морҗалы өй юк иде. Капка төбендәге әнә ул карт өянкегә ышыкланып Мифтахның ничәмә-ничә тапкыр тәрәзә аша Гөлҗиһанга кызыгып торганы бар...

Чуар-чабыр киенгән хатын-кыз Глөҗиһаннар ишек алдында тыз да быз килә. Хәзер анда, дөньяларын онытып, кияү каршыларга җыеналар. Кияү керәсе әнә ул ак келәтне чаршаулар, сөлге-тастымаллар белән матурлап курчак өе иткәннәр булыр. Иптәш кызлары гел яңадан киендереп теге нине, кәнтәйне, аппак чыбылдык эченә кертерләр. Аппак урыннар өстенә Мифтах алып кайтып биргән матур одеалларны җәярләр, йомшак мендәрләргә ул бүләк иткән ислемайларны сөртерләр...

Мифтахның күзләре кысылып бетте, зәңгәрләнгән иреннәре бөрешеп килде. Ул керәсе келәт бит ул, ул кочасы Гөлҗиһан! Ә болар аның башын ашап үзләре генә рәхәт чикмәкче! Юк, чибәркәем, алай булмый торсын әле! Сәләй белән башын-башка куеп ятасы йомшак мендәрләргә кайнар яшьләрен түгәсе бар әле Гөлҗиһанның... Кырмыска түмгәгенә салган елан шикелле үрле-кырлы сикертә әле сине Бүкән Митак!

Сакчы янчыгыннан Мифтах тагын берне төрде. Янган йөрәк басылсын өчен Моршан махоркасын йотлыгып эчкә суырды. Ләкин янгын басылмады. Авыл ягыннан сыерлар мөгерәгәне, бәтиләр кычкырганы ишетелде. Хәзер анда көтү кайткандыр, хатын-кыз сыер саварга утыргандыр, ир-ат кырдан, болыннан кайтып атын тугара, төнгелеккә башак болгата, хайваннар улагына яшел печән сала булыр... Ләкин болар Мифтахның күңелендә бернинди җылы тойгы уятмады. Сирәк агачлар арасыннан күренгән әнә ул йорт түбәләренә дә Мифтах кашларын җыерып, ачу белән генә карап алды. Аның күңелендә бу авылга бармак башы тикле генә дә җылы тойгы юк иде. Каян булсын?! Килмешәк булып

килде Мифтах бу авылга, килмешәк булып кеше типкәсендә үсте, килмешәк дип аны моннан атарга җибәрделәр. Аңа монда исеме белән дә дәшмәделәр. Мифтах түгел, «Бүкән» иде ул монда, «Бүкән!» Ләкин үзе белмәгәнгә салынса да ачу гына түгел иде аның күңелендә, йөрәкне сызлата торган үпкә дә бар иде. Нигә бөтен дөньяга хур итеп аңа гына приговор җыйдылар? Нигә ул гына авылга сыймады? Нигә, нигә? Ул кемнән ким? Ул шуңа җавап таба алмый. Аның күңелендә кара сөрем булып рәхимсез, аяусыз үч тойгысы гына кайнаша. Алар шулай икән, менә Мифтах та болай! Әгәр бу кара йөрәкле авылны күз яше белән җылатырлык итеп китмәсә, исеме Мифтах булмасын!

Өстәге аланда җирән кашканың чебен-черки ашаганга дөп-дөп тибенгәләп йөрүен ишеткәч, Мифтах бераз тынычланып яңадан күпергә күз салды. Кияү дигәннәрен кыз янына ахшам белән ясту арасында кертәләр. Тәмәкесен суыргалап, Мифтах куак төбеннән чамалап ятты: күпер киң түгел, дилбегә ике катларга да җитә. Түбәнтенрәк бәйләсән, атлар чабып килгән шәпкә шуңа абынып күпер өстенә мәтәлер, тарантас авар, кияү атлар өстенә очар. Мәрәкә!.. Мифтахның тирән утырган кара күзләре елтырап китте, калын кашлары сикергәләнеп алды. Ул аягының үтереп сызлавын онытырга тырышып, Сәләй белән Гөлҗиһаннан тагын да явызрак итеп ничек үч алу турында гына уй йөртте. Бу аның үтереп аягы сызлавын оныттырып торды, ул шуннан җан рәхәте тапты. Электән килгән йолаларны, ишеткән-күргәнен исенә төшерде. Мондый чакта күпергә аркылы бүрәнә салганда да шәп чыга. Ул малайрак чагында Бигәнәйдә, шундый бүрәнәгә абынып, кияүнең аты аягын сындырды, кияү үзе тарантасы-ние белән суга барып төште. Һа, һа, һа! Кая инде ул суга төшкән тавыкка кыз янына керү?! Хур булып кире авылына таймасынмы кияү! Мифтахның авылда чагы булса, болай гына калдырыр идеме? Күпернең баганасын кисеп куйган булыр иде. Ул мактанчыкның битенә сасыган күкәй чәпәр иде. Һа, һа! Аннары Сәләй белән Гөлҗиһанның әдәм көлкесенә калулары турында бәет чыгарып, аны дус егетләре белән урам буенча такмаклап узар иде.

Гөлҗиһаннар турысында
Чебеш күзли тилегән;
Гөлҗиһанның эшләр кәкәй,
Елый-елый тилергән.

Шул кирәк тә ул кәнтәйгә! Борынын бик югары чөймәсен!..

Якын-тирәдә ул-бу ишетелми иде. Мифтах сул аягын сөйрәп диярлек җирән кашка янына менде дә аны тышаулап калдырды. Дилбегәне алып күпергә таба атлады. Әмма шул вакыт урман юлында арбасындагы яшел печән өстендә җырлый-җырлый авылга таба кайтып баручы ялгыз атлы күренде. Анысының карасы гына күмелүгә, шул ук юлда хатын-кызлар тавышы ишетелде. Муеннарына җиләк савыты аскан өч-дүрт яшүсмер кыз белән шар-шар такылдап кайтучы бер хатын икән. Мифтах аның тавышын ишетүгә ук кашларын җимерде: ташкулчим! Каян туры килеп тора! Бу аның үги анасы бит! Кайсы дию пәрие китереп ташлады бирегә ул җәһәннәм кисәвен?

Билгеле инде, авылда туйлар кузгалып торган көннәрдә хатын-кыз бүтән нәрсә чәйнәсен?! Алар күптән үк шул туй белән авыз чайкаганнар булса кирәк. Үги ана булган кеше бүксәсен киереп кайткан килешенә кайсынындыр сүзенә каршы төште:

— Китче кит! Ул тиңмени аңа! Гөлҗиһанның кисеп ташлаган тырнагына да тормый ул, беләсең килсә!

Исемен әйтмәсә дә моны үз өстенә алды Мифтах. Бик яхшы сизеп ята ул: аны чәйни бу убырлы карчык, аны! Мифтахның аю булып үкерәсе, бүре булып улыйсы килде. Ул гарьләнеп кызган мангае белән

дымлы чирәмгә капланды. Үги анасы булса да аның өендә үсте бит ул! Трибуналга да бит аның йортыннан алып киттеләр. Атылуы турында ишеткәндер бит инде? «Ай бичара» дип кенә дә әйтми бит! Аңа карата бер генә җылы тойгысы да калмады микәнни?! Тамчы кадәр генә дә якын итмәдеме икәнни ул аны?

Аның бернәрсә дә ишетәсе килми, үзе турында ул яхшы сүз ишетүне өмет итми иде инде. Астан менгән сүзләр аның колагын авырттырып, көчләп керделәр. Шулай да күпер өстеннән ишетелгән бер яшь тавыш йөрәгенә ятышлырак иде.

— Алай димә, Хөмәйрә түти. Колаклы кызыл ыштан белән ялтыравыклы итекләр киеп кайткач, кызларның күзе ут булды. Гел аның тирәсендә бөтерелделәр!

Үги анасы тагын нидер әйтте, тик Мифтах аның соңгы сүзләрен генә ишетеп калды.

— ...Шул тиклеләр дә бизде җаным, шундый өшеде җаным!..

Мифтах ачуыннан тешләрен шыкырдатып куйды. Юха елан! Ничек боргалана, ничек алдаша! Янәсе, ул аны электән үк чит күргән, янәсе, трибунал атарга эшләгән ул явызга Хөмәйрәнең бер бәйләнеше дә юк! Үләрсең гарьләнеп! Мифтах алып кайткан күпме кием-салымны сеңдерде ул. Бу убырлы карчыкның өстендә дә, астында да гел Мифтах алып кайткан чүпрәк-чапрак бит! Мифтах аны күзен дә йоммыйча атып егар иде, тик эш кенә бозыла! Ул кесәсендәге шырпы тартмасын чытырдатып кысты. Тукта, монда эш беткәч, ындыр артыннан узып барышлый, сиңа да өлеш чыгар әле, урам себеркесе! «Ник тудым?!» көненә төшерә әле сине Бүкән Митак!

Бала чагында ничек кенә бәгъренә тимәде аның бу явыз хатын. Үз анасы Бигәнәйдән Мифтахны күрергә килгәч, Хөмәйрә, малайны яшереп, я мунчага, я келәткә бикләп куяр иде. Ничә тапкырлар Мифтахның алачык ишеген дөбердәтеп, җылый-җылый, «әни, әни!» дип кычкырганы бар. Анасы, улын күрә алмаганга үзәкләре өзелеп, бернисез Бигәнәйгә кайтып китәр иде.

Шушы хатын аркасында аны Ямбызда атасыннан бүтән берәү дә үз исеме белән дәшмәде. Ул урамда «килмешәк», өйләрендә «Бүкән» булды. «Әй, Бүкән, юынтык суны ташла! Әй, Бүкән, житте сиңа! Шартлаганчы тыгынма!» Үги ана күз яшьләре чыкканчы борып-борып аның beләкләрен, ботларын чеметте, ыштанын салдырып акырта-акырта арт ягын кычыткан белән чапты, колакларын борды. Шуннан малайның колагы ага торган булып калды.

Әмма баланың күңелендә төзәлмәстәй яра булып уелып калганы, мөгаен, улыннан атасын яңаклатуы булгандыр. Иреннән үч аласы булса, үги ана моны малай кулы белән эшләтә иде. Үзе биленә таянып, «Яле, уңлы-суллы чалтырат әле шул бозауның яңагына! Кизәнебрәк, ныграк! Менә шулай!» дип азындырып торыр иде. Тыңламыйсың икән, үз яңагыңа эләгә.

Шул чакта малайда үзен-үзе яклый алмаган кешеләргә карата нәфрәт уянып калды. Атасын бер дә кызганмый дип әйтеп булмас иде. Әмма ул аны таза гына гәүдәле, нык кына ир кеше була торып, шушы хатыннан үзен-үзе мыскыл иттерүенә хурлана, «шул кирәк сиңа, шул кирәк!» ди-ди, үч итеп яңаклый иде.

Әти кешене кыйнауның бик зур әшәкелек икәнен ул бераз үсә төшкәч, сугышта үлеп калган атасы сагындыра башлагач кына аңлады. Үги анадан алган кыеннар, түбәләү, мыскыллауларның үчен Мифтах урамга чыккач бүтәннәрдән кайтара торган булды. Ул кечкенәдән үк явызлыкның зәһәре белән агуланып, аның «тәмен татып», шуннан рәхәт табып үсте. Ул үзенең корбанына тешләрен кысып, йодрыкларын йомарлап ташлана да аның иң авырта торган, иң «нечкә» урынына

кадала, сынын катырып эченә тибә, кан чыгарып тешли, бармакларын, кулларын каера, елатмыйча, егып салып өстенә менеп атланмыйча туктамый иде. Үги анасы аңа монда да «сабак» бирүчән иде. Мифтахның балаларны кыйнавын авызын ерып карап торганда: «Касыгына тип, касыгына, кәҗә мае чыгар!» дип кычкыра торган иде.



## VI

Авыл кешеләренең кайтасы кайтып бетте булса кирәк, урман юлында бүтән берәү дә күренми башлады. Бу вакытта инде манара тәрәзәсендә шәфәкъ нуры да сүнгән иде. Мифтах күпердә эшне тиз тотты. Аннан аксый-туксый менеп җирән кашканың тышавын алды да аны яшеренрәк урынга кертеп, агачка бәйләп куйды. Җирән кашка тамагын туйдырган, колын да ял иткән, алар,белән тимер юлга таң атканчы уйнап кына барып җитәсе.

Озак та үтмәде, урман юлында, кияү киләсе яктан, кыңгырау тавышы ишетелә башлады. Иң элек төпкә җиккән атның дугасына тагыла торган зур кыңгырау чыңы колакка килеп керде, бераздан ваграк шөлдерләр тавыш бирде. Үзенә күрә түгел, пар ат җиккән булганнар шул селәгәйгә! Ләкин ул мактанчык озакламыйча күпергә мәтәлеп төшәчәк! Әйе!.. Кеше өлешенә борынынны сузмассың, эттән туган!

Тик шул вакыт кыңгырау тавышына дәртләнеп булса кирәк, һич көтмәгәндә җирән кашка кешнәп җибәрмәсенме! Тамагына пычак кына кергере! Мифтах ут капкандай кабаланып сикереп тормакчы булган иде, сыны катып кире ауды. Аның сул аягы яман да шешкән, тик ул аны, бөтенләй изелеп төшмәс өчен, сизмәгәнгә генә сабыша иде. Ул, карабинын әзер тотып, тирә-юньгә колак салды. Кешнәгән тавышны ишетеп әзләп килсәләр... Ләкин хәзергә шикләнерлек берни дә ишетелмәде.

Җәйге төн урманда дөм караңгы булмый. Мифтах яшеренгән урыннан күпер өсте әлҗе-мөлҗерәк кенә булса да бераз күренә иде. Менә кыңгырау тавышларына кушылып атларның пошкыруы, кияү егетләренең үзара мыдыр-мыдыр сөйләшүләре, көлешеп алулары ишетелә башлады.

Тавышларыннан чамалаганда, кияү янында ике кияү егете, ат башында тагын бер егет булырга тиеш иде. Мифтах карабинын күпер өстенә төзәп куйды. Күпердәге тозактан муеннарын сындырмыйча узсалар, ул мылтыктан атып аларның атларын дулатачак! Ачуы-ачу! Барыбер бөтен тирә-як авылларга хур итә ул аларны! Аңа барыбер!..

Атларның дөбердәп күпергә килеп төшүләре булды, кинәт нидер чытырдады, нәрсәдер шартлап сынды, атлар ыңгырашты, кайсыдыр ачыргаланып «ай!» дип кычкырып җибәрде. Күпер өстендә атлар, кешеләр бөтенесе бергә болгана башлады. Шул әүмәкләнгән йомгак эченнән кемнеңдер ыңгырашканы, кайсыныңдыр үһылдавы бәреп чыкты.

— Кулым, ку-лым! — диде берсе.

Кемдер ачы тавыш белән:

— Пычак! Китерегез пычак! Айгыр буыла! — дип акырды.

— Кис камыт бавын, кис чөелдерекне! — диде берсе.

— Юкмы ичмасам балта, бирегез булса!

Күпер өстендә мәхшәр: сүгенәләр, нәрсәдер үһылдап күтәрәләр, атлар мышнаганы, кешеләр көчәнгәне ишетелә иде:

— Күтәр тарантасны!

— Алдын күтәр, алдын!

— Айгырның аягын чыгар, менә шулай! Уф, кот чыкты!

Атның нәрсәдәндер котылгандай дөпелдәп аягына басуы, пошкырып куюы ишетелде. Кешеләр дә нәрсәнедер җайлаган, урынына утырткан-

дай бераз иркенләбрәк сулыш алдылар шикелле. Берсе авыр сулап сүгенеп ташлады:

— Идрит танауларын! А-ай шәп каршы алды бит Ямбыз, ә?! Кирәкне бирде, бөтен Мишә буена хур итте!

— Ярар, без дә төшеп калганнардан түгел! Бәйрәм ашы кара-каршы!

Беравык тынып торганнан соң:

— Нишлибез? — диде берсе.

— Нишлисең? Пычагым эшлисеңмени? Кендек сынды, тәртә каерылып чыкты! Бу килеш кая барасың?

— Чистай хәерчеләре шикелле, тәртә башын яндырып теләнергә керсәң генә инде!

— Әй, лыгырдама әле юкны!

Кайсыдыр кияүгә үпкәсен әйтте:

— Их, кияү, кияү! Каян килеп ягылдың шул кыңгыраулы кызга? Чибәрләр үзебезнең авылда беткәнмени? Хәзер бит кызлар белән хет тегермән бөя!

— Матур дип авыз сулары корыды ич!

— Күрсәтте матурың күрмәгәннәреңне! Бөтен тирәне сасытты, кешегә күренерлекне калдырмады!

Аларга сыкраныбрак зәгыйфь кенә бер тавыш җавап бирде:

— Ярар, анысы сезнең эш түгел! Никах укылган, эш беткән! Ә менә кул, кул!.. Авыртуына чыдап булмый! Нишләтергә, кая барырга?

Аңа җыйнаулашып киңәш бирергә тотындылар:

— Кыз янына сынык кул белән барып кермәссең инде, уйларга кирәк!

— Кыз кайгысымыни әле монда! Зурга китмәсен. Бар, айгырга атлан да элдерт үзебезнең авылга.

— Әйе, әйе! Туп-туры Хөсниҗамал әбигә кайт!

Кияүне айгырга атландырып озаттылар булса кирәк, Мифтах күпер өстендәге тавышлардан шуны абайлады.

Бөтен ягының битенә төкергәч инде аңа койрыкны сыртка салырга да вакыт иде. Тик шунда ул үзен дә искә алуларын ишетте:

— Кем эше булыр бу, ә? — диде берсе. — Кайсы каһәр төшкәннең мондыйга кулы барыр?

— Кем булсын? Үчлек белән эшләнгән явызлык бу! Кем каныгып йөрде Гөлҗиһанга? Кемнең Сәләйгә ычкындырасы килмәде?

— Алай булгачыннан Митак эше инде бу, тач шуныкы!

Аңа кайсыдыр каршы төште:

— Кит әле моннан, нәрсә син булмаганны! Кабереннән чыгып кайтсынмыни ул?! Шартлатканнар инде аны!

— Шулай, кич кенә Хәйретдин кайтып әйтте!

— Ә-ә-ә... — диештеләр.

Мифтах жене чыгып карабинына ябышты. Бәлки ул күпер ягына атып бу килмешәкләрнең дә котын алган булыр иде, шул чакны авыл ягыннан атлар пошкырганы, тарантас тәгәрмәчләре текелдәгәне ишетелде. Кияү килгәнне авыл башына чыгып тыңлап торганда, кыңгырау тавышы кинәт тынудан шикләнеп, авыл егетләре каршы алырга чыкканга охшый иде.

Мифтах ат янына ашыкты. Барысы бергә урманга таралып гаепле кешене эзли башласалар, аның эше шәптән түгел иде. Боларның да трибуналы кыска булыр. Аны, кызган баштан, торкан урында ук...

Җирән кашканы урынында күргәч кенә аның эченә җылы керде.

Мифтахның исәбе — якындагы разъездга турыдан бәреп чыгарга да, берәр поездга эләгеп, Себер ягына шыңкаю иде. Анда тагын күз күрер, тик монда ат өстеннән сөйрәп төшермәсеннәр дә муен тамырына кусәк кенә төшмәсен!

... Җирән кашка кыен ашап үсмәгән, чыбыркы-камчы уйнатканны күтәрә алмый торган нәзберәк хайван иде. Өстендәге каты куллы кешенең кыйнавына, авызлыгын тартып аның үзәгенә үтүенә рәнҗеп, бөтен гәүдәсе белән куырылып килсә дә ул баштарак карышмады, чаба бирде. Әмма колынның караңгыда берүзе аерылып калуына ул бик борчыла, колакларын уйнатып гел колынның тавышын тыңлап бара иде. Юл өстендәге инеш ярына килеп җитүгә, ул кинәт туктады, Мифтахның рәхимсез кыйнавына карамастан, ике аягын терәде дә катып калды, инеш аркылы чыкмады. Бәлки колыны су аркылы чыга алмас кебек тоелгандыр, бәлки анасының исен югалтырдыр дип курыккандыр?

Җирән кашка шулай киреләнеп торды-торды да кире әле генә килгән якка ыргылды. Авызлыгын тешләде дә, мылтыклыга баш бирмичә, караңгыда чатыр-чотыр куаклар сындырып узды. Чаба торгач сулышы буылып, гыжылдап ниндидер сулы чокырлар, канаулар аша сикерде. Мифтахның шлемы төшеп калды, ботаклар сыдырылып бите канады, яралы аягы агачка бәрелеп күзләреннән утлар чәчрәде. Ул инде бу котырынган хайванны җиңүне өмет итми башлады. Күпергә генә алып чыкмасын... Инде беттем, инде кадалдым, дигәндә, куаклар арасында адашып йөргән колыны янына килеп чыктылар. Җирән кашка колыны табылу шатлыгыннан нишләргә белмәде. Ул эһелди-эһелди аны юатырга, иркәләргә кереште. Маңгаен ялады, башыннан аягына кадәр иснәп чыкты, ботларын аерып басты да, имчәкләренең тулып сулкылдавына тәкате калмыйча, колынын борыны белән төртеп имиләренә таба этәрде.

Мылтыклының үз хәле хәл иде. Аның үтереп-үтереп аягы сызлый, нигәдер йөрәге уйный, кан күп китүдән башы да әйләнә башлаган иде. Шуның өстенә, күпер ягыннан ниндидер тавышлар ишетелә. Шушы кире беткән хайван аркасында күсәк астына килеп керергәме? Юк инде!

Мифтах актык көчен җыеп атны китәр юлга куа башлады. Җирән кашка, колынын имезүне туктатырга теләмичә, койрыгын болгады, башын чайкады, әмма баскан урыныннан кузгалмады. Мифтахның җене чыкты. Ул мылтык көпшәсе белән җирәннең кабыргаларын дөмбәсләде, ике колак арасын төйде. Алай да җиңә алмагач, авызлыгын әле бер якка, әле икенче якка тартып атның авыз кырыйларын канатып бетерде. Җирән бия авыртуга түзә алмыйча кеше шикелле ыңгырашып куйды. Ниһаять, аның да түземлеге төкәнде. Ул колыннан читкәрәк сикерде дә зыр-зыр бер урында әйләнергә, арт санын өскә чөеп, чиный-чиный тибенергә тотынды. Мылтыклыны алай да егып төшерә алмагач, көтмәгәндә арт аякларына басты да кинәт кенә җиргә килеп төште. Янадан шәм кебек үрә катты да аркасыннан мылтыклы шуып төшкәндә аны тибеп очырды.

Җирән кашканың тоягы Мифтахның сул иңбашын бөтенләй ватып ташлаган, сул кулы сәп-сәер булып кире ягы белән каерылып ята. Аннан бик күп кан киткән, аның чыкмаган җаны гына калган иде. Ләкин, адәм җаны — эт җаны дилərме, таң беленә генә башлаганда ул, ничектер күзен ачты. Аңа инде бу дөньяда берни дә кирәкми, ачу да, үч тә, гарьләнү, хәтта кемнән дә булса курку да калмаган. Исәп-хисап тәмам өзелгән иде. Шулай да аның ярым йомык күзләре нидер эзләнде. Аның сүнәр-сүнмәс кенә җилфердәп торган нәни генә аң чаткысы, зәгыйфь кенә көзге шәүләсе кебек, шушы үзе яшәгән ямьле дөньяның берәр газиз күренешен үзе белән алып китәргә теләдеме? Җирән кашка аннан ерак та түгел, колынын күкрәгенә сыендырып, гүя аны кемнәндер саклагандай колакларын шәмәртеп сагаеп тора иде. Боларга күзе төшүгә, Мифтах күңелендә ниндидер бик татлы, бик тә кадерле бер тойгы уянды. Бу тансык тойгы аның күңелендә сабый чактан ул калган иде шикелле. Шушы җылы, ягымлы, тансык тойгының янадан рәхәтен сизәсе килеп, Мифтах җирән кашка белән аның колынына текәлебрәк ка-

рарга теләде. Ләкин күз кабаклары авырайганнан авырая бара, соңга калып уянган ул газиз, тансык күңел җылылыгы да акрын-акрын сүнә бара иде.

Җирән кашка төне буе баласының йокысын саклап чыкты. Тора торгач ул калыгып китә дә тиз үк сискәнеп күзен ача, колакларын торгызып мылтыклы яткан куак төбенә текәлә. Анда бернинди хәвеф-хәтәр күренмәч, тагын тынычлана, яңадан күзләре йомыла башлый иде.

Яшь колын таң атканда чыр-чу килгән кошлар тавышына уянды. Торып басты да, авызын зур ачып, тәмле итеп исәнде, бөтен гәүдәсен дерелдәтеп, рәхәтләнеп бер селкенеп алды. Аннары, әнисенең имиләренә сузылып, күзләрен йома-йома, йомшак койрыгын селки-селки тамагын туйдырырга кереште. Җирән кашка тел очы белән колынның чык төшкән юеш аркасын, янтауларын корытты. Матур уелган борын тишекләрен кыймыл-кыймыл китереп аны тагын бер иснәп чыкты. Кичә юлда туктап торган арада яңа хуҗасы, алъяпкычына салып, солы ашаткан иде. Шунда ул аның маңгай чәчен, борын өсләрен сыйпаган, ял төпләрен кашыган иде. Шул ук ис, яңа хуҗаның ягымлы исе, колыны аркасында да калган икән. Ул ис аңа кичә капчык төбендә калган солыны хәтерләтте, Җирәннең уртларына тәмле су килде.

Таң атып аланга мул булып яктылык иңә башлауга, алар, мылтыклы яткан куак төбен читләтеп уздылар да, аналы-балалы, кичә тугарып калдырган арба янына таба кайтырга чыктылар.

## Укучының күңел дәфтәренә

### Осетин мәкальләре һәм әйтемнәре

*Биюне аю бии, акчасын чегән ала.*

*Үзеңә теләмәгәнне башкаларга эшләмә.*

*Ничек итеп аваз салсаң, шундый яңгырык килер.*

*Мичкә тулы татлы балны бер кашык деготь боза.*

*Ничек пешсә, шулай ашыйсың.*

*Тавыш-тын ишеттермичә апара да әчеми.*

*Талашкан этәч симез була алмый, җитез колынны бүре буа алмый.*

*Урманы булса, балта табыла.*

*Тәңгә иркен, җанга кысан.*

*Кеше күңеле — кара урман.*

*Үз оясын пычраткан кош — кошларның иң начары.*

*Син аңа буйга саласың, ул аркылыга үлчи.*

*Өеңдә шайтан булмаса — кыз бир дә кияү китер.*

*Күп сөйләгән кеше аз эшли.*

*Телең белән ашыкма, эшеңдә кызу бул.*

*Буш тегермән сусыз да тарта.*

## Рәфикъ Юнысов

### Истәлеккә

Тарих түрендәге бер мизгелдә,
Җырлар җырлап тостлар аралаш,
Елдашларым минем бәйрәм итә...
Ә уртада — чыршы-замандаш!

Бөтерелә шар — Җир, орчык мыни!
Гасырларны урый, чорларны.
Ә без — бергә! Ә без, бокал тотып,
Сәламлибез бер үк елларны!

Күпме буын артта чират көтә —
Башкаларга күчәр безнең җыр.
Юка катлам булып ятып калыр,
Ятып калыр Җирдә безнең чор.

Миллионлаган еллар өелер өскә.
Таулар калкыр. Таулар ишелер.
Килер тарихчылар дәверләрне,
Гасырларны бутап интегер...

Тик онытмас Җирем, алга илтер
Смольныйның изге ташларын!
Онытмас Җир — беләм, беркайчан да! —
Безне — Ленин замандашларын!

Гасырларда уйнар Октябрьда
Без дөрләткән янгын шәүләсе!..
Һәйкәл булып барыр Җирне яклап
Җиргә ауган егет гәүдәсе.

...Галәм базарына илтә кораб
Туксанынчы гасыр товарын.
Космонавт белә: ул сәфәрнең башы —
Егерменче гасыр, Гагарин...

Без яшәдек Җирдә. Яшн белдек!
Бу яшәүнең аргы ягында
Тарих төпсезлеген балкытырлык
Бер хатирә калсын тагын да!

Горур иңсен Җиргә заманыбыз.
Кысып учка сугыш чакмасын.
Тамга булып ятсын — бездән өстә
Археолог корал тапмасын!

## Яшәү хакында уйлану

...Янмый кояш безнең өчен генә.
Бәхет кырык. Көтми артыгын.
Безнең елмаюлар, безнең шатлык —
Походтагы солдат шатлыгы.

Кайда булып,ниләр төземәдек,
Тартышмадык җирдә кем белән?!
Тормыш уйный бездә — безнең аша
Көрәшә ул шулай төн белән.

Кеше — филтә, вакыт — лампа мае —
Мөмкин иде моны аңларга!
Яшәү бит ул — яну: вакыт — бездә,
Без — вакытта тиеш янарга!

## Оча йөрәк

*Кош сулкылдый эчтә, күкрәктә.*
Зөлфәт

Оча йөрәк, оча, оча, оча —
Канат кагышларын санамый.
Океаннар кичте, океаннар!
Ә туктарга аңа ярамый.

Ядрә булып кайгы тишеп үтә,
Шатлык аны кинәт яралый.
Авырая канат. Таяныч юк.
Их, кунасы иде. Ярамый!

Бары аңа, бары аңа гына
Йокы да юк, ял да тынгы да.
Чыдамаска аңа ярамый! Һич!
Тик еларга ярый тын гына.

Очыш! Төнлә, көндез, томан булып
Бозлы сагыш йөзгән таң белән.
Давылларны ярып үтәсе бар
Каурыйсыз тән, сабый тән белән...

Менә дулкын бәрде — авыр-авыр.
Тагын бәрде аннан көчлесе.
Кара тынлык. Кап-караңгы тынлык...
Уян, йөрәк! Йөрәк! Ниш-ли-се-е-ең?!.

Төпсезлеккә, салкын төпсезлеккә
Инде төшеп җиттем дигәндә
Алып чыкты, алып чыкты йөрәк!
Яз, бәбкәләр йөри чирәмдә...

Килер ул көн: инде соңгы тапкыр
Талпыныр да тынар канатлар.
Ә ул, сүнә барып, «Туктамаска!
Туктамаска!» диеп кабатлар...

Ул сискәнер, очып китәр әле,
Кагылсагыз аңа сак кына.
...Лаек булсын гомер — безнең өчен
Барган бөек очыш хакына!

## Рәнҗемәгез

Китәбез дә югалабыз...
Ниләр күрми газиз башлар.
Оныттылар, кайтмыйлар, дип
Рәнҗемәгез, авылдашлар!
Иссә җилләр туган яктан,
Күңелләрдә — давыл, давыл!
Сөйгән ярлар онытыла,
Онытылмый туган авыл!

Биредә элек Ак инеш
Кайсы эздән ага иде,
Кайсы төштә иде басма,
Кайда бәртәс каба иде,
Нинди хуш ис килә иде
Ул чактагы үләннәрдән?

Сез аны бездән сорагыз,
Бездән — читтә йөргәннәрдән!

Китә егет, авылының
Соң сурәтен алып китә.
Күрше кызы һаман анда,
Нәни килеш, каэлар кәтә.
Шул авылга кайта егет,
Урамнардан кат-кат үтә.

Монда кайтсаң — бар да үзгә!
Ятсыналар хәтта ташлар.
Оныттылар, кайтмыйлар, дип,
Рәнҗемәгез, авылдашлар!

## Учак янында

Сары җылы, йомшак җылыда
Күпме талгын шатлык күмелгән!
Һәр күмердә бии ал өмет.
Ә шулай да моңсу күңелгә.

Әнә шулай килер мизгелне
Ялмап ала ялкын телләре.

Алма кебек алсу көннәрнең
Кала бары, кала көлләре.

Ә барыбер җылы күңелгә!
Бу — ышану биргән җылыдыр.
Дөрләп янган безнең бу көннәр
Бик күпләрне әле җылытыр.

# НАМУС КУШКАНЧА



Бу юлы ДОСААФ Үзәк Комитеты Президиумы утырышы озаккарак сузылды. Хәрби-патриотик, масса-оборона темаларына, шулай ук Совет Армиясенә таза, чыныккан, хәрби яктан хәзерлекле кадрларны җибәрү турында яңа мөһим фикерләр әйтелде. Президиум утырышыннан соң авиация маршалы Александр Иванович Покрышкин Гайнулла Шакировка ягымлы карап һәм ягымлы тавыш белән:

— Гайнулла Шәрипович, әйдәгез, кереп, берәр чынаяк чәй эчеп алыйк әле, — дип, аны үзенең эш бүлмәсенә әйдәде. Гайнулланың тартынуын сизенде булса кирәк, маршал яңадан кыстады: — Әйдә, әйдә, мин бит татарларның чәй яратканын бик яхшы беләм! Берәр чынаяк чәй эчеп, сөйләшеп утырырбыз, миңа да күңелле булыр, — диде һәм, култыклап үз кабинетына алып кереп китте.

Генерал белән маршал озак сөйләштеләр. Советлар Союзы Герое Муса Җәлилне искә алдылар, батырлыгына соклandылар. Александр Покрышкин саубуллашкан вакытта болай дип өстәде:

— Бөек Ватан сугышы фронтларында татар егетләре белән күп очраша идем. Аларның батырлыклары турында да күп мактау сүзләре ишеттем, үзем дә күрдем. Синең тырыш хезмәтең минем фикеремне бик яхшы раслый. Рәхмәт, Гайнулла Шәрипович, зур эшләр башкарасың, ун ел буенча Бөтенсоюз ярышында җиңүче булып чыгу җиңел эш түгел.

Гайнулла Шакиров Мәскәүдә эшләрен тәгәлләде дә, яхшы кәеф белән «Татарстан» поездына утырып, Казанга кайтырга чыкты. Агачлар шау чәчәктә. Кояшның якты һәм җылы нурлары вагон тәрәзәсеннән кереп, идәнгә сузылганнар. И табигатьнең гүзәл вакыты! Генералның күңелендә яраткан җыр моңнары уянды. Ул, вагонның ачык тәрәзәсеннән карап, әкрен генә көйләп җибәрде:

Һаваларда очкан кошлар кебек
Ярсый-ярсый канат кагынып,
Туган җирем, кайттым мин талпынып,
Күз нурларым, сезне сагынып.

Туган җир... Туган җир, туган ил барыннан да газиз, барыннан да кадерле! И туып-үскән Мамадыш яклары, туган туфрак, туган нигез... генералның күз алдына туган авылы Катмыш килеп басты. Ул бала чакларын, башыннан узган вакыйгаларны хәтерләде...

Мамадыш төбәге күбрәк игенчеләре, тегүчеләре, хәтта ат караклары белән телгә алынган як иде. Революциягә хәтле монда сәүдәгәрләр, байлар һәм кулаклар гына әйбәт яшәгән. Ә ярлы-ябагай көннән-көн хәерчеләнгән, ашарга икмәк җитмәгәнлектән, тирә-якка кәсепкә чыгып китә торган булган. Менә шул авыр елларда яшәгән яшүсмер Шәрифулла, бәхет эзләргә дип, ерак сәфәргә юл тоткан. Тик хәерчеләнеп кайткан. Ул үз авылларыннан Хәсникамал атлы чибәр генә кызга өйләнеп яши башлаган. Тормыш авыр. Гаиләсендә биш кыз, аларга җир бирелми, икмәк кыш уртасына чаклы да җитми. Авыл халкы тормыш җиңеләер, бәхет кошы безнең дә өй түбәсенә кунар дип өмет иткән. Көткән шатлыклы һәм бәхетле көннәр Октябрь революциясеннән соң гына килгән. Авыл ярлылары, байларның җирләрен үзләренә алып, иркен тормышта яши башлаганнар. Соңга таба, күмәк хуҗалыклар төзелә башлагач, авыл халкы колхоз оештырган. Менә шул кечкенә генә колхозга Шәрифулла абый да, Хәсникамал апа да кергән һәм җиң сызганып эшли башлаган, менә шул гаиләдә берсеннән-берсе матур һәм таза өч малай дөньяга килә. Шуларның берсенә Гайнулла дип исем кушалар. Гайнулла исеменең гарәпчә мәгънәсе бар: дәүләтнең күренекле кешесе дигәнне белдерә.

Беренче классны тәмамлагач, атасы аны Мамадыш базарына алып бара. Гайнулла кызыл йолдызлы шлем кигән бер кызылармеецны күреп соклана.

— Нәрсәгә шаккатып карап торасың? — ди әтисе.

— Әнә кызылармеец абый.

— Ә-ә!

— Мин дә зурайгач кызылармеец булам.

— Булырсың, улым! Тырышып укысаң, командир да булырсың әле!

Тулы булмаган урта мәктәптә укыганда ул, чыннан да, үзен хәрби кеше кебегрәк итеп тота башлый: иртәнге якта физзарядка ясый, гимнастика белән шөгыльләнә, спорт ярышларына катнаша, йөзәргә өйрәнә, граната ыргытуда мәктәптә беренчелекне ала. «Сугыш уены» уйнаганда исә Гайнулла командир була. Район күләмендә үткәрелгән хәрби ярышларда да Гайнулла Шакиров сынатмый.

Бер чакны Кама елгасы буеннан узып барганда, ул ком-таш арасында ялтырап торган бер нәрсә күреп ала. Янына барып ком-ташны актарып караса, исе китә: атылмаган патроннар! Малай аларны тиз-тиз генә җыя башлый. Унга якын. Кая куярга? Өйгә алып кайтса, атасы ачуланачак. Нишләргә? Патроннарны кепкасына тутыра да мәктәпкә йөгерә. Директор — тарихчы. Патроннарның азинчыларныкы икәнен белә ул, берсенә «Рәхмәтуллин Газиз Азин дивизиясе» дип тә язылган иде. Патроннарны район хәрби комиссариатына илтеп тапшырдылар.

Җиденче классны тәмамлагач, сигезенчегә 15 чакрымдагы Котлы-Бөкәш мәктәбенә йөри башлый. Аннан соң Чистайга 5 нче һөнәр училищесына укырга китә. Слесарь һөнәре алгач, Казанның Горбунов исемендәге заводына эшкә җибәрелә. Бу вакытта Бөек Ватан сугышы башланган була. Заводтагы күп кенә эшчеләр немец-фашист илбасарларга каршы сугышу өчен фронтка китәләр. Ул да, фронтка җибәрүләрен сорап, хәрби комиссариатка гариза бирә. Аңа: «Әлегә

яшең җитеп бетмәгән, курыкма, сиңа да чират җитәр, — диләр. Һәм дөрестән дә, җитә чират. Ул 1943 елны Кызыл Армия сафына үзе теләп китә. Аны Горький өлкәсендәге Арзамас шәһәренә хәрби мәктәпкә укырга җибәрәләр. Гайнулла Шакиров монда да сынатмый: уку отличнигы була һәм мәктәпне уңышлы тәмамлый. Сержант дәрәҗәсе алып отделение командиры булып хезмәт итә. Отделениесе мәктәп күләмендә беренчелекне ала һәм тырыш сержантны хәрби училищега җибәрәләр. Училищеда уку Гайнулла өчен шатлыклы да, мактаулы да була. Монда ул гражданнар һәм Бөек Ватан сугышында катнашкан командирлар белән очраша, алардан дәресләр ала.

1945 елның октябренда Гайнулла хәрби училищены тәмамлап чыга. Ул — Совет Армиясе офицеры, взвод командиры. Взводта олы яшьтәге солдатлар, араларында Бөек Ватан сугышында катнашканнары бар. Яшь һәм тәҗрибәсе җитеп бетмәгән лейтенант алардан да өйрәнә. Взвод полк күләмендә алдынгы була. Гайнулла Шакировны штабка алалар. Ул өлкән офицерлар, генераллар белән аралаша, аларның киңәшләрен тыңлый. Әмма биредә Гайнулла үзенең бер кимчелеген бик тиз сизеп ала: аның урта белеме юк бит әле. Уйлыйуйлана да шундый карарга килә: яшьләр өчен кичке мәктәпкә керергә!

Шуны үтенеп директор исеменә гариза яза, һәм аны укырга кабул итәләр. Ул урта мәктәпне алдынгы укучыларның берсе булып — көмеш медальгә тәмамлый. Ә аннары Мәскәүдәге К. Е. Ворошилов исемендәге хәрби академиягә имтиханнар тапшыра. Балачагыннан ук гражданнар сугышы геройлары Чапаев, Щорс, Дундич, Пархоменко, Ворошилов, Тухачевский турындагы китапларны укып үскән авыл малае үзе дә полководецлар укыган академиядә белем ала башлый.

«1951 ел. Минем өчен иң зур шатлык: мин хәрби академия тыңлаучысы. Бу турыда күптәннән хыяллана идем. Шул уй-хыялым тормышка ашты! Шатлыгымнан хәтта җырлап җибәрдем. Хәрби академиягә керүчеләр арасында күп төрле милләт уллары бар. Алар да шат һәм көләч, туып-үскән җирләрендәге әти-әниләренә, яраткан кызларына минемчә үк куанып үз телләрендә хатлар язалар».

«1957 ел. Хәрби академиядә уку бик зур тырышлык таләп итә. Моның өчен төннәр буе укырга, лекцияләрне калдырмаска, үз-үзеңне аямаучан булырга кирәк. Зур тәҗрибә туплаган, фронтларда булган кешеләр белән бергә укыйбыз. Алар — безгә үрнәк. Монда безгә гражданнар сугышында катнашкан олы яшьтәге генераллар да, Бөек Ватан сугышында зур батырлыклар күрсәткән яшь офицерлар да сабак бирә. Һәрбер курсант Ватан өчен файдалы белгеч булырга тели. Хәрбиләр арасында «Һәр солдат генерал булырга тырыша!» дигән сүз тикмәгә генә йөрми. Үткән көрәшләрдә халык арасыннан күпме генераллар чыкты! Алар барысы да башта солдат булганнар ич. Академия — ул югары белем бирә. Югары дәрәҗәле хәрби булу — ул үзеңнең тырышлыгыңнан килә. Без хәрби яктан талантлы булырга, армия хезмәтен яратырга тиеш. Көн үтсенгә генә укып йөрсәң, тырышмасаң үсеп булмый. Бу турыда Суворов та, Кутузов та, совет хәрби җитәкчеләре дә әйткәннәр, китаплар язганнар. Хәрби академия тәмамлаган кеше һәр яктан да җитлеккән, аның һәр ягы матур, ул Ватанның чын патриоты булырга тиеш. Ватан-ана, Коммунистлар партиясе безне шуңа өйрәтә, шуңа чакыра. Без моны намус белән үтәрбез!» Якташыбыз көндәлегендә мондый язмалар бик күп.

Академияне тәмамлагач инженер-капитан Гайнулла Шакиров хәрби частьта эшли башлый. Хәрби мәктәптә һәм хәрби училищеда

укыта. Аннан соң Казанга кайтып республика гражданнар оборонасы штабында хезмәт итә. Анда ул үзенең сәләтле оештыручы булуы һәм тырышлыгы белән танылa. Шуның өчен аны 1967 елны Татарстан ДОСААФ өлкә комитеты председателе итеп күтәрәләр. Республика ДОСААФ өлкә комитеты елдан-ел югары күрсәткечләргә ирешә, Советлар Союзы күләмендә призлы урынны яулап ала. Соңгы дүрт ел эчендә исә, социалистик ярышта бөтен ил күләмендә беренче булып, ВЦСПС, ВЛКСМ Үзәк Комитеты һәм ДОСААФ Үзәк Комитетының Күчмә Кызыл байрагын алуга ирешә. Сугыштан соң төрле сәбәпләр белән республика ДОСААФ оешмасында булган биналар, каралтылар башка оешмаларга таратылган, ату тирлары җимерек хәлгә килгән, яшьләрне армия сафларына әзерләү өчен кирәк булган техника, кораллар һәм башка җиһазлар бик азайган була. Бу исә оешма абруен әлбәттә күпмедер дәрәҗәдә төшерә. Нәрсәдән башларга, җирле ДОСААФ оешмаларын элекке Осоавиахим оешмалары дәрәҗәсенә ничек күтәрергә, моның өчен ниләр эшләргә кирәк?

«Барыннан да элек кадрлар, матди база кирәк!» — дип билгели комитет председателе Шакиров үз бурычын — оештыручы да, төзүче дә, дипломат та булырга туры килә аңа. Еллар уза... Нәтиҗә әйбәт: спорт корылмалары, йөзләрчә ату тирлары һәм башкалар барлыкка килә.

Кадрлар хәзерләү аеруча яхшы оештырыла. Полковник Гайнулла Шакиров сәләтле җитәкче, эшне дөрес оештыруы белән танылa. Республикада гына түгел, бөтен ил күләмендә ДОСААФның Татарстан өлкә комитетын мактап телгә алалар. Аның башлыгы ДОСААФның Бөтенсоюз съездларында күп мәртәбәләр делегат булып катнашты. Бөек Ватан сугышы ветераннары арасында зур эш алып барганы һәм ярдәме өчен Гайнулла Шакировны Советлар Союзының сугыш ветераннары комитеты өч тапкыр медаль белән бүләкли. Аларны комитетның җаваплы секретаре, Советлар Союзы Герое легендар очучы Алексей Маресьев тапшыра. Полковник Шакиров, йөрәгеннән ташып чыккан кайнар хисләрен белдереп, болай ди:

— Сезнең батырлыгыгыз безне зур җиңүләргә рухландырды. Рәхмәт сезгә, Алексей Петрович!

ДОСААФның Татарстан өлкә комитеты җитәкчесе буларак, тырыш хезмәтләре өчен Гайнулла Шәрифулла улы Шакиров Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почет билгесе» орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә. Комсомол һәм яшьләрнең Бөтенсоюз походында актив җитәкчелек иткәне һәм зур тырышлык күрсәткәне өчен аңа Советлар Союзы маршалы И. Х. Баграмян рәхмәт белдерә һәм медаль белән бүләкли.

Гайнулла Шакировның портреты инде күп еллар буе М. В. Фрунзе исемендәге Үзәк Авиация һәм Космонавтика йортында, маршаллар һәм генераллар, Советлар Союзы Геройлары белән бергә — түрдә эленеп тора. Яшьтән үк хәрби хезмәтне үз иткән, бөтен көче һәм сәләте белән Ватаныбыз өчен армый-талмый эшләгән Г. Шакиров, ниһаять, зур хәрби дәрәҗәгә лаек булды: ул хәзер генерал-майор. Тырыш хезмәтләрен «Советский патриот» газетасы мактап язды. Социалистик илләрнең оборона җәмгыятьләре белән тыгыз элемтәдә булып, аларга оборона эшләрен оештырудагы зур ярдәме өчен Г. Шакировны күптән түгел Ю. Цеденбал Монголиянең «Халхин-Голын ялалт» дип аталган медале белән бүләкләде. Генералның өй архивында аның тырыш хезмәтләренә зур хөрмәт күрсәтеп бирелгән башка бик күп медальләр, Советлар Союзы оборона министры Д. И. Устинов тапшырган Почет грамотасы һәм күп кенә башка истәлекле бүләкләр бар.

Генерал Гайнулла Шакиров — СССР Журналистлар союзы члены. Аның мәкаләләре «Военные знания», «Коммунист Татарии», «За рулем», «Радио» журналларында, күп кенә газеталарда басылып чыга. Өч китабы — «Патриотлар мәктәбе», «Батырлыкка әзер бул» (Казанда), «Увлеченность» (Мәскәүдә) басылып чыкты. Хәзер ул Осоавиахим һәм ДОСААФ тарихы турында зур җыентык әзерли.

Генерал татар әдипләре белән дә тыгыз элемтәдә тора. Ул язучылар белән әледән-әле очрашып, аларга хәрби-патриотик темага язу өчен төрле киңәшләр, кыйммәтле материаллар бирә. Аның турыдан-туры катнашы белән ачылган хәрби музейда татар язучыларының автограф белән бүләк ителгән күп кенә китаплары бар. Хәрби-патриотик темага яхшы әсәрләр язганы, лекцияләр укыганы өчен генерал Шакиров берничә язучыны «ДОСААФның почет билгесе» знак-медале һәм Почет грамоталары белән бүләкләде.

Польша Халык Республикасыннан, Ямән Демократик Халык Республикасыннан һәм башка илләрдән, союздаш һәм автономияле республикалардан килгән делегатлар һәм кунаклар ДОСААФның Татарстан өлкә комитеты ирешкән уңышларга сокланалар, зур бәя бирәләр. Алар һәммәсе:

— Рәхмәт сезгә, генерал! — дип саубуллаша Шакиров белән.

САМАТ ШАКИР.

**Ринат Мөхәммәдиев,**
филология фәннәре кандидаты

# СИНЕҢ ТАКТАШЫҢ БАР...

*Уюта — нет, покоя — нет.*
Александр Блок



Шигърият, син нинди бәхетле! Сокланам, табынам, баш иям алдыңда... Күкнең зәңгәрлегенә, җирнең җылылыгына, кешенең олылыгына сокланып туймаган җырчыларыңа сокланам. Һичкемгә баш бирмәс түрәләрне, чәчәкләрдән аера алмаслык гүзәлләрне табындырган илаһиятең каршында табынам. Явыз палач алдында да баш имәгән, туры яшәп горур китә белгән, кирәк чакта бөркет, кирәк булса былбыл була белгән тугрылыклы улларыңа баш иям. Шигърият, син нинди бәхетле!..

Пушкин һәм Тукай, Лорка һәм Назыйм Хикмәт, Маяковский һәм Такташ, Җәлил һәм Неруда... — минем өчен син шундый исемнәрдән башланасың. Бары да киткән, әйе, киткәннәр... Ә җырлары безне алга әйди, алга дәшә: яңа көрәшләргә, яңа җиңүләргә, чиксез мәхәббәткә. Дәвам итүчеләрме? Бар! Синең чишмәң саегуны белми, һәр яңа көн яңа көрәш дигән сүздер — яңа җырчылар, яңа җырлар туа тора. Кеше рухы, халык рухы, инеш һәм елгалардан аермалы буларак, елдан-ел тирәнәя генә бара. Күпмилләтле Ватаным поэзиясенең бер тармагы булган татар совет шигъриятендә генә дә синең олы принципларыңа ахыргача тугрылыклы булган затлар аз түгел! Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев һәм тагын байтак кына исемнәрне бер горурлык белән атап китәргә була.

...Ләкин «Матур гына мактап киләләр дә, иң ахырдан «Ләкин» сүзен кыстырып куялар», — дип, күрәмсең, шагыйрь дә юкка язмагандыр. Бу очракта да ләкин сүзенә урын кала. Чөнки шигырь исеме астында укучыга тәкъдим ителүче әсәрләребез арасында төрлеләре бар. Сүз дә юк, йомшак әсәрләр, пешеп җитмәгән шигырьләр элгәреге чорларда да аз язылмаган. Пушкинның һәр яңа әсәре рус әдәбиятында бер вакыйга буларак кабул ителгән көннәрдә һичнинди идея-эстетик кыйммәткә ия булмаган дөнья кадәр буш сүз шигъри калыпка салынып җилгә очырылган кебек, «Әлгасрелҗәдит» һәм «Аң» журналларында Тукай исеме белән янәшәдә күпме автор шагыйрьлеккә дәгъва иткән, шигырь язарга омтылган. Табигатьтән би-

релгән шигъри рух, дөнья камертоны булырдай сизгер йөрәк сирәк очрый икән, кемне гаепләргә... Юк, талантларның сирәк тууына сылтап, таләпчәнлекне бераз киметү кирәклеген якларга җыену түгел бу. Халык рухы, халык күңеле байлыклары чиксез. Ә инде талантларны эзләү һәм тәрбияләп үстерү Партия һәм Дәүләт тарафыннан даими кайгыртылып килгән илебездә андый кытлык булуы һич мөмкин түгел. Димәк, сәбәпне дә объектив шартлардан түгел, субъектларның үзләреннән эзләргә кирәк булып чыга.

«Ә шагыйрь булу нинди авыр... Еллар буе кешеләр тудырган белем, фән, хис, фикер — тормыш эченнән туып та, бертөрле рәвешкә кермәгән уйларны, хисләрне бер төрле рәвешкә кертергә, аның үзенә кирәк буяуларын табарга, шуны оештырырга омтыласың», — дип язган Һади Такташ хатларының берсендә. «Шагыйрь булу нинди авыр...» Кем-кем, әмма Такташның, һәр сүзе, һәр строфасы бер җиңеллек белән уйнап-җырлап торган Такташның шулай язуы бер карашка гаҗәбрәк тоелырга мөмкин.

Их!
Авыл кырын тотырып бодай үсә,
Дулкынлатып аны җил исә,
Ташлап шагыйрьлеген җил иркенә,
Калыйм мәллә монда югыйсә...

Гайшә кызы килә казлар куып,
Артта кала аксак бәбкәсе,
Бөгелеп алган чакта бәбкәсен ул,
Шалтырап китә талир тәңкәсе...

Мең газаплы иҗат уңышлары, шигъри камиллек, йөгереклек, күрәмсең, Такташка да җиңел генә бирелмәгән. Такташ шәкертләре (шигырь язам дип кулына каләм алган һәр яшь авторны мин, билгеле бер дәрәҗәдә, Һади Такташ шәкерте дип беләм) исә шушы гармония һәм җитлеккәнлектән читенергә хаклы идеме икән. Әлбәттә, сүз нәкъ Такташча язу, аңарга сукырларча иярү турында бармый. Ә Такташ поэтикасының төсләре гаммасы, шигъри осталык һәм оригинальлектә аңардан әле бик күп өйрәнергә кирәклеге хакында. «Нәни разбойник», «Әйдә, энем!», «Картайдым шул», «Әй җырлыйсы килә шушы җырны», «Тамбов урманнарын ташлап китәм», «Мокамай», «Алсу» әсәрләренә игътибар итик! Бүген поэзия мәйданында яхшы гына ат уйнатып килгән кордашларым-чордашларымның яңа шигырьләрен укыганда еш кына күңелгә әлеге шигырь юллары килә. Чын шигырьләр, яхшы шигырьләргә сусаганнан дип әйтә алмыйм, чөнки бүгенге поэзия, ул берничә буын талантлы шагыйрьләр гаиләсе дигән сүз. Яхшы әсәрләр туа тора. Шулай да күңелгә Такташ килә.

Такташ... Туган ягым урманнарына килеп кергәч тә, ни гаҗәптер, иң элек аның шигырьләре хәтергә төшә. Су буеннан казлар куып кайтып килгән бер сабыйны күреп калсаң, ниндидер ассоциацияләр аша «тагы шул ук шигырьләргә юлыгасың. Җилдә чайкалып утырган түк башаклы бодай кырлары, ап-ак каен, уттай янган усак яфраклары, адашкан песи — бары, бары да, әйтерсең, бер Такташ шигырьләрендә генә тасвирланган. Аның шигырьләре сабый чаклардан ук матурлык, гүзәллек символы булып кабул ителгәнгә шулаймы?! Такташны сагынумы бу... Сагынудыр, әмма Такташ шигъриятендәге җиңеллек, йөгереклек, рифма һәм ритм оригинальлегенә генә кайтып калмый бугай ул сагынуны тудырган, дөньяга чыгарган сәбәпләр. Куактан-куакка кунып, болын, урман-кырларның иркенлеген, гүзәллеген мактап җырлаган былбыл гына түгел Такташ. Шигърият серләрен, халык поэтикасын соң нечкәлекләренәчә үзләштергән җырчы гына да түгел. Сирәк очрый торган хәзинәгә ия бәхетле шагыйрь генә дә түгел. Такташ — шәхес! Ул һәм аның иҗаты, барыннан бигрәк, гадәттән тыш олы җанлы, киң күңелле, бар дөньяга гашыйк шәхес белән характерлана. Һәм нәкъ менә шул масштаблы шигъри шәхес булуы белән гыйбрәтле, яңадан-яңа буын шагыйрьләргә остаз булып торырга лаек. Бүгенге поэзия үрнәкләре белән танышып утырган җирдән еш кына кайтып-кайтып Такташка, Тукайга һәм

Җәлилгә мөрәҗәгать итүнең сере дә ерак яшерелмичә әлеге шәхес, принципиаль һәм масштаблы шәхес мәсьәләсенә тоташа булса кирәк. Шунда ук тагы бер искәрмә: шигъриятебезгә шәхес буларак формалашмаган авторлар килә дип әйтү түгел, шигырьләрдә шул шәхесләрнең үз-үзләрен табуы һәм бөтен тулылыгы белән ачылуы, тулы бер шигъри шәхес булып мөстәкыйль яши башлавы күздә тотыла.

Шәхес... Бу төшенчәне аңлауда ниндидер конкрет, һичнинди бәхәс, икеләнүләргә урын калдырмаслык рецепт биргән сүзлекне минем әлегәчә очратканым булмады. Шигъри шәхес, шагыйрь шәхесе хакында сүз чыккан очракларда да, аны төрлечәрәк, төрле аспекттан килеп аңлатырга омтылулар яши. Әлеге мәкаләдә исә игътибарны шулай ук, нигездә, шагыйрь шәхесе мәсьәләсенә юнәлтеп, сүзне Такташ иҗаты мисалында дәвам итәргә исәп.

Такташның тууында да бер символик мәгънә бар. — Яңа гасырның беренче көне, таңга иртәсе (1901 ел, 1 гыйнвар). Аның дөньяга карашы, әйләнә-тирәгә мөстәкыйль үз мөнәсәбәте ачыклана башлаган еллар, шагыйрьнең биографиясенә һәм истәлекләргә нигезләнеп фикер йөртсәк, Гражданнар сугышы башланган, социаль контраст һәм каршылыклар соң дәрәҗәдә кискенләшкән чорга очрый. Ә инде шәхес буларак формалашу, эзләнү, үз-үзен табарга омтылу вакыты тиңдәшсез олы тарихи борылыш — Бөек Октябрь революциясе дәверенә туры килә. Сүз дә юк, масштаблы һәм яңа шигъри шәхес формалашу өчен тагын да кулайрак шартларны күз алдына да китерү мөмкин түгел. Ләкин Такташның олылыгын елларга гына кайтарып калдырсак, без шулай ук зур хата ясаган булыр идек.

**Безнең гомер бөек планетаның**
**Шау-шулы бер чорына очрады.**
**Планетада бүген зур дау бара.**
**Ыгы-зыгы**
**Килеп тора бөтен почмагы.**
**Мин бу дауның үткән тарихына,**
**Бездән алда булган чорына**
**Туктап тормыйм,**
**Бары бүгенгене**
**Сюжет итеп алам җырыма.**

Һәр чорның үз проблемалары, кабатланмас тарихи вакыйгалары, иҗтимагый һәм рухи йөзе була. Шәхес шул объектив чынбарлык продукты, аның иҗтимагый-политик һәм интеллектуаль карашлары, принциплары конкрет шартларда тамырлана һәм яфрак яра. Гадәттән тыш күзәтүчән, сизгер һәм эмоциональ булган шагыйрь күңеле, шагыйрь йөрәге, шул чор сулышын бөтен барлыгы белән сеңдерә килеп, иҗатында яңача, сәнгатьле ачыш югарылыгына күтәреп дөньяга чыгарга тиеш. Әлбәттә, бу турыдан-туры эшкәртеп, барын түкми-чәчми шигырь юлларына салып бару булып та аңлашылмас. Иҗтимагый, рухи һәм эстетик идеал бу процессның бөтен барышын, агышын бер системага салып торыр. Такташ поэзиясендә исә әлеге системаның барлыгы аермачык булып һәр даим күзгә ташлана. Шагыйрь булган, шигърияттә кабатланмас үз дөньясын тудырырга омтылган, конкрет бер чорның масштаблы шигъри шәхесе (микро шагыйрьләр булуын гомумән күз алдына китерү кыен) булырга дәгъва иткән һәр авторның, миңа калса, югарыда искә алынган идеаллар суммасыннан гыйбарәт үз системасы да туарга тиеш. Шунсыз мөстәкыйль шигъри шәхес була алмый. Бер әсәрендә үзе булып, икенчесендә остазларыннан бераүгә ияреп, өченчесендә бармактан суырып ни эләкте шуны шигырь юлларына салырга ашкынып торган, замандашларына һәм килер буыннарга үз җаныннан саркып торган әһәмиятле, яңа әйтер сүзе булмаган шигырь язучыларны, әлбәттә, шигърияттә әле үз шәхесен тапкан дип әйтеп булмый. Үз чорын, үз күңелен, һәм, гомуман, үз-үзен укый һәм аңлый белмәгән (әлбәттә, бу уку һәм аңлау аерым очракларда хаталы һәм ялгыш булырга да мөмкин) автор укучысына ни тәкъдим итәргә мөмкин?! Шигырь өчен тема, сюжет таба алмый зарланып йөргән һәм очраклы рәвештә „эләктереп алынган информация һәм шигъри детальдән көчәнеп шигырь ясарга ашкынып торган авторларга бу хакта җитди бер уйланып алу зыянга китмәс төсле. Тагын да

Такташның үзенә сүз бирү урынлы булыр: «Домна мичennән рәттән тезелеп аккан рудалар йөрәктән агып чыккан шигырь юлларына охшыйлар. Ләкин алар һәр акканда үзенә бер формага агарга, хәзергә кадәр булмаган бер рәвешкә керә барырга һәм һәрбер агып чыккан шигырь рудасы үзе белән яңалык алып килергә тиеш».

Такташ тудырган лиро-эпик дөнья күз алдыбызда. Ул бөтен, тулы канлы, өзлексез хәрәкәттә һәм гомерле. Югары гражданлык аның үз холкы, үз психикасына гына хас интим тойгылар белән чиратлашып килә. Үз шигъри «Мин»ең ясап, өреп кабартырга газапланасы юк, ул болай да бар һәм әллә каян күзгә ташланып, чәчрәп тора. Шигырь өчен «Мин» һәм «Без» зат алмашлыклары, гомумән, гадәти күренеш, аларны теләгәнчә кулланганы өчен шагыйрь, тәҗрибәле өлкән шагыйрьме ул, әллә башлап язучы гынамы, гаепләү һич урынлы булмас. Ләкин инде авторның «Мин»е үз-үзендә казыну, үзенә дә аңлашылып бетмәгән шәхси уй-тойгыларны укучыга шигырь рәвешендә көчләп тагуга хезмәт итә икән — бу аяныч күренеш һәм ул тәнкыйтьне битараф калдыра алмый.

Күп кенә башка талантларга да хас булган, үз дәрәҗәсен белү, үз иҗатының олылыгын тоемлау һади Такташка шулай ук чит түгел.

Пушкин:

**Я памятник себе воздвиг нерукотворный,**
**К нему не зарастет народная тропа...**

Тукай:

**Шигъре Лермонтов вә Пушкин — олугъ саф диңгез ул,**
**Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов, Тукай — өч йолдыз ул.**

Байрон, Гете, Лермонтов, Маяковский, Җәлил кебек шагыйрьләрнең аерым әсәрләрендә дә әлегедәй үз иҗатларына ышаныч мотивлары очраклы күренеш түгел. Такташ шигырьләренең структурасына да шул рәвешле ышаныч белән язылган юллар килешеп тора:

**Мин яралдым серле моңнарым белән бар дөньяны**
**Еглатырга. Әйе, миндә көчле Байроннар җаны...**

яисә икенче бер шигырендә, үзенә генә хас дуамал шаяру белән ул болай дип өстәп куя:

**Мин биш елда үземә бурыч итеп куям**
**Пушкиннарны узып китәргә...**

Әлбәттә, бу характердагы юллар шагыйрьне гадәттән тыш җаваплылыкка чакыра. Иҗат белән исбат ителми икән, алар укучыга коры бер шапырыну булып тоелырга мөмкин. Ә Такташта исә җаваплылык хисе җитәрлек; заман укучысы каршында гына түгел, киләчәк буын алдында да олы җаваплылык хисе тоеп иҗат итә ул. Әледән-әле үзе дә абайламыйча дигәндәй, утызы да тулмаган шагыйрьнең «Такташ бабагыз» дип куюын да гади шаярудан бигрәк, килер буын укучыларына мөрәҗәгате дип аңларга мөмкин. Программ әсәрләреннән берсен «Киләчәккә хатлар» дип исемләп, әле җирдә тумаган буын укучылары белән күзгә-күз сөйләшү, фикер алышуы исә шагыйрьнең үзе яшәгән чор белән генә чикләнеп калмыйча, килер көн, килер буыннар бәхете өчен дә янып иҗат итүен ачык раслап тормыймыни?!

**Без беләбез сезнең киләчәкне,**
**Без беләбез сезнең киләсен,**
**Без беләбез соңгы көрәшләрнең**
**Безгә җиңү алып бирәсен!**

Шагыйрьнең гади хыялы янсә күрәзәлек итеп утыруы нәтиҗәсе генә түгел, әлбәттә, бу юллар. Тарихи оптимизм, үзе янып яшәгән идеалларның реаль булуына, тормышка ашачагына ныклы ышаныч беркелеп тора алардан. Әлеге ышаныч, әлеге иҗтимагый-политик оптимизм аның бөтен иҗатына якты нур биреп тора. «Киләчәк көн якты, Тарих канаты Безне алып бара...» кебек юллар Такташ өчен һич очраклы түгел.

Шул ышаныч, шул ук оптимизм шагыйрьгә үзе яшәгән чорның гүзәллеген, табигать һәм хезмәт кешеләренең матурлыгын җырлап туймаслык илһам бирә.

Ах,
Мин җир өстен артык сөйдем бугай,
Артык сөйдем аның гөлләрен,
Һәрбер буйга җиткән каен кызын
Усак егетеннән көнләдем...

Үзе көрәшеп, янып яшәгән чорның кыенлыклары булуын да күрми калмаган, әлбәттә, шагыйрь. Әмма алар булган очракта да Такташ дөньясын, бөтен әйләнә-тирәсен каһәрләргә ашыкмый, ә гади бер шаяру сыман гына уен-көлке итеп уза бедә. Әйтик, «Әйдә, энем» шигырендәге шаяру, дөрес булса, турыдан-туры шагыйрьнең тормышында булган кыенлыклар — материаль җитмәүчелек белән бәйле икән. Шуңа да карамастан, анда аз гына да зарлану нотасы тапмассың, киресенчә, шигырь киләчәккә нык ышаныч беркелеп торган юллар белән тәмамлана:

Җәен үсәр зәңгәр чәчәкләрнең
Җырын ишетәм инде —
Яз килер,
Карлар эрер,
Бозлар китәрләр;
Тау битләре ачылыр,
Безнең кырда
Зәңгәр гөлләр күкрәп үсәрләр.

Шул характердагы әсәрләрдә шагыйрь шәхесе күңелләрне җилкендерерлек матур яклары белән ачыла. Үз кайгы-хәсрәтеңнән, үзеңнең нәни борчу һәм мәшәкатьләреңнән өстен булу, югарырак тору, үз урыныңны һәм үз миссияңне Ватан, Җир һәм Тарих кебек олы төшенчәләр киңлегеннән бәяли, таный белү — һай, ни дәрәҗәдә сокландыргыч сыйфат шагыйрь өчен. Черки тешләгәнгә каравыл кычкырырга гадәтләнгән, сөйгәне белән аңлаша алмадым дип еллар буе иҗатында күз яше түгәргә өйрәнгән, характер җитенкерәмәү сәбәпле үз-үзенә кыенлыклар чыгарып, шуны катлаулы, каршылыклы язмыш сурәтендә укучыга җиткерергә күп сорамаган авторларга Такташның бу сыйфатына игътибар итү зыян итмәс иде.

Шау-шулы шәһәр тормышыннан ераклашып туган авылы Сыркыдыга кайткач та шагыйрь йөрәге үзенә тынгылык таба алмый. Авыл аның балачак бишеге, дөньяның шагыйрь күңеленә иң якын һәм үз почмагы. Монда ул тулысы белән балачак хатирәләренә бирелә, туган як табигатенең гадилеге, бөтенлеге белән назлана:

— Пи-би-би-бип... —
Ди дә каз бәбкәсе,
Яхшатланып килгән, сөйләнә...
Каз бәбкәсе, белмим телеңне.
Шуңа бүлешә алмыйм сереңне...
Белсәм иде, мин дә тыңлап сине,
Аунап ятыр идем чирәмдә.
Син дә, ашый-ашый, теләгәнчә
Сайрап йөрер идең тирәмдә...

Ләкин бу җыр никадәрле генә җанга якын һәм үз булмасын, еллар үткән, инде яшьлек хатирәләре белән генә чикләнеп, тыныч авыл кочагында кәеф-сафа корып яшәп ята торган чаклар түгел: «Җырланган җыр кебек яшьлек таңы шаулап үтте, шаулап үтте инде гомергә». Зур тормыш эчендә кайнап, дөньяда һәм Туган илдә барган олы үзгәрешләрнең ургылып торган ноктасында булырга күнеккән шагыйрь җанын кая куярга белми башлый: «Кит лә, кояш! Уйнап йөрмә монда. Болай да бик кызу йөрәктә...» Туган якларының якты киләчәге, иртәгәсе көннең матурлыгы хакына җирдә зур көрәш, хәлиткеч көрәш барган вакытта ул, әлбәттә, ямьле табигать һәм тыныч авыл кочагында озакка кала алмый. Тынгылык белмәс шагыйрь йөрәге яңадан уттай кызу көрәш кырына ашкына. Төн күбәләгенең утка ташлануыннан аермалы буларак, бу адым — шагыйрь шәхесенең табигатеннән килгән аңлы омтылыш нәтиҗәсе.

**Тамбов урманнарын ташлап китәм,**
**Нишлим!**
**Шау-шуларга күңел чыныккан,**
**Давылларда туып канатланган**
**Бунтарь йөрәк кача тынлыктан...**

Шагыйрь биографиясеннән, шул рәвешле, кайсы гына чорга мөрәҗәгать итмә, бер нәрсә ачык булып күзгә ташланып тора — ул һәрвакыт Ватаны һәм халкы өчен яшәүне, шәхес буларак, иң изге бурычы, намусы эше дип саный. Куен дәфтәрендә язылган: «**А партия, [...] шатлыгым да, янар яшьлегем дә, җырларым да сиңа булсыннар...**» кебек юлларның артында кыска гына гомер юлы узып та, зур масштаблы иҗат һәм яшәү үрнәге калдырган шагыйрь тормаса, сагаю һәм шикләнүләргә дә урын калыр иде. Ә Такташта исә сүз белән эш, иҗат белән тормыш бер бөтенне тәшкил итеп бергә кушылып ага, бергә ургыла. Һәм бүгенге укучы, аның «Киләчәккә хатлар»ын алган замандаш, шагыйрьме ул, эшче яисә игенчеме, илдә яңа тормышның ныклы нигезен кору өчен көрәш барган елларда үтелгән әлеге яшәү үрнәгенә игътибарлырак булсын иде. Сүз белән эш, иҗат белән тормыш, яшәү рәвешенең бергәлеге — бик еш кына онытабыз кебек әле без болар турында.

Шунда ук Такташның шәхес буларак шигырьләрендә ахыргача үзе булып калуына, ихласлыгына сокланмау мөмкин түгел. Чорның катлаулы тормышын, мең каршылыклардан торган көрәшен җырларга алынган шагыйрь өчен, бер карашка, бөтенләй әһәмиятсез булып тоелган деталь һәм фактларны да ул гадәттән тыш уңышлы һәм зәвык белән файдалану юллары таба. Әйтик, шагыйрь тикле шагыйрьгә үзенең балачак шуклыкларын искә алып, кыяр урлап йөргән чакларын, күрше карчыгының ак әтәчен суюны, мәчет тәрәзәсен бәреп вату кебек меңләгән гөнаһларны яңартуның кирәге шул кадәр үк зур идеме икән. Әлбәттә, түгел. Халыкка һәм партиягә, Ватанга, кешеләргә мәхәббәте ташып торган масштаблы шигъри шәхеснең кайтып-кайтып казлар, песи кызлары һ. б. белән мавыгуы да килешеп бетмидер кебек. Югыйсә, үз вакытында тәнкыйть тә шундый «ваклыклар» өчен Такташны әледән-әле чеметкәли, тарткалый килгән. Ә Такташ үзенчә язган, башлаган юлын дәвам иткән — Такташ булып калган. Шагыйрь яшәү һәм иҗат принципларына ахыргача тугрылыклы булганы кебек, күрәмсең, үз мавыгуларына, үзе үткән юлга, балачагына да хыянәт итмәскә, тугрылыклы калырга тиештер. Кеше арасына кердем дип, үзең сабый чакта киеп йөргән ямаулы чалбар һәм олтанлы итекләрне бөтенләйгә онытып, үзең аунап үскән чирәм һәм инеш буйларын искә дә алмый үз биографияң һәм үз-үзеңнән уңайсызланып, оялып яшәү белән шагыйрьлек янәшә килә аламы икән? Миңа калса, шагыйрь күңеле, Такташтагыча, дөньяның барлык эре һәм ваклыклары өчен бер дәрәҗәдә шәрран ачык булырга тиеш. Дөресрәге, шагыйрь өчен эре һәм вак нәрсәләр гомумән булмаска да мөмкин, сүз әһәмиятлене әһәмиятсездән аеру хакында гына барырга тиеш.

Ә без исә юк-юк та үзебезнең әсәрләрдә, башкалар алдында сынатудан шелләп, тулысынча ачылып бетүдән сагаябыз, җан теләгәнчә шаяртып алу, елмаюны да җитди проблема күтәргән әдәби әсәр өчен чит-ят нәрсә дип саныйбыз. Укучының иң әһәмиятле, җитди проблемаларны да мөмкин кадәр гади, гадәти итеп кабул

итәргә гадәтләнгәненнән хәтердән чыгарабыз. Гадилек, гадәтилекнең әйтеп бетергесез үтемле эстетик чара булуын искә алып бетермибез. Монда исә, Такташтан өйрәнерлек урын шулай ук бар. Мисал өчен, җитди генә проблема күтәргән шигырьдә, һич көтмәгән җирдә «көтүләрдә хәзер кем кәҗәсе алдан чабып йөри торгандыр...», дип уйга калу урынсызрак тоелырга мөмкин. Яисә Зәбәйдәнең чәчәк атмас борын шиңгән мәхәббәте турында укып килгәндә шундый юлларга очрыйсың:

**Ул төнне ай күктә эш тапмыйча,**
**Эче пошып сүгенеп йөрегән,**
**Ул төнне Әүхәди юлга чыгып,**
**Кире кайткан куркып бүредән...**
**Шушы төнне Гыймади, эт өрсә дә,**
**Тәмле йокысыннан тормаган,**
**Шәкүр карак аның абзарыннан**
**Күк айгырын кереп урлаган...**

Ләкин гадәти булмаган шундый күчешләр һич кенә дә логик эзлексезлек булып аңлашылмый, ә кызыксынуны бермә-бер арттырып, үстереп җибәрә, әсәрнең лирик аһәңен көчәйтеп, эпик киңлеген бермә-бер колачлырак, масштаблырак итә. Турыдан-туры шагыйрь шәхесенең ихласлыгы белән элемтәдә булган әлеге үзенчәлек уникальлеге белән аерылып торган Такташ поэтикасын тудырган чараларның берсе булып тора. «Шигырьнең кыйммәте нәни бер идеяне кеше аңламаслык итеп язуда түгел, бәлки бөек идеяләрне җиңел, гади рәвештә өч-дүрт җөмләдә әйтеп бирә алуда... Тормышка бәйләнмәгән абстракт образлар шигырьне матурламый да, тирән мәгънәле дә итми», — дип язган шагыйрь үзе дә. Ихласлык, гадилек һәм тормышчан детальләр белән үз поэтикасын тудырган шагыйрьнең сүзләре берсүзсез, махсус игътибарга лаек, актуаль.

Шигырьләрдә — үзең булып яшәү, үзең булып хәрәкәт итү, үз-үзең белән каршылыкларга кереп бәхәсләшә-бәхәсләшә берөзлексез үсү. Социаль-политик карашларың, интеллектуаль йөзең белән генә түгел, ә бөтен характерың, темперамент һәм психик үзенчәлекләреңнән дә аерылмый яшәү — шигърияттә шәхеснең тулысынча ачылуы өчен мөгаен боларның барысы да булу шарттыр. Һади Такташ шигырьләрен яңадан кайтып-кайтып укыганда тагын бер кат әнә шул хакта уйланасың. Шагыйрь үзенең әсәрләрендә күңелен ниләр били, җанын ниләр борчый, барын да әйтергә омтылган кебек, ул уйларны шигырь юллары тарсынып дип икеләнеп тә тормаган. Ә шул ук вакытта аның иҗаты тулаем сокландыргыч бербөтенне тәшкил итә. Димәк, иҗатны бер йодрыкка туплап торган принципиаль һәм ахыргача үз-үзенә тугрылыклы шәхес булганда күтәрелгән проблема, кузгатылган мәсьәлә, борчыган уй, хәтергә килгән истәлек һәм шаяруларның төрлелеге, стиль һәм поэтик сурәтләү чараларының күптөрлелеге генә ваклый алмый, таркатмый икән. Такташ дигәч тә күз алдына масштаблы шагыйрь, трибун, үз халкы һәм ватанына, үзе яшәгән һәм иҗат иткән данлы елларның төп проблемаларына соң чиккәчә бирелгән шагыйрь килә. — Моңарга һичкем шик белдермәс. Шагыйрьнең гражданлык ялкыны, ашкыну һәм борчылулары — аның һәр шигырендә. Шаярамы ул, елмаямы, сарказмга күчәме, чәчтән сыйпыймы, башка китереп сугамы — һәр очракта аның шигырьләреннән яңа өчен, матурлык өчен көрәш пафосы бәркелеп тора. Шагыйрь буларак, шәхес буларак үзенең төп миссиясен ул ачык белә:

**Авыр көрәш, бөек еллар өчен**
**Кирәк булган минем тууым!**

«Интернационал»ны «Тормыш симфониясе»нә тыңлап, «җырда бөек елларның үз Ленинын тудырырга» омтылып иҗат итә шагыйрь. Тынычлык һәм хаклыкны яклап дәүләт җитәкчеләре, министрлар белән бәхәскә керә («Лорд Чәмберленга СССР крестьяны Һади Такташтан җавап нотасы»), дөньяның төрле почмагында барган социаль көрәш, политик вакыйгаларны эзлекле күзәтеп барып, аларга үз мөнәсәбәтен белдерә килә («Оятсыз юк сатлык юлбасарның», «Пуанкарә», «Яңа лордлар, пер-

вый сортлар»). Туган ил чикләренең дә тыныч түгеллеген яхшы аңлап, совет сугышчылары арасына омтыла, интернационализм һәм патриотизм хисләре белән тулы яңа шигырьләр циклы язып чыга. Әле Октябрь революциясенә кадәр үк беренче шигырьләрендә кан койгыч империалистик сугышны давыл сыман кубып кире каккан, тәнкыйть иткән шагыйрьнең яшь совет армиясен уяулык һәм хәзерлеккә чакыруы бер набат булып яңгырый сыман.

Такташның гражданлык активлыгы һәм чорның аеруча җаваплы, эре планлы мәсьәләләре, вакыйгалары белән янып яшәвен күрсәткән факт һәм мисалларны аның иҗат һәм тормыш юлыннан күпләп китерергә мөмкин. Шулай да шагыйрьнең даһи Ленин образына мөнәсәбәте, арада якты йолдыз кебек, игътибарны үзенә аеруча җәлеп итеп тора. Такташның гомумән ил күләмендә Ленинга багышланган беренче поэма язып тәмамлавы мәгълүм факт. Ләкин эш шагыйрьнең оперативлылыгында, бөтен прогрессив кешелек өстенә авыр кайгы булып килгән тетрәндергеч вакыйгага беренче булып шигъри әчкыч табуында гына да түгел. Барыннан да элек, әлеге чиксез олы югалтуның дәрәҗәсен кешелек тарихында яңа бер эпоханы ачкан Ленин образының масштабын шул көннәрдә үк ачык тоеп язылган булуы белән сокландыра поэма. Шул ук вакытта ул гадәти багышлау, даһи исеменең олылыгына соклану һәм дан җырлау рухында гына язылмаган, юкса бу теманың әһәмиятен тоеп, шул рәвешле иң традицион һәм гадәтләнгән җиңел юлдан барып язылган шигъри әсәрләр әле безнең көннәрдә дә бик еш күренгәли киләләр. Такташ, әйтерсең, ил өстенә, халык өстенә зур кайгы булып ишелгән вакыйгадан репортаж язган, чын шигъри репортаж! Илнең пульсы күтәренке хезмәт ритмы белән типкән бер мизгелдә килә авыр бу хәбәр. Һәм кинәт ялкынлы речь белән чыгучы докладчы туктап кала, үз вакытында әйтеп бетергесез дәрәҗәдә популярлык казанган «Тарзан» фильмы барганда лента өзелә, залда ут сүнә һәм әйләнә-тирә туңып кала, заводта төнге сменада эшләгән мастер Иванов күз яшьләрен сөртә, җир шарын болыт чорнап ала.— Шул рәвешле гадәти һәм табигый эпизодлар, детальләр тиз арада зур масштаблы кайгы картинасын күз алдына китереп бастыралар. Ул гына да түгел, бөтен җир шары, бөтен прогрессив кешелек хәрәкәткә килә. Париж, Лондон, Испания, Дания, Германия, Төркия туган илебез шәһәр һәм авыллары белән бер булып кайгы кичерә:

> **Миллион йөрәкләр берьюлы**
> **Тын гына тибә:**
> **Ленин!**
> **Ленин!**
> **Ленин!**

Нинди колач, ни дәрәҗәдә эпик масштаблылык, һәм шул вакытта шигырьнең камиллегенә, ритм һәм рифма гармониясенә сокланып туймаслык.

Шул рәвешле зур булмаган вакыт аралыгы, нибарысы минутлар эчендә булып узган вакыйгаларны тасвирлап, шагыйрь гасырлар кешесе — Ленинның кешелек тарихындагы урынын, ул ачкан яңа чорның олы киләчәген, ленинизмның мәңгелеген раслауга ирешкән. Минутлар аша гасырларны күрә, күзаллый алган Такташның поэмасы «Гасырлар һәм минутлар» дип исемләве символик мәгънәгә ия. Ленинизм идеяләренең тарихи перспективасын, көчен зирәк рәвештә аңлаган шагыйрьнең соңгы юллары инде минутлардан түгел, гасырлардан репортаж сыман кабул ителә:

> **Ул үлмәде.**
> **Җир шары өстендә Ленин**
> **Шәүләсе көн-төн йөри,**
> **Уң кулында канлы байрак,**
> **Сул белән**
> **Куркыныч елларны алга өстери.**
> **Ул, кояш нуры кебек нурлар сибеп,**
> **Төрмәләр, подвал, заводларга керә,**

Я, коточкыч байрагын тоткан килеш,
Ул кинәт килеп чыга зур
Парламентлар өстенә!..

Сүз дә юк, даһи Ленин исеменә лаеклы поэма, ә соңгы юллар исә поэмага лаек аккорд булып яңгырыйлар. Тик бер нәрсәдән канәгать түгел күңел — «Гасырлар һәм минутлар»ның әлегәчә илебез халыклары телендә, барыннан да элек, рус телендә тиешле яңгыраш алмавы кызганыч. Ленинниананың иң гүзәл җәүһәрләреннән берсе булып торган бу әсәргә игътибар һәм кайгыртучанлык кимемәсен иде! Хәер, бер поэма гына түгел, татар әдәбияты тарихында яңа тормышның ялкынлы җырчысы буларак үзенә бер аерылып торган Такташ иҗаты, гомумән, олы кайгыртучанлыкка лаек. Даими игътибар һәм кайгыртучанлыкка әдәбиятка килүче яшь үсентеләр генә түгел, танылган каләм осталары һәм, барыннан да элек, безнең арада үлмәс җырлары калган талант ияләре мохтаҗ. Вакыт-вакыт бүгенге әдәби процессның мең төрле мәшәкатьләре белән әвәрә килеп, без иң изге бурычыбызны үтәп җиткерми кичектерә киләбез түгелме?! Шигъриятебез күгендә якты йолдыз булып янган, шәхес һәм сәнгатьле сүз остасы буларак кабатланмас Такташыбыз иҗатын искә алганда әлеге борчуның урынсыз түгеллеге шик тудырмас төсле.

Шигърият, шулай да бәхетле син! Синең Такташың бар!..

## Хәсән Туфан

# ҖЫРЛАНГАН ҖЫРЛАР ТУРЫНДА

Шагыйрь! Кем ул? Шагыйрь — шигырь язучы гына түгел, шагыйрь — үзе шигырь ул. Шигырь дигән сүзне әйтү белән, күңел күзе алдына Тукайлар, Есениннар килеп баса. Такташ шундыйларның берсе иде. Такташ — шигырь иде ул.

1923 елда Уралда шигъри Такташ белән (аның беренче шигырьләре белән) очрашкан көнем гомер юлымдагы иң бәхетле көннәремнең берсе булып истә калды. Аның канатлы, тылсымлы, җан азыгы булган шигырьләре йөрәкне биләп алды, әйтеп бетермәслек бәхет бирде. Шундый шигырьләрне иҗат итә алган шагыйрь җирдән, анадан туып түгел, легендалар, эпослар, халык әкиятләре дөньясыннан килгәндер кебек булып тоелды. Гадәти-гади кеше генә түгел бу, чын талантның иҗади кодрәтнең кеше булып гәүдәләнешедер бу! Такташның үзен күреп белгәч тә, аның белән иң якын дусларча бергә яшәгән елларда да бу тойгы үзгәрмәде. Бөек җан булып, ачылып җитмәгән тылсым булып тора ул. Аның әдәби абыйсы булган Тукай да шулай. Бер үк халыкның балалары булганга күрәдер, аларның характерларында да күзгә бәрелеп торган уртаклыклар төсмерләнә.

Халык телендә бер риваять бар. Диңгездә давыл күтәрелгәндә, көймәләрне һәлакәттән коткарып калу өчен, гаҗәп зур балык рәвешенә кергән диңгез анасына корбан буларак, берәр фидакарь суга ташланырга тиеш... Тукай моны 1905 ел революциясеннән соңгы реакция чорында иҗтимагый җирлеккә күчереп:

Көймә бата... йота торган балык өчен
Үзен фида итә алган бер җан кирәк!

— дип, ил өчен фида булырга әзер икәнен әйтә.

Такташ та шуны ук, ләкин Такташча югары накал белән, кан тамырлары шартлап китәрлек киеренкелек белән белдерә:

**Төн уртасы. Әнкәй, мин дар ясыйм.**
**Әмер булган мине асарга.**
**Мин дар ясыйм яшь бер пәйгамбәргә**
**Дарга басып күккә ашарга...**

Шагыйрьләр — тумыштан ук фидакарь җанлылар алар.

Коры дидактика чын шагыйрь эше түгел ул. Такташ ни генә әйтсә дә, күз алдына китереп бастырырлык итеп, сурәтләп әйтә. Сурәтләмәгән очракта да, барыбер, аның сүзе ничектер тылсымлы, җанны дулкынландырырлык, каныңны кайнатырлык.

Такташ халык йөрәгенә эчтәлеге ягыннан да, формасы ягыннан да бөтенләй яңа авазлы шигырьләр белән килеп керде. Шигырь сөючеләр аны беренче адымнарында ук яратып кабул иттеләр. Такташны яратмаган кешене табуы читендер. «Моның төп сәбәбе нәрсәдә иде соң?» дигән сорау туа. Ул халыкның шигъри романнары һәм легенда-әкиятләре белән сугарылган хисләренә хуш килде. Аның романтикалы, гыйсьянлы — бунтарь рухлы шигырьләренә һәр өйдә ишекләр ачык иде. Такташның Үзбәкстандагы һәм, гомумән, Төркстандагы хезмәт массасының кара көчләр белән көрәше турындагы, җимерелгән иске дөнья урынына яңа дөнья төзеләчәге турындагы шигырьләре халык күңелендәге өметләр, омтылышлар белән бертуган иде. Такташның күпчелеккә аваздаш буларак язылган беренче чор шигырьләре, турыдан-туры халык авазы булган икенче чоры белән — Казан чоры белән тәмамланды.

Такташ, Маяковскийның үлеменә ачынып язган «Чигенү» шигырендә «мин сәламәт, көчле, шул килеш тә бик күпләрне гашыйк итәрлек» дигәненчә, күркәм, таза, нык кеше иде. Көтмәгәндә, һичбер көтмәгәндә очраклы тифтан генә башланган чир аның могҗиза кебек гаҗәп гомерен чикләде. Шулай буласын җаны, әйтерсең, алдан ук сизгән. «Әйтче, кайсын шунда җырлап бетереп була безгә тигән кыска гомердә?» дип куйгалавы һәм, шигырьләренең дөньяга чыкмаган бер вариантында: «Әйтергә дә оят: утыз яшькә җитми арылган», — рәвешендәге сүзләре сагайта, уйландыра иде. Ләкин без мондый сүзләрне, никтер, уйнап кына әйтелгәнгә санадык... Такташка гына хас булган үзенчәлеккә күнеккән булганбыз, күрәсең. Аның шигырьләрендә бит юмор белән үтә җитдилек һәрвакыт бер рәттә тора. Мәсәлән, «...Болай... гади бер җыр гына» дигән шигырендә никадәр елмаюлар бар. Ә шунда ук иң авырткан җирен менә ничек искә ала ул:

**Синең атың кебек җирән атта**
**«Аны» озатып бардым киткәндә,**
**Аерыласы килми сарылды ул,**
**Соңгы кабат мине үпкәндә...**

Бу — Алсу турында. «Алсу» шигыре елмаюдан гына тора кебек, ләкин анда Гәззә Алсуның сүзен көткән урында шигырь тагын җитдиләнеп китә:

**Сөйләсенме матур яшьлегенең**
**Зур елларга туры килүен.**
**Сөйләсенме җирне, бүгенгене**
**Бар нәрсәдән артык сөюен!**

Гомумән, хатын-кызларны иң кешелекле, саф, керсез йөрәк белән ихтирам итүче бөек Такташ гаиләә, мәхәббәт мәсьәләләре турында да никадәр гүзәл шигырьләр, кулланма итеп йөртерлек сүзләр калдырды.

**Аһ, син, илем,**
**Ничек үләргә соң!**
**Сагынып кешеләр синдә булганда!**

Такташыбызны сагынучылар нинди күбәү без бүген!

Газиз Иделле

# СӨЕКЛЕ ШАГЫЙРЕБЕЗНЕ САГЫНГАНДА

Такташ!

Бу исем — күңелләргә бик тә якын, үз, кадерле исемнәрнең берсе. Аның иҗат кыры безне төрле төстәге чәчәкләр белән мул бизәлгән киң сахра кебек сокландыра. Бик җитди дә, гади дә, катлаулы да, интим дә, шаян да тоннарда язылган шигырьләре, поэмалары, нәни шаярулары, пьесалары, җыентыклары — басылган берсе бик тиз таралып бетә, укыла, өйрәнелә, ятлана, кыйммәтле рухи азык була. Алар сине уйландыралар да, көлдерәләр дә, бәхәсләштерәләр дә, шатландыралар һәм тормышка аек карарга, көрәшнең алгы сафында булырга чакыралар. Кыскасы, Такташ иҗаты безне бер дә битараф калдырмый.

Такташ турында, ул үткән тормыш һәм иҗат юлы турында шактый күп китаплар, истәлекләр, гыйльми хезмәтләр язылган... Аларның һәр кайсында шагыйрь талантының яңа яклары, үзенчәлекләре дә, кеше буларак шәхси сыйфатлары да гел тулырак ачыла бара, ул безгә якынайганнан-якыная, тагын да кадерлерәк, сөйкемлерәк була бара.

Аның замандашларыннан берсе буларак, мәнә мин дә шагыйрь турында кайбер фикерләрем һәм истәлекләрем белән уртаклашырга теләдем.

Казанга килгән беренче елларымда ук (1926—1927) мин Такташны бик еш урамда очратып, сокланып карап кала идем. Хәтта кием-салымнарында да гадилек, матурлык, пөхтәлек бар иде аның. Җәй көннәрендә бигрәк тә. Күбрәк яланбаш йөри иде (куе, озын, матур чәчен нигә баш киеме астына яшерсен ул!). Ак чалбар, изүе ачык киң якалы ак күлмәк — ул чакта шул «апаш күлмәк» шактый модада иде. Кулында нечкә генә матур таяк була иде аның — таянып йөрү өчен түгел — селтәп-болгап йөрү өчен генә... Кыскасы, бөтен кыяфәте, йөзе-чырае, күз карашлары белән күркәм күренде миңа шагыйрь.

...Әдәби кичәләр, киңәшмәләр, җыелышларның зурлары һәм иң әһәмиятлеләре мәдәният йортында (хәзерге ТЮЗ бинасы) үткәрелә иде. Әле яңарак кына исемнәре күренә башлаган яшь язучыларның җыелышлары исә — яшьләр газетасы, журналы редакцияләрендә була. М. Әмир, Ф. Хөсни, Г. Минский, Ф. Кәрим, Д. Фәтхи, Н. Баян, Сирин, Ә. Түрәй, К. Хәмзин, Й. Усманов, Ф. Мөсәгыйть, С. Каратай... — яшь исемнәр ул елларда да аз түгел иде. Аларның кайбер утырыш-җыелышларында Һади Такташ, Гадел Кутуй кебек инде киң танылган әдипләр дә катнаша, укыган-ишеткән әсәрләр турында яшьләргә акыллы киңәшләрен бирә торганнар иде. Кайнап торган әдәби хәрәкәт, фикер алышулар, таләпләр, кызу-кызу бәхәсләр... Матбугат битләрендә дә шулай. Безнең өчен үзе бер мәктәп.

Такташның яшьләргә игътибары да, йогынтысы да бик көчле иде. Берәүләр аны кабул итә, мактый, яра; берәүләр килешми, тәнкыйть итә... Төрле каршылыклы фикерләр... Шуларны аңларга тырышып мин кайчакларны аптыраулы хәлдә дә калгалыйм. Такташ язганнарны кат-кат укырга керешәм. Тәнкыйть итүчеләр, аңа төрле гаеп ташлаучылар шагыйрьнең башлангыч чорда язган әсәрләрен кабул итмәүләренә күбрәк басым ясыйлар, аны идеалистлыкта гаеплиләр. Мин моның тенденциоз икәнлегенә төшенә башлыйм. Такташ иҗатын бутап аңлатулары, язулары белән һич тә килешмим. Әсәрләре белән күбрәк таныша барган саен, бүгенге Такташның гади-

леге һәм галилеге миндә өстенлек ала һәм мин аны шул чор әдипләренең алдынгы сафында күрәм.

Шагыйрьнең зур аудиториядәге чыгышлары аеруча истә. Сәхнәдә күренүе була — әле авызын ачарга да өлгермәгән, ә зал тулы халык инде дәррәү кул чаба. Ә ул, уңайсызланыбрак, күпмедер вакыт сүзен башлап китә алмый елмаеп тора... Аннары инде укыган шигыре һәрбере шаулы алкышларга күмелә. Аны тагын-тагын, кат-кат сәхнәгә чакырып чыгаралар.

Сәхнәдә чын мәгънәсендә яши иде ул! Халыкка якын булу, аның белән бергә булу, гади кешеләр турында язу, алар алдында шулай иҗат хисабы бирү — аны шул яшәтә иде.

**Мин гомерем буе шул кешеләрнең**
**Йөрәк тавышларын тыңладым,**
**Канына манчып язган һәр җырымны**
**Алар теле белән җырладым.**

Татар дәүләт театрында да еш кына күренә Такташ: нечкә, сизгер зәвыклы тамашачы да ул, артистлар белән дуслыгы да яхшы һәм эшлекле. Премьераларның берсен дә калдырмый карый иде. Сәхнә сәнгатенә мәхәббәте аның иҗатына йогынты ясады — соңрак Такташның оста драматург булып танылуы шуннан, әлбәттә.

Шулай, төрле урыннарда, төрле очракларда — урамда, әдәби кичәләрдә, театрларда күрү-очрашулар ешая баргач, ничектер, баш иеп исәнләшүләргә дә җиттек, бугай. Әдәбият-шигърият белән кызыксынучыларны, җыелышларга, әдәби кичәләргә йөрүчеләрнең күпчелеген инде ул күреп белә-таный иде. Шуның өстенә тагын минем ТатЦИК аппаратында эшләвем дә бар бит әле. Ә аның монда килгәләвен дә хәтерлим. Республика җитәкчеләренә ул бик яхшы таныш иде дисәм дә ялгышмамдыр.

...Бүгенге миллионлы шәһәребезнең күп кенә урамнарында чал тарих эзе сакланган йортлар аз очрамый. Мәсәлән, миңа еш кына Пушкин урамы буйлап үтәргә туры килә. Урамның сул ягындагы 37 нче йортка аеруча игътибар итмичә калмыйм. Бик күптән салынган өч катлы гади генә бу йорт кай ягы белән үзенә тарта, хәтердә онытылмаслык истәлекләр кузгата соң? Моңа бик кыска, ачык җавап — аның стенасындагы мемориаль такта: «Бу йортта 1925 елдан 1931 елга кадәр Һади Такташ торды».

«1931 елга кадәр...» Тагын да төгәлрәк әйткәндә — шул елның 8 декабренә чаклы. Чөнки шул көннең таңында Һади Такташның зәңгәр, сөйкемле, акыллы күзләре мәңгегә йомылды.

Хәрби хезмәтемне дәвам иттерү өчен Куйбышевтан Казанга килгәч тә Гомәр Галиләрдә кунак булып яшәгән көннәрем иде. Такташ Гомәрләргә еш кына килеп чыга. Якын дуслар иде алар. Соңгы көннәрдә ул күренми башлагач, Гомәрдән сорашам.

— Ишетмәдеңмени, авырып китте бит әле ул, — диде моңсурак тавыш белән.

— Ничегрәк соң хәле, нинди авыру?

— Тиф дип әйтәләр. Әлегә әйбәт түгел.

Такташның шулай кинәт авырып китүе күпләрне борчуга төшергәндер. Кызганыч. Ә минем беренче ишетүем. Минем белүемчә, аның иң шатлыклы көннәре кебек иде бу. Газета-журнал битләрендә басыла килгән шигырьләре, поэмалары аерым җыентыклар булып та чыга. Ә менә яңарак кына калын, тулы җыентыгы, зур рәсеме белән, Гомәр Галинең шулай ук күләмле, тирән эчтәлекле мәкаләсе белән беренче мәртәбә басылып чыкты. Аның шул китабын кулына тотып ничек шатланып йөргәне әле дә күз алдымда. Анда, 1916 елдан 1930 елгача иҗат ителгән барлык әсәрләре — шигырьләре, поэмалары, хикәяләре, драмалары урнаштырылган һәм кара катыргы тышлыкта кызыл буяу белән «I том» дип тә билгеләнгән. Димәк, алда әле, һичшиксез, безне — укучыларын куандырып, аның тагын бик күп язасы, I томының дәвамнарын — II, III, ...томнарын күрәсе бар... Күрергә тиеш! Мин моңа бик ышана идем.

Еллары да нинди бит — тарихи бишьеллыклар башланган чор. Хезмәт дәрте, рухи күтәренкелек еллары. Әдәбият, сәнгать өлкәләрендә дә яңа куәтле илһам тудырган чак. Такташның да:

Хыял безнең өчен чит бер нәрсә,
һәрбер теләк — якын киләчәк,
һәрбер совхоз,
һәрбер гигант колхоз
Яшәү көче безгә бирәчәк!..
Бишьеллыкның бөек гигантлары
һаман үсә,
һаман күккә таба үрелә...

— дип дулкынланып, безне дә дулкынландырып иҗат иткән еллары...

Сораштыра торгач шуны да белдем: Такташны сәламәтләндереп яңадан аякка бастыру өчен медицина барлык чараларны күрә икән. Профессор Терегулов, профессор Ворошилов, доцент Вилендлар катнашы белән әледән-әле консилиумнар үткәрелә. Сәламәтлек саклау һәм мәгариф комиссариатлары, язучылар оешмасы, Татиздат, республика газеталары, литфонд — барысы да үзләреннән тиешле ярдәмне күрсәтеп торалар. Шундый зур ярдәм, игътибар да булгач, таза, көр, җор күңелле яшь Такташыбыз бик җиңел генә бирешмәс ул авыру дигәннәренә! — шулай оптимист булып яшәгән идек ул көннәрдә...

1927 ел. Такташның «Азат хатын» журналы редакциясендә эшләгән еллары. Мин яңа гына Ленинградтан, экскурсиядән кайтып төшкән идем. Шул көннәрдә, аның белән очраклы гына бер күрешеп, исәнләшкәч-сөйләшкәндә, әлеге экскурсия дә сүз арасына кысылып китте. Мин бер дә көтмәгәнчә, бу сәфәр шагыйрьне бик кызыксындырды. Моның сере шунда ук аңлашылды да: без күргәннәр арасында аны аеруча кызыксындырганнарыннан берсе — Детское селога барып (хәзер ул Пушкин шәһәре дип атала), андагы патша сарайларын карап йөрүебез булды, ахры. Бу турыда ишеткәч тә, бераз уйланып, менә шулар турында безнең журналга бирәр нәрсә язып бирә алмассыңмы, дип соравын бик яхшы хәтерлим. Александр сараенда соңгы патша Николай II дә торган бит. Халык канын эчеп яткан ул патшалар үзләре ничек иркен яшәгәнен укучыларга җиткерү бик файдалы булыр иде, дип конкрет тәкъдим дә ясады. Такташ хәтле Такташ үз журналларына язуны сорап тора бит!

Ленинградта ашык-пошык теркәп барган язмаларымны, алып кайткан сувенирларны, рәсемнәрне актара башладым. Икенче көнне очерк сыман язманы һәм бишалты открытканы Такташның үз кулына тапшырдым. Күпмедер вакыт үткәч, әлеге материал басылып та чыкты. Минем өчен бу көтелмәгән куанычлы вакыйга булды.

...Шулай көннәр, атналар, айлар үтә... Такташның матбугатта чыгып килә торган һәрбер яңа шигырен көтеп алып, йотылып-яратып укый барам. Дөресен әйтим, баштарак Такташның үзе белән мин әле һаман да якыннан аралашып-дуслашып китә алмадым. Югыйсә, җае чыкканда теге материалны үзе үк искә төшереп тора, сораша... безгә яраклы тагын бирәр нәрсәң булмасмы, ди...

Эш арасында һәм ял вакытларында инде хикәяләр яза башлаган чагым иде. Алар турында беркемгә, бер сүз әйткәнем юк әле. Авыр языла... Такташны канәгатьләндерерлек сыйфатлысын яза алмам дип борчылам. Ике арадагы бик зур аерма үзен нык сиздерә... Ихтимал, бу кыюсызлыгымнан да киләдер.

Әмма тора-бара миңа бернәрсә ачыклана башлады. Халык игътибарын, ихтирамын казанган атаклы шәхесләр үзләрен алай бер дә эре тотмыйлар, масаймыйлар, гади булып калалар, ә кешеләр арасында булырга, укучылары белән очрашырга үзләре үк омтылып торалар. Чөнки иҗатчы өчен гомумән халыкны түгел, ә конкрет аерым кешеләрне мөмкин кадәр якынрак танып белү кирәктер бит? Без укып-күреп белгән геройларның, персонажларның төс-кыяфәтләре, характерлары, уй-тойгылары,

эш алымнары, сөйләү манералары, эчке дөньялары шулкадәр ачык, төгәл һәм төрле-төрле булуына нәкъ менә авторның шундый хезмәте нәтиҗәсендә генә ирешеп була торгандыр. Соңрак, журналистика белән бергә әдәби әсәрләр тудыруга да омтыла башлагач, үзем дә моны сизми-аңламый калмадым.

Егерменче еллар — Һади Такташ иҗатының романтикадан реализмга, халыкчанлыкка кискен борылыш чоры һәм үз популярлыгының да иң югары ноктасына күтәрелә барган еллары да иде, бугай. «Сыркыды авылы», «Байрак тегәбез», «Мәхәббәт тәүбәсе», «Мин дезертир бугай, командир», «Тамбов урманнарын ташлап китәм...», «Иптәшләр», «Алсу», «Мокамай» һ. б. шедеврлары — кемнәрдә генә тормышка, көрәшкә рухландыру-ашкындыру хисләрен көчәйтми калдырды икән! Ә «Гасырлар һәм минутлар», «Киләчәккә хатлар» исә — шул еллардагы иҗатының ялтырап торган таҗы!

Ә Һади Такташ, даһи Такташ үзе тормышта һаман шул гади Такташ булып кала бирде. Иҗат колачы, талант дәрәҗәсе белән үз бәясен инде үзе дә яхшы белсә дә, масаю дигән нәрсә аңа һич тә хас түгел иде, — шул ягы белән ул кешеләрне үзенә тарта, шул ягы белән ул миңа да якынрак була бара, аның белән тартынмыйча сөйләшергә, аралашырга мөмкин икән дигән нәтиҗәгә килдем.

...ТатЦИК председателе Шәймәрдәнов янына да аның берничә тапкыр килгәне булды. Нинди йомыш белән килүен әйтми, мин аны сорамыйм да, Такташ хәтле Такташтан моны соравы да уңайсыз. Кабинет ишеге алдындагы минем өстәл янына килеп утыра. Исәнлек-саулык, кәефләр, теге-бу турында шулай елмаеп азрак сөйләшеп утырулар... Ул, ишеккә таба ымлап, үзе генәме анда, дип сорый. Әле генә берәү кереп киткән иде, дим. Ярар, ашыкмыйм, ул чыксын, хуҗаның үзе белән икәү генә утырып сөйләшәсе сүзләр бар әле, ди. Шунда аның күптән түгел «Кызыл Татарстан» газетасында басылып чыккан «Үпкәлим» дигән шаян бер шигыре искә төшкәч, минем аңа, тукта, хәзер үк Шәймәрдән абзаңа кереп белдерәм, нарком Такташ үзе килде, дип әйтәм, ул момент Сезне чиратсыз кабул итәчәк, дип шаярып алырга телем бик кычытып торса да, дәшми калдым. Ничек кабул итәр бит ул мондый шаяруларны?.. Такташ өстәлдәге яңа газеталарны караштыргалап, сабыр гына көтеп утырды да, теге кеше чыккач, кабинетка кереп китте. Ул анда озак булды кебек хәтеремдә калган. Кәефе күтәрелеп чыкканын күреп калдым. «Булды, хуш» диде дә миңа, ашыгып китеп барды. Үз йомышы белән килгән идеме, әллә бүтән берәүнең гозерен үтәп йөрүе булдымы, ул кадәресен белә алмадым.

Гадилектә — даһилык, дип дөрес әйтә халык. Такташның әнә шундый күркәм сыйфаты язучыларның 1929 елда булган тарихи экскурсиясе вакытыннан да истә калган. Без булган шәһәр, өлкә, республикаларның күбесендә рәсми очрашулар — танышулар һәрвакыт әдәби кичә-концертлар белән тәгәлләнә торган иде. Бу өлешендә исә, башлыча, шагыйрьләр мәйдан тота. Күпчелек очракта кунакчыл хуҗаларыбызның поэзия осталары белән безнең шагыйрьләребез аралашып чыгыш ясыйлар. Мәсәлән, Бакудагы шундый кичәләрдән аеруча истә калганы — коммунальниклар клубы бакчасында, ачык һавада үткәрелгәне. Бик зур бакча халык белән шыгрым тулы. Күпчелеге — татар эшчеләре. Мондый кичәләрдә, очрашуларда кунакларның урыны сәхнәдә була иде. Тагын — азербайҗан язучылары, шагыйрьләре, җәмәгатьчелек вәкилләре... Кыскасы, сәхнә дә тулы. Бер-береңә шулай якын булу, янәшә утыру, бер-береңнең сулышын тою дуслык, туганлык хисләрен тагын да көчәйтеп җибәрә... Башта — хуҗаларның котлау сүзләре, безнең җитәкчеләребезнең сәлам һәм рәхмәт белдергән җавап чыгышлары... һәм башлана шигырь укулар! Безнең Такташ, Кутуй, Демьян Фәтхи үзләренең ялкынлы, лирик шигырьләре белән соклandырдылар. Бигрәк тә Такташ һәм азербайҗан шагыйрьләреннән Сәләйман Рөстәм. Бу ике зур иҗатчы беренче көннәрдән үк бик тиз танышып, уртак тел таптылар. Характерлары белән бер-беренә охшаганга күрәдер, бәлки: икесе дә бик мөлаем, садә, кешеләр белән бик тиз һәм якыннан аралашучан иделәр.

Такташның Бакуда нефтьчеләр алдында ясаган бик уңышлы чыгышлары да истә. Анда татарлар күп һәм алар арасында Такташның якташлары мишәрләр дә күпчелек иде, бугай. Чыгышлар тәмамлангач та алар Һадины сырып алалар, сорашалар,

аны яннарыннан тиз генә җибәрәселәре килми, Такташка бу бик ошый, алар белән үз итеп, бертуктаусыз елмаеп сөйләшә...

Ә менә Грузиядә Такташның шундый ук уңыш-мәхәббәт казануы инде, чын шагыйрь булуы белән бергә, үзен бик ягымлы кеше итеп тә танытуына бәйле иде. Аның нәкъ шундый булуына Казанда без инде күнегеп беткәнлектән, ул чакта артык игътибар да итмәгәнбездер. Шагыйрь бит, Такташ бит, шулай булырга тиеш тә, диебрәк фикер йөрткәнбездер. Ә бу — артык гади аңлау-аңлату булган икән. Шул ук Грузиядә трибун шагыйрь Такташның үз шигырьләрен ана телендә укуы (тәрҗемәләре юк) тыңлаучылар өчен аңлашылмаса да, шигыренең эчтәлегенә бик ярашлы итеп үзен сәхнәдә тоту манерасыннан, яхшы, ачык дикциясе, авыз, күз, йөз хәрәкәтләреннән үк аның нәрсә турында сөйләвен, нигездә, төшенеп алучы грузин дуслар аз түгел иде. Шул ук Грузиядә Такташның танылган яшь тәнкыйтьче һәм әдәбиятчы Бесо Жгенти белән бик тиз танышып, бер-берен бик тиз аңлап, уртак сүз табулары, төрле очрашуларда, шәһәр белән танышып йөргәндә аларның гел янәшә булуы бик гадәти булып күренә башлады. Сәбәбе: бердәй ягымлылык, әдәбиятка, тормышка караштa бердәмлек, әлбәттә.

Сәяхәтебезнең ахырында Мәскәүдә Максим Горький белән очрашу-сөйләшү барыбыз өчен дә гомердә онытылмаслык якты истәлек булып калды. Бу сәяхәт турында минем тәфсилләп язганнарым укучыларга мәгълүм. Такташ исә Горький белән очрашуны үзенең «Киләчәккә хатлар» поэмасында барыбызның да хисләрен эченә алган шигъри юллар белән мәңгеләштереп калдырды.

Инде соңрак, мин «Безнең юл», «Атака» журналларында эшләгәндә, бер юлы ТАПП секретаре вазифаларын да үтәгәндә, Такташ редакциягә еш кына килеп чыга һәм без төрле темаларга сөйләшә дә торган идек. Бусы инде — журналларда минем хикәяләр, очерклар басыла башлагач, инде Кырымда дәваланып ятучы Галимҗан ага Ибраһимов үзенең «Ерактан сәлам» исемле мәкаләсенең яшь язучылар турында сөйләгән өлешендә минем исемне дә телгә алганнан соң...

Такташ та яшь язучылар иҗаты белән якыннан кызыксынучы, аларга актив ярдәм итәргә һәрвакыт әзер торучы өлкән әдипләребезнең берсе иде. Минем язганнарымны да (басылып чыкканнарын) укый баруы мине бик шатландыра һәм канатландыра торган иде.

Журналда эшләгәндә Арча районының «Кызыл Казанбаш» колхозында булып кайткан идем. Әле күптән түгел генә оешкан бу колхозның эшен-тормышын, кешеләрен ныклап өйрәнеп язган очеркым «Атака» журналында басылып чыкты. Бу очеркта тасвир ителгәннәр арасыннан гыйбрәтле бер фактка (колхозга кергәндә тапшырган атының үлүен элекке хуҗасы ничек авыр кичергәне турындагы вакыйгага) Такташның аеруча игътибар иткәне һәм аны үзенең «Киләчәккә хатлар»ында Мохтар карт образы аша бик оста файдаланганы билгеле.

...Яңадан 1931 елга, Пушкин урамындагы 37 нче йортка кайтыйк.

Кайнап торган зур Казан шәһәре өчен бу гади көннәрнең берсе булгандыр да бит... Әмма...

Күпләр өчен шундый гади сыман күренгән көннәрнең берсендә Гомәр Галинең эштән сизелерлек күңелсезләнеп кайтып кергәнен хәтерлим. Эше бик җаваплы бит — «Безнең юл»ның баш редакторы ул. Шунда берәрсе белән сүзгә килгәндер, кызып киткәндер дә... диебрәк уйлаган идем. Сорашып торырга уңайсызландым. Көндезге аш, кичке чәй алдында да әллә ни күп сөйләшмәде. Ә характеры белән бик сүзчән Гомәр иде ләбаса ул... Әллә... Такташның хәле начарландымы икән? Гомәр үзе әйтмәсә дә, аңа еш кына барып йөргәнен беләм-сизәм бит. Мин хәрби хезмәт кешесе булганга, кичләрен күп вакыт бергә булырга туры килми иде...

— Әйдә әле, Газиз. Такташ янына кереп, хәлен белеп чыгыйк әле, — ул көнне кичке өстәл яныннан кузгалгач та беренче сүзе шул булды.

Һәм без чыгып та киттек. Гомәргә бик таныш йортның икенче катына мендек. Ул саклык белән генә ишеккә кагылды. Бераздан ачылып киткән ишектән, күп төн-

нәрен йокысыз үткәргәнә йөзенә чыккан, арыган күзләре белән Гөлчирә ханым күренүгә, ничектер кинәт сагаеп калдык.

— Әйдә, узыгыз, — диде ул тонык тавыш белән.

Такташ яткан бүлмәгә кердек... Ләкин Такташ анда юк иде. Караватта сузылып яткан гәүдә бар, ләкин бу — Такташ түгел, без белгән Такташ түгел...

Үзенә табынуыбыз дәрәҗәсенә лаеклы, хаклы булган Һади Такташыбызны шундый кызганыч хәлендә күрүдән мин телсез-аңсыз калдым диярлек. Моны бик тиз аңлагач, Гөлчирә ханымны да, тыныч булырга өндәп, үзенең җылы сүзләрен әйтергә ашыкты.

Әмма йөрәк сизә иде инде:

**Ашкынып җырлаган теләкләрнең**
**Чәчәкләрен килә күрәсе,**
**Канатларны еллар каерса да...**
**Ах!**
**Үләсе килми, үләсе...**

Бу минутларда Такташның бөтен җаны, тәне, һәрбер күзәнәге, соңгы көчләрен җыйнап, аһ-зар белән шул юлларны сүзсез генә кабатлый иде сыман.

...Иҗатыннан барыбыз да беләбез: аның бөтен җанында, йөрәгендә кешеләргә, табигатькә, тормышка, барлык тереклек дөньясына чын мәгънәсендә гыйшык уты яна бит. Юк, мондый дәртле янган иҗат уты сүнмәс, сүнмәскә тиеш... «ашкынып җырлаган теләкләрнең чәчәкләрен» ул әле, һичшиксез, күрер, күрергә тиеш!

Әмма... мондый тойгылар, мондый теләкләр, мондый өметләр, салкын акыл белән уйлаганда, могҗизага ышану булып кына калдылар, ахры. Чөнки дәвалаучы медицина әһелләре «өметсез» дигән нәтиҗәгә килгән булганнар икән инде. 21 ноябрьда тимгелле тиф белән авырый башлаган һәм авыру үзәге ми шешүгә әйләнгәнлеге безгә консилиум нәтиҗәләреннән дә билгеле булды.

Икенче көнне иртән иртүк, әле урыннан да тормаган идек, тышкы ишекне шакыдылар. Гадәтенчә бик иртә торып, беренче бәбиләре Алсуны кулында тирбәтеп йөргән Харирә ханым ишекне ачуга аннан Такташның энесе, төсе киткән Габит килеп керде һәм «Абый үлде» дип әйтүе белән елап ук җибәрде.

1931 елның 8 декабрь көне иртәнге 6 сәгать 30 минутта булган бу авыр югалту вакыйгасы шул ук көнне күпләрне тирән кайгыга салды. Ә икенче көнне бөтен халык Такташны газета битләрендә кара рамкаларда күреп тетрәнде. Бик күп оешмаларның кара сызыкларга төренгән кайгы белдерүләре күңелләрне сыкратты.

...Мәрхүмнең мәете Мәдәният йортының ак залына урнаштырылган. Бик күп чәчәкләр, веноклар... Сөекле шагыйрьләре белән соңгы тапкыр саубуллашырга килгән халык агымы ике көн буе төнге 12 гә кадәр өзлексез дәвам итте. Аларның саны 10 меңнән артты. Язучыларның күбесе гел шул залда, Такташ янында булдылар. «Кызыл Татарстан» газетасы аның истәлегенә тулы бер бит багышлады. Кави Нәҗминең «Үлем түгел бу!», Фатих Сәйфи-Казанлының «Идеалистлыктан диалектик материализмга таба», Закир Галиенең «Күтәрелештән», минем «Такташның иҗат юлы һәм аның нәтиҗәләре» исемле бер утыруда, бер сулыш алуда дигәндәй язылган мәкаләләребез, Фатих Кәримнең «Онытылмаслык иптәш» дигән шигыре шул 10 декабрь санында басылып, иртән үк укучылар кулына җиткерелде.

Шагыйрьне соңгы юлга озату алдыннан митинг Ирек мәйданында башланды. Бөтен мәйдан һәм аның тирә-ягы шыгрым тулы халык алдында Такташның бөеклеген, аны вакытсыз югалту авырлыгын сөйләүчеләр аз булмады. Мин, ул елларда хәрби кеше буларак, гарнизон начальнигы Якуб ага Чанышевның тирән эчтәлекле чыгышын аеруча яхшы хәтерлим. Ул Такташның талантлы шагыйрь генә түгел, ә чын солдат икәнен дә ялкынланып-дулкынланып сөйләде. Якуб ага I татар полкында хезмәт иткәндә, үзенә йөкләнгән сугышчан бурычны намус белән үтәп баруы өстенә, армиябез турында, сугышчыларыбыз турында махсус шигырьләр язып калдыруына зур бәя бирде. Һәм аннары мәйданда кызылармиячеләрнең шагыйрь белән саубуллашу салюты бик еракларга яңгырады.

Әйе, без шул көнне, шул сәгатьләрдә поэзиядә дә, тормышта да чын солдат булып танылган сөекле Такташыбызны соңгы юлына озаттык.

Роберт Миңнуллин

# ӘҢГӘМӘ ДӘВАМ ИТӘ

Гомәр ага Бәшировка да 80 яшь тулды. Шулай. Әдәбиятыбызның хөрмәтле аксакаллары берәм-берәм дә, бергәләп тә 60, 70, 80 яшьләрен җиткерәләр, сиздерми генә, акрын гына олыгаялар, ләкин бирешмиләр, картаймыйлар. Алар инде күптән бабай булырлык, югыйсә. Әмма аларга үзләренең оныкларыннан гайре берәү дә бабай дип эндәшкәне юктыр әле, мөгаен. Бу — табигый да. Чөнки алай дип әйтергә беркемнең дә теле бармый. Алай дип әйтәсе дә килми. Бу инде уңайсызланудан гына я булмаса күнегелмәгәннән генә түгел. Бабай дип олылауга бик лаеклы алар, сүз дә юк. Ләкин бит алар, чыннан да картаймыйлар, алар үзләре яшәгән шаулы, җитез һәм тынгысыз заманга, чорга охшаганнар. Алар кайчан карама — көрәш мәйданының уртасында. Аларның һәм тормыштагы, һәм иҗаттагы фидакарьлеге күпләр өчен, бигрәк тә безнең кебек яшь буын өчен, якты үрнәк булырлык. Алар — безнең укытучыларыбыз, остазларыбыз.

Гомәр ага Бәширов турында, аның бай тормыш юлы һәм олы иҗаты турында уйланганда, ирексездән, әдәбиятыбыз түрендәге аксакаллар — өлкән буын язучылары күз алдыннан кичә. Аларны бер-берсеннән иҗатлары белән дә, фигыль-холыклары белән дә аерып ала алмассың кебек. Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Әмирхан Еники, Әхмәт Исхак, Сибгат Хәким, Нури Арсланов... Алар — салмак, сабыр, тыныч, тыйнак. Җыелышларда булсын, төрле әңгәмәләр вакытында булсын, алар бер чакта да чәчрәп чыкмаслар, күкрәк сукмаслар. Җыелыш саен нинди дә булса сүз әйтү аларга хас нәрсә түгел. Әмма бер әйтсәләр, берәгәйле әйтәләр инде.

Бу әдипләр — халык исеменнән сөйли алучы халык вәкилләре. Алар — халыкның үзеннән чыккан кешеләр. Шуңа микән, халкыбызга хас холык, характер аларга күчкән. Иҗатларына да күчкән. Саллы һәм тыйнак әсәрләр, әмма онытылмас әсәрләр иҗат итәләр. Күрәсең, һәр буынның үз характеры, үз холкы буладыр. Өлкән буын язучыларыбызның да нәкъ шулай. Бу характерны тынгысыз көрәш, авыр сугыш еллары, тыныч хезмәт еллары формалаштырган.

Гомәр ага Бәшировка да 80 яшь тулды. Бер уйласаң, ай-һай зур гомер инде бу! Күпме иҗат газаплары, күпме иҗат куанычлары кичерелгән. Күпме иҗат ителгән. Әйтүе генә җиңел. Әмма яшь төшенчәсе язучы өчен шартлы әйбер. Ә инде укучы өчен язучының яшь төшенчәсе бөтенләй яшәми дияргә мөмкин. Әйтик, язучы Гомәр Бәшировны татар укучысы менә ничә дистә еллар инде, мәктәптә укыган чагыннан ук, олы язучы дип белә. Соңыннанрак — олыгайгач, чәчләренә чал кунгач та, Гомәр Бәширов укучы өчен шундый ук олы язучы булып кала. Шулай булып калыр да. Чөнки чын әдәби әсәр алдында еллар да, хәтта гасырлар да көчсез...

Татар укучысы язучы белән иң элек «Сиваш» повесте аша таныша һәм гомерлеккә яратып кала. Гомерлеккә үзенең якын дусты, киңәшчесе, юлдашы итә. «Сиваш»ны укып гражданнар сугышының кечкенә бер вакыйгасы белән танышасың. Ләкин шул бер вакыйга да гражданнар сугышының бөтен катлаулылыгын, авырлыгын, кызыл сугышчыларның батырлыгын күз алдына китерергә ярдәм итә. Әсәр ышандыра, чөн-

ки язучы аны үзе кичереп язган, ул вакыйгаларда үзе катнашкан. Сивашны үзе кичкән. Перекопка үзе бәреп кергән. «Сиваш» дигәннән, бәләкәй генә бер очрашу турында әйтеп үтәсем килә.

1972 елда миңа яшь шагыйрьләрнең Әрмәнстанда уздырылган V Бөтенсоюз фестивалендә катнашырга насыйп булган иде. Шунда без — бер төркем яшь шагыйрьләр — солдатлар белән очрашуга бардык. Башта әллә ничә телдә шигырьләр укыдык, әдәбият, шигърият турында сөйләштек. Якташларыбызны очратып, алар белән гәпләшеп утырдык. Аннары солдатлар безне үзләренең тормышлары белән, дивизияләренең данлы юлы белән таныштыра башладылар. Бу — данлыклы, миңа күптән таныш «Сиваш» дивизиясе иде. (Ул хәзер «Инза, Сиваш һәм Штеттин» дивизиясе дип атала). «Сиваш» повестендагы вакыйгалар бер-бер артлы уемнан кичте. Шуңа күрә, ахры, экскурсоводның сөйләве миңа икеләтә тәэсир итте. Дивизиянең Сугышчан дан музеенда татар совет язучысы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Бәшировның «Сиваш» исемле автографлы китабы, шулай ук язучының хаты да саклана икән. Күргәч, җанга рәхәт булып китте. Әдәбиятыбыз өчен, Гомәр ага өчен горурлык тойгылары күңелне биләп алды. Казаннан икәнемне белгәч, илебезнең төрле почмакларыннан җыелган солдатлар миңа «Сиваш»ны яратып укуларын сөйләделәр. Гомәр аганы әле дә дивизиянең солдаты итеп исәплауләрен әйттеләр, күп итеп сәлам җибәрделәр, сәламәтлек теләп калдылар. Ерак Әрмәнстанда «Сиваш» белән очрашу чыннан да дулкынландырырлык вакыйга иде. Әйе, «Сиваш» татар укучысыныкы гына түгел инде, ул — бөтенсоюз укучысыныкы да.



*Г. Бәширов. Украина язучылары съезды кунаклары арасында. 1949 ел.*

«Сиваш» турында сүз булган саен Гомәр ага Бәширов минем күз алдыма кызылармияче формасыннан, буденовка кигән яшь-яшь сугышчы булып килеп баса. Язучы үзе дә «Сиваш»ны кулына алган саен яшь чакларына әйләнеп кайтадыр, мин кичергән хисләрне кичерәдер. Ул бит гомер буе солдат булып калган кеше. Партия солдаты булып. Әдәбият солдаты булып. Ә солдат булу — үз иңенә олы бурычлар алу дигән сүз. Ил алдында, партия алдындагы, халык һәм әдәбият алдындагы изге бурыч ул...

Гомәр ага Бәшировның һәрбер әсәре укучыны уйландыра, дулкынландыра. «Намус»ны алыйк. Совет әдәбиятының алтын фондына кергән әсәр ул. Исеме үк уеңны хәрәкәткә китерә торган. Намус. Шулкадәр дөрес сайланган исем. Чыннан да, кеше намусы турында бит ул китап. Бөек Ватан сугышы елларында тылда калган колхозчы хатын-кызлар Намусы, солдаткалар Намусы. Ватан алдындагы, фашистларга каршы сугышып яткан солдатлар алдындагы Намус. Романның беренче юлыннан ук шул тылсымлы һәм көчле сүз сине биләп ала. Ахыргы биткә кадәр шул сүз сине озата бара. Китапның һәр юлы, һәр бите шул сүз аша укыла. Ул сиңа тынгы бирми, битараф калдырмый. Китап күптән укылып беткән инде. Ә күңелдә һаман шул Намус сүзе яңгырый. Сугыш чоры хатын-кызларына булган хөрмә, күңелдә мәңгегә сеңеп кала. Нәфисә, ирексездән, күңелдә татар хатын-кызының идеалына әверелә.

«Намус» уңае белән дә кызыклы бер сөйләшү искә төшә. Күптән түгел без шагыйрь Рәдиф Гатауллин белән Башкортстанның Кушнаренко районында булып кайттык. Партия райкомының беренче секретаре Фәйлас Кәшбиевич Муллагалиев безне үзләренең эшләре белән таныштырды. Ул әле районга күптән түгел генә килгән. Олы максатлар, зур теләкләр белән килгән. Районның киләчәге турында сүз чыккач, ул болай дип сүз башлады: «Без барыбыз да Гомәр Бәшировның «Намус»ын укып үскән малайлар. Нәфисә бригадасы әле шул чорда ук икмәкнең һәр гектарыннан 140 ар пот уңыш җыеп алган. Ә бит заманы нинди булган?! Бүген исә кайбер колхозлар, бригадалар Нәфисә бригадасы үстергән икмәкне дә үстерә алмыйлар. Моның белән һич тә килешеп булмый, әлбәттә...» Әгәр партиянең җаваплы хезмәткәре әсәр героен мисал итеп китерә икән, бу инде әсәрнең бәхете, язучының бәхете дигән сүз. Димәк, «Намус» яши, көрәшә, халыкка хезмәт итә.

Публицистика — язучының чын гражданин булуын аермачык күрсәтә торган сугышчан жанр. Язучының теге яки бу вакыйгага, җәмгыятебездәге бөек күренешләргә мөнәсәбәте нәкъ менә публицистик чыгышларда ачык чагыла да инде. Үзенең йөрәгендә йөргән борчылуларын, әйтәсе килгән фикерләрен бик ашыгыч булганда, кичектерергә һич тә ярамаганда публицистикага мөрәҗәгать итә ул. Дөресен әйтергә кирәк, безнең күпчелек язучылардан публицистик мәкаләләр яздыру бик тә авыр. Газета-журналларда эшләгән иптәшләр моны үз җилкәләрендә шактый татыганнары бардыр. Ә менә Гомәр ага Бәшировның публицистик мәкаләләрен укучылар газета-журнал битләрендә еш очраталар. Язучының «Бүген дә, иртәгә дә» исемле китабын укып чыкканнан соң, язучының гомер буе халык белән, ил белән яшәвен, әдәбият дөньясында кайнавын, өзлексез уйлануын, әйтергә теләгән бер генә сүзен дә эчендә калдырмаска тырышуын күрәсең. Язучының иң олы вазифасы нәкъ менә шунда түгелмени?

Әйе, Гомәр Бәширов, Тукай әйтмешли, «коеп куйган» язучы гына түгел. Ул — публицист та, фольклорчы да, телче дә, җәмәгать эшлеклесе дә. Шуңа күрә дә ул олы әдип, халкыбызның мәртәбәле кешесе. «Бүген дә, иртәгә дә» исемле китапны белмим, кем ничектер, мин үзем шигырь җыентыгы кебек бер тында укып чыктым. Язучының уйланулары, борчылулары, әдәбият турындагы, тел турындагы фикерләре укучы күңеленә шул кадәр якын икән. Алар укучы фикере белән шулкадәр тәңгәл килә икән. Бу — язучының халык кичерешләре белән яшәвеннән, кешеләр тойганны тоеп, алар янган утта янып гомер итүеннәндер, ахры. Әлеге китапны ябып куясың. Язучының күпме уйлары, фикерләре, әйтәсе килгән сүзләре җанга көчә дә, үзеңнекенә әверелә. Язучы белән бергә үзең дә сабан туйлары турында, гореф-гадәтләребез турында уйлана башлыйсың. Авыллар ямьле булсын өчен, туган табигатебез ярлыланмасын өчен нәрсә дә булса эшлисе килә. Мәхәббәт фәлсәфәсе турында уйланасың. Икмәкнең кадерен тагын бер тапкыр тоясың...

Гомәр ага Бәширов — укучы балаларның да, бигрәк тә «Яшь ленинчы» газетасы укучыларының якын дусты, киңәшчесе. Газетага даими рәвештә әсәрләр, публицистик мәкаләләр язып торганы өчен генә түгел. Ул озак еллар газетадагы «Туган ягым — яшел бишек» операциясенең башлыгы да булып торды. Язучының тынгысызлыгына тагын бер мисал бу. Чыннан да, ул бик күп әсәрләрендә, кеше күңеле турында язу белән бергә, туган җир күңеле, табигатебез күңеле турында да, чишмәләр, инешләр җаны турында да яза. Белеп яза, бөтен күңеле белән тоеп яза. Борчылып, өзгәләнеп яза. Чөнки ул җирне ярата. Ул шунсыз булдыра алмый. Җаны

кушмый. Вөҗданы кушмый. Ул, кайчан гына булмасын, табигатькә ярдәм кулын сузарга омтыла, чишмәләрнең, болыннарның, урманнарның, күлләрнең хәлен ничек кенә булса да җиңеләйтергә тырыша... Әмма безнең әдәбиятта Г. Бәширов публицистикасы һәр очракта да ялгызы аерым бер жанр булып кына яшәми. Язучының публицистик сүзе аның һәрбер әсәренә үткен, саллы һәм гыйбрәтле очкыннар булып чәчелгән. Шулай булса да ул фикерләр повесть яисә роман битләреннән аерылып, «менә мин» дип кычкырып тормыйлар. Язучы публицистиканы үз әсәрләренең аерылгысыз бер өлеше, компоненты итеп файдалана. Вакытында һәм урынында файдалана. Аны әсәр тукымасыннан аерып ала алмыйсың.

Менә «Туган ягым — яшел бишек» исемле автобиографик повесть. Халкыбызның гореф-гадәтләре, үзгә йолалары, аның рухи матурлыгы, якты хисләре, уй-кичерешләре, холык-табигате — һәммәсе дә бар бу әсәрдә. Татар халкының этнографиясен, фольклорын, йолаларын бергә туплаган энциклопедик повесть. Аның битләрендә ягымлы, мөлаем авыл кешеләре, җылы, сыгылмалы халык теле, кабатланмас характерлар, үзенчәлекле көнкүреш, яшәеш, гыйбрәтле язмышлар. Һәм шуларның һәммәсен үз аңы, үз күңеле аша кичергән лирик герой. Бу әсәрендә язучы арадашчы ролен үти — халыкның узганы белән бүгенгесен тоташтыручы, берләштерүче арадашчы. Язучы бу очракта үз халкының бөтен тормышын хисапка алып, күздән кичереп, барлап баручы елъязмачы булып күз алдына килеп баса. Ә елъязмачының язганнары киләчәккә, бездән соң яшисе буынга бик кирәк!

«Җидегән чишмә». Монысы Гомәр Бәшировның соңгы елларда язган күләмле әсәре. Бүгенге татар авылы тормышына багышланган. Кискен мөнәсәбәтләр хакындагы роман. Кеше белән кеше, кеше белән җир, кеше белән табигать арасындагы мөнәсәбәтләр. Төп проблемасы — әхлак мәсьәләсе. Әсәрдә көрәш бара. Кеше өчен, табигать өчен, матурлык һәм яхшылык өчен көрәш. Үзгә көрәш. Әсәрдәге кайбер вакыйгалар, кайберәүләрнең кылган тискәре эшләре, кайбер конфликтлар, беренче карашка, беркатлырак, зыянсыз да шикелле. Ләкин язучы өчен вак яхшылык яки кечкенә явызлык була алмый. Һәрбер яхшылык, һәрбер явызлык кечкенәдән башлап һәм олы изгелеккә, гуманизмга, я булмаса, кансызлыкка, зур җинаятькә әверелә. Язучы әлеге хакыйкатькә һәрвакыт турылыклы.

Язучының, алда әйтелгәнчә, табигатькә, бигрәк тә, чишмәләргә аерым бер мәхәббәте бар. «Табигатьнең кадерле бүләге» исемле мәкаләсендә ул болай яза: «Һәйбәт чишмә суы әле хәзер дә авылның иң кадерле сыйларыннан санала. Кунак-мазар килдеме, берәрсе ерак юлдан кайттымы, апалар, җиңгиләр иң башта чәйгә чишмә суы алып кайтырга ашыгалар. «Суыбыз бик тәмле безнең!» — дип, чын күңелдән горурланып, кунакны кыстый-кыстый сыйлыйлар. Авылның иң газиз бер өлеше итеп, яратып, халык чишмәләргә ягымлы исемнәр дә кушкан: Ак чишмә, Татлы чишмә, Шифалы чишмә, Түбылгы тау чишмәсе...» Әлеге чишмәләргә тагын берәү өстәлде. Ул — Җидегән чишмә. Язучының сөекле композиторыбыз Сара апа Садыйкова белән бергәләп иҗат иткән шул исемендәге җыры — соңгы елларда халкыбызның иң яратып җырлана торган җырларыннан берсе. Ул миңа, ни өчендер, «Җидегән чишмә» романының җыр варианты шикелле тоела. Чөнки романның бөтен асылы, эчке рухияты белән бик нык аваздаш ул. «Җидегән чишмә» безнең өчен гади җыр гына түгел. Гади Көй, Моң, Аһәң, Сагыш, Шигырь генә дә түгел. Ул әлеге төшенчәләрнең күңелдәге җыелмасы, тупланмасы. Ул — язучының гомер буе үз әсәрләрендә язган һәм язарга теләгән фикерләрен берничә юлга сыйдыра алган тылсымлы җыр. Ул — яшәү мәгънәсе турындагы җыр. Ул — Гомәр Бәширов иҗатының визит карточкасы...

Язучы Гариф Ахунов үзенең Г. Бәшировка багышланган бер мәкаләсендә болай ди: «Гомәр Бәширов нәкъ менә туган-үскән җирне олылаучы язучылар рәтенә керә. Тик аның әсәрләрендә булган мәхәббәт, җирне олылау хисе күзгә ташланып, чекерәеп тормый. Әйтик, тукымага буяу ничек сеңгән булса, Бәширов әсәрләрендә дә илне, җирне ярату хисе әсәрнең тукымасыннан аерып алып булмастай дәрәҗәдә табигый булып, бер бөтен булып яши. «Намус»ны укыган чакта үзеңне гел хуш исле үләннәр арасында, болын тугайларында итеп тоясың, язның шыпырт сулышын һәм башаклар кыштырдавын ишетәсең, сине гаҗәеп тыйнак һәм эчкерсез кешеләр, хәтта басынкырак, тыныграк кешеләр мохиты урап ала. Сиңа рәхәт. Болар синең якын-

нарың, боларга син ышанасың, алар сине уңайсыз хәлдә калдырмаячаклар. Алар кеше җилкәсенә ышыкланып яшәргә өйрәнмәгәннәр...» Бу сүзләр «Намус» романына карата әйтелгән. Әммә алар язучының бөтен иҗатына да кагыла. Нәкъ шундый җир турында, нәкъ шундый кешеләр турында яза Гомәр Бәширов. Яратып, бирелеп, хөрмәт белән яза.

Хәсән ага Туфанның язучыга багышлап язган шундый юллары бар:

> **Хөрмәтли сине Туган ил.**
> **Ә ул, юк, ялгышмый бит:**
> **Иҗатта гына түгел, син**
> **Һәркайда намуслы бит!**

Язучы намусы. Никадәр хаклы шигырь юллары. Безгә бары кушылырга гына кала бу сүзләргә. Куәтләргә генә кала...

Мин Гомәр ага белән күрешкәнем, очрашканым бар, гәпләшеп, сөйләшеп утырганым юк. Ләкин бу олы язучы минем гомерлек әңгәмәдәшем, фикердәшем. Мин аның белән китаплары аша сөйләшәм, әңгәмә алып барам. Бер мин генә түгел, башка укучылар да шулайдыр. Алар да мин кичергән тойгыларны кичерәләрдер. Язучы белән сөйләшәләрдер, аңа мөрәҗәгать итәләрдер. Язучы белән укучы арасында Тормыш, Кеше, Намус, Табигать турындагы әңгәмә дәвам итә...

# ЭНҖЕ БӨРТЕКЛӘРЕ

„Сүз эчендә энҗе бар»,— ди халык. Бу мәкаль сөйләгәндә һәм язганда сүзнең мәгънәсен, эчке хосусиятен, чамасын аңларга кирәклеккә искәртә. Һәм, чыннан да, суны таяк белән, кешене сүзе белән үлчиләр дигәндәй, кемнең кем икәнлеген теле аша да билгеләп була бит. Әдәби әсәрдә урынсыз кулланылган бер сүз, ап-ак сөткә тамган бер тамчы деготь кебек, нәфисләкнең дәрәҗәсен төшерә.

Гомәр ага Бәширов — нәфис сүз остасы. Сүзне энҗе бөртекләре урынына кадерләүче. Һәр сүз эчендә энҗе барлыгын аңлап язучы. Алай дигәч тә, тышкы яктан энҗедәй ялтыравыклы, «күз явын алырлык», матур-матур сүзләр сайлау турында фикер йөртелми. Баллы сүз баш әйләндерә, дип тә әйтә халык. Туган телнең гасырлардан-гасырларга тупланып килгән бай сүзлек хәзинәсе бар. Анда, галимнәр теле белән әйтсәк, ниндиләре генә юк: гомумкулланыштагы сүзләр, поэтизм, нейтраль лексика, архаизм (искергән сүзләр), неологизм (яңа сүзләр), гади сөйләм лексикасы, алынма сүзләр... Әдәби әсәрдә, стиль таләп итсә, аларның барысы да кирәк. Гомәр Бәширов әсәрләрендә дә без аларның һәртөрлесен очратабыз: поэтизм (энҗе, сайрау, дулкын), гарәп сүзе (вәкар), архаизм (собханалла, иман, фида кылу), гади сөйләм лексикасы (бакчы, маташу, авыз еру), рус сүзләре (дисвительни, наверняка, безобразне) һ. б. Әсәр тукымасында алар аерым хәлдә яшәми, башка сүз һәм сурәтләү чаралары белән эчке яктан органик мөнәсәбәткә кереп, билгеле бер эстетик функция үти. Архаизм, рус, гарәп сүзләрен, гади сөйләм лексикасын әдип бик кирәктә, күбрәк төрле персонажларның холык-фигыльләрен ачыклый төшү максатында куллана. «Намус» романындагы Сәйфи, мәсәлән, ничек сөйләшә? «Ай-яй! — диде,— дисвительни, мулдан икән үзеңнең исәп». Бозып әйтелгән рус сүзе Сәйфинең холкын-фигылен дә күрсәтеп тора.

Образ-персонажның эчке, рухи дөньясын ачыклыйммы, аның портретын тасвирлыймы, табигать күренешләрен, төрле вакыйгаларны сурәтлиме — һәр очракта язучы аз сүз белән күп мәгънә аңлатырга, җанлы картина тудырырга тырыша. Моның өчен, билгеле, төрле сүз-әйбер, сүз-образ җәләп ителә. Кайбер очракта гомумкулланыштагы гади генә сүзләр дә зур эмоциональ-экспрессив көчкә ия була. «Намус» романыннан бер мисал: «Кем белә, Сталинградта хәзер, ихтимал, таш өстендә таш калмагандыр». Таш өстендә таш калмау — һич кечанми, гади генә, халыкча әйтелгән

сүзләр. Сугышның коточкыч картинасын чагылдыра ул. Шул сүзләр аша без җимерек йортларны, янып яткан танкларны, кыскасы, зур фаҗигагә дучар булган шәһәрне күз алдына китерәбез.


Телебез бай, аның эчке мөмкинлекләре зур. Әле язма әдәби тел булмаганда да халык синтетиклашкан поэтик формулалар, соклангыч мәкаль-әйтемнәр, төрле сурәтләү чаралары иҗат иткән. Без аларның матур үрнәкләрен Болгар чорында иҗат ителгән «Йосыф-Зөләйха» поэмасында, аннан соңрак «Төхфәи мәрдән», «Нуры содур»ларда, Г. Кандалый, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, һ. Такташ, Ф. Хөсни һ. б. әдипләрдә күрәбез. Традицион сурәтләү чаралары гасырлардан-гасырларга, әсәрләрдән-әсәрләргә күчеп килә. Чорга, тарихи шартка, социаль күренешләргә, әсәрнең идея-эчтәлегенә, стильгә бәйле рәвештә алар тышкы һәм эчке яктан үзгәрә дә. Шуның белән бергә, яңа чор яңа сурәтләү чаралары таләп итә. Ул тел һәм культура, техника һәм экономика үсешенә бәйле. Гомәр Бәшировсәсәрләрен укыганда хәзерге таләпчән укучы бу мәсьәләгә дә игътибар итми калмыйдыр.

Г. Бәширов иҗатында традицион тасвир чаралары күп очрый: болын күбәләгедәй уенчык, күгәрчендәй гөрләшеп тору, арсландай егетләр, пыяладай боз, карлыган төсле кара күз, курчак өе кебек матур булмә һ. б. Әмма халык телендә, җырларда, моңа чаклы күп язучылар тарафыннан кулланылып, «төсе уңган» әзер поэтик чаралар белән генә иҗат итү оста язучыны канәгатьләндерми. Ул аларны үзенчә яңартырга омтыла. Бу вакытта телбизәк тышкы (формаль) һәм эчке (мәгънәви) яктан үзгәрүгә дучар була. Язучы, билгеле, инде бу сурәтләү чарасы укучыны туйдырган, шуңа күрә, мәгънәсен саклап, башка сүзләр белән бирим әле, дип уйламаска да мөмкин. Әсәрнең рухы, персонаж, сюжет-композиция, яңача тасвирлануга мохтаҗлык шуны таләп итә. Халык, мәсәлән, юлны тасмага охшатучан. Г. Бәширов «Намус»та тасманы соры дигән сыйфат белән ачыклый: «Мәүлиха түтинең иреннәре, нидер пышылдап, тиз-тиз кыймылдый. Ул, бераз саный да, күзләрен кыса төшеп, җемелдәп яткан киң кыр ягына карап ала. Әнә шул якта кыр өстеннән соры тасмадай бөргаланып узган язгы җепшек юл белән озакламыйча аларның бригадирлары кайтырга тиеш». Язгы җепшек юл — абстракт төшенчә, картина, күзаллау юк. Тасмадай бөргалану да искитәрми. Ә кышкы юлны тасмага охшату мөмкин түгел, юлның шомалыгын күз алдына китерү өчен, аны көзгә белән чагыштыру гына бар. Мопассан әйткәнчә, һәр әйберне тәгъбир итүче сүз, характерлаучы сыйфат, җанландыручы фигыль була. Шул исем, шул сыйфат, шул фигыльне тапмыйча калмаска кирәк. Әйберне якынча атау, җанландыру, сыйфатлау белән беркайчан да канәгатьләнергә ярамый. Стендаль Бальзакка язган бер хатында исем алдыннан яки аннан соң сыйфат кую өчен еш кына унбиш минутлап уйлануы турында әйтә... Югарыда телгә алынган «соры тасма» да, поэтик бизәк буларак, Мәүлиха түтинең уй-хисләрен, рухи халәтен ачыклауга ярдәм итә. Ул бит шушы җирнең, туган туфракның яшәүгә дәрт, илһам, куәт бирә торган илаһи бер тылсымын татып үскән. Эш вакытында соры тасмадай бөргаланып узган язгы җепшек юлга карап алу аның күңеленә садәлек өсти, чөнки әсәр тукымасында «соры» сүзе сурәткә әверелә, образлы картина тудыра, эстетик вазифа үти.

Шулай итеп, халыктагы гыйбарәләрне төрлечә үзгәртә язучы. Ул үзе дә төрле тасвир чаралары иҗат итә. Бусы тагын да авыррак, әлбәттә. Ул тел диңгезенә кат-кат чуму, аны бер аркылы, бер буй йөзү, төбенә төшеп эзләнүне таләп итә. «Каз бәпкәләредәй муенын сузган бодай кыяклары»,— ди автор бер урында. Күңеле белән җиргә береккән кеше, **бодай кыягы** дигән сүзне ишеткәч, хис-тойгыга бирелмичә кала алмый. Чөнки бодай кыягы аның җандай якын күргән кырларын күз алдына китереп бастыра. Аларны муенын сузган каз бәпкәсенә чагыштыру да тышкы матурлык өчен генә кирәк булган дип уйларга ярамый. Күпме эчке мәгънә бу чагыштыруда! Бәпкәне дә даими карап, тәрбияләп, күзәтеп торып үстерәләр. Игеннә дә шулай. Бәпкәгә балага булган тәрбия кирәк. Җитмәсә, бу чагыштыруны язучы икмәкнең иң кыйммәт, аеруча кадерле вакытында («Намус»та) куллана. Шуның белән ул хезмәткә мәхәббәт уята, хезмәтнең эстетикасын ача. Мондый мисалларны Г. Бәшировтан бик күп китерергә мөмкин булыр иде. Аның автор хикәяләвен һәм персонажлар телен дә игътибарсыз калдырып булмый. Автор хикәяләвендә үк персонажның кем, нindирәк табигатьле кеше икәнлеген сизәсең, шуннан ул шәхеснең үз сөйләмен ишетәсе килә башлый; ишеткәч, әлеге сиземләү раслана да куя. Киресенчә дә була. Үз характерын ачып са-

лырдай сүзләр белән башта персонаж сөйли. Аннан аның эчке дөньясы автор хикәяләвендә тагын да ныграк ачыклана. Шул ике нәрсә арасында билгеле бер динамика, диалектик берлек яши. Бер генә мисал: «Аның майлы күзләре мутланып елтырыйлар. Кан бәреп торган калын иреннәре үз алдына тетрәнеп-тетрәнеп китә. Әлипә, яшел кашлы көмеш йөзек кигән кыска бармагы белән ялкау гына орлык чүпли-чүпли, Мәүлиха түтигә карап алгач, тамак төбе белән генә тагын бер көлеп куйды. Җайлабрак утырды да, әллә Мәүлиха түтине үчекләп, әллә вакыт уздырыр өчен:

— Әле тегендә ата каз каңгылдагач исемә төште,— дип мәзәк сөйләргә тотынды.— Былтыр яз мин үзебезнең мишәр ягына бардым ие бит, бакчи, Шәйморзага. Күршеләргә шылай, килен төшкән икән. Да. «Әлипә түтәй, дир, атакай йортыннан ана каз алып килдем ие, дир, мондагы ата каз шуны сүми генә бит, дир. Ишегалды буйлап ысылдай-ысылдай куып ери. Шуның берәр әмәлен белмисеңме?» — дир».



Мутланып елтыраган майлы күзнең эчке дөньясы персонажның үз сөйләмендә әнә ничек ачыклана. Автор аларны тагын үз сүзләре белән ныгытып куя: «Әлипә, кашларын сикертә-сикертә, түмле итеп сөйли, гүя, үз сүзләренең рәхәтенә үзе үк оеп киткәндәй, ара-тирә авызын чәпелдәтеп куя, күзләрен йомгалый».

Нәфисә, Айсылу, Сөмбел һәм башкалар турында язганда автор хикәяләвендәге интонация, аһәң дә үзгәрә, персонажлар да үз телләрендә сөйләшә.

Гомәр Бәшировның тагын бер үзенчәлеге итеп шуны күрсәтергә була: аның теле грамматик яктан төзек. Миңа берничә ел мәктәптә укытырга туры килде. Диктант өчен текстны һәрвакыт «Намус»тан сайлый торган идем. Җөмләнең төрле типлары бар анда. Тыныш билгеләре дә дөрес куелган. Җөмләнең аерымланган кисәкләрен генә алыйк. Аларны сәнгатьчә куллана белү язучыдан зур осталык сорый. Кайбер язучының әсәрендә ул бик сирәк очрый. Моның матур үрнәкләрен прозада Г. Ибраһимов күрсәткән иде. Гомәр Бәширов аерымланган кисәкле соклангыч җөмләләр төзи. Мәсәлән: «Ул (Нәфисә — С. П.), үзенең җитеп килә торган бер кыз булуын бөтенләй онытып хәлдә, муенсасының гәрәбәләрен аралый-аралый, сабыйлар беркатлылыгы белән, зәңгәр күкнең төпсез тирәнлегенә, күз алдында җәелеп яткан киң табигать күренешенә хәйран калып, исе китеп карый иде». Бер җөмлә эчендә күпме аерымланган кисәк! Шулар ярдәмендә күпме җанлы картина барлыкка кил-

гән! Без, үзебез дә сизмәстән, табигатьнең матур, серле дөньясына да кереп китәбез, Нәфисәнең саф, садә, хисле күңелен, кайнар тойгы ташып торган рухи байлыгын күреп шатланабыз.

Соңгы вакытта кыска җөмлә белән язуның өстенлеге турында сүз китте. Җыйнаклыкка, кыскалыкка бәрәү дә каршы түгел. «Кыска сүз — алтын, озын сүз — балтун»,— ди халык. Әдәбиятта кыскалык өчен көрәш күптән килә. Ләкин гел кыска җөмләләр белән эш итү дә формализмга алып бара, — фикер өзелә, мәгънә ягы «аксый» башлый.

Бүз җее белән, сүз җае белән, дип тә әйтә бит халык. Телнең җае бар. Җөмләнең кыскасы да, озыны да кирәк. Әмма ул урынлы булсын. Язучының теле һәм стиле хакында сөйләшкәндә, без бу мәсьәләләрне күп вакыт урап үтәбез. Академик В. В. Виноградов лингвистик поэтикага телнең барлык элементларын кертә: фонетика, морфология, синтаксис, лексик-фразеологик состав, сурәтләү чаралары, ритм, тон, аһәң һ. б. Сәнгатьле сөйләмдә алар, бер-берсе белән табигый бәйләнеп, язучының эстетик концепциясенә буйсынырга тиеш. Гомәр Бәширов әсәрләрендә телнең төрле формасын, грамматик чараларын җайга китереп язуына кадәр сокландыра (урынтын, уздыргалыйлар, беркайчанга).

Бу осталык үзеннән-үзе генә килми, әлбәттә. Г. Ибраһимов шагыйрь булу өчен башта анадан шагыйрь булып туарга кирәклек турында әйтә. Аннары талант өстенә дөньяга прогрессив караш таләп ителүен искәртә. Талант телгә дә бәйләнгән. Тел — язучының төп коралы. Сүз сәнгате остасы булу өчен язучы-галим дәрәҗәсенә күтәрелү зарури. Гомәр Бәширов нәк шундый сыйфатларга ия. Икенче төрле әйтсәк, телнең фәнни нигезен белүче. «Тел турында кайбер фикерләр» исемле мәкаләсендә ул болай ди: «Нинди юллар белән генә баетмый язучы үзенең телен! Бу яктан аны алтын һәм асылташлар эзләүчеләр белән тиңләргә мөмкин булыр иде. Андый язучы яки тел белгече сирәк очрый торган берәр кадерле сүз очраткан саен, аны, асылташ табучы галим шикелле, әйләндерә-әйләндерә карап, аңа соклана, ул аның тарихы, хәзерге тормышы, киләчәге белән кызыксына, матурлыгыннан яки тапкырлыгыннан ләззәт таба, куана». Сүзне җиң сызганып, тирләп-пешеп дигәндәй, әнә шулай эзләмәсә, әдип мондый фикер әйтә алмас иде. Абай да бит: «Сүзнең эче — алтын, тышы — көмеш», — дигән.

Җыйнап әйтсәк, телнең бай лексик составы, фонетикасы, морфологиясе, синтаксисы, фразеологиясе, мәкаль-әйтемнәре, тасвирлау чаралары — кыскасы, бөтен бар элементы Г. Бәширов әсәрләрендә сәнгатьчә яңгыраш тапты. Сүздән энҗе коя ул!

**СУФИЯН ПОВАРИСОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# ИҖАДИ КАЗАНЫШЛАР ЮЛЫННАН



Нәҗип Җиһановның тормыш һәм иҗат биографиясе Бөек Октябрьдан соңгы күтәренке революцион пафос белән тулы чорга, элек изелеп яшәгән халыкларның экономик һәм рухи тормышын социалистик нигездә үзгәртеп кору барган заманга туры килде. Ул яңа милли культура төзү идеаллары, татар халкының моңарчы булмаган дәрәҗәдәге профессиональ музыка сәнгатенә нигез салу хыялы белән янды. Зарури бер максат, һичшиксез, тормышка ашарлык чынбарлык рәвешендәге бу хыял яшь музыкантны күп милләтле совет музыкаль культурасының алгы сызыгына алып чыкты.

Сәнгатьтәге теләсә кайсы әһәмиятле һәм үзенчәлекле күренеш кебек үк, Н. Җиһановның иҗатын да ул чорга хас иҗади хәрәкәттән аерымланган хәлдә аңлау мөмкин түгел. Аның иҗаты совет чорында гына музыкаль профессионализм үрләренә омтылу мөмкинлеге алган милли мәдәниятләрнең аякка басу процессы белән аерылгысыз бәйләнгән.

Әлеге юлда татар, башкорт, чуваш һәм башка пентатоник культуралар вәкилләренә аеруча катлаулы бурычлар хәл итәргә туры килде, чөнки бу милләтләрнең яшь профессиональ сәнгате музыкаль тәҗрибә һәм традицияләрдән бөтенләй диярлек мәхрүм иде.

Композиторлык иҗаты өлкәсендә профессиональ сәнгатьнең әлеге яңа булган формаларын һәм жанрларын тирәнтен үзләштерү һәм мәйданга чыгару проблемасы килеп басты. Аны халык авыз иҗаты традицияләренә, аерым алганда, бер тавышлы пентатоник моңның үзенчәлекле сыйфатларына сак килгәндә генә хәл итеп була иде.

Моңарчы күрелмәгән синтезга ирешүдә бай — халыкчан-реалистик принциплар һәм Европа, беренче чиратта, рус музыка классикасы мирасы, шулай ук совет сәнгате казанышлары нигез булып хезмәт итте. Илебезнең күп кенә республикаларында, шул исәптән, Идел буе автономияле республикаларында музыкаль профессионализмның беренче нигез ташларын салучыларның талантлы эшчәнлеге халыклар күңелендә мәңге сакланыр. Композиторлык иҗатының барлык өлкәләрендә — җырда һәм хор музыкасында, музыкаль театрда, симфонизмда һәм камера музыкасында күренекле казанышларга юл салган Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров һәм Василий Виноградовларның, шулай ук аларның яшь замандашлары Нәҗип Җиһанов, Александр Ключарев, Фәрит Яруллин, Җәүдәт Фәйзи һәм Заһит Хәбибуллинның кыю новаторлык тәҗрибәсе беркайчан да онытылмас.

Бу тамырдан яңарыш процессында, бигрәк тә милли опера, балет һәм симфоник жанрларның уңышлы үсешендә Нәҗип Җиһановның иҗаты күренекле урын алып тора.

# Музыкаль сәхнә драматургиясе остасы

Татар опера сәнгатенә юл сызган һәм милли музыкаль театрның нигез ташларын салышкан Н. Җиһанов үзенең иҗатында Ватанга мәхәббәт, халыкның азатлыгы һәм бәхете хакына батырлык турында җырлаучы, социаль-тарихи пафос белән сугарылган темалар алып килде. Бу темаларда совет композиторының гражданлык һәм иҗади омтылышлары бик тулы гәүдәләнә. Шуңа күрә дә, мөгаен, аның һәр әсәре, нинди материалга корылган булуына да карамастан, батырлыкка һәм игелеклелеккә багышланган җыр, халыкның бетмәс-төкәнмәс көченә һәм рухи бөеклегенә гимн булып яңгырый.

Иң беренче тарихи операларны — крепостной татарларның Пугачев җитәкчелегендәге көрәше турында сөйләүче «Качкын» әсәрен (Ә. Фәйзи либреттосы. Бу опера белән 1939 елның 17 июнендә Татар дәүләт опера һәм балет театры ачылды) һәм Бөек Октябрь алдыннан Казан губернасында булган революцион вакыйгаларны тасвирлаучы «Ирек» операсын (З. Сафин либреттосы) гына искә төшерик. Шуннан соң, әкият һәм риваятьләргә корылган дүрт сюжетның ике монументаль опера спектаклендә һәм ике балетта гәүдәләнеш табуын билгеләп үтәргә мөмкин. Операларның берсе — 1948 елда СССР Дәүләт премиясенә лаек булган «Алтынчәч» (М. Җәлил либреттосы), икенчесе — соңгы редакциясендә «Түләк белән Су сылу» исеме алган «Түләк» (Н. Исәнбәт либреттосы). Балетларның берсе — «Зөһрә» (Ф. Гаскәров либреттосы) һәм икенчесе — «Нжери» (шәрык әкиятләре мотивлары буенча Н. Җиһанова язган либретто). Һәм, ниһаять, бу исемлекне заман героикасы белән сугарылган «Илдар» (М. Җәлил либреттосы), «Намус» (Г. Бәширов романы буенча Ә. Исхак либреттосы), «Шагыйрь» (Ә. Фәйзи либреттосы) опералары белән тәгәлләргә була. Соңгы сюжетның яңа варианты шул ук авторлар тарафыннан иҗат ителгән «Җәлил» опера-поэмасына нигез булды.

Н. Җиһановның музыкаль-сәхнә драматургиясенә иҗтимагый-тарихи конфликтларны мораль-әхлакый конфликтлар белән тыгыз бәйләнештә сурәтләү хас. «Качкын» операсында, мәсәлән, Рәйхан белән Булат социаль көчләргә һәм шул ук вакытта дошманнарның мәкерле, түбән мәнфәгатьләренә каршы торалар; Түләк белән Аембика — туган җирләренең азатлыгы өчен генә түгел, ә хыянәткә, хакимнәр башбаштаклыгына һәм мәкергә каршы көрәшүчеләр; Тугзак, Алтынчәч, Җик-мәргән, халыкның азатлыгын һәм бәйсезлеген яклаучы батырлар булу белән беррәттән, гаделлек, игелеклелек һәм матурлык символына әверелгәләр; Нәфисә халык байлыгы өчен көрәшә, шул ук вакытта, вөҗдан кушуы буенча, яла ягучыларны, көнчеләрне һәм ялганчыларны фаш итә; Илдар үзенең хата уй-фикерләреннән һәм шикләнүләреннән арынып, рухи сафлыкка ирешә, яңа тормыш башлый; Җәлилнең батырлыгы — кайнар патриотизмында һәм героик үлемендә генә түгел, ә куркакларга һәм хыянәтчеләргә каршы аяусыз көрәшүендә дә.

Социаль-тарихи һәм әхлакый проблемаларның тыгыз бәйләнеше опера әсәрләрендә лирик, эпик, драматик һәм героик башлангычларның табигый кушылуын тәэмин итә. Операларның һәркайсында патриотик рухлы якты сәхифәләр тирән драматизм яки якты лиризм белән сугарылган күренешләргә ялганып китә. Алар сәхнәдәге төрле фантастик һәм дөньяви вакыйгалар белән иркен үрелеп баралар.

Җиһанов операларында тәэсирлелекнең һәм сурәтләүнең күп планлы булуы үзенчәлекле жанр синтезы тудыра. Аның монументаль легендар-героик операларына аеруча хас булган бу синтез бер үк әсәрдә эпик, лирик-психологик, фантастик элементларның табигый кушылмасы рәвешендә барлыкка килә.

Н. Җиһановның музыкаль сәхнә әсәрләрендәге динамик, кискен конфликтлы драматургия дә бу күп планлылыктан аерылгысыз. Чыннан да, характерлар капма-каршылыгы, үзара дошман лагерьлар арасында аеруча кискен вакытлар, гадәттә, музыкаль драматик үсешнең мөһим ноктaларын тәшкил итәләр. «Качкын»да Әбләйнең Рәйханны эзәрлекләве яки Рәйханны җәзалау күренешләре; әсирлеккә төшкән Алтынчәчне Хан тирмәсендә юмалау күренеше, Илдар белән Арыслан яки Җәлил белән Ханзафаров арасындагы бәрелеш күренешләре; ниһаять, Нәфисәнең ир ягы

туганнары йортыннан китәр алдыннан булган конфликтлар җыелмасы әнә шундыйлардан.

Мондый драматик бәрелешләрдән кала, кульминация әһәмияте зур булган көрәшләргә сугышлар да керә. Мәсәлән, «Качкын»да крестьяннар баш күтәрүе, «Алтынчәч»тә Җик-мәргәннең Кулупай белән сугышуы... Ләкин һәлак булган Рәйханны кызганып елаган чакта кинәт башланып киткән һәм восстание турында хәбәр иткән янгын («Качкын»); Тугзак йортында барган мәҗлесне бүлеп, Хан гаскәрләренең бәреп керүе («Алтынчәч»); Җәлил-Гомәровның совет әсирләре белән очрашуы һәм немецларның аны фаш итүе кебек тагын да киеренке эпизодлар конфликтлы драматургия өчен аерым әһәмиятле булып тора.

Әсәрнең төп музыкаль-драматик нигезе, гадәттә, менә шундый үзәк көрәшләрдән төзелә. Лирик һәм халык тормышы-көнкүреше вакыйгалары, легендар-героик опералрда исә болардан тыш фантастик вакыйгалар да әлеге үзәк тирәсенә тупланә.

Бер-берсен тулыландыручы вокаль-хор һәм оркестр партияләренең табигый бердәмлеге шулай ук опера-симфония драматургиясенең үзенчәлекле сыйфаты булып тора. Әлеге партияләргә аерым лейтматик темаларның төрлечә үзгәрешләре һәм үсеше бер үк дәрәҗәдә хас. Бу һәр интонацион, ритмик, гармоник штрихның һәм оркестр мөмкинлекләренең тәэсир итү көчен тагын да арттырырга ярдәм итә. Мәсәлән, «Алтынчәч» операсындагы музыка даими үсештәге интонацион үзгәрешләр һәм үзара эчке бәйләнешләр белән тулы, финалдагы тантаналы җыңу хорында исә күп темаларның элементлары интонацион яктан гомумиләштерелә. «Тулак белән Су сылу» операсында төп темаларны эшкәртү һәлак булган каһарман кызга багышланган финал реквиемы белән тәмамлана һәм ул реквием үзенчәлекле музыкаль символга — Ватан символына әверелә. Шушы ук рухтагы «Җәлил темалары»ның һәм аңа каршы куелган «сугыш темалары» комплексының гаять динамикаль эмоциональ-образ үзгәрешләре дә поэма-операның музыкаль-драматик нигезенә салынган.

Бу ысул операның ирекле формаларын кулланганда төрле характердагы эпизод-күренешләрне киң колачлы, аерым очракларда хәтта монументаль картиналарга берләштерергә һәм бердәм музыкаль-сәхнә композициясе төзергә мөмкинлек бирә.

Көчле эчке җегәр Җиһановның музыкаль-драматик фикерләвенә хас образ-тема полифониясе алымнарыннан килә. Контрастлы сурәтләрнең бергә үрелүе, шулай ук капма-каршы тема элементларының кушылып яңгыраулары музыкада драматизмны һәм эмоциональ-психологик тирәнлекне арттыра. Бу хәл сәхнәдә күзгә күренеп һәм күренми бара торган туктаусыз хәрәкәтне бирүне тасвирлау мөмкинлеге бирә. Бирәдә сыналган ысуллар — лейттематик реминисценция, тематик «дулкыннар» һәм симфоник гомумиләштерүләр зур роль уйный.

Н. Җиһановка хас музыкаль-драматик принциплар, тулаем алганда, аның музыкаль-театраль концепциясенең асылын тәшкил итә. Ул концепциянең нигезе үсүенә рус һәм Европа опера классикасының реалистик драматургиясе нык йогынты ясый. Глинка һәм Бородинның героик әсәрләре, Римский-Корсаковның әкияти-хыялый һәм эпик музыкасы, Чайковский һәм Вердиның лирик-трагик опера принциплары — менә шушы илһам чишмәләреннән гыйбрәт һәм тәҗрибә ала Н. Җиһанов. Аның иҗат концепциясе күпмилләтле совет опера традицияләре белән дә нык бәйләнгән. Бу яклылык героик идея-тема юнәлешендә дә, опера жанрларын синтезлау тенденциясендә дә, музыканың интонацион төзелешенә заманча төс бирергә омтылуда да чагылды.

Н. Җиһановның «Качкын»нан башлап «Җәлил»гә кадәрге иҗат юлы — сәнгатьчә матурлыгы белән күңелләрне җилкендерерлек, Ватанга һәм туган халкына мәхәббәт уятырлык татар совет операсы өчен көрәшү юлы ул. Бу көрәш нәтиҗәсендә, уңышлар белән бергә аерым уңышсызлыклар чиратлашып килсә дә, татар халкының Болгар чорыннан — Пугачев восстаниесенә, Бөек Октябрь социалистик революциясеннән Бөек Ватан сугышына кадәрге героик тарихын сурәтләүче зур күләмле әсәрләр галереясе барлыкка килде.

## Күренекле симфонияче

Музыкаль-сәхнә әсәрләре белән бергә композитор бик күп романслар һәм фортепиано пьесалары да иҗат итте. Аларның шактый өлеше миниатюралар яки сюжетлы цикллар рәвешендә нәни башкаручылар һәм тыңлаучыларга багышланган.

Яңа, социалистик чор кешеләренең хисләрен һәм фикерләрен актив һәм кыю сурәтләүче җыр жанрында да бөтен күңелен баглап эшли композитор. Интим-лирик, марш һәм гимн, кантата рухындагы җырларын тыңлаганда, Туган илгә, тормышка һәм хезмәткә гашыйк иҗат кешесенең дәртле йөрәк тибешен, нечкә күңелен тойгандай буласың.

Нәҗип Җиһанов үзенең Беренче симфониясен консерваториядә укыган елларында ук яза. Әлеге симфония 1938 елда Татар дәүләт консерваториясе ачылу уңае белән оештырылган тантаналы концертта башкарыла. Әмма ул вакытта, опералар язу хыялы белән канатланып йөргәнлектән, яшь композитор симфонияләр иҗат итүне «онытып» тора. Шулай да иҗади фикерләүнең иң катлаулы ысулы булган симфонизм белән кызыксынуы һич тә кимеми. Ул музыкаль-сәхнә драматургиясенең симфонияләштерелгән форма һәм эчтәлегендә дәвам итә. Операларындагы киңәйтелгән увертюралар һәм симфоник күренешләр, шулай ук аларның лейттематик үсеше шул хакта сөйли. Кырыгынчы елларда, симфониягә кабат әйләнеп кайткач, композитор иҗатында хасил булган зур сыйфат үзгәрешләре шуңа күрә бик табигый иде.

«Кырлай» дигән программ әсәре белән Н. Җиһанов милли сәнгатьтә яңа жанр — симфоник поэма башлангычына нигез салды. «Намус» операсының тематик материалына корылган «Нәфисә» драматик поэма-увертюрасы да игътибарга лаек уңыш иде. «Кырлай»да автор халык әкиятләрендәге яхшылык белән яманлык көрәшенең динамикасын җанлы һәм хәрәкәтчән итеп тасвирлый алган булса, «Нәфисә» увертюрасы исә психологик күпкырлылыгы һәм лирик-драматик пафосы белән хәтердә кала.

Н. Җиһанов иҗатында сюита жанры зур урын алып тора. Ул татар симфонизмы формалашуда зур урын тоткан, принципиаль мәгънәгә ия булган әсәрләр иҗат итте. Шундыйлардан «Татар темаларына сюита»ны (аның өчен композитор 1950 елда СССР Дәүләт премиясенә лаек булды), «Симфоник новеллалар»ны һәм «Симфоник җырлар»ны күрсәтеп үтәргә мөмкин. Бер-берсеннән никадәр генә аерылып тормасыннар, аларны бер үк иҗади тенденция берләштерә: аларның нигезендә симфоник оркестр чаралары белән халык көйләрен һәм оригиналь темаларны сәнгатьчә югарылыкта интерпретацияләү ята.

Җиһановның әлеге өлкәдәге эш принциплары да үрнәк булып тора. Халык иҗаты үрнәкләрен эшкәртүне ул саф иҗатка тиңли, аңа гаять зур сизгерлек һәм осталык сорый торган хезмәт дип карый.

Н. Җиһановның балет һәм операларыннан төзелгән сюита цикллары да бар: «Зөһрә» балетыннан ике сюита һәм «Алтынчәч» сюитасы.

Композитор соңгы ун ел эчендә симфония жанрында ару-талуны белми, илһамланып эшләде. Моңа илһамлы башлангычны 1970 елда СССР Дәүләт премиясенә лаек булган «Сабан туе» дигән Икенче симфония бирде. Халык бәйрәмендә тантаналы күңел күтәренкелегә хөкем сөргән кебек үк, бу симфония дә тормышка, аның матурлыгына дан җырлый. Әсәр динамик сурәт-композиция төзелеше белән аерылып тора. Анда тирән лиризм һәм мәһабәт эпос, киеренке драматизм һәм югары героика бер бөтен булып оеша.

1971 елда башкарылган Өченче «Лирик» симфониядән алып 1979 елның көзендә премьерасы булган Унынчы симфониягә кадәр, һәр ел саен язылган сигез симфониянең һәркайсы игътибарга лаек. Бу симфонияләрне аерым-аерым тикшерү әле киләчәк эше. Биредә безнең карашка бик мөһим тоелган бер генә күренешкә — концепция, тематика, структура-композиция ягыннан бер-берсеннән нык аерылып торган хәлдә дә, әлеге симфонияләрнең заманчалык тойгысы һәм оптимистик рух белән берләшүләренә игътибар итәргә кирәк.

Композиторның симфоник иҗаты белән музыкаль-сәхнә драматургиясе нигезләре арасындагы эчке бәйләнешләр да зур әһәмияткә ия. Бу тәэсир-йогынты симфо-

нияләрнең күпкырлы эмоциональ-образ һәм композиция структураларында да, шулай ук инструменталь тематизмнарның характерында һәм үсешендә дә чагыла.

Н. Җиһановның соңгы еллардагы симфоник иҗатын һәм татар симфоник музыкасына керткән зур өлешен профессор Г. И. Литинский югары бәяләде. «Сигезенче симфониядә, — дип язды ул, — композитор үзенә генә хас көчле һәм үзенчәлекле яклары белән яңадан ачылды. Халыкчан музыкаль традицияләргә мөнәсәбәттә оригинальлек, һич кыланмыйча, чуарламыйча, төгәл һәм ачык итеп язу, конструкцияләрнең гаҗәеп пропорцияле булуы, мәгънәле һәм тәэсирле тематизм, оркестрлаштыруда кыюлык һәм зирәклек... һәм, ниһаять, иң мөһиме — заман сулышын тоеп, дөньяга оптимистик караш белән иҗат ителгән музыка, күңелгә якын һәм ифрат тормышчан тәэсирләр, ассоциацияләр тудыручы тере аһәң». («Советская музыка» журналы, 1978 ел, 7 сан, 29 бит.)

## Алдынгы иҗат принципларын яклап көрәшүче

Татарстанда профессиональ композиторлык осталыгына ирешү өчен иҗади хәрәкәтнең башы 20 нче елларга туры килә. Бу хәрәкәт татар музыкасының тыйнак агымына яңа куәт өстәде, аны башка халыкларның музыкаль культура хәзинәсендәге катлаулы чаралар һәм алымнар белән баету мөмкинлеге тудырды. Форма төзелешендә, тональ-гармоник һәм полифоник үсеш өлкәсендә пентатоник системаның классик принциплар белән үзара тыгыз мөнәсәбәте көн тәртибенә баскан мәсьәләләрнең берсе булды.

Пентатоник музыкалы культураларга үзләренең халыкчан-милли сәнгать традицияләрен һәрьяклап үстерү һәм киңәйтү юллары ачылды. Бу үсеш-үзгәреш, әлбәттә, әлеге традицияләрнең классик мирас белән, дөнья сәнгатендәге, барыннан да бигрәк совет музыкасындагы, заманча алдынгы күренешләр белән иҗади бәйләнешы нигезендә генә мөмкин иде. Дөнья халыклары сәнгатенең бай тәҗрибәсенә таянып пентатоник музыканың сулышын киңәйтеп җибәрергә, аны яңа эчтәлек белән тулыландырырга омтылу зур уңыш белән төгәлләнде. Татар музыкасы чын мәгънәсендә революцион рух белән сугарылган әлеге киң колачлы, күпкырлы процессны әйдәп баручылар сафында атлады.

Н. Җиһанов әсәрләренең музыкаль теле саф яңгырашка, кабатланмас мәгънәләргә ия. Аның нигезендә татар халык музыка сәнгатенең интонацион һәм ритмик үзенчәлекләрен гәүдәләндергән моң ята. Хәлбуки халык иҗатының асыл сыйфатларын үзләштерү композиторның музыкаль тел үсешенә киртәләр куймый. Ул тәэсир-сурәт чараларының, композицион принципларның, оркестр язмасы, тональ һәм тематик үсеш алымнарының бөтен байлыгыннан файдалана ала.

Композитор пентатоник музыкага халык моңнарыннан, операдагы салмак моңлы көйләрдән, рус классик ариозо һәм романслары мелодикасыннан, шулай ук революцион һәм совет чоры җырларының интонацион-ритмик төзелешеннән килүче элементларның табигый кушылуына ирешә. Әнә шул рәвешле, жанрлары һәм формалары буенча төрле-төрле әсәрләр героик көрәш пафосы, каһарманнарны данлау рухы белән сугарыла, аларда киеренке драматик вакыйгалар һәм бәйрәм тантанасы, гүзәл табигать сурәтләре һәм әкияти күренешләр гәүдәләнә, сада кичерешләр һәм кояшлы юмор хисләре чагылыш таба.

Иҗатының иң биек ноктаYларын билгеләүче операларга, симфоник һәм вокаль әсәрләргә хас бу сыйфатлар композиторның төп стиль юнәлешен билгеләп тора. Ул — тормыш һәм заман белән тыгыз бәйләнешләр нәтиҗәсендә туган реалистик сурәтлелек, музыкаль телнең ачык милли бизәкләре, классикадагы һәм хәзерге заман сәнгатендәге төп принципларның табигый нисбәте. Н. Җиһанов әсәрләрендәге бердәм образ-композиция төзелеше форма масштаблылыгы һәм үсеш динамикасы белән нечкә-нәфис детальләрне, барлык чараларның үзара ярашуын бергә куша.

Композитор үзенең иҗат тамырларына яшәү суты бирүче классика принципларында «музыкаль үсешнең тереклек суын күрә. Шунлыктан ул «рус музыкасының даһи үрнәкләрен — Глинкадан алып Шостаковичка кадәр — кабат-кабат һәм бик зур игътибар белән өйрәнергә» чакыра. Татарстан музыкаль культурасын үстерүгә күре-

некле рус сәнгатькәрләре керткән өлешне һәрвакыт аерым бер хөрмәт белән тәкъдир итә.

Мәкаләләре һәм чыгышлары белән танышканда Н. Җиһановның музыкадагы милли хасиятләр һәм интернационализм мәсьәләләре турында җитди уйлануларын күрәсең. «Милли үзенчәлек әсәрне башка халыкларның кабул итүенә һәм аңлавына беркайчан да киртә булмады, — ди ул. — Алай гынамы әле, музыканың милли хасиятләре ачыграк бәлдерелгән саен, халыкның фикерләр, омтылышлар, идеаллар дөньясы тирәнрәк һәм тулырак ачылган саен, традицияләрнең игелекле нигезенә зуррак иҗади активлык һәм кыюлык белән таянган саен, әсәрнең интернациональ үзеге көчәя-ныгый гына бара». Аның фикеренчә, талантлы автор әһәмиятле милли теманы үзләштереп, заманча тел-сурәтләр белән ача алса, һичшиксез, үз республикасы чикләрендә генә калмаслык әсәр иҗат итә. Әлеге әсәр башка халыкларга да якын һәм аңлаешлы булачак.

Шунысы аеруча гыйбрәтле: нәкъ менә Н. Җиһановның үз иҗаты бу фикерләрне исбатлаучы мөһим дәлил булып тора. Бер генә мисал китерик. Үзенең бер мәкаләсендә күренекле совет композиторы Д. Д. Шостакович: «Үз көйләрен һәм милли җирлекләрен җуймаган хәлдә, башка халыкларның музыкаль культурасы казанышларын үзләштерә алган авторларның әсәрләре, кагыйдә буларак, гомумхалык хәзинәсенә әвереләләр, — дип язган иде. — Бу очраклы хәл түгел. Мәсәлән, азербайҗан композиторы Кара Караевның иң яхшы әсәрләрен, бигрәк тә «Күк күкрәү сукмагыннан» балетын, яки татар композиторы Н. Җиһановның «Җәлил» операсын искә төшерү дә җитә» («Правда» газетасы, 1962 елның 16 январь саны).

Музыка сәнгатебезгә керткән өлешен һәм шәхес буларак йөзен тагын да тулырак күз алдына китерү өчен, Н. Җиһановның күпкырлы иҗат белән чикләнеп калмыйча, партия, дәүләт эшләрендә актив катнашуын, зур иҗтимагый-педагогик эшчәнлек алып баруын да әйтергә кирәк.

Республикабызда композиторлар оешмасы төзүчеләрнең берсе буларак, Н. Җиһанов кырык елга якын ТАССР Композиторлар союзы эшен җитәкләде. 1962 елдан бирле СССР Композиторлар Союзы идарәсенең Секретаре булып тора. Казан дәүләт консерваториясенә нигез салышкан Н. Җиһанов—бүген дә аның алыштыргысыз ректоры. Ул халыкның лаеклы вәкиле сыйфатында ТАССР, РСФСР һәм СССР Верховный Советларының төрле чакырылышлары эшендә катнашып килде. Н. Җиһанов — озак еллардан бирле КПССның Татарстан өлкә комитеты члены. СССР Министрлар Советы каршындагы Ленин һәм Дәүләт премияләре комитеты члены, шулай ук республикабызның Тынычлыкны яклау комитеты һәм Г. Тукай исемендәге ТАССР Дәүләт премияләре комитеты члены буларак, ул җаваплы һәм мактаулы эш алып бара.

Күпмилләтле совет музыкаль культурасын үстерүгә багышланган ярты гасырлык уңышлы иҗади һәм иҗтимагый эшчәнлеге өчен Н. Җиһанов дәүләтебез бүләкләренә, халык ихтирамына лаек булды.

СССРның халык артисты, СССР Дәүләт премияләре һәм Г. Тукай исемендәге ТАССР Дәүләт премиясе лауреаты профессор Нәҗип Гаяз улы Җиһанов үзенә җитмеш яшь тулу көннәрен зур хезмәт уңышлары яулап, яңа уй-ниятләр белән рухланып каршылый. Димәк, аның иҗатына багышланган мәкаләбезнең исеменә үк «юл» сүзе керү һич тә очраклы түгел. Иҗат кешесе һәрвакыт юлда. Нәҗип Җиһановның олы юлы киләчәктә дә сәнгатебез хакына яңа мөһим иҗади казанышлар белән бизәлер дип ышанабыз.

**ЯКОВ ГИРШМАН.**

**Харис Якупов,**
СССРның халык художнигы

# «ЗУР ИДЕЛ» КИҢЛЕКЛӘРЕ

Гүзәллеге белән җырларга күчкән киң Идел! Аның текә ярына килеп бассаң, дулкыннар шавы еракта калган тарихи вакыйгаларны искә төшерер. Идел язмышы халык язмышыннан аерылгысыз. Шатлыкларның да, кайгы-хәсрәтләрнең дә шаһиты булган ул киң Идел.

Әнә, каекларда — Разин сугышчылары...

Әнә, агымга каршы баржалар өстерәп баручы бурлакларның үзәк өзгеч моңлы җыры ишетелә. Идел авыр сулап куя...

Әнә, елга ярында яшь Ульянов басып тора. Гаделлекнең булачак бөек юлбашчысы күңелне тетрәткеч җырларга колак сала да киләчәк турында тирән уйга чума...

Әнә, туп тавышлары яңгырый — Идел өстендә революция байрагы җилферди.

Хәзер инде дулкыннарда башка җырлар тирбәлә:

**Идел ага, Идел ага,**
**Идел ага яктыга...**

Бу — татар җыры. Әлеге җырда халыкның күркәм тормышы чагылыш тапкан. Заманалар алышыну белән җырларның да моңы, эчтәлеге үзгәрде. «Идел ага яктыга!» — ди бит халык. Чынлап та, Идел буе шәһәрләренә күз ташласаң, гаҗәпкә калырлык. Ап-ак йортлар, тук башаклы иген басулары, шат-көләч йөзле кешеләр...

Идел! Теплоходта барганда, каршыда сокландыргыч күренеш ачыла. Элек мул булып аккан елга, еллар узган саен, ярларын калдырып, кечерәя башлаган иде. Бүген карагыз сез аңа: иксез-чиксез диңгез балкып ята. Әйе, Идел киңәйде, Идел зурайды. Анда йөзүче пароходлар, теплоходлар, тиз йөрешле лайнерлар да диңгездәге куәтле судноларны хәтерләтә.

Без, рәссамнар, зона күргәзмәсен юкка гына «Зур Идел» дип атамадык. Иҗатыбызның бөек елга — Россиянең «үзәк урамы» кебек зур булуын, тирән булуын телибез, дип аңларга кирәк моны.

Үзәк урам шәһәрнең тулаем йөзен билгеләп торса, «Зур Идел» тамашачыларга күпсанлы һәм күптөрле рәссамнарның иҗади мөмкинлекләрен күрсәтергә булышты.

Күргәзмә 1980 елның март аенда Татарстанның башкаласы Казан шәһәрендә ачылган иде.

Урамда — яз. Агачларның бөреләре тулышып килгән чак. Март кояшының ягымлы нурлары бакчаларны, тәрәзәләрдән караган гөлләрне иркәли. Әле кайчан гына Комлев һәм К. Маркс урамнары кисешкән чатны койма белән әйләндереп алганнар иде. Койма эчендә исә галәмәт зур жирафны хәтерләткән төзелеш краны чайкала иде. Хәзер бу урында үзенчәлекле архитектура композициясе — тар һәм биек тәрәзәләр уелган бина калкып чыкты. Идел буенда яшәүче һәм иҗат итүче рәссамнарның зона күргәзмәсен үткәрү өчен махсус җиткерелде ул. Тротуарда һәм бинаның алгы өлешендә зәңгәр буяу белән «Зур Идел» дип язылган белдерүләр тора. Янәшәдә генә кызыл әләмнәр тирбәлә. Күргәзмә ишеге янында бакырдан коелган хатын-кыз сыны — «Идел» исемле символик композиция (Волгоград сынчысы Р. Харитонов эше). Кулларын кояшка сузган «Идел» дулкыннары өстендә әкияттәгедәй гүзәл туган ягыбыз байлыгы — икмәк, балык, нефть... Әйтерсең лә, урамдагы халыкны күргәзмәгә чакыра «Идел».

Казанда уздырылган «Зур Идел» күргәзмәсе сан ягыннан бишенчесе. Әлеге күргәзмәләр 1964 елны — Куйбышев шәһәрендә, 1967 елны — Волгоградта, 1970 елны — Ульяновскида, 1974 елны Горький шәһәрләрендә үткәрелгән иде.

Арттырып әйтү түгел: Казанда ачылган «Зур Идел» күргәзмәсе алдагыларыннан күп өлеш әйбәтрәк оештырылды һәм анда куелган әсәрләр идея-художество дәрәҗәсе белән дә, тематик төрлелеге ягыннан да сынлы сәнгать дөньясына яңалык өстәделәр.



*Васил Маликов. Муса Җәлил*

Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр кайбер халыкларның милли сынлы сәнгатьләренә нигез дә салынмаган иде әле. «Зур Идел» күргәзмәләре әлеге халыкларның культура казанышлары белән якыннанрак танышырга мөмкинлек ачты. Татарстан, Чувашстан, Удмуртия, Мари АССР рәссамнары бәйрәмне бигрәк тә зур уңышлар белән каршыладылар.

Казандагы «Зур Идел» ике күргәзмә арасындагы башкарылган эшләргә йомгак ясау рәвешендә уздырылды. Хезмәттә совет халкы яулаган җиңүләрнең аерылгысыз бер өлеше ул рәссамнар иҗаты. Бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 110 ел тулу бәйрәмен бөтен ил хезмәт күтәренкелеге белән билгеләп үтәргә җыенган бер

чорда, әлбәттә, рәссамнар зур җаваплылык тоеп эшләделәр. Һәм аларның ленинианага мөрәҗәгать итүләре дә бик табигый. Чөнки бүгенге матур тормышыбызның мәңге саекмас чыганагы революция даһие исеме белән бәйле. Рәссамнарның игътибар үзәгендә — юлбашчының революционер буларак формалашуы. В. И. Ленинның балачак һәм яшьлек эзләрен Идел буе кадерләп саклый. Ул менә нәкъ биредә — Идел буенда беренче революцион чыныгу алган, гади эшчеләр һәм крестьяннар белән аралашкан, марксистик әдәбият белән танышкан, гади халыкның — хезмәт ияләренең нинди уй-хыяллар белән яшәвен тоемлаган.

Б. Худяковның «Туганнар» дип исемләнгән картинасы юлбашчының үсмерчагы темасына багышланган. Рәссам, традицияләргә хилафлык китермичә, Александр һәм Владимир Ульяновларның күңелгә уелып калырдай портретларын эшләгән.

Ленинианага үземнең иҗат дәверемдә мин дә берничә мәртәбә мөрәҗәгать иттем. «Зур ‹Идел» күргәзмәсе ачылуга, «Казан студентлары. 1887 нче ел» диган зур полотноны картина тәмамладым. Әлеге әсәр Володя Ульянов катнашуында Казан университетында булган сходканы хәтердә яңарта. Бу картинада мин тамырларында «Пугачев» каны уйнаган яшьләрнең рухи дөньясын чагылдырырга тырыштым. Анда сходканың кульминацион ноктасы — студентларның университет ректорына петиция тапшырулары сурәтләнгән. Петициягә исә болай дип язылган: «Җәмгыятебезнең, шул исәптән студент тормышының түзә алмаслык газаплы шартлары — безне монда җыелырга мәҗбүр иткән сәбәпләрнең берсе...»

Студентлар сходкасында катнашу яшь Ульяновның революцион эшчәнлеге башлану чоры ул. Кулга алынган ике йөзгә якын студент арасында Володя Ульянов та була. Теманы дәвам итеп, рәссам Н. Смирнов үзенең полотносында В. Ульяновның сходкадан соң кулга алынуы һәм Кокушкинога сөргенгә озатылуы хакында сөйли.

Мәскәү янындагы басуларда сабан таккан беренче тракторга сынау үткәрәләр. «Беренче буразна» картинасы (Н. Овчинников) В. И. Ленинны нәкъ менә шушы мизгелдә тасвирлый. Яңа тракторның вак-төяк детальләре кызыксындырмый рәссамны. Иң мөһиме — Ильичны урап алган кешеләрнең тантаналы күз карашы, балаларның шатлыклы авазы. Җылы һәм ачык төсләр белән бирелгән аяз күк һәм көзге алтынсу табигать картинага тагын да бәйрәмчә рух өстәгән.

А. Обвинцев, Б. Скляру‹ һәм А. Сорокиннарның график әсәрләре безне Ульяновскидагы Ленинга бәйләнешле урыннарда сәяхәткә алып чыга. Скульпторлар П. Гусев һәм П. Малков эшләгән «В. И. Ленин» портреты, Е. Кисилеваның «Ленин безнең белән» триптих-плакаты һәм башка рәссамнарның В. И. Ленинга багышланган әсәрләре ленинииананы тагын да баеттылар, тулыландырдылар.

Күргәнебезчә, «Зур Идел»дә катнашучы рәссамнар бөек юлбашчының якты образын гәүдәләндереп, аның балачагыннан башлап тарихи шәхес буларак формалашуына кадәрге чорны җанлы картиналар аша тамашачыларга җиткерделәр.

Шулай ук Идел буендагы революция дулкыннары, халык бәхете һәм азатлыгы өчен көрәшкән батырлар һәм Бөек Ватан сугышының дәһшәтле сәхифәләре урын алган картиналар да тәрбияви яктан зур әһәмияткә ия. Мондый эчтәлектәге картиналар тамашачыларны үткән белән күзгә-күз очраштыра. Болар — дингезчеләребезнең ак интервенциягә каршы көрәшүе турындагы «Төньяк голгофасы» (А. Дягилев), Сембердә яшь совет дәүләте дошманнары белән каты сугышны сурәтләгән «Сембер, 1918 нче ел» (В. Мишов), гражданнар сугышында утны-суны кичкән каһарман яшьләр турындагы «Комсомол туе» (И. Хәликуллов), сәнгать кешеләре белән героик совет халкы бердәмлегенә дан җырлаган «Рәссам» (П. Павлов) һәм башка картиналар.

Күргәзмәнең әлеге бүлегенә шулай ук «Азык-төлек отряды Чувашстанда» (А. Симаков), «Гражданнар сугышы» (М. Бедный), «Революция ялкынында» (В. Слюшкин) кебек шанлы үткәнебезгә багышланган картиналар тулыландырып тора.


«Зур Идел» күргәзмәсе Бөек Җиңүнең 35 еллык бәйрәменә туры килде. В. Сафроновның «Блокада» һәм «Авыр ел» картиналарын карагач, күңелдә шундый хисләр туа: әйтерсең, еллар аша сузылган көчле прожектор нурлары Бөек Ватан сугышының дәһшәтле көннәрен яктырта. Кырыс еллар... «Авыр ел» картинасында сурәтләнгән вакыйгалар әрнүчә тәэсирле: сугышның беренче көннәре, чигенү... Әмма совет сугышчыларының рухы сынмаган. Аларның күзләрендә — өмет, җиңүгә ышаныч, дошман алдында тез чүкмичә, яңадан һөҗүмгә ташлану теләге. Әмма чигенергә кирәк. Солдатлар көнчыгышка таба хәрәкәт итәләр. Җилкәләрендә минометлар, пулеметлар, патрон тутырылган тартмалар, полкның кызыл байрагы. Носилкада һәлак булган ана ята. Бер читтә солдатлар кабер казыйлар. Янәшәдә бу хәлне аңламаган кечкенә генә бала әнисенең күкрәгенә ташланган. Ятим калган баланы шәфкать туташы үзенекә иткән.

Шактый тирән мәгънә салынган картинаның эчтәлегенә. У‹, әйтер‹ ң лә, тамашачыга эндәшә: «Менә шундый мәрхәмәтсез, миһербансыз ул сугыш!» һәм миллионнарның бердәм авазы яңгырагандай була: «Безгә сугыш кирәкми!..»

«Кайту» (В. Шемерикин) исемле картинаның эчтәлеге дә Ватан сугышы ‹ ‹рларына карый. Солдатлар азат ителгән авылга керәләр. Туып-үскән якларга шатлык, матур хыяллар, мәхәббәт әйләнеп кайта. Алгы планга рәссам бәләкәй генә малайны

урнаштырган. Ул горур атлый һәм гүя солдатларга рәхмәт әйтә: «Сезнең батырлыкны беркайчан да онытмабыз, абыйлар!»

И. Корнев полотносы исә Бөек Ватан сугышындагы дәһшәтне безнең көннәр аша сурәтли. Үзәктә — сугыш каһарманнары истәлегенә салынган һәйкәлне ачу күренеше. Митингка сугыш ветераннары, авыл хезмәтчәннәре җыелган. Рәссам сугыш ветераннарының эчке дөньясын тышкы кыяфәтләре аша ачарга омтыла.




*И. Л. Язынин. «Кабул ит, Ватан».*

Р. Барановның «Һәлак булганнар истәлеге», В. Литвиковның «Комбат», А. Прокопенконың «Бурыч», А. Храмовның «Минск шоссесында», И. Рәфиковның «Җәлилчеләр», Г. Репинның «Совинформбюро белдерүе», В. Кудельскинның «Советлар Союзы Герое Н. Якупов», сынчы В. Маликовның «Соңгысы» дигән скульптура композициясе һәм Муса Җәлил портретлары да, сугышка багышланган башка әсәрләре дә совет сынлы сәнгатенә яңалык булып өстәлделәр.

Тарихи темаларны үз эченә алган картиналар белән беррәттән «Зур Идел»гә заманыбызның тыныч төзелешләренә, совет халкының хезмәттәге батырлыгына багышланган әсәрләр дә куелган. Мәсәлән, берничә картинада Кама автогигантындагы хезмәт тантанасын күрергә мөмкин. Бу җәһәттән рәссамнарның да иҗат коллективында алып барылган бик мөһим эш турында әйтеп үтәсе килә. Яр Чаллыга иҗади командировкага барып кайтмаган рәссамны очратуы кыен хәзер безнең коллективта. Кама буйларында автозавод салыну хәбәрен ишетүгә, эшчеләр белән бергә рәссамнар да килде. Чаллыга беренче мәртәбә баруым әле дә хәтердә. Алдыбызда тип-тигез кырлар җәелеп ята. Еракта, бик еракта — шәһәр һәм завод цехлары салынган тирәләрдә соры тузан болыты күтәрелә. Чылбырлы тракторлар, куәтле автомашиналар чокырлап бетергән юллар тәртипсез рәвештә төрле тарафларга сузылган. Булачак шәһәрне һәм автозавод тирәсендәге авылларга төзүчеләрне урнаштырдылар. Баштарак, хәтта кыш көннәрендә дә, кайберәүләр палаткаларда яшәделәр. Менә шундый авыр шартларга карамастан, төзелеш җитәкчеләре рәссамнарга төрле уңайлыклар тудырырга тырыштылар: тулай торaклардан урыннар бирделәр, соңрак остаханәләр табарга булыштылар. Хәзер инде КамАЗда рәссамнарның зур отряды эшли. Шунысын да әйтик, «Зур Идел» күргәзмәсендә Чаллыдан унбер рәссам катнашты. Әлбәттә, төрле республикалардан һәм өлкәләрдән җыелган 584 рәссам арасында бу зур сан.

В. Скобеевның «КамАЗ металлурглары» һәм «Металл эретү цехыннан мастер Алексеенков портреты» картиналары тигез һәм төгәл детальләр кулланып эшләнүе белән аерылып тора. «Студентлар бригадасы»нда исә автор якты, ачык зәңгәр төс аша яшьләрдәге хезмәт романтикасын сурәтли. Ф. Якуповның «Кызлар (КамАЗ)» полотносында яшьлек сылулыгы, яшьлек дәрте самимилеге белән игътибарны үзенә җәлеп итә. Монтажчы Мәҗит Ибәтуллин портрет-композициясе дә ( Е. Симбирин картинасы) төзелеш панорамасының киңлеген, зурлыгын тасвирлый. Яшь монтажчының ышанычлы, горур карашы төзелешнең колачлылыгын тагын да арттыра төшкән. В. Завацкийның төзелеш пейзажлары эшчеләр көч-куәтенең тиңсезлеген раслый.

Әлеге темага минем дә, «Чаллы сылулары» дигән картинам куелган иде. Андагы егетләр һәм кызлар — Чаллының «беренче карлыгачлары». Нәкъ менә алар — зәңгәр күккә ашкан ак шәһәрне иҗат итүчеләр, төзелешне башлап җибәрүчеләр.

И. Язынинның камазлылар турында «Кабул ит, Ватан!», «Үз йолдызыңны кабыз!», «Дан — беренчеләргә!» исемле плакатлар сериясе композицион яктан кыска, әммә эчтәлекле поэмалар тәэсирен калдыра. Л. Владыкинның «КамАЗ» дип исемләнгән офортлар (цинкны яки бакырны кислота белән яндырып эшләнгән гравюралар) сериясе дә яңа форма эзләүнең матур бер үрнәге булып тора.

Соңгы елларда рәссамнарыбыз үз геройларының тормышына бәрмә-бер якынайдылар. Кайбер әсәрләр турыдан-туры төзелеш мәйданнарында, колхоз һәм совхозларда иҗат ителә. Замандашларыбызны нәкыш сәнгатендә тулы канлы итеп чагылдыру традициягә әверелде. Моның өчен исә тормышны тирәнтен өйрәнергә, аның төрле катламнарына үтеп керә белергә кирәк. Нәкъ менә шушы омтылыш иҗади эшчәнлекнең яңа формаларын эзләүгә китерде дә инде. Шуларның бер төре — рәссамнарның иҗат группаларын халык хуҗалыгы объектларына беркетү.

Идел буенда әлеге группалар 70 нче елларда оештырылды. Россия Федерациясендәге 42 иҗат бригадасының сигезе безнең зонага — Идел буена карый. Горькийда — «Кызыл Сормово», Казанда — «Авыл», «Нефть», «КамАЗ», Чабаксарда, Ижевскида һәм Ульяновскида — «Авыл», Саратовта «Химия» бригадалары уңышлы эшләп килә.



*Фәрит Якупов. Кызыл туй*

Татарстан авылларында иҗат итүче рәссамнар да нәкыш сәнгатендә яңалык булырдай әсәрләр бирделәр. В. Кудельнин Куйбышев районындагы «Никольский» совхозының берничә алдынгы савымчысы портретын күргәзмәгә куйган иде. Кыр чәчәкләреннән үрелгән такыя кебек, әлеге портретлар күңелне иркәли, җанга сафлык бирә. А. Радионовның «Ат караучылар» дип исемләнгән картинасы шулай ук Куйбышев районы терлекчеләре тормышын чагылдыра.

Н. Карачарсков та «Авыл» группасында нәтиҗәле эшләп килә. «Балта осталары бригадиры Алексей Федорович» дигән картинаны ул чуваш авылында иҗат иткән. «Фермада» һәм «Бозау караучы Щербакова портреты» исемле картиналар (А. Моторин) — Ульяновск өлкәсендәге авылларда яшәүче гади һәм намуслы эшчеләр турында чын хикәят. А. Моторинның якташы И. Лежнин күргәзмәгә шулай ук берничә

картина тәкъдим итте. «Яңгырдан соң», «Сигналчы Саша Слепов», «Язга таба», «Барысы да кырда» кебек нәкыш әсәрләрен тамаша кылганнан соң, күңелдә хезмәт кешесенә ихтирам хисләре уяна.

Саратов рәссамнары да сәнгать бәйрәмен лаеклы каршыларга тырышканнар. А. Учаевның «Икмәк вакыты» дип исемләнгән картинасы музыкальлеге, шигърилеге белән игътибарны үзенә җәлеп итә. «Күңелле котүче», «Сөйләшү», «Тракторчы В. Черков» әсәрләреннән (Б. Давыдов) тамашачы күңеленә җылылык күчә.

«Зур Идел» күргәзмәсенең үзенчәлекле ягы тагын шунда ки, биредә яшь рәссамнар күпләп катнашты. Бу аларның беренче имтиханы иде. Һәм, әйтергә кирәк, яшьләр сынауны уңышлы уздылар.

«Фронтка озату» (И. Ефимов), «Җыр туганда» (Г. Вяльцев), «Иртәнге яңалыклар» (А. Денисов), «Борынгы Астрахань» (С. Дьяков) кебек картиналар турында озаклап сөйләшергә, фикер алышырга мөмкин булыр иде. С. Худяков, Б. Клевогин, Ю. Панцырев, Н. Николаев, П. Петров хезмәтләре дә нәкыш сәнгатенә яңа исемнәр өстәлү хакында хәбәр итә.

СССР Художество академиясенең Казандагы иҗат остаханәсендә эшләүче яшь рәссамнарны аеруча мактап телгә аласы килә:

О. Сильяковның «Совет власте өчен» исемле картинасы тамашачылар хәтерендә озак сакланыр дип уйлыйм. Үзенең эшләнеше — композициясе, фикерләр авазадашлыгы ягыннан ул В. Маяковскийның «Сул марш»ын искә төшерә.

Ш. Шәйдуллинның «Ипи турында баллада»сы тетрәткеч вакыйгага — Идел буендагы ачлык ел темасына корылган. Шуңа күрә дә бу әсәр янынннан тамашачы тыныч кына узып китә алмый. «Сабантуй» исә, киресенчә, бәйрәмчә рух бирә. Язгы эшләрдән соң халык табигатьнең иң матур җиренә җыелган. Композициянең уртасына баскан курайчы малай төркем-төркем булып тирә-якка сибелгән кешеләрне бер ноктага — курай моңына берләштереп тора. Теманың дәвамы — С. Слесарскийның «Игенчеләр» дигән картинасында. Рәссам игенченең авыр, әмма мактаулы хезмәтеннән җырлый.

З. Гыймаевның «Әбигә хат килде» дигән картинасы да авыл тормышына багышланган. Әбигә еракта яшәүче улыннанмы, кызыннанмы хат килгән. Аны хәзер кечкенә оныгы укып бирергә тиеш. Ирексездән, әбигә кушылып, син дә куанасың. Ни әйтсәң дә, күптән көтелгән хат ич.

Ф. Якуповның «Кызыл туй» әсәре халкыбызның күркәм йолаларыннан берсе — туй үткәрү турында сөйли. Яшьләр никахлашудан соң өйгә кайтканнар. Күрше-тирәдәге яше-карты аларны каршыларга чыккан. Кияү белән кәләшнең күз карашыннан яңа гаилә, ныклы гаилә оешуны белергә мөмкин...

Сәнгать белән очрашу һәрвакыт тантаналы бәйрәм ул: иҗат итүчеләр өчен дә, әсәрләрнең сәнгатьлелек дәрәҗәсенә бәя бирүче тамашачылар өчен дә. Аннары шунысын да онытмаска кирәк: сәнгать хәзер рухи ихтыяҗга әверелде. Ә халыкның рухи ихтыяҗын канәгатьләндерерлек әсәрләр иҗат итү — сәнгатькәрләрнең изге бурычы. Болар исә иҗатчыдан тормыш дөреслегенә, гуманизм һәм гражданлык идеяләренә турылыклы булуны сорый.

«Зур Идел» күргәзмәсенә куелган әсәрләр рәссамнарыбызның әнә шундый зур җаваплылык тоеп иҗат итүләрен раслады.

# ВАСИЛИЙ ЮДИНГА 70 ЯШЬ



Центриздат тарафыннан чыгарыла торган «Чувашский крестьянин» газетасында беренче шигыре басылып чыкканда Василий Юдинга унбиш яшь тә тулмаган була. Ә унтугыз яшендә инде ул Казанда чыга торган «Утам» («Адым») дигән альманахта шигырьләр бәйләме белән катнаша.

1932 елның гыйнварында В. Юдин Мәскәүдә чуваш телендә чыгарыла торган «Коммунар» газетасына чакырыла. Яшь язучы монда җиң сызганып эшкә тотына. Бу газетада эшләгәндә В. Юдин җитмешләп очерк һәм фельетоннар яза. Яшь язучының әлеге публицистик чыгышлары проблема күтәрүләре, тема яңалыгы, тел образлылыгы белән аерылып торалар.

Василий Николаевич Чувашгосиздатта матур әдәбият секторы редакторы, аннары Татарстан радиокомитетында чувашча тапшырулар редакторы, «Советская Белоруссия» газетасының үз хәбәрчесе булып эшли. Ләкин аның иҗаты чәчәк аткан чор Казанда чыгып килгән чуваш газетасы «Херле ялав» (соңыннан «Ленин ялаве») редакциясендә эшләгән елларга туры килә. Бу газета 1936—1963 елларда чыгарылды. В. Юдин анда җаваплы секретарь һәм редактор урынбасары булып эшләде. Шул елларда ул редакция каршында яшь чуваш язучыларының әдәби түгәрәген оештырып җибәрә, аның утырышларына эшчеләр, журналистлар, студентлар йөри. Озакламый бу түгәрәк әдәби берләшмәгә әверелеп китә һәм 1958 елда шушы берләшмә нигезендә Татарстан Язучылар союзы каршында чуваш язучылар секциясе барлыкка килә. Секция җитәкчесе Василий Юдин шул елны Язучылар союзына член итеп алына.

Язучының беренче хикәяләрен, повестьларын, драмасын укыганда, күз алдына чуваш халкының авыр үткәне килеп баса. Түшәмен төтен караллып бетергән кара өй, черек стеналары менә-менә аварга тора. Шул өйдә нужадан йончыган чуваш хатыны җеп эрли, хуҗа үзе чабата үрә. Чуваш өендә бу бердәнбер аяк киеме. Чувашның җанын әрнеткән нәрсә бер кара өй генә түгел. Бәгырьне телгаләгән хәсрәтләр күп. Патша изә. Шуның өстенә төрле чирләр интектерә: тиф, трахома, чәчәк, туберкулез... Ачлык... Кырга чыкса — агач сука интектерә. Авылда тоташ наданлык. Патша ялчылары халыкка белем бирүдән курkалар.

Василий Юдинның беренче әсәрләрендә болар барысы да ярыйсы ук ачык чагылдырыла. Мәсәлән, «Улямпи» (чуваш кызы исеме) дигән радиодрамасында Юдин трахомадан бөтенләй сукырайган бер кыз образын сурәтли. Яңа власть — Совет власте килгач, врачлар аның күзләрен ачалар, ул бәхетен эштә таба. Улямпи

тырышып эшли, укырга-язарга өйрәнә. Ә моңарчы аның язмышы авыр иде бит: эшкә яраксыз хәлдә көннәр буе бакчада утырды, «көш тә көш» каргалар һәм тавыклар куып торды.

Язучының бу драмасы Татарстан һәм Чувашстан радиосы буенча күп еллар буе тапшырылды. Тыңлаучыларны Улямпиның язмышы әсәрләндерде, алар авторга һәм радиокомитетка туктаусыз хатлар язып тордылар, тапшыруны, кабатлауны үтенделәр.

Колхоз авылының беренче уңышлары турында язучы зур күтәренкелек белән иҗат итте. Күп кенә хикәяләр, очерклар язды, социалистик хезмәтнең беренче ударниклары — игенчеләр, агротехниклар, көтүчеләр, умартачыларның самими образларын тудырды.

«Үлемсез батырлык» дигән документаль повестьта язучы Советлар Союзы Герое С. В. Коноваловның тормыш һәм сугышчан юлын сурәтли. Бөек Ватан сугышы темасына язылган әсәрләреннән тагын «Утлы түй» хикәясен дә күрсәтергә кирәк. Анда Белоруссия партизаннарының сугышчан батырлыгы гәүдәләндерелә, хикәя татар теленә дә тәрҗемә ителгән.

Алтмышынчы елларда ул авыл кешеләрен яхшырак, белебрәк сурәтләргә иде дигән карарга килә, һәм авылга китә. Ярты ел буе Татарстанның Октябрь районындагы Камышла авылында булачак геройлары белән бергә эшли. Моның нәтиҗәсе сөенечле булды: 1972 елда Чувашстан китап нәшриятында Юдинның «Игелекле кешеләр» дигән очерклар китабы басылып чыкты. Бу китап сәхифәләренә язучы укучыга образлар аша да, публицистик фикер белән дә мөрәҗәгать итә. Очеркларда заман сулышы сизелеп тора. Аларда сурәтләнгән уңышлы образлардан колхоз председателе Алексей Харитоновны, авылның баш механизаторы Николай Евдокимовны, агроном, Социалистик Хезмәт Герое Леонтий Петровны, терлек каравучы Валерий Кульметьевны, чөгендер игү остасы Ольга Бойкованы, бакчачы карт Алякки бабайны, көтүче Ефимны, партком секретаре Иван Семеновны һәм башкаларны искә алырга кирәк.

«Докторлар» дигән повесте өстендә В. Юдин озак эшләде. Әсәр совет медицинасының казанышларын сурәтләүгә багышланган. Ул Чувашстан Язучылар союзы органы «Ялав» («Байрак») журналында басылып чыкты. Повестьның сюжеты шактый кискен вакыйгаларга корылган. Медицина фәнендә искелек белән яңалыкның бәрелешен язучы ышандырырлык итеп сурәтли алган. Әсәрдәге образлардан доцент Ахмер Шиһапов, врачлар Петр Андреевич һәм Серафима Акимовна Кургановлар, профессор Василий Васильевич Иоков һәм башкалар җанлы итеп гәүдәләндерелгәннәр, истә калалар.

Василий Юдин — талантлы тәрҗемәче дә. Илле еллык иҗат эшчәнлеге дәверендә ул чувашчага бик күп әсәрләр тәрҗемә итте. Алар арасында Г. Бәшировның «Намус»ы аеруча оста эшләнгән. Чуваш укучылары аның тәрҗемәсе аша Г. Гобәйнең «Маякчы кызы», Ш. Рәкыйповның «Чәчәкләр сөйли белә», Г. Бакирның «Минем укытучым» повестьлары, К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романыннан өзекләр, А. Шамов, Г. Әпсәләмов, Г. Минский, Ф. Хөсни, Л. Ихсанова, Х. Сарьян һәм башка татар язучыларының хикәяләре белән таныштылар. Тәрҗемә иткәндә, В. Юдин оригиналның шигърияттен, тел үзенчәлекләрен сакларга омтыла һәм аңа ирешә дә. Татар телен яхшы белә, шунлыктан татар язучыларын оригиналдан тәрҗемә итеп, чуваш телендә дә оригинал шикелле үк яңгырашка ирешә.

Василий Юдин — тынгысыз кеше. 1958 елдан бирле инде ул Татарстан Язучылар союзы каршындагы чуваш язучылары секциясенә җитәкчелек итә. Өлкән яшьтә булуына карамастан, яшь язучылар белән эшләүгә күп вакыт һәм көч бирә. Эшчәнлекнең нәтиҗәсе дә күз алдында. Чуваш язучылары секциясе эшли башлаганга инде егерме ел. Бу вакыт эчендә заманында секциядә катнашкан талантлы яшьләр зур әдәбият юлына чыктылар. Мәсәлән, Анатолий Емельянов хәзер Чувашстан Язучылар союзы идарәсе председателе, Порфирий Афанасьев пионер журналының редакторы, Валем Ахун Чувашкнигоиздатның өлкән редакторы, Михаил Сениэль һәм Юрий Айдаш танылган шагыйрьләр.

Хәзерге вакытта чуваш язучылары секциясе 17 кешене берләштерә. Секция членнарының әсәрләре тупланган альманах чыгарыла. «Хусан» («Казан»)ның ике саны дөньяга чыкты инде. Өченчесе нәшриятка тапшырылган.

Чуваш секциясенең бюро председателе В. Юдин чуваш мәктәпләрендәге һәм кайбер район газеталары редакцияләре каршындагы әдәби түгәрәкләр белән тыгыз элемтәдә тора.

Василий Николаевич Юдин 1911 елның 16 нчы гыйнварында хәзерге Татарстан АССРның Тәтеш районы Большое Бисярино авылында ярлы крестьян семьясында туа. Яшьли ятим калып, балалар йортларында тәрбияләнә. Уnике яшеннән инде малай үз язмышына үзе хуҗа булып кала. Җәй айларында көтү көтә, ә кыш көннәрендә кулакларда батрак булып йөри. Кечкенәдән эшчеләр белән аралашканга, күрәсең, Василий Юдинның күңелендә, йөрәгендә пролетар рух яши. «Үз кулмәгем үземә якынрак» дигән нәрсәне танымый, инкарь итә ул. Бөтен җаны-тәне белән кешеләргә, алар белән дуслыкка омтыла язучы. Ул кешеләрне ярата, татар халкын ихтирам итә.

...Минем аның өендә, кунакта булганым бар. Гаҗәп кунакчыл кеше Василий Николаевич. Күе итеп ясалган тәмле, хуш исле чәй белән сыйлый. Карчыгы Вера Михайловна табынга төрле-төрле вареньелар, гөмбәләр, балык ашлары тезә. «Барысы да үзебез әзерләгән ризыклар, җитешегез!» дия-дия сыйлый ул. Шунда беләсең инде: Василий Николаевич оста балыкчы да, гөмбә җыярга хирыс кеше дә икән. Вера Михайловна белән алар ике кыз үстерделәр.

— Өч тапкыр бабай инде мин! — ди Василий Николаевич, шаяртып.— Өч оныгым тәгәрәп үсеп килә.

Чувашларда борынгыдан килгән бер ышану бар: әгәр ялтырап торган бизәкле салават күпереннән узса, чал чәчле карт яшәрер, ул яшь кешегә табигатьнең бөтен серләре ачылыр, аның бөтен-бөтен хыяллары эшкә ашар, имеш. Миңа калса, безнең Вася бабай нәкъ менә шул салават күпереннән үткән кешедер кебек. Ул үзен һаман яшьләрчә хис итә. Аңа табигатьнең төрле серләре ачыла... Ләкин, тукта! Аның бөтен-бөтен хыяллары эшкә ашып җиткәне юк әлегә. Үзе әйтмешли, ният иткәннең яртысын гына үти алган әле ул. Хәзер Василий Юдин автобиографик повесть (ә бәлки роман ук булып чыгар?!) яза. Анда исәпсез-хисапсыз вакыйгалар, күренешләр, детальләр!..

Шкафларда, өстәлдә, тәрәзә төпләрендә — һәркайда кулъязмалар. Төннәр буе, йокыны-ялны онытып эшли безнең юбиляр. Озын гомер, сәламәтлек, дәрт, яңа иҗат уңышлары телик.

**КОНСТАНТИН ПЕТРОВ.**

# НИЛ ЮЗИЕВКА 50 ЯШЬ



Нил Юзиевка илле яшь... Бу хәбәргә ышанулы кыен. Чачләре дә табигый төсен җуймаган, шаянлыгын да куймаган — хуҗасына бер шөгыль табып, гел як-якка сибелеп тора. Маңгаендагы сырлары да, илле һәм җиңел хәрәкәте дә «иллегә каршы» дәлилләр. Олы титуллары йөзенә тәкәбберлек, өстенлек буяулары төшермәгән, күзләрендә туган ягы Башкортстан табигатенең ягымлы нуры сакланган. Күрәсең, чын иҗат шәхесенең, тормышы бөтен барлыгы белән халыкка хезмәткә багышланган шәхесләрнең биология законнары белән көрәшерлек кодрәте, «серле даруы» бардыр. Иллене алыштырган Г. Ахунов, Ә. Баянов, А. Гыйләҗев, Ш. Галиевләр бик яшь күренә, теләсә нинди буаны тишеп чыгарга әзер терекөмешләр шикелле, тормышка һәм иҗатка ашкынып торалар, катлаулы чынбарлыкның кеше рухының яңадан-яңа катламнарын актарып чыгаралар.

Филология фәннәре докторы, тәнкыйтьче, әдәбият галиме, сектор мөдире, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, СССР Язучылар Союзы әгъзасы — Нил Юзиев та шул сафка басты. Исәп-хисап тотарга иртә әле. Шуңа күрә биографиясен, тормыш юлын сөйләүне киләчәк юбилейларга калдырып, әдипнең иҗат юлына бер генә караш ташлыйсы килә. Бусы да кыен эш. Аның хезмәтләрен колач белән дә, күз белән дә, фикер белән дә иңләве кыен.

Ул татар әдәбият фәненә Тукай премиясен алып биргән «Шигырь гармониясе» (1972), «Хәзерге татар поэтикасы» (1973) исемле тирән фәнни хезмәтләр авторы. Тәнкыйтьче аларга юлны башка китаплары («Муса Җәлил поэмалары», 1960; «Тормыш поэзиясе», 1961; «Традицияләр яңарганда», 1966; «Сәнгатьчә матурлык һәм осталык», 1969; «Сугыштан соңгы татар поэзиясе», 1971), дәреслекләре, дистәләгән мәкаләләре, төрле конференцияләрдә ясаган чыгышлары белән ярып бара. Каләме елдан-ел үткенләнә, камилләнә, үз колоритын таба килә.

Нил Юзиевның татар тәнкыйтенә, әдәбият белеменә алып килгән яңалыгы нидән гыйбарәт? Иҗатының китаптан-китапка күчеп килгән төп хасияте нәрсәдә? Шул сораулар турында уйланып, авторның кылган эшләрен янәдән күздән кичереп утырганда, ни өчендер һ. Такташның мәгълүм юллары келт итеп искә төште: «Шигырьдә үгет-нәсихәт, сафсата бетәргә тиешле... Шигырьдә матур сүзләр уйнатудан мәгънәгә күчү дәвере килде...»

Минемчә, «Иҗадиятем турында» исемле декларация язса, Н. Юзиев Такташның бу сүзләрен хәзерге тәнкыйтькә, әдәбият белеменә нисбәтән кабатлый алыр иде. Беренче адымнарыннан ук ул эчтәлек сөйләү, мәгънә белән форманы аерым-аерым бәяләү, акыл сату, дидактика кебек тәнкыйтьнең традицион кимчелекләренә каршы чыга. Шигырьнең көчен, матурлыгын, аһәңен, эчке музыкасын ачуның яңа юлларын эзли.

Н. Юзиев әдәби хәзинәне тормыш белән янәшә куеп, чагыштырып тикшерә, язучының иҗат лабораториясенә үтеп керү юлларын киңәйтә, тирәнәйтә (анкета алымыннан киң файдалана, хат аша сораулар белән мөрәҗәгать итә һ. б.). Ул тәнкыйть белән әдәбият гыйлемен органик кушып китә алды, ачык фәнни стиль тудыруга зур өлеш кертте.

Татар поэтикасын өйрәнүне фәнни нигезгә салуда, мөстәкыйль үсеш кануннарын раслауда Н. Юзиевның роле гаять зур. Гасыр башы поэзиясе, татар совет әдәбиятының башлангыч чорлары турында язса да, аны бәрәү дә тарихка, фәнгә кереп батуда, салкын академик стильне алга сөрүдә гаепли алмас. Чөнки галим поэзиянең тарихи үсешенә бүгенге теоретик фикер югарылыгыннан килә, аның актуаль проблемаларын хәзерге әдәби процесс белән бәйләп тикшерә.

Н. Юзиев үзен билгеле бер чор поэзиясе, аерым язучы иҗаты яисә билгеле бер жанрны өйрәнү белән генә чикләми. Тәнкыйтьчене шигъри нәфислеккә ирешү юллары, әдәбият белән сәнгатьнең башка төрләре арасындагы якынлык, иҗат психологиясе, поэтик индивидуальлек мәсьәләләре, кыскасы, әдәбиятның өйрәнү өчен иң катлаулы һәм четерекле эчке хасияте кызыксындыра. Ул сүз сәнгатен философия, тарих, экономика шикелле фәннәр, музыка, кино, театр, сынлы сәнгать белән тыгыз бәйләнештә өйрәнә. Сәнгатьнең башка төрләре белән аралашу, керешү әдәбиятка зарар китерми, аның үзенчәлеген, «автономлылыгын» юкка чыгармый, мондый «дуслык» художникның фантазиясенә канат бирә, яңа фикерләр, хисләр, ассоциацияләр уята. Әдәбиятны сәнгатьнең якын кардәше буларак өйрәнү — язучының иҗат лабораториясенә күз ташларга, аның эрудициясен, интеллектын, зәвыгын тулырак ачарга мөмкинлек бирә.

Тәнкыйтьче сүзне әдәбиятның башка сәнгать төрләре ачкан эстетик кыйммәтләрне үзләштерүе, алардан ямь алуы турында гына алып барса, аңгәмә берьяклырак булыр иде. Сурәтле фикерләүнең иң борынгы төрләреннән берсе буларак, әдәбият та үз байлыгы белән уртаклашуда саранлык күрсәтми, сәнгатьнең башка төрләренә, яңа тармакларына ярдәм кулын суза килә.

Хезмәтләренең күбесен Н. Юзиев Фәннәр Академиясенең имән ишекләре артына яшеренеп, тыныч, ярау бүлмәләрдә язмый, Казан университетының студентлары, аспирантлары, юнәлеш эзләп, киңәш-табыш сорап килгән яшь шагыйрьләр, тәнкыйть-

челәр белән эшләү чорында йокы һәм ялга тиешле вакыт аралыгында иҗат итә. Педагог булуы эрудициясенең тирәнәюенә (ул еш кына милли чикләрне кисеп, дөнья әдәбияты тәҗрибәсенә, дәһи акыл ияләре мирасына таяна), үзәккә алынган проблеманың нигез тамырына төшә алуына ярдәм иткәндер. Әлбәттә, төп рольне аның әдәбиятка тугрылыклы булуы уйный.

Н. Юзиевның иҗат диапазоны киң. М. Җәлилнең архивын, эпик мирасын өйрәнүгә беренчеләрдән тотына, Ә. Фәйзинең әдәби-тәнкыйть әсәрләрен, хатларын туплап, фәнни комментарияләп, сүз башы язып чыгара. Проза турында уйлануларында да рациональ орлык бар. Әмма стихиясе — поэзия.

Аны шигырьнең эчке закончалыклары һәм поэманың үсеш юллары, фикерләү поэзиясе традицияләре һәм романтик тенденцияләрнең тернәкләшүе, бердәм социалистик реализм рамкасындагы стильләр төрлелеге үзенә җәлеп итә. Үткәннең гүзәл казанышлары белән бүгенге кыю ачышлар арасындагы диалектик якынлыкны, традиция белән новаторлыкның эчтәлеген, мәйданын ачу һәрвакытта тәнкыйтьченең игътибар үзәгендә. Зур теоретик һәм практик әһәмияткә ия булган әлеге проблемаларны ул коры фикер йөртү һәм логик конструкцияләр ярдәмендә хәл итми. Тәнкыйтьче тирән эстетик анализ белән киң гомумиләштерүне, аерым язучы иҗаты турында фикер белән бөтен поэзиягә хас даими закончалыклар турында уйлауларын бергә үреп бара белә. Төрле чор һәм төрле буын шагыйрьләре иҗаты турында сүз йөрткәндә дә, һәркайсының үзенә генә хас иҗат үзенчәлекләрен, индивидуальлекләрен ачып салырга омтыла. Бер үк иҗтимагый-тарихи шартларда яшәгән, уртак иҗат методына таянып эш иткән заманда шагыйрьләрнең кабатланмас шигъри үзенчәлеген күзаллау җиңел эш түгел. Бу юлда Н. Юзиев зур уңышка ирешә, берничә җөмлә аша шагыйрьнең фикерләү үзенчәлеген күз алдына бастыра белә. Мәсәлән, С. Хәким поэзиясенең төп үзенчәлеген ул тормышка якынлыкта, табигыйлектә, лиризмда күрә: «С. Хәким шигырьләрендә татар халкының хәзерге рухи дөньясын, аның көнкүрешен, кешеләрен бөтен табигыйлегендә күрәсең». «Х. Туфанда шагыйрь характеры, шагыйрь акылы башка төрлерәк алымнарда ачыла. Шагыйрьне без күп очракта кем беләндер, я нәрсә беләндер серләшкән, сөйләшкән, я бәхәсләшкән хәлдә очратабыз».

Тәнкыйтьче Ә. Фәйзи, Ш. Маннур, С. Баттал, Ә. Давыдов, З. Мансур, Ш. Галиев, Г. Афзал, И. Юзеев кебек шагыйрьләрнең иҗат дөньясына, сурәтле фикерләү үзенчәлекләренә алып керә, аларның һәркайсына хас шигъри «серләрен» ачып сала. Автор бервакытта да поэзиянең иң нечкә, иң катлаулы сәнгать икәнен онытмый һәм үз фикерләрен соңгы сүз дип тәкъдим итми. Ул укучыны поэзия турында бергәләп уйланырга, бәхәсләшергә чакыра, нәтиҗәне үзенә ясарга урын калдыра.

Н. Юзиев күбрәк татар поэзиясенең «йөзек кашлары» — халык рухына тирән үтеп кергән талантлар турында язса, алар тәҗрибәсен гомумиләштерсә дә, кайбер тәнкыйтьчеләр «һәм башкалар» рәтендә йөрткән шагыйрьләр иҗатын да читләтеп үтми, анда да яңа «шигъри материклар» таба, яңа гына каләмгә ябышкан яшьләр лирикасында шытып килгән аерым табышларны күреп ала, эзләнүләрен яклап һәм раслап чыга.

Тәнкыйтьче татар поэзиясен үсештәге җанлы организм буларак өйрәнә. Ул катлаулы чынбарлыкның төрле якларын үзәккә алган, төрле стиль агымнарына өстенлек биргән шагыйрьләр иҗаты арасында эчке якынлык, уртаклык таба. Менә шул концепция әдәбият галименә шигъри елгаларның, сукмакларның бергә кушылган урыннарын кыюрак күзәтергә, поэзиянең иң тирәндә, айсбергның күзгә күренми торган өлешендә яткан «су асты» агымнарына үтеп керергә, гомуми үсеш закончалыкларын ачарга мөмкинлек бирә.

Югарыда аталган хезмәтләрдә татар поэзиясенең үсеш юлы киң тарихи-иҗтимагый фонда өйрәнелә. Күп гасырларның акылын, хисен, зирәклеген үзенә сеңдерә ала килгән, әмма салкын җәйдә ачыла алмый калган чәчәк шикелле, бу байлыгын эчтә, тирәндә сакларга мәҗбүр булган татар поэзиясенең XX гасырда дөррәү атылып югарыга күтәрелүен Н. Юзиев иҗтимагый прогресс, халык аңы үсеше, революцион яңарыш белән аңлата. Эчтәлекнең яңачалыгы үзенә бәрабәр формалар таләп итә. «Шигырь гармониясе» дигән хезмәтендә, бигрәк тә «Аваз ярашуындагы яңа өл-

геләр», «Аһәңлелекнең бай чыганаклары», «Тотрыклылык һәм хәрәкәтчәнлек», «Канун юкка чыкмый, тик өлгеләр үзгәрә» кебек бүлекләрдә татар совет поэзиясенең яңачалыгы, эчтәлек белән форма арасындагы катлаулы мөнәсәбәт тирән һәм нечкә анализлана.

Зур шигъри ачышлар халыкчан рухлы, иҗтимагый проблемалар гражданлык хисләре белән тирән сугарылган әсәрләрдә ясала дигән идея тәнкыйтьченең бер китабыннан икенчесенә күчә, үстерелә, баетыла. Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи, Х. Туфан, С. Хәким иҗатларында җир шары һәм шәхес, тарих һәм шәхес дәвер һәм шәхес кебек олы темалар, масштаблы проблемалар сурәтле фикерләүдә яңадан-яңа үзгәрешләр тудыра. Татар совет поэзиясенең горурлыгы — Һ. Такташ хакында күп язылды. Аның поэзиясе турында, әлгәреңне кабатламыйча, яңа сүз әйтү кыен шикелле. Шагыйрьнең мирасын чагыштырмалы-типологик өйрәнү, анализлау методының төрлелеге, камиллеге Һ. Такташ поэзиясенең әллә ни чаклы яңа кыйблаларын ачарга мөмкинлек биргән. Романтик һәм реалистик тенденцияләрнең, лирик һәм иҗтимагый-публицистик агымнарның органик кушылуы нәтиҗәсендә бер-берсенә тартылып торган синтетик шигъри формалар барлыкка килүе, музыка һәм кино сәнгатьләренә якынлык, таныш кануннарның яңа сыйфатларын ачу һ. б. күзәтүләр Һ. Такташ турындагы мәгълүматыбызны баетты, тулыландырды.

Шигырь сәнгатен тикшерүнең яңа алымнарына киң таяну Роберт Әхмәтҗанов, Р. Фәйзуллин, Ш. Мәхмүтов, Р. Харис кебек шагыйрьләрнең метафорик, ассоциатив алымнарын татар поэзиясенең гомуми үсеш фонында ачу юлына алып чыккан.

Хәзерге татар поэзиясендә шартлы алымнарның роле үсү, зиһен ташкынын, интуитив сизенүне тулырак чагылдыруга омтылу, рух диалектикасын, шәхеснең интим кичерешләрен тулырак чагылдыру ихтыяҗы белән кушыла. «Поэзия кабат үзенең телескобын кеше йөрәгенә юнәлтте, кеше җанының шигырьдә моңарчы яктыртылмаган почмакларын, якларын күзәтә башлады», — ди тәнкыйтьче. Аның фикеренчә, поэзия кешенең салават күпередәй төрле төсле кичерешләр байлыгын — шатлыгын, моңын, дәртен, кайгысын, мәхәббәт ялкынын, сөю сагышын тулырак чагылдыра бара. «Романтик канатларның» ныгуын, эмоциональ-хисси башлангычның көчәюен хуплый, аны чорыбызга хас бер халәт дип бәяли. Шул ук вакытта тәнкыйтьче соңгы еллар поэзиясенә хас социалистик реализм методының бер канатын тәшкил иткән романтик стиль белән революция һәм гражданнар сугышы чоры поэтикасы арасында мөһим аерма яшәвен искәртә, аны ышандырырлык дәлилли. Хәзерге романтик стильгә куәт һәм илһам биргән чыганак — бүгенге чынбарлык, халыкның рухында туган яңарыш, шагыйрьнең дөньяга карашында туган үзгәрешләр.

Н. Юзиев үзенең фикерләрен раслау барышында схематик фикерләүгә, катлаулы иҗади процессны алдан әзерләп куелган калыпка көчләп кертүгә, шагыйрь иҗатын ак һәм кара төсләргә генә бүлеп өйрәнүгә каршы чыга. Ул И. Нуруллин, З. Мәҗитов, Х. Хәйри, Б. Гыйззәт, Ә. Исхак, Ф. Хәсни шикелле әдәбият белгечләре һәм язучылары белән күп очракта урынлы бәхәскә керә, үз фикерен көнләштерерлек дәрт, полемик ялкын белән исбатлый белә.

1978 елда Н. Юзиевның «Әдәбият хәзинәләре» исемле китабы басылды. Авторның игътибар үзәгендә методологияне камилләштерү, сәнгатьчә осталык закончалыкларын, сурәтле фикерләүнең эчке механизмын өйрәнүдә типологик, чагыштырмалы, системалы структур алымнарын акыллы эшкә җигү мәсьәләләре тора.

Тәнкыйтьче катлаулы, авыр терминнарны, теоретик төшенчәләрне халык теленә якын әйләнмәләр белән аңлатып бирә белә. Бу алымнар фәннилеккә һәм тирәнлеккә зарар китерми, киресенчә, сөйләмне җанландыра, ышандыру көчен арттыра. Аның җөмләләре төгәл, җыйнак, җиңел һәм сыйдырышлы.

Әйе, алтмышынчы-җитмешенче еллар тәнкыйтен, әдәбият белемен Н. Юзиев исеменнән башка күз алдына китереп булмый. Аның җитди таләпчән сүзе үтемле, үсеш юлы эзлекле, хисе, фикере заманча. Тәнкыйтьченең һәммә язганын идеаллаштыру, фәләннәр югарылыгына күтәреп кую турында сүз бармый. Н. Юзиев белән еш кына бәхәскә керәсе, концепциясен үз теленнән ачыклатасы килә. Оппонентының уен уята, зиһенен эшләтә белү үзе бер прогресс. Фикере бурычка алынган китап сүзеннән чыкмаган, соры тәнкыйть белән бәхәскә кереп булмый бит.

Алда — киң иҗат перспективасы. Татар совет поэзиясенең алты томлыгы, борынгы һәм хәзерге әдәбиятны комплекслы өйрәнү бурычлары. Н. Юзиев бу проблемаларның күбесен һәм җитәкче һәм галим буларак үз җилкәсенә ала. Татар әдәбиятының иң катлаулы күренешләрен, теоретик һәм гамәли мәсьәләләрен, буталчык төеннәрен тотып ала да, әдәбият белеме фәненең иң камил методологик принципларына таянып, тәнкыйтьче туктаусыз алга атлый, югарыга ашкына.

ТӘЛГАТЬ ГАЛИУЛЛИН.

# АДЛЕР ТИМЕРГАЛИНГА 50 ЯШЬ



Ә сез фәнни фантастика билгеләрендә үзегезне ничек хис итәсез? Анда кайбер проблемаларның, фикерләрнең авырлыгы югалу күренешен җиңел кичерәсезме? Йолдызлы күктә, алма бакчасындагы кебек, иркен сулап йөри аласызмы?.. Иҗатның тылсымлы кодрәте белән төргезелгән катлаулы һәм кабатланмас бу дөнья иң әүвәл эзләнүләр романтикасы, ачышлар ләззәте белән матур бит!

Дөресен әйткәндә, акыллы машиналар һәм ят тереклек ияләре белән Җир кешесе арасындагы мөнәсәбәтләр татар язучыларын соңгы елларга кадәр бик аз кызыксындырып килде. Әдәбиятның фәнни фикер үсеше белән бәйләнешле бу төре, нигездә, тәрҗемә әсәрләр исәбенә яшәде диярлек. Шуңа күрә Адлер Тимергалин иҗаты кул тимәгән темалары белән генә дә укучыны үзенә җәлеп итә алыр иде. Ләкин аның беренче әсәрләрен үк чын мәгънәсендә канатлы иткән сыйфат — тема үзенчәлеге генә түгел...

Әлбәттә, әлегә аз үзләштерелгән өлкәгә аяк басканда, язучы ике юл чатында кала. Беренче карашка, баш әйләнгеч фикер-фаразлар белдерү яки чит дөньялар галәмәтен сурәтләүдән дә яңарак, кызыклырак нәрсә юк кебек тоелырга мөмкин. Һәм фәнни фантастикада шул рәвешле генә язылган әсәрләр шактый. А. Тимергалин, бәхеткә каршы, өстә яткан катламны күтәрү белән мавыкмады. Шулай да укучыны үзең төзегән хыялый дөньяга ияләштерү җиңел түгел, хәзинәдә булганын күрсәтеп каласың килә, һәм шунлыктан урыны-урыны белән чама тойгысын җуюың да бар. Тикмәгәме уңышлы гына әсәрләрдә, икмәк эчендә өешып калган тоз кебек, хөры информация утраулары әледән-әле очрап куя! (Мәсәлән, «Ерак планетада» хикәясенең ахырына таба «Ялгызак» планетасы, андагы фантастик җәмгыять хакында турыдан-туры мәгълүмат б рү күбәеп китүен искә төшерик.) Сурәтләү урынына санап-сөйләп китә чыгу укучыда кызыксынуны сүрелдерә.

Күренешләрнең, мохитның үзгәлегенә, гайре табигый булуына әерым мәгънә салынганда — язучы мондый форсаттан файдаланырга тырыша — хосусый нечкәлекләр, «шереп»ләрдән башлап, күк җисемнәренә кадәр яңабаштан «ярату» (иҗат итү) таләп ителә. Бу очракта ике дилбегәнә — хыял очышы белән мәгънә үсешен тигез тоту тагын да кыенлаша. Чөнки, ахыр чиктә, космопланнар гына түгел, галәмдәге сәер күренешләр һәм тереклек ияләре дә, «космик телдә» әйткәндә, укучыны әдәби әсәрнең идея-художество орбитасына алып чыгуда катнашалар. Ул «орбитага» күтәрелә алганда, безгә, «Рәшад эффекты»ндагы кебек, үз-үзебезне читтән күрү мөмкинлеге ачыла: үткәнебезне, хәзергебезне, киләчәгебезне. А. Тимергалинның бер үзенчәлеге шунда: ул татар фәнни фантастикасының урын-вакыт кысаларын киңәйтте. Хәлбуки,

бу — мәсьәләнең тышкы ягы гына әле. Язучы әлеге «өч заман призмасы» ярдәмендә бүгенге чынбарлык алдында торган проблемалар һәм бурычларны бер ноктага туплый алды. Шушы җирлектән ераклашкан саен, «орбитадан ычкыну» куркынычы да зуррак,— әгъни әсәрләрнең сәнгатьчә ышандыру көче кимегәннән-кими бара. Кешеләр белән ят цивилизация вәкилләре очрашуын тасвирлаган хикәяләрне үзара чагыштырып караганда, шундый нәтиҗәгә киләсең.

Билгеле, дөньялар, заманнар багланышы үзәккә куйганда төп фәлсәфи каршылык адәм баласы һәм чит культура мөнәсәбәтләренә кайтып кала. Тик Җиргә килүчеләрнең «яшь мәдәниятләргә ярдәм кулы сузуы» асылда коры теләктән узмый, яисә баскынчылыкка әверелә. Галәм кунакларыннан калган тылсымлы аппаратларның да безнең геройларга әллә ни игелеге тими. Вакытның табигый агышын теләгәнчә үзгәртергә сәләтле «темпоратор», мәсәлән, тулаем уңышлы уйлап табылган («Сез мине үзегезнең вөҗданыгыз дип уйлый аласыз» — !), тик ул да үзен акламый... «Темпораторны башка дөнья вәкилләре Җирдәге талант ияләрен тормыш белән конфликтлардан саклау өчен калдырганнар икән («Кабул булсын теләгең» хикәясе). Ул нинди дер Рэй Олдриджга язмышын дүрт тапкыр яңадан башлау мөмкинлеге бирә. Аңлашылганча, вакыйга безнең көннәрдә, гаделсез җәмгыять шартларында бара һәм Рэйның дүрт тормышы да фаҗигале тәгәлләнә. Әмма котылгысыз фаҗиганең социаль җирлектәге тамырлары күренеп бетми, киресенчә, язмыш кешенең үзеннән генә тора дигән фикергә урын кала.

Җир улларын галәмгә чыгарып яңа тереклек ияләре белән очраштырганда исә А. Тимергалинның иҗади мөмкинлекләре тулырак ачыла төсле. Мондый багланышларның асылы үсештә күрсәтелә, реаль катлаулылыгы һәм каршылыклары белән күз алдына китерелә. Глорийлар (агачсыман тереклек ияләре) җәмгыяте белән бәйләнешкә керү мисалы гына да безне мөһим нәтиҗәгә алып килә: галәмдә дә, җирдә дә кешелекле мөнәсәбәтләрнең нигезе — башка культураның үсеш законнарын тирәнтен аңлау, аның белән психологик уртаклык табу («Космос әчкерлелекне яратмый, аны кулга-кул тотышып, пакь йөрәк белән генә яулап була...»). Адәм балалары үзләреннән көчсезрәк тереклек янында — акыллы, ә бик алга киткән җәмгыятьләр белән очрашканда көчле рухлы булып кала алалар, дип раслый язучы. Шундый оптимизм, эчке горурлык хисе — аның хикәяләренең иң күркәм сыйфаты.

Фәнни фантастика — үзенә генә хас мәсьәләләр һәм чишелешләр әдәбияты, һәм бу үзенчәлекнең фән үсешенә теге яки бу дәрәҗәдә бәйле булуы табигый. «Мәңгелек» темалар, «үтәли» проблемалар да — фәндәге сыман... Ләкин фәнни-хыялый әдәбият теләсә нинди мәсьәләне киңрәк куя — аның фәлсәфи, әхлакый һәм иҗтимагый тамырларын ачарга омтыла.

Галәмдәге табышмаклар белән баш ватудан кешелек җәмгыятенең үз карынында яралган күренешләрне, проблемаларны өйрәнүгә күчә бару А. Тимергалин иҗатына да хас. Кешенең рухи яшәеше, эчке мөмкинлекләре дөньясына ул үз «алтын ачкычын» эзли. һәм бу эзләнүләр вакытында фантастка, фәнни зирәклектән дә бигрәк, үз заманындагы әйдәп баручы карашлар белән бәйләнешнең мөһимрәк булуы ачыла бара.

Уйлап табуның да, маҗаралы-хыялый күренешләрнең дә төрлесе бар, билгеле. Кешене үзенең кем икәнлеген онытырга мәҗбүр итәләр, «ярымкеше-ярыммәймүн»лар әзерләүче конвейерга салалар. Бу сатташкан акыл ияләре тырнагыннан үзенең сөйгән егетен һәм аның кебек күпсанлы корбаннарны егерме яшьлек кыз бала коткара («Уян, сөеклем!» хикәясе). Фантастик буяулар куе булса да, бирегә тормышның реалистик сурәтләре өстенлек итә башлый.

«Хәерле юл» хикәясендә шушы үзенчәлек тагын да нәтиҗәлерәк файдаланыла. Шартлылык фантастиканың тормыш белән кушылып китү дәрәҗәсенә күтәрелә. Фәннең сугыш чукмарларына хезмәт итүен теләмәгән галимне юлдан алу операциясе әлеге тәэсирне тагын да көчәйтә. Мондый төр конфликтны без инде «Шартламасын», «Киңәшче-1М» хикәяләрендә очраткан идек. «Хәерле юл»да ул тормышчанрак чишелеше белән аерылып тора. Биредә сюжет белән бергә геройларның да эчке үсешүзгәрешенә игътибар ирешелә, кешеләр, идеяләр арасындагы киеркен бәрелеш маскалар көрәше генә булып калмый. Профессор Хайрам, мәсәлән — «Шартламасын»дагы Генрига, «Киңәшче-1М»дагы Стенли Моуска караганда тулырак, җанлырак образ. Аның эш-

хәрәкәтләре белән холкы-фигыле, дөньяга карашы арасында эзлекле бәйләнешне күрүе читен түгел. Вакыйгаларны Клемент Сойль исеменнән (беренче затта) бәян иткәнлектән, язучы төп каһарманның күңелендә, аңында барган катлаулы хәрәкәтне аеруча нечкә һәм тирән сурәтләүгә ирешә. Шушы максат белән кулланылган психологик сынау алымы да уңышлы (мәсәлән, Сойльгә профессорны үтерү бурычы йөкләтелүе). Хикәянең реалистик яңгырашы төгәл һәм мәгънәле күренешләр ярдәмендә көчәйтелә (әсирлектә белем алу, фәнни лаборатория һ. б.).

А. Тимергалин башка әсәрләрендә дә күренеш-детальләрдән зәвык белән файдалана. «Мәңгелек хатирәләр»дә замандашларыбыз кулындагы гаҗәеп кристалл-ачкыч, «Әфсен түгел...» хикәясендә — Болгар чорындагы мохит, психологик шартлар. Ерак планеталардагы һәм үткән заманнардагы манзараны, вакыйганы тасвирлаганда безгә таныш-мәгълүм детальләр ярдәмендә фантастик күренешләрне ачу осталыгы бигрәк тә күзгә ташлана. Нәтиҗәдә, хыялый картина җир үлчәмнәренә нисбәтләнеп, чынбарлык киеменә төрелә. Сәер күк җисеменең «иясен югалткан яки адашкан терлеккә» охшавын күрүдә генә дә күпме шигърият: «Кулга бик ияләшкән эт, хуҗасыннан калса, шулай каңгырып йөри...» («Адашкан йолдыз»).

Гомумән, язучының әсәрләре образлы һәм үткен теле белән сокландыра, анда «саклангынны космос үзе саклар ди» рәвешендәге халыкчан, җор тәгъбирләр энҗе кебек сибелеп ята. Бу сыйфат бигрәк тә аның юмористик һәм сатирик хикәяләрен бизи. Шулай да, җорлык димәктән, А. Тимергалин укучыны ничек тә көлдерергә тырышканда түгел, нәкъ менә җитди генә мәсьәләләрне «мыек астыннан елмаеп» тасвирлаганда күбрәк уңышка ирешәдер төсле. «Телефон» хикәясендә «теле бик кычыткан чакларда да тыелып калган өчен» акча сорарга килүче хатынны хәтерлисезме? Яисә, «Өлкәр» хикәясендә йолдызның адәм баласына уңай тәэсире бардыр дигән ырым ничек гади һәм матур чишелә! Кеше белән дошманлаша белмәгәнлектән «Әүлия» кушаматы алган Бретка исә бу хыял бик кирәк. «Ул мине тормыш шакшысыннан саклый»,— ди егет. Аның беркатлы килешүчәнлеге шелтәле көлү катыш, зур әдәплелек белән, әмма катгый кире кагыла.

Язучыларыбызның бер зур җыелышында Атилла ага Расих: «Фәнни фантастика жанрының татар прозаикларын зарыгып көткәнлеген басым ясап әйтәсе килә. Минемчә, фәнни фантастика безнең әдәбиятта чәчәк атарга тиеш»,— дигән иде. Чыннан да, бу юнәлештә бөтен күңелен баглап әлегә бер Адлер Тимергалин гына иҗат итә, бугай. Аның уңышлары безне сөендерә, мөмкинлекләре өметләндерә. Җыентыктан җыентыкка язучының осталыгы арта, әйтер сүзе саллырак була бара. «Ерак планетада», «Рибб Локсның үлеме», «Хәерле юл» кебек катлаулы һәм кызыклы әсәрләр җанлы дөньясы, үсеш-үзгәрештәге геройлары, кайнар хискә, үзенчәлекле сурәтләргә юмарт теле белән хәтердә кала. Әдәбиятыбызга тематик яңалык кына түгел, фикер, сурәт һәм стиль яңалыгы да алып килде А. Тимергалин. Бу иҗатның төп девизын мәгълүм канатлы сүзләр белән: «Дөньяда кешедән дә кызыклырак нәрсә юк. Иң әһәмиятлесе — аны фикерләргә өйрәтү»,— дип билгеләргә мөмкин булыр иде. Киләчәк тойгысы аша ул безне бүгенге көннең асылына тирәнрәк төшенергә, чор сулышына сизгеррәк булырга чакыра.

Язучы ачкан фәнни-хыялый дөньяда без инде төп юнәлешне күрә алабыз. Ул юлны Кешегә ышаныч һәм Киләчәккә Өмет йолдызы яктырта.

САЛИХ МАННАПОВ.

# ФӘНДӘ ЗУР АДЫМ

Халкыбыз, культурабыз тарихын өйрәнү юлында төрле ысул, төрле планда башкарылган хезмәтләр бар. Аларның кайберләре гомуми проблемаларны киң планда, икенчеләре аерым мәсьәләләрне җентекләп тикшерүгә юнәлгән. Өченче хезмәтләргә әлеге ысулларны бергә кушу омтылышы характерлы. Тарихчы һәм әдип Миркасыйм Госмановның яңа чыккан «XIV—XVI гасыр Җучи Улусының ярлыкаш актлары» дигән зур монографиясе соңгы тип гыйльми тикшеренүләргә керә[1].

Иң элек, хезмәтнең эчтәлегенә кергәнче, кайбер аңлатмаларга тукталып үтү артык булмас, чөнки анализлана торган кайбер төшенчәләр һәм атамаларның киң җәмәгатьчелеккә яңа булып тоелуы бар.

«Җучи Улусы» дигән төшенчә XIII гасырда монгол яулап алуларыннан соң, төгәлрәк әйткәндә, «бердәм» Монгол империясе таралгач, Көнбатыш Азия һәм Көнчыгыш Европада оешкан зур политик берләшмәне — империяне аңлата. Популяр һәм бары рус чыганакларына нигезләнгән хезмәтләрдә ул дәүләтне гадәттә Алтын Урда дип атыйлар. Ләкин бу атама тарихи дөреслеккә тәмам туры килеп бетми. Беренчедән, әлеге империя яшәгән чорда андый исем гамәлдә булмаган; икенчедән, «Җучи Улусы» дигән төшенчә «Алтын Урда»га караганда күпкә киңрәк. Соңгы атама, нигездә, Түбән Идел һәм Көньяк далалардагы политик берләшмәгә карата кулланылса, беренчесе исә Бату яулап алулары нәтиҗәсендә барлыкка килгән корама империя составына кергән барлык регион һәм төбәкләрне элгәрге дәүләт һәм кабилә-халыкларны эченә ала. Димәк, рецензияләнә торган хезмәтнең эчтәлеге урта гасырларда яшәгән бер ил, бер дәүләт тарихына мөнәсәбәтле чыганакларга гына кайтып калмый икән. Әйе, М. Госмановның хезмәте, чыннан да, гомумтюркологик планда язылган.

«Ярлыкаш актлары»на килгәндә, ул феодаль дәүләт тарафыннан аерым шәхесләргә (мәсәлән, зур милек ияләре, эре руханилар, ыру-кабилә башлыкларына һ. б.) тегеяки бу юридик, экономик, хәтта политик-административ махсус хокук, ягъни матди һәм сәяси өстенлек хокукы бирә торган рәсми закон-фәрманнарын — указларын аңлата. Ул заманнарда мондый төркичә документларны «ярлыклар» дип йөрткәннәр. Икенче төрле әйткәндә, «ярлык» — ул монарх указы. «Ярлыкаш актлары» исә хезмәттә менә шундый әмер-фәрманнарның махсус бер зур төркеменә, конкрет льготалар хокукы бирә торганнарына карата кулланыла.

Мондый документларны өйрәнү җәмгыять эчендәге иҗтимагый, экономик, шул исәптән, аграр мөнәсәбәтләрне, аларның социаль нигезен, ягъни базис үзенчәлеген аңлау өчен ышанычлы нигезне тәшкил итә. Димәк, галимнең хезмәте Җучи Улусы составына кергән төрле халыкларның, беренче чиратта, төркиләрнең, социаль-иҗтимагый үткәнен чагылдыра торган нигез-таш чыганакларны өйрәнүгә багышланган. Шул ук вакытта бу документларның гомум хаким культураның конкрет өлкәләрен: язма традиция, әдәби тел, эш кәгазьләрендәге функциональ стильләр мәсьәләләрен өйрәнү өчен дә гаять мөһим чыганак икәнлеген онытмаска кирәк. Шулай ук, тарихыбызның борынгы чорына караган җирле язма истәлекләренең бик аз сакланып калуын, чит илләрдә барлыкка килгән язма мәгълүматларның табигый рәвештә шактый бертяклы, хәтта субъектив булуларын искә алсак, төркичә бу актларның иң ышанычлы чыганаклар булуын аңларбыз.

[1] М. А. Усманов. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV—XVI вв. Издательство Казанского университета, 1979, 318 бит.

Хезмәт зур гына кереш, махсус проблемаларга багышланып, «Археография», «Палеография», «Сфрагистика», «Дипломатика» дип аталган дүрт кисәктән (аларның һәрберсе аерым бүлекләрне эченә ала) һәм төп нәтиҗәләрне эченә алган йомгактан тора. Монография тиешле гыйльми аппарат белән дә тәэмин ителгән.

Керештә автор тикшерелә торган объектларның чорын, географиясен һәм төр чикләрен билгели, бу чик һәм билгеләрнең тарихи нигезен, фәнни-теоретик закончалыкларын ачыклый. Шуннан чыгып тикшерү объекты итеп алынган мәсьәләләрнең спецификасын аныклый, хәл кылачак бурычларны билгеләп үтә. Әйтергә кирәк, М. Госманов куйган мәсьәләләр һәм проблемалар субъектив тәкъдимнәр рәвешендә түгел, бәлки, документларның табигатеннән килә торган объектив таләпләр сыйфатында килеп баса. Галим борынгы күренешләрне, фактларны бәяләгәндә мәсьәләгә конкрет тарихилык принцибыннан килеп, аларның табигатен сыйнфыйлык позициясеннән чыгып билгели. Бу хәл исә өлеге фактларны, күренешләрне эзлеклелектә, хәрәкәттә, үсештә карарга мөмкинлек бирә.

Керешнең икенче өлеше әдәбиятта, фәндә очрый торган кайбер төшенчәләр, атамалар кулланышындагы буталчыкларга, борынгы исемнәрне язудагы башбаштаклыкларга, шулардан арыну юлындагы чараларга багышланган.

«Археография» дип исемләнгән беренче кисәк (20—84 бб.) СССРда сакланган ярлыкларның төп коллекцияләре, ярлыкаш актларның тасвирламасы, кайбер документларның саклануы, тарихи дәресләре һәм хәзерге мәгълүм төрки-татарча актларның регионара бүленеше кебек мәсьәләләргә багышланган дүрт бүлектән тора. «Археография» дигән атама, гадәттә, борынгыдан калган язма истәлекләрнең барлыкка килү, яшәү, таралу тарихын, саклану рәвешен тикшереп, шуннан чыккан нәтиҗәләр нигезендә аларны ничек өйрәнү, бастыру һәм фәндә куллану мәсьәләләрен эченә ала. Шушы таләпләргә җавап рәвешендә, автор төркичә оригиналда сакланып калган ярлыкаш актларын эзләп табып, аларны төр һәм эчтәлекләре, сакланыш халәтләре буенча классификацияләп чыга.

Ассызыклап әйтергә кирәк, М. Госманов ярлыкларны эзләү, барлау, табу, ачыклау буенча моңарчы бездә беркем дә башкара алмаган казанышларга ирешкән. Моның шулай булуын күрсәтү өчен Й. Хаммер, В. В. Григорьев, Я. О. Ярцов, И. Н. Березин, В. Д. Смирнов, А. Н. Курат кебек мәгълүм ориенталистларның тырышлыгы нәтиҗәсендә барлыгы сигез тарханлык ярлыгы актив фәнни әйләнешкә кергән булса, монография авторы моңарчы беркемгә дә мәгълүм булмаган тагын 24 ярлыгын тапкан[1]. Шулар өстенә, фәнни әйләнешкә кертелмәгән 53 ярлыкның төркичә оригинальләрен беренче булып фәнни хәрәкәткә кертеп җибәрә. Шулай итеп, авторның монографиясе барлыгы 61 ярлыкка нигезләнә! Моның тюркология фәне өчен чагыштыргысыз зур казаныш, фәндә яңа зур адым икәнлеге үзеннән-үзе күренеп тора. Бу уңайдан шуны да әйтеп үтәсе килә: М. Госманов халкыбызның кульязма мирасын, борынгы кульязма китапларны барлау, эзләү, туплау буенча Шиһап Мәрҗани, Сәед Вахиди һ. б. кебек галимнәрнең традицияләрен актив дәвам итүче галим дә. Татар халкы яши торган төрле өлкә, республика, төбәкләрдән меңләгән кульязма әсәрләрне табып, югалтудан саклап калды. Аның археография өлкәсендәге бу фидакарь хезмәтенә атаклы совет галимнәре «Правда» газетасында (1973, 14 август, 226 сан) зур бәя биреп үтте.

Саннар сыйфатка әверелә, диләр. М. Госмановның яңа хезмәте шуңа мисал булып тора. Ярлыкаш актларның үзләреннән тыш рәсми документларның башка төрләреннән актив файдалану[2], өйрәнелә торган истәлекләрнең саклану үзенчәлекләрен, тышкы кыяфәтләрен төгәлрәк һәм әтрафлырак аңларга, ачыкларга ярдәм иткән. Нәтиҗәдә кайсы документның төп нөсхә, кайсыларының күчермә генә, ясалма ялган (фальшивка) булуын документаль исбатларга мөмкинлек биргән. Кульязма документны фәнни «укый» алу өчен аның кәгазен, стилен, хәтта, язу ысулын, тышкы оформлениесен дә таный белү кирәк икән.

«Палеография» дигән икенче кисәк (85—134 бб.) үзенең эчтәлеге, әһәмияте буенча да, татар историографиясе тарихы өчен дә әр-яңа этап дип билгеләүгә лаек.

Палеография — ул борынгы язуларның

---

[1] Бу турыда үзәк матбугатта язылды: М. А. Усманов. О новых ярлыках ханств Джучиева Улуса XIV—XVI вв.— Археографический ежегодник за 1978 год. Мәскәү, 1979, 46—51 бб.

[2] М. А. Усманов. Официальные акты ханств Восточной Европы XIV—XVI вв. и их изучение.— Археографический ежегодник за 1974 год. Мәскәү, 1975, 117—135 бб.

тышкы рәвешен өйрәнә, шул юл белән тикшерелә торган документларның язу хосусиятләрен төрле яклап ачыклый торган махсус фән. Безнең язма-истәлекләргә карата ул бөтенләй эшләнмәгән. М. Госманов менә шушы «чирәм»не күтәреп борынгы татарча рәсми документларның язу һәм почерк (хат), кара, каләм һәм кәгазь үзенчәлекләрен җентекләп тикшереп чыккан. «Палеография» кисәгенең эчтәлеге, кыйммәте чагыштырмача таррак функцияле эш кәгазьләре дөньясы белән чикләнми. Монографиянең бу өлешендә чыгарылган нәтиҗәләрнең әһәмияте күпкә киң: автор тикшеренүеннән Идел буе төрки халыкларының — әлбәттә, татарларның да — язу культурасы, бу культураның чыганак һәм традицияләре хакында гомум мәгълүмат туплап була. Димәк, ул культурабыз тарихы өчен дә зур әһәмияткә ия.

Тарих фәненең «Сфрагистика» (139—183 бб.) дигән тармагы рәсми документлардагы таныклык билгеләрен, ягъни мөһер һәм печатьләрне тикшерә. «Таныклык билгеләренең характеристикасы», «Печатьләрнең функция һәм йөкләмәләре» дигән ике бүлектән торган бу кисәк урта гасыр татар ханлыкларыннан калган дәүләт мөһерләрен анализлауга багышланган. Моңарчы фәндә андый таныклык билгеләренең дүрт-биш кенә үрнәге тикшерелгән иде. М. Госманов исә фәнни кулланышка тагын егермедән артык билге кертә, димәк, тагын да күбрәк һәм баерак фактлар белән эш итә. Хезмәтнең бу кисәгендә каралган материаллар өйрәнү, тикшерү өчен гаять дәрәҗәдә катлаулы һәм четрекле. Квадрат формалы кызыл, күк һәм сары алтын төсендәге мөһерләр күптән онытылган гарәпчә куфи почеркы, аның да катлаулы синтез дәвамында Идел буенда иҗат ителгән, бары шунда гына кулланылган сирәк төре белән башкарылган. Мондый төр куфи почеркын укый белүчеләрнең саны хәзер бөтен илдә бер кулдагы бармаклар белән генә санарлык.

Ниһаять, М. Госманов мөһер текстларын махсус өлешләргә бүлеп, тексттагы һәр компонентның формаль мәгънәсен, иҗтимагый эчтәлеген, рәсми йөкләмәсен дә ачыклый. Нәтиҗәдә печатьләрдәге язуларның теге яки бу дәүләт башлыгы өчен нинди политик, идеологик лозунг функциясен үтәүләре мәгълүм була. Шулай итеп, информацион җәһәттән гаять чикләнгән истәлекләрнең дә мөһим тарихи чыганакка ия була алуы күрсәтелә. Хезмәтнең бу өлеше белән М. Госманов фәнебезгә, бер яктан, яңа мәгълүматлар алып килсә, икенчедән, татар-төрки сфрагистикасына нигез сала.

Акт чыганакларын махсус өлешләргә бүлеп, аналитик җентекләп тикшерә торган тарих фәне тармагына «дипломатика» дип әйтәләр. Монографиянең «Дипломатика» өлеше (183—282 бб.) урта гасыр төрки-татар эш кәгазьләрен эзлекле рәвештә җентекләп тикшерүгә багышланган. Бу кисәк документларның баш, төп һәм йомгак өлешләрен формаль-типологик, типик-функциональ яктан махсус анализлаган һәм борынгы актларның тарихи үсү үзенчәлекләрен билгеләгән, аларны төрләр буенча классификацияләгән дүрт бүлектән гыйбарәт. Автор дәлилләп күрсәткәнчә, документлардагы һәр статья, һәр формула аерым функциягә һәм, шуннан чыгып, үзенә генә хас мәгънәгә, йөкләмәгә ия икән. Төрле документлардагы махсус функцияле статья һәм формулалар арасындагы уртаклык, яисә аерма әлеге документларның үзара типологик бердәмлеген яки үзенчәлеген тәэмин итә. Документлар арасындагы «формаль» үзгәлеккә килсәк, ул аларның юридик функция һәм бурычларындагы аермаларга күрсәтә, социаль-иҗтимагый максат һәм йөкләмәләрен чагылдыра. Димәк, үзгәлекләр (тарихи күзлектән караганда — үзгәрешләр!) тормышның үзендәге экономик үзгәрүләрне — базис үзенчәлеген чагылдыра булып чыга. Акт чыганакларын болай җентекләп тикшерү ахыр чиктә үзмаксат түгел. Ул әлеге документларда теркәлгән социаль, аграр мөнәсәбәтләрне, борынгы чорда хөкем сөргән изү формаларын ачыклауга хезмәт итә. Чөнки һәр статья һәм формуланың асыл мәгънәсен, мәгънә төсмерләрен билгеләү ярлыкларда очрый торган күп санлы налог-салымнарның конкрет эчтәлекләрен ачыклауга булыша. Бу исә ул чордагы эксплуатация хакында декларатив рәвештә генә сөйләшмичә, аның турында тарихи төгәл нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Совет тарих фәнендә соңгы вакытларда гына җанлана башлаган, край тарихында төрки-татар чыганакларын өйрәнүдә беренче мәртәбә М. Госманов хезмәтендә генә иҗади кулланылган дипломатика дисциплинасы, ярлыкаш актларын анализлаудан тыш, гомум эш кәгазьләре системасында башка тип рәсми документларның да төрләрен, урыннарын билгеләргә, ягъни

рәсми актларны гомум классификацияләргә мөмкинлек ачкан. Алай гына да түгел, автор башка төр язма чыганакларда чагылмаган иҗтимагый, аграр үзгәрешләр, хәтта реформалар турында да (282—289 бб.) фикер йөртү мөмкинлекләренә ирешкән. Моны тарихи фактлар һәм ерак гасырлардагы хәлләрне аңлау юлында соңгы елларда табылган зур яңалыкларның берсе дип бәяләргә мөмкин.

Хезмәтнең йомгак өлешендә (292—295 бб.) автор, ирешелгән нәтиҗәләрдән чыгып, нинди яңа бурычлар тууын ачыклый. Бу исә хезмәткә логик тәгалләнгәнлек һәм перспектив динамика өсти: ирешелгән нәтиҗәләрнең бүгенге әһәмияте ачыклану өстенә, тарихыбыз үсешендә аларның киләчәктә тотачак урыннары да билгеләнә.

Монография гарәпчә язулы борынгы текстлардан иллюстрацияләр, язу һәм галәмәт үрнәкләрен, формула һәм атамаларны анализлауга багышланган иллюстрацияләр һәм таблицалар белән тәэмин ителгән. 500 гә якын әдәбиятны эченә алган библиография хезмәтнең бай методик базасын, гыйльми колачын ачык күрсәтә.

Бу монографиядә канәгатьсезлек тудырган кайбер моментлар да очрый. Мәсәлән, алтмыштан артык ярлыкаш актларның үзләрен, шулай ук тагын йөзләгән башка төр рәсми документларның материалын җәлеп иткән хезмәттә бер-ике ярлык тексты тулысынча урнаштырылган булса, хезмәтнең күргәзмәле дәлил базасы тагын да көчәеп, нур өстенә нур гына өстәр иде. Хезмәттә кайбер мәсьәләләрнең бик кыска бирелүе дә сизелеп тора. Шулай ук авторның бу өлкәдә үзенә хәтле эшләгән галимнәрнең эшчәнлеге хакындагы күзәтүләре дә монографиядә тулы бирелмәгән. Ниһаять, теоретик планда җентекләп өйрәнелгән актларның текстларын бастырып чыгару эшен дә озакка сузмаска кирәктер, чөнки өйрәнү объекты булган бу документлар башка галимнәр өчен дә кыйммәтле чыганак булып торалар. Ә җыеп әйткәндә, М. Госмановның бу монографиясе заманында дан тоткан Казан ориенталистика мәктәбенең, тәгәлрәк әйткәндә, аның юнәлешле Казан тюркологиясе традицияләрен дәвам итүенә дәлил булып тора. Чөнки хезмәтнең эчтәлеге, тирәнлеге, әһәмияте бер халыкның социаль-иҗтимагый, культура тарихына гына сыеп калмый, бәлки, күпкә киң, күпкә тармаклы. Һәм менә шушы киң диапазонлыгы, колачлыгы аңар борынгы татар язма традицияләрен, әдәби телен, татарча рәсми эш башкару культурасы тарихын җентекләп өйрәнергә, тирәнтен аңларга, ачыкларга мөмкинлек биргән.

**ӘБРАР КӘРИМУЛЛИН,**
филология фәннәре докторы.
**РИФ ХӘЙРЕТДИНОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

# ӘДӘБИЯТКА ТАРИХИ КАРАШ

Совет әдәбият фәнендә барлык милли әдәбиятларның тарихи юлын тоташ күздән кичерү һәм җитди теоретик-эстетик йомгак ясау чоры башланды. Элек игътибардан читтәрәк калып килгән борынгы дәверләрне ачыграк күз алдына китерү зарурлыгы туды. Шунсыз зур тарихлы әдәбиятларның соңгырак чордагы казанышларын тәгәл билгеләү мөмкин дә түгел.

Татар әдәбиятының да борынгы дәверләрен өйрәнү актуаль бурычлардан санала. Әдәбият үсешенең тарихи контекстын ачыклау юлында мөһим этап итеп Газиз Гобәйдуллин һәм Гали Рәхим хезмәтләрен күрсәтергә мөмкин. Татар поэзиясе үткән юлның тарихи һәм эстетик бөтенлеге теоретик һәм хрестоматик планда «Татар поэзиясе антологиясе»ндә чагылыш тапты. Күренекле тюрколог Әмир Нәҗипнең урта гасыр Идел буе төрки әдәбияты ядкәрьләре хакындагы мәкаләләре үткәндәге бай мирасны реаль күзаллау юнәлешендә кирәкле баскычлар булды. Борынгы әдәбиятыбызның аерым әсәрләрен өйрәнү дәвам итте, урта гасыр әдәбиятын барлауның мөһим мәсьәләләре күтәрелә торды. Ш. Абилов, М. Җәлалиевләр белән беррәттән К. Дәүләтшин һәм Х. Миңнегулов кебек яшьрәк буын галимнәр әдәбият тарихын тулыландыруга яңа мәгълүматлар өстәделәр, борынгы дәверне өйрәнүнең яңа аспектларын ачтылар. Аерым проблемаларны өйрәнү белән бергә шуларга синтез зарурлыгы да үзен сиздерә барды һәм бу бурычны хәл итүгә өлкән буынның тәҗрибәле вәкилләре алына торды. Х. Госманның «Татар поэзиясе тарихында Тукайның урыны» исемле мәкаләсе (1966 ел) шушы ихтыяҗны тоеп башкарылган хезмәтләрдән

булды. Нәтиҗәдә әдәбият тарихының мөһим маяклары шактый анык булып төсмерләнә башлады.

Әмма борынгы әдәбиятны тикшерүдәге үтә үткен мәсьәләләр хәл итүне һаман көтә бирде. Аерым алганда, урта гасыр әдәби мирасына варислык мәсьәләсе язма культура тарихы ерактан килә торган кардәш төрки халыкларда кискен бәхәсләр уятуында дәвам итә. Бәла бу өлкәдә нигезгә алынган принципларның төрле булуында, карашларга тарихилык җитенкерәмәүдә һәм, әлбәттә, мәгълүматларның аз булуында иде.

60 нчы еллардан башлап татар матбугаты битләрендә яңа һәм гаять кызыклы исем күренә башлады. Бу — көнчыгыш фәне белгече, Ленинград университеты профессоры, Е. Э. Бертельс шәкерте Габдрахман ага Таһирҗанов иде. Аның «Казан утлары»нда басылган «Фирдәүси һәм Кол Гали» исемле мәкаләсе безне бик нык борчыган сорауларга җавап бирүе, татар халкы өчен гаять кадерле әсәрне өйрәнүгә бик тә кирәкле ачыклыклар кертүе белән кыйммәтле. Шул рәвешчә, Йосыф сюжетына язылган беренче төрки поэманың оригинальлек дәрәҗәсе хакында сүз алып бару өчен нигез салынды. Кол Гали әсәрен иңәсеннән җебенә чаклы тикшерү мөмкинлегенә ышаныч туды һәм андый тикшеренүнең кузгалу ноктасы табылды.

Озак та үтмәде, галим «Палестина мәҗмугасы»нда мәкалә бастырып, «Кыйссаи Йосыф» әсәренең болгар тарихына кагылышын ил һәм дөнья галимнәре каршында фәнни нигезләп чыкты. Гыйльми җәмәгатьчелек алдына борынгы болгар мәдәниятен төрле яклап күз алдына китерерлек мәгълүматлар туплап чыгарылды.

Фарсы теле һәм әдәбиятының абруйлы белгече булган галимнең әдәбият тарихы өчен бәяләп бетергесез тагын бер файдасы Котбның «Хәсрәү вә Ширин» поэмасын аның элгәресе булган Низами әсәре белән тәфсилле чагыштыруда күренде. Болар — киң карашлы галимнең конкрет мәсьәләләргә таянаеп алуы иде. Һәм, ниһаять, шуларның үстерелеше һәм логик нәтиҗәсе буларак, Г. Таһирҗановның бер-бер артлы өч мәкаләсе дөнья күрде. Аларның мөһим яңалыгы әдәбият тарихындагы хәл ителеп бетмәгән, яки өр-яңадан хәл ителәсе мәсьәләләрне киң колач белән иңләүдә, аларга комплекслы якын килүдә һәм тарихилык принцибын эзлекле үткәрүдә иде.

Галимнең 1979 ел азагында Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган хезмәте шушы мәкаләләрнең камилләштерелгән һәм органик бер бөтенгә тупланган варианты булып тора. Автор аны «Тарихтан — әдәбиятка» дип атаган. Ягъни китапның исемендә хезмәттә кулланылган төп принцип чагыла.

Китапның беренче һәм төп өлеше «Татар әдәбиятының катлаулы мәсьәләләре» дип алынган. Бу бүлекнең үзәгендә урта гасыр төркиләренең, аерым алганда болгарларның, әдәби мирасы һәм шуңа варислык мәсьәләсе тора. Галим аны хәл итүгә халыкның килеп чыгышы (этник тарихы) аша якын килә һәм бу өлкәдә тупланган мәгълүматларны тәнкыйть күзлегеннән кичерә. Моннан тыш: «...борынгы чордагы әдәби процесны тикшергәндә тагы өстәмә таләпләр дә туа,— ди ул.— Мәсәлән, бер-берсенә якын, кардәш телләрдә иҗат ителгән борынгы әсәрләрнең миллилеген ничек аныклап, соңгы дәверләрдә өешкән милли әдәбиятларның чикләрен ничек билгеләргә?» «Шагыйрь яки әдип кайда, кайсы халык арасында туып үскән яисә иҗат иткән; әсәр нинди телдә язылган яисә кайсы конкрет тел-шивә мохитында сакланып калган; истәлектә нинди конкрет төбәкнең табигате сурәтләнеп, кайсы халыкның гореф-гадәте, тарихи шартлары чагылыш тапкан» булудан чыгып — ягъни тарихи, этнографик, тел, әдәби һәм фольклор мәгълүматларының барысын берьюлы күздә тотарга кирәклеген искәртә.

Г. Таһирҗанов әдәби мирас мәсьәләсен күтәргәндә иң дөрес алшарт итеп, совет тюркология фәнендә эшләнгән һәм кабул ителгән, әмма җирле галимнәр игътибарыннан еш кына читтә калучан принципны ала, ягъни борынгы мирасны уртак итеп карау фикерен алга сөрә.

Гарәп һәм фарсы телләрен камил белүе галимгә борынгы төрки һәм татар мәдәниятына кагылышлы чит ил кульъязма чыганакларына киң таяну мөмкинлеге бирә, Идел буе, Урта һәм Кече Азия тарихын төгәлрәк күзалларга ярдәм итә. Галимнең хәзерге татар әдәбияты, археология, тарих, этнография һәм тел фәне казанышларын үзләштереп баруы, гомумтөрки планда киң мәгълүматы һәм марксистик-ленинчыл фикерләү ысулы аны гаять нәтиҗәле синтезларга, гомумиләштерүләргә алып килгән. Мәсәлән, аның Иран әдәбиятын яхшы белүе фарсы телле халыклар арасында булып узган варислык дәгъваларының гыйбрәтле тәҗрибәсен төрки әдәбиятларга карата да искә алырга ярдәм иткән. Әйтик, бары территориаль принцип белән генә эш иткәндә, бөек мирасның уртак варислары булган таҗикларны, иранлыларны, һинд һәм әфганнарны я Сәгъди белән Хафиз, я Әмир Хөсрәү Дәһләви белән Габделкадыйр Бедил, я Низами белән Хагани исемнәреннән мәхрүм кылу очраклары булып алды. Төрки әдәбиятларда да уртак мирасны бүлгәләп үзләштерү нәкъ шундый нәтиҗәләргә илтә. Галим борынгы төрки әдәбият белгечләрен нигезле рәвештә бу хаталардан кисәтә.

Ленинград галименең гаять әһәмиятле һәм киң колачлы күзәтү-нәтиҗәләреннән берсе — ул урта гасыр Идел буе төрки әдәбиятының Урта Азиягә һәм Кече Азия төрек әдәбиятына тәэсирен исбатлап күрсәтү, ягъни бу әдәби үзәк-төбәкләрнең бер-берсенә мөнәсәбәтен объектив-тарихи ачып бирүдә. Тарихи-диалектик карашның иң мөһим йомгагы дияргә кирәк моны. Галим төрек әдәбиятының башка төрки әдәбиятларга тәэсире XV гасырдан гына башлануын әйтә һәм анда да тәэсирнең эпигоннарча ияру түгел, бәлки иҗади үзләштерү рәвешендә барганлыгын һәм жир-

ле әдәбиятларда ул казанышларны үзләштерерлек үсеш дәрәҗәсе һәм ихтыяҗ югарылыгы булганлыгын күрсәтеп бирә. Совет әдәбият белемендә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре төрек поэзиясенә ясаган йогынтыны дәлилле итеп беренче исбатлаган галим Габдрахман ага Таһирҗанов булды.

Хезмәттә татар әдәбияты тарихы һәм әдәбият белеме өчен генә түгел, гомумән, Совет һәм чит ил Көнчыгышы әдәбиятлары тарихы өчен дә әһәмиятле фикерләр һәм төгәллек кертүләр бар. Мәсәлән, «Кәлилә вә Димнә» әсәренең төрки тәрҗемәчесе хакындагы хөкемнәр, яки төрек шагыйре Әхмәд Гирмиянинең моңарчы фәндә билгеле булмаган «Йосыф вә Зөләйха» поэмасы хакындагы мәгълүматлар. Шунысы кызыклы, соңгы әсәр кулъязмасы галим тарафыннан аның туган ягы Апас районында табып алынган.

Әдәби бәйләнешләр һәм аларның нәтиҗәләре хакындагы бүлектә татар эшлекләренең тугандаш халыклар әдәбиятына һәм культурасына хезмәте хакында гаять кызыклы мәгълүматлар китерелә. Галим төрки әдәбиятлардагы үзара йогынтының төрле чорларда төрлечә булуын тасвирлаганда нечкәлек һәм тарихи-фәнни төгәллек белән эш итә, суфичылык әдәбиятының татарлар арасына үтеп керү тарихы белән таныштыра. «Бакырган китабы»ның антология характерында булуына һәм, ышанычлы чыганакларга таянып, анда теркәлгән авторларның болгар-татар шагыйрьләре икәнлегенә дәлилләр китерә. Көнчыгыш әдәбиятлары белән бәйләнешнең татар әдәбияты яңарыш чорына килеп кергәндә дә дәвам итүе бай фактлар җирлегендә яктыртыла. Шундый дәлилләрдән «Сәйфелмөлек», «Тутыйнамә» китаплары белән бергәттән, М. Харәзминең «Мәхзәнел-әсрар»ы, Ф. Гаттарның «Пәндnамә»се, Җәләлетдин Руми әсәрләренең бездә кулъязма һәм басма китап рәвешендә киң таралганлыгын әйтергә кирәк. Нәван әсәрләре дә кулъязма хәлендә укылып йөргән. XIX йөз татар поэзиясендә моның нәтиҗәсе ачык күренә. Ә. Каргалый, Һ. Салихов кебек шагыйрьләрдә, мәсәлән, Руми йогынтысын аермачык билгеләп була.

Хезмәттә урын алган бүлекчәләрнең соңгы икесе конкрет әдәби ядкарьләргә багышланган. Аларның берсендә «Кыйссаи Йосыф» поэмасының чыганаклары хакында өстәмә мәгълүматлар китерелеп, әсәрне Идел буе әдәби мохитына бәйли торган дәлилләр баетылган. Автор ядкарьнең татар әдәбияты тарихындагы бәрәкәтле урынын күрсәтү белән бергә аның Көнчыгыш әдәбиятларында тоткан ролен дә киң бәяли. Әмма поэманың теленә килгәндә, андагы угыз элементларының әһәмиятен бераз кечерәйтү кебек омтылышлар да сизелеп куя. Әсәрнең милли җирлеген һәм кем мирасы булуын хәл иткәндә, бу момент кирәкмәгәнгә куертелә. Чынлыкта исә әсәрдә угызчылыкның тамырлары шактый тирән. Мәсьәлә фонетика һәм лексикага гына кайтып калмый, фразеология һәм фольклорга да барып тоташа. Хәлбуки угыз этник компоненты һәм угыз тел элементлары татар халкы һәм телендә дә шактый урын били. Соңгы вакыттагы топонимик һәм диалектологик тикшеренүләр шуны күрсәтә.

Аеруча җентекле һәм әтрафлы башкарылган өлешләрдән «Котб һәм аның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре» дигән бүлекне күрсәтергә мөмкин. Низами поэмасы белән текстуаль чагыштырулар Идел буе шагыйренең зур талант көчен һәм оригиналь иҗат өлешен шактый тулы күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. Шагыйрьнең язмышына, иҗтимагый-фәлсәфи карашларына һәм тарихи вакыйгалар эчендә тоткан урынына карата автор китергән дәлилләр шактый ышандыру көченә ия, гөман кылу — гипотеза рәвешендә әйтелгән фикерләрдә дә логик нигез нык.

Әлеге бүлектә археологларның, тарихчы һәм телчеләрнең, этнографларның игътибарын җәлеп итәрлек бер гипотеза бар — ул шагыйрь Котбны искил кабиләсенә бәйләп карау. Мәгълүм ки, болгарлар составында, Ибне Фазлан сүзләренә карагында, искил кабиләсе дә булган. Мәхмүд Кашгари сүзлегендәге һәм рун язмаларындагы мәгълүматларга таянып, искилләрнең Идел буена ничек килеп чыгуы һәм шулар арасыннан күтәрелгән булуы ихтимал, шагыйрьнең телендә борынгы сүзлекләргә теркәлгән формаларның чагылыш табуы һәм алар сөйләшенең хәзерге мишәрләрдә саклануы галимгә гаять кызыклы һәм тапкыр гипотеза күтәреп чыгарга нигез биргән.

Дөрес, искил-мишәр һәм шуңа бәйле ядкарь теле хакындагы бу гөманны хезмәтнең фәнни редакторы М. Госманов бәхәс астына ала. Бәхәсләр киләчәктә дә булыр дип уйлыйк. Әмма гипотеза моның белән үзенең әһәмиятен җуймас. Галим мәсьәләләрнең барысын да чишәргә алынмый да. Яңа мәсьәләләр куюы археолог, тарихчы, телче һәм әдәбиятчылар өчен уйланырга азык бирүе белән дә кыйммәт.

Хезмәтнең белешмә чыганак булу ягыннан бер әһәмияте шунда ки, аңарда көнчыгыш тарихы, әдәбияты һәм географик даирәсенә кагылышлы термин-атамаларның төгәл һәм дөрес үрнәкләрен табабыз.

Тарихи һәм филологик характердагы хезмәткә фәнни редактор итеп һәр ике өлкәдә бердәй абруйлы белгечнең билгеләнүен нәшриятның тапкырлыгы дип бәяләргә кирәк. Редакторның сүз башы хезмәтнең мөһим якларын төшенергә ярдәм итә. Аерым урыннарда ул автор белән үзенең килешеп бетмәвен әйтә. Бу исә хезмәттәшлекнең иҗадилыгын чагылдыра. Сүз башы әдәбият фәне даирәсен һәм укучыларны күтәрелгән мәсьәләләр хакында җитдирәк уйланырга мәҗбүр итә, эзләнүләрнең ихтимал юнәлешләрен чамаларга булыша.

Кыскасы, бу хезмәтнең төп кыйммәте әдәбият тарихын яңа дәлилләр һәм идеяләр белән баетудан, бу өлкәдәге бик әһәмиятле мәгълүматларны системага салып бирүдән гыйбарәт. Аерым фикерләрне төзәтү яки үстерүләр — киләсе тикшеренүчеләр эше.

НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВ.

# ТАТАРСТАН АССР ТӨЗЕЛҮ ҺӘМ ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТ

Коммунистлар партиясе Бөек Октябрь социалистик революциясенең беренче көннәреннән үк, экономика һәм политика өлкәсендәге кичектергесез проблемаларны хәл итү белән бергә, милли мәсьәләгә дә, җитди игътибар бирде, ленинчыл милли программаны тормышка ашыру буенча эзлекле чаралар үткәрде.

Элек изелгән, экономик һәм культура ягыннан артта калган халыкларның фактик тигезлегенә ирешү өчен кирәкле шартлар тудыру милли мәсьәләне хәл итүнең төп алшарты булып тора иде. В. И. Ленин әле Октябрь революциясенә кадәр үк, милләтләрнең тигез хокуклылыгын тулысынча тәэмин итү өчен аларга үзбилгеләну һәм һәръяклы демократик үзидарә хокукы бирергә кирәк, автономия һәм үзидарә хокукы алган өлкәләрнең чикләрен билгеләгәндә шушында яшәүче халыкның хуҗалык һәм көнкүреш шартлары, милли составы һәм башка шундый билгеләр исәпкә алынырга тиеш, дигән иде.

Ленинның бу күрсәтмәләре рус булмаган халыкларга автономияле республикалар, автономияле өлкәләр һәм милли округлар рәвешендә милли дәүләтчелек бирү юлы белән тормышка ашырылды. 1919 елның мартында Башкортстан АССР төзелде. РКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросының 1920 елның 26 гыйнварында уздырылган утырышында Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын төзү мәсьәләсе уңай хәл ителде. 1920 елның 27 маенда Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты һәм РСФСР Халык Комиссарлары Советы Татарстан АССР төзү турында декрет кабул иттеләр. Шушы елның 10 июнендә Сәхибгәрәй Сәетгалиев председательлегендә Татарстан Автономияле Республикасының Вакытлы Революцион комитеты оештырылды. Ике атнадан соң — 1920 елның 25 июнендә — Советларның Казан губерна башкарма комитеты үзенең вәкаләтләрен Вакытлы Революцион комитет кулына тапшырды. Бу дата тарихка Татарстан АССР туган көн булып кереп калды.

Татарстан АССР төзелгәч, республика партия оешмасы алдына экономика һәм культура төзелеше өлкәсендә кичектергесез хәл итүне сорый торган яңа бурычлар килеп басты. Культура өлкәсендәге ул мөһим бурычларның берсе матбугат мәсьәләсе иде.

Октябрь революциясеннән соң Казанда һәм губерна өязләрендә татар, рус, чуваш һәм башка телләрдә уннарча исемдә газета-журналлар чыга башлап, автономияле республика игълан ителгәнгә кадәр үк инде губерна партия оешмасы матбугат органнарына җитәкчелек итү, аларны партиянең губерна комитеты алдында торган бурычларны хәл итүгә тарту буенча шактый тәҗрибә туплаган иде. Партиянең Казан губерна комитеты, РКП(б)ның VIII съезды кабул иткән «Партия һәм совет матбугаты турындагы резолюциясе положениеләренә һәм Ленин күрсәтмәләренә таянып, губернада совет матбугаты челтәрен булдыру һәм үстерү юнәлешендә шактый эш башкарды. 1918 елның ахырында РКП(б) губерна комитеты каршында махсус матбугат секциясе оештырыла. Аңа партия-совет матбугатына җитәкчелек итү, матбугат органнарының идея-политик юнәлешен даими күзәтеп тору, нәшрият эшләрен үзәккә туплау, матбугат органнарын һәм нәшриятларны кирәкле средстволар белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл кылу вазифалары йөкләнә. Газета һәм журналларның идеялелеген тиешле югарылыкка күтәрү, матбугат чыгышларының принципиаль партиялелеген тәэмин итү мәсьәләләренә аеруча игътибар ителә.

Ачыктан-ачык контрреволюцион характердагы яки вак буржуаз милләтчелек рухы белән сугарылган газета-журналлар 1918 елның урталарына кадәр инде ябылган булсалар да, Совет властена дошман элементлар матбугатны үз максатларында файдаланырга омтылуларыннан һич тә баш тартырга җыенмыйлар. 1919 елның гыйнварында, мәсәлән, Казан губернасы кооперативлары съезды карары белән рус телендә «Казанская кооперация» дигән журнал чыга башлый. Ул вакытта Казан потребкооперациясе башында торган меньшевик-эсер элементлар журнал аша үз идеяләрен пропагандаларга керешәләр. Журналның беренче саннарында ук совет власте үткәрә торган чараларга ризасызлык белдергән, хәтта ул чараларга каршылык күрсәтергә өндәгән мәкаләләр басыла. Шундый ук эчтәлекле, тик бераз әйләнгечрәк телдә язылган материаллар ара-тирә бүтән басмаларда да күренгәли.

Матбугат эшләрен җайга салуны, аның эчтәлегенә дөрес юнәлеш бирүне күздә тотып, партия губерна комитеты кайбер оештыру чаралары үткәрә. 1919 елның декабрендә ул, әлеге мәсьәләне махсус тикшереп, «Знамя революции» газетасы ре-

дакциясе, матбугат һәм полиграфия секцияләре, Россия телеграф агентлыгының губерна бүлекчәсе, Казан шәһәр Советының милләтләр бүлеге вәкилләре составында киңәш бирү органы булдыру турында карар кабул итә. Бу органга бөтен нәшрият эшләренә күзәтчелек итү, һәр басманың эчтәлегенә игътибарны көчәйтү бурычы тапшырыла.

Татарстан территориясе фетнәче чехлардан һәм акгвардиячеләрдән азат ителгәннән соң, губерна партия-совет оешмалары империалистик һәм гражданнар сугышы чорында җимерелгән халык хуҗалыгын торгызу эшенә алыналар.

Кичекмәстән хәл ителергә тиешле иң мөһим бурычларның берсе авыл хуҗалыгын торгызудан, аның продукция һәм чимал җитештерүен арттыру өчен көрәшне көннән-көн киңрәк җәелдерүдән гыйбарәт була. Менә шуңа күрә дә авыл хуҗалыгы фәненең иң элементар мәгълүматларыннан да хәбәрдар булмаган крестьяннар арасында бу өлкәдәге казанышларны пропагандалау, нәселле терлекләр үрчетүнең әһәмиятен аңлату, җирдән файдалануны тәртипкә салу кирәклеген төшендерү, аларны кумәк хуҗалыкларга берләшүгә хәзерләү буенча бик күп эшләр башкарасы бар иде. Шуны искә алып партия губерна комитеты крестьяннар өчен «Деревенские думы» дигән махсус газета булдырырга карар бирә. Аның беренче саны 1920 елның 15 январенда В. Бахметьев һәм Г. Гордеев редакторлыгында чыга. Газета крестьяннар арасында марксизм-ленинизм тәгълиматын тарату, Коммунистлар партиясенең һәм совет властеның крестьяннарга карата үткәрелгән политикасын аңлату эшләре алып бара. Аның битләрендә «Җир һәм ирек өчен», «Безнең әңгәмәләр», «Авыллардан хәбәрләр», «Укучыларның сорауларына җаваплар» һ. б. рубрикаларга киң урын бирелә, якшәмбе өмәләре, авыл хуҗалыгы артельләре һәм коммуналары тормышы, үзара ярдәмләшү, крестьяннарның җирне бергәләшеп эшкәртүләре һәм урыпҗыю эшләрен кумәк башкарулары яктыртыла. Мәкаләләр һәм очерклар гади крестьяннарга аңлаешлы тел белән язылалар. Газета тиз арада укучыларның ихтирамын казанып өлгерә һәм партия-совет органнарының югары бәясенә лаек була. Газетаның беренче саннары чыккач, РКП(б) Үзәк Комитеты секретаре Е. Стасова партиянең Казан губерна комитетына хат җибәреп, Үзәк Комитетның авыл эшләре бүлеге «Деревенские думы» газетасын хуплый, дип яза һәм аның һәр санын берничәшәр данә җибәреп торуны сорый. Кызганычка каршы, кәгазь һәм акча кытлыгы аркасында «Деревенские думы» ун гына сан чыгып кала — 1920 елның августында ул ябыла.

Партиянең өяз һәм район комитетларына житәкчелекне яхшырту, аларга ярдәмне көчәйтү максатында 1920 елның 10 февраленнән партия губерна комитеты «Известия губкома РКП(б)» дигән бюллетень чыгара башлый. Беренче өлкә партия конференциясеннән соң ул «Бюллетень обкома РКП(б)» дигән исем белән чыга, ә декабрендә «Вестник обкома РКП(б)» дип үзгәртелә. 1921 елның көзеннән 1924 ел ахырына кадәр «Коммунистический путь», 1925 елның январь-апрель айларында «Путь Ильича», май-сентябрь айларында «Причал» исеме белән чыгуын дәвам итә.

Яшьләр арасында тәрбия-оештыру эшләрен көчәйтү нияте белән 1919 елның 25 октябренда РКСМның Казан губерна комитеты бүгенге «Комсомолец Татарии» газетасының башлангычы булган «Клич юного коммунара»ны чыгара. 1920 елның 22 январенда «Кызыл яшьләр» газетасының (хәзерге «Татарстан яшьләре») беренче саны дөньяга күрә. 1919 елның мартында Үзәк мөселман хәрби коллегиясе политбүлеге органы булган «Кызыл Армия» газетасы редакциясе Казанга күчерелә. Ул 1918 елның 20 апрелендә Мәскәүдә чыга башлаган була. 1918 елның 27 сентябрендә Казанда, партия Үзәк Комитеты каршындагы Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы органы булып «Эшче» газетасы чыга башлый. Унөч саны чыккач, шул ук елның ноябренда ул Мәскәүгә күчә. Ә 1920 елның 2 февраленнән яңадан Казанда чыга. 1921 елның мартыннан берничә ай тукталып тора. Төрки халыкларның Үзәк бюросы оештырылгач, Мәскәүдә берничә сан чыга да тагын ябыла. 1922 елны «Эшче», РКП(б) Үзәк Комитетының Татар-башкорт бюросы органы сыйфатында, кабат чыга башлый һәм 1933 елда «Игенчеләр» газетасы белән кушыла.

«Эшче» һәм «Кызыл Армия» газеталары төрки халыклар хезмәт ияләрен политик тәрбияләү, бигрәк тә татар һәм башкортлар арасында марксизм-ленинизм тәгълиматын тарату, большевиклар партиясенең социалистик төзелеш программасын, совет властеның бу өлкәдә үткәрә торган чараларны пропагандалау буенча шактый зур эш башкаралар. Галимҗан Ибраһимов, мәсәлән, «Эшче» газетасының татарлар арасында пролетариат диктатурасы идеяләрен таратуга һәм пролетариат гегемониясенең әһәмиятен аңлатуга зур өлеш керткәнлеген басым ясап әйтә[1].

1920 ел башларында инде РКП(б)ның күпчелек өяз комитетлары үз газеталарын булдыралар.

Кыскасы, совет властеның беренче елларыннан ук Татарстанда вакытлы матбугатның киң челтәре булдырыла, матбугат белән җитәкчелек итү һәм аның хезмәт ияләре белән элемтәсен ныгыту буенча шактый тәҗрибә туплана. Ләкин вакытлы матбугат эшендә әле байтак кына хәл кылынмаган проблемалар да яшәп килә. Матбугат белән төрледән-төрле оешмалар шөгыльләнә. Бу исә аңа җитәкчелек эшен таркауландыра. Шуңа күрә нәшрият һәм вакытлы матбугат эшен партия оешмалары күзәтүе астына алу талап ителә. Татарстан АССР игълан ителгән вакытка Казанда һәм республика өязләрендә барлыгы илледән артык партия-совет, хуҗалык, хәрби һәм яшьләр газета-журналлары, шул исәптән,

---

[1] «Эшче» газетасы, 1923 елның 23 август саны.

татар телендә ундүрт, рус телендә егерме җиде, чуваш һәм мари телләрендә дүртәр, удмурт һәм венгр телләрендә берәр газета-журнал чыга.

Булган матбугат челтәрен ныгыту белән бергә, яшь совет республикасы өчен кирәкле яңа басмалар да таләп ителә. Татарстан АССРның беренче рәсми органы «Известия Ревкома ТАССР» газетасы була. Аның беренче саны 1920 елның 30 июнендә чыга. Татарстан АССР Советларының I съездыннан соң аның исеме «Известия ТатЦИКа и обкома РКП(б)» дип үзгәртелә, «Эш» газетасы урынына 1920 елның 2 июленнән яшь республиканың татар телендәге беренче рәсми органы булган «Татарстан хәбәрләре» газетасы чыга башлый. «Известия ТатЦИКа» газетасының редакторы итеп В. Бахметьев, «Татарстан хәбәрләре»нең редакторы итеп В. Шәфигуллин билгеләнә.

1920 елның 25 февралендә үк инде «Кызыл Армия» газетасына кушымта рәвешендә рус телендә «Красная Армия» дигән газета чыга башлаган була. Татарстан АССР төзелгәч, 1920 елның 12 июленнән башлап аның урынына «Красный Восток» газетасы басыла. Ул Үзәк мөселман хәрби коллегиясе политбүлеге тарафыннан чыгарыла. Запас Армиянең Революцион хәрби советы политбүлеге «Красный боец» дигән газета чыгара. 1921 елның гыйнварында аның исеме «Татарская беднота» дип үзгәртелә. Запас Армия составының нигезендә крестьяннардан булуын исәпкә алып, газетага авыл хуҗалыгы мәсьәләләрен киңрәк яктырту бурычы йөкләнә. Ләкин аның гомере озын булмый: кәгазь җитмәү һәм башка материаль кыенлыклар аркасында 1921 елның мартында ул чыгуыннан туктый.

Татарстан АССР төзелгәч, элегрәк туктап калган өяз газеталары яңадан басыла башлыйлар, ә аңарчы бөтенләй газета чыгарылмаган өязләрдә яңалары оештырыла. 1920 елның июнь ахырларында, мәсәлән, Чистайда «Берлек» газетасын яңадан чыгара башларга рөхсәт бирелә, ә ике атнадан рус телендә «Власть труда» газетасының беренче саны дөнья күрә. 1920 елның 10 августында Минзәләдә рус телендә «Крестьянин» газетасы чыга, озак та үтми, укучылар татарча «Игенче» газетасының беренче санын алып уку бәхетенә ирешәләр. Әйтергә кирәк, «Игенче» бик тиз арада иң әйбәт газеталарның берсе булып танылa. Газетага үзәк матбугатта да югары бәя бирелә. Аерым алганда, «Красная печать» журналында аның турында берничә уңай рецензия урнаштырыла.

Буа, Бөгелмә, Спас өязләрендә дә рус һәм татар телләрендә газеталар булдырыла. Байтак кына яңа журналлар барлыкка килә. Алар арасында бай эчтәлекле, кыска гына вакыт эчендә укучыларның ихтирамын казанып өлгергән басмалар да бар. Әйтик, 1920 елда чыга башлаган һәм Татарстан Мәгариф комиссариаты каршындагы музей эшләре һәм сәнгать памятникларын саклау буенча Бөтенроссия коллегиясенең Казан бүлекчәсе органы булган «Музейный вестник» дигән шактый зур күләмле журнал әнә шундыйлардан. 1924 елга кадәр чыгып килгән бу журнал гаять бай эчтәлекле. Анда музей эшенең теоретик һәм практик мәсьәләләре киң яктыртылган, кыйммәтле тарихи памятниклар турында материаллар, аеруча мөһим экспонатларны тасвирлаган мәкаләләр урнаштырылган. Журнал үзәк матбугатта шулай ук югары бәя ала. Мәскәүдә чыга торган «Печать и революция» журналында басылган хәбәрдә, мәсәлән, менә мондый юлларны укыйбыз: «...Провинциаль үзәкләрнең берсе булган Казанда музей эшләренә багышланган рәсемле махсус журнал чыгару өчен әзерлекле кешеләр дә, кирәкле средстволар һәм мөмкинлекләр дә табылган. Бу журнал бирелә нык нигезләнгән һәм шактый күләмле булып чыгуында дәвам итә. Анда җирле авторлар гына түгел, башкала эшлеклеләре дә актив катнаша»[1]. Китап сөючеләр җәмгыятенең Казан бүлекчәсе тарафыннан нәшер ителгән «Казанский библиофил» дигән журнал да бик кызыклы һәм игътибарга лаек.

1921 елда Революцион хәрби совет политидарәсенең Көнчыгыш бүлеге татар телендә «Кызыл дәфтәр» дигән әдәби-иҗтимагый журнал чыгару эшенә керешә. Бу журналның беренче саны шактый бай эчтәлекле була. Анда Ф. Бурнашның «Кызыл Армия — хезмәт штабы», М. Галиенең «VIII съезд һәм Кызыл Армия» һәм хезмәт иярәре депутатлары Советларының асылын аңлатуга багышланган «Кызыл парламент» дигән мәкаләләре басылган. Әдәбият бүлегендә Ф. Әмирхан, Б. Рәхмәт, Ф. Бурнаш, К. Әмири, С. Җәләл, М. Максуд шигырьләрен һәм нәсерләрен укырга мөмкин. Кызганычка каршы, бик әйбәт башланган бу журналның да гомере, ул еллардагы башка байтак кына басмаларныкы кебек үк, бик кыска булып чыга.

1921 елның гыйнварында Татарстан Халык хуҗалыгы һәм өлкә профсоюзлар советлары рус телендә «Труд и хозяйство» дигән журнал чыгара башлыйлар. Ул утызынчы елларгача чыгып килә һәм республикада гына түгел, ил күләмендә дә иң яхшы экономик журналлардан санала. Журнал үзенең беренче саныннан ук республиканың хуҗалык тормышын киң яктырта, Татарстан экономикасының торышы хакында статистика материаллары һәм төрле диаграмма-таблицалар урнаштыра, Казандагы һәм өязләрдәге завод-фабрикалар, эшчеләр һәм кустарьлар тормышына багышланган материалларга киң урын бирә, авыл хуҗалыгы һәм урманчылык өлкәләрен дә читләтеп үтми.

Шулай итеп, Татарстан АССР төзелгәч, республикада вакытлы матбугат челтәре шактый киңәя, төрләнә һәм баый. Дөрес, барлык басмалар да көн таләпләренә тулысынча җавап бирерлек булмыйлар әле. Матбугат органнары эшчәнлегендәге төп кимчелек аларның гомуми характердагы озын-озын материалларны куплап урнаштыруларында, җирле тормышны һәм

[1] «Печать и революция» журналы. Май-июль, 1921 ел, 165 бит.

ихтыяҗларны яктыртуга игътибар биреп җиткермәүләрендә, редакцияләрнең эшен тыныч төзелеш шартларына нисбәтән үзгәртеп коруның бик сүлпән баруында була. Хәтта өяз газеталары да җирле тормыш турында ун-унбиш юллык хәбәрләр бастыру белән чикләнәләр, эчтәлекләре белән үзәк газеталарга охшарга тырышалар. Фәтхи Бурнаш үзенең «Вакытлы матбугат хакында» дигән мәкаләсендә, бу хәлгә почынып, кайчакта җирле газетаны кулга аласың да гаҗәпкә каласың, аңарда урыннардагы тормыш турында, өязләрдәге һәм республикадагы политик, экономик һәм иҗтимагый хәлләр хакында берни дә таба алмыйсың, дип яза.

РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты, партиябезнең матбугат турындагы директиваларын тормышка ашырып, республика газета-журналларының эшчәнлеген тиешле югарылыкка күтәрү буенча күп кенә практик чаралар күрә. 1920 елның 20 октябрендә, мәсәлән, өлкә комитеты бюросы утырышында «Известия ТатЦИКа» газетасы редакторы В. Бахметьевның доклады тыңлана һәм газетаның эшчәнлеген яхшыртуга, эчтәлеген тирәнәйтүгә, басылган материалларның нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән карар кабул ителә. Аерым алганда, карарда газетаның җитәкче ролен үстерү, партия тормышын яктыртуга игътибарны көчәйтү, газета битләрендә «Эшче тормышы» бүлеге булдыру турында әйтелә. Республика матбугаты алдында торган бурычлар шул ук елның 7 декабрендә волость партия работникларының Казанда үткәрелгән I республика съездында да тикшерелә.

Республика матбугатына партия җитәкчелеге турында сөйләгәндә Татарстан өчен хас булган үзенчәлекләрне дә искә алырга кирәк. Октябрь революциясеннән соңгы беренче елларда Казан илебездәге иң зур нәшрият үзәкләренең берсе була. Университет булу, Көнчыгыш халыклары педагогия институты, ә соңрак татар коммунистик университеты ачылу Татарстан башкаласын Урта Идел автономияле һәм өлешчә Урта Азия республикалары өчен дә милли кадрлар, шул җөмләдән, журналистлар һәм полиграфия работниклары хәзерләү үзәгенә әверелдерә. Казанда тугандаш республикалар һәм өлкәләр өчен шрифтлар җитештерелә. Егерменче елларда монда «Эшче», «Кызыл Армия», «Кызыл шәрык» кебек илебездәге барлык татарлар арасында таратыла торган һәм үзәк партия-совет оешмалары органнары булган газета-журналлар чыгарыла. Республикадан читтә яшәүче татар хезмәт ияләрен басма сүз белән тәэмин итүне күздә тотып, Татарстан газета-журналлары еш кына очракларда үзәк һәм республика партия-совет, комсомол оешмаларының уртак органнары итеп чыгарылалар. Мондыйлар рәтенә «Мәгариф» һәм «Октябрь яшьләре» журналларын кертергә мөмкин. Бу әлбәттә, әлеге басмаларның эчтәлеген һәм тематикасын үзгәртүне, аларның битләрендә бүтән республикаларда һәм өлкәләрдә яшәүче татарларның тормыш-көнкүрешен, культурасын чагылдырган материаллар урнаштыруны таләп итә.

Татарстанда шулай ук күршедәге тугандаш халыклар телләрендә дә, шул нәүбәттән, чувашча «Канаш» («Киңәш»), «Херле ялав» («Кызыл байрак»), «Сенейал» («Яңа авыл»), «Шурампус» («Таң»), мари телендә «Йошкар кэче» («Кызыл көн»), «Тул» («Чаткы»), «Йошкар увэр» («Кызыл хәбәр»), «Уйлыш» («Яңа тормыш»), удмуртча «Сюрло» («Урак») һ. б. газета-журналлар нәшер ителә. Аларның кайберләре хәтта бу халыкларга автономия бирелгәч тә үзләрендә ныклы полиграфия базасы булдырылганга кадәр Татарстанда басыла.

Бу үзенчәлекләр партия өлкә комитетына матбугат эшләре белән җитди шөгыльләнү, һәр басмага конкрет якын килү кебек мөһим бурычлар йөкли. Шуны истә тотып, ул автономияле республика игълан ителүнең беренче айларыннан ук бернинчә телдә чыга башлаган төрле характердагы вакытлы матбугатка җитәкчелекнең әр-яңа формаларын һәм ысулларын эзли. Татар матбугатының эшен үзәкләштерү, аның алдында торган төп бурычларны ачыклау һәм хәл итү максатыннан чыгып, партиянең Татарстан өлкә комитеты, Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмасы Үзәк Бюросы белән берлектә, төрки халыклар арасында эшләүче журналистларның Бөтенроссия конференциясен уздырырга карар бирә. Конференциягә кадәр «Эшче», «Татарстан хәбәрләре» һәм «Кызыл Армия» газеталарында татар матбугатына кагылышлы мәсьәләләр буенча фикер алышу үткәрелә. «Эшче» газетасының 1920 елгы 11 октябрь санында, мәсәлән, Татарстан Халык Комиссарлары Советы председателе Сәхипгәрәй Сәетгалиев татар матбугатының ул вакыттагы торышы турында зур мәкалә белән чыга. Автор анда татар телендә басыла торган газета-журналларның төп кимчелеге итеп аларның әле һаман да хезмәт ияләре белән тыгыз элемтә урнаштыра алмавын, басылган материалларның еш кына очракларда йомшак язылган булуын, тәҗрибәле һәм белемле журналистлар җитеп бетмәвен күрсәтә. Мәкаләдә конференциядә тикшереләчәк проблемалар турында да сүз бара.

Шул ук газетаның 18 октябрь санында Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл штык һәм кызыл каләм» исемле мәкаләсе басыла. Мәкалә авторы татар матбугатындагы кимчелекләр, ул кимчелекләрне китереп чыгарган сәбәпләр һәм аларны бетерү юллары турындагы фикерләре белән уртаклаша. Фикер алышуларда катнашып, Ф. Бурнаш «Кызыл Армия», В. Шәфигуллин «Эшче» газеталарында чыгышлар ясыйлар.

Кыскасы, татар журналистларының Бөтенроссия конференциясе эшлекле шартларда узуы өчен шартлар җентекләп әзерләнә.

Ул 1920 елның 17 ноябрендә Казанда ачыла. Аның эшендә Татарстанның барлык өязләреннән, шулай ук Башкортстан һәм Кыргызстаннан, Самара, Саратов, Мәскәү, Екатеринбург шәһәрләреннән барлыгы 46 вәкил катнаша. Конференциянең көн тәртибенә агымдагы хәл, Көнчыгыш халыкла-

ры коммунистик оешмасы Үзәк Бюросы нәшрият бүлеге отчеты, урыннардан докладлар, пролетар әдәбияты һәм матбугаты кебек мөһим мәсьәләләр куела.

С. Сәетгалиев агымдагы хәл турындагы докладында вакытлы матбугатка да киң туктала. Безнең матбугат, ди ул, шушы көнгәчә башлыча теоретик мәсьәләләр белән шөгыльләнә, экономик проблемаларга бик аз игътибар итә. Ә бит татарның татар икәнлеген исбат итү өчен озын-озын мәкаләләр язганчы, татар агаеның ияре нигә агачтан һәм шлеясе нигә юкәдән икәнлеге, яки аның кепчәге ни өчен тимер кыршаусыз булуы хакында күбрәк язганда әйбәтрәк булыр иде. Экономикага кагылышлы менә шундый нәрсәләр турында күбрәк язарга, шул рәвешле Көнчыгыш халыкларына хуҗалык-көнкүреш эшләрендә алга бару юлын сайлауда булышырга кирәк... Безгә күктән җиргә төшәргә һәм эшчеләр белән крестьяннарга якынрак килергә күптән вакыт инде*.

Доклад буенча конференция кабул иткән резолюциядә татар матбугаты алдында торган кичектергесез бурычлар күрсәтелә, газеталарның коллектив пропагандист, коллектив агитатор, коллектив оештыручы буларак әһәмияте ачыла.

Пролетар әдәбияты һәм матбугаты турындагы докладны Галимҗан Ибраһимов ясый. Ул әдәбият белән матбугатның хезмәт ияләрен социалистик рухта, интернационализм һәм коммунистик әхлак рухында тәрбияләүдәге роленә аеруча басым ясый; игътибарны татар телен фәнни үстерү, татар теле терминологиясен тәртипкә салу, аны эшче-крестьян массаларының киң катлавына аңлаешлы итү кирәклегенә, басылып чыккан материалларда вакыйгаларны фәнни анализлауга, коммунистик җәмгыять төзүнең конкрет юлларын күрсәтүгә әһәмият бирелергә тиешлегенә юнәлтә. Аның докладындагы фикерләр һәм тәкъдимнәр конференция резолюциясенең нигезенә салыналар.

Конференциядә катнашучылар Көнчыгыш халыкларының нәшрият эшләрен үзәкләштерү мәсьәләсенә дә зур игътибар бирәләр. Бу хакта махсус резолюция кабул ителә. Анда хәрби, теоретик һәм тарихи әдәбият бастырып чыгаруны берләштерү чаралары күрергә тәкъдим ителә. Ул чараларны тормышка ашыруның басмаларның сыйфатын яхшырту, кәгазь һәм типография чыгымнарын киметү өчен шартлар тудырачагы әйтелә. Шул уңайдан татар телендә чыгып килгән үзәк һәм республика газеталарының төп юнәлешләре билгеләнә. Республика газеталарына, бер-берләрен кабатламыйча, төп игътибарны җирле тормышны яктыртуга юнәлдерергә, ә үзәк матбугатка башлыча халыкара революцион хәрәкәт, Көнчыгыш халыклары арасында коммунистик идеяләрне тарату формалары һәм ысуллары, гомумтеоретик характердагы мәсьәләләр белән шөгыльләнергә киңәш ителә.

Бер үк вакытта татар телендә яңа басмалар булдыру чаралары күрелә. 1921 елда Татарстан Халык мәгарифе комиссариаты органы — «Мәгариф» журналы яңадан чыга башлау шуның бер дәлиле. Ул педагогик журнал гына булып калмыйча, республиканың культура тормышын һәрьяклап яктыртучы киң профильле иҗтимагый-фәнни характердагы басмага әверелә. Аны чыгарышуда Г. Ибраһимов, Ш. Әхмәдиев, В. Шәфигуллин, Г. Сәгъди, Ф. Сәйфи-Казанлы, М. Фазлуллин, Х. Мөштәри, М. Корбангалиев, Г. Алпаров, В. Горохов кебек күренекле язучылар, галимнәр, журналистлар актив катнаша. Аларның журнал битләрендә әледән-әле урын алган тирән эчтәлекле мәкаләләрендә милли республика шартларында мәгариф һәм культура эшләрен оештыруның теоретик һәм практик проблемалары тикшерелә, җитди иҗтимагый һәм гыйльми мәсьәләләр күтәрелә, формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культура үсешендә ирешелгән казанышлар яктыртыла.

1922 ел башында комсомол өлкә комитетының «Кызыл шәрык яшьләре» дигән иҗтимагый-әдәби журналы барлыкка килә. Бер ел чамасы туктап торганнан соң, 1924 елның маеннан ул «Октябрь яшьләре» исеме белән чыгуында дәвам итә. 1925 елның июленнән журнал комсомолның Татарстан өлкә комитеты һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының Татар-башкорт бюросы органына әйләнә. Исеме «Авыл яшьләре» дип үзгәртелә. 1922 елның май аенда укучылар РКП(б) өлкә комитеты органнары булган «Безнең юл» журналының, шул ук елның 18 октябрендә «Безнең байрак» газетасының, 1923 ел башында «Чаян» журналының беренче саннарын алалар. Болардан тыш 1921 елның сентябреннән «Игенче», 1926 елның августыннан «Азат хатын» журналлары, 1924 елның 25 апреленнән авыл хезмәт ияләре өчен татар, рус һәм чуваш телләрендә «Крестьян газеты», 10 октябреннән балалар өчен «Яшь ленинчы» газетасы чыга башлавын әйтеп узарга кирәк.

Керәшен татарлары арасында аң-белем таратуны көчәйтү өчен 1919 елның октябрь аенда ук оештырылган «Кызыл әләм» газетасы Татарстан АССР төзелгәч тә чыгуында дәвам итә. 1921-1922 елларда «Белемнек», 1924 елда «Киңәш» журналлары чыгып килә. Бу газета-журналлар татар телендә рус алфавиты белән басыла. Чөнки революциягә кадәр керәшен татарларына бары тик русча гына укырга рөхсәт ителгән, алар гарәп алфавитын белмәгәннәр. Әлеге басмалар керәшеннәрне патша самодержавиесенең милли һәм дини политикасы тудырган бербереңне куралмаучанлык чиреннән арындыруда, бердәм милли культураны үстерү өчен керәшкә туплауда зур роль уйный.

Республика партоешмасы җитәкчеләре еш кына очракларда үзләренең төп эшләрен башкару белән бер үк вакытта газета-журналларның редакторлары вазифаларын да үтиләр. 1920 елның декабрендә «Вестник обкома РКП(б))» журналы чыга башлагач, мәсәлән, аның редакторы итеп партия өлкә комитетының беренче секретаре Александр Петрович Таняев раслана.

Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты председателе Борһан Мансуров та талантлы публицист була.

Татарстан АССР төзелүнең беренче елларында аның вакытлы матбугатын үстерүгә Вәли Шәфигуллин һәм Владимир Матвеевич Бахметьев та зур өлеш кертәләр.

**КАСЫЙМ ФӘСӘХОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## КПССның XXVI СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Октябрь аенда партия өлкә комитетының Политик мәгариф йортында КПСС-ның XXVI съездына багышланган иҗтимагый-политик укулар башланды. Алар партиянең XXVI съезды ачылганчы ай саен үткәрелеп барыла. Укуларның тематикасында КПССның социаль-экономик бурычларны хәл итүдәге, халыкара коммунистик хәрәкәтне үстерүдәге роле, тынычлык, халыкара киеренкелекне йомшарту өчен көрәше, Татарстан хезмәт ияләренең партия съезды хөрмәтенә яулаган уңышлары турында докладлар һәм лекцияләр каралган.

Укуларны КПССның Казан шәһәр комитетының беренче секретаре М. К. Рәмиев ачты.

«Ленинчыл Коммунистлар партиясе — чорыбызның акылы, намусы һәм вөҗданы» дигән темага доклад белән КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Р. М. Мусин чыкты.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ АЧЫК ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Г. Тукай исемендәге клубта Татарстан язучыларының ачык партия җыелышы уздырылды. Җыелыш КПСС Үзәк Комитетының октябрь (1980 ел) Пленумы карарлары һәм республикабыз язучыларының бурычлары турында сөйләшүгә багышланган иде. Көн тәртибендәге мәсьәлә буенча доклад белән Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты Г. А. Ахунов чыкты. Ул үзенең чыгышында партия Үзәк Комитеты Пленумы карарлары яктылыгында язучылар алдында торган бурычлар турында сөйләде, СССР Верховный Советының дүртенче сессиясеннән алган тәэсирләре белән уртаклашты.

Фикер алышуларда катнашкан язучылар, КПСС Үзәк Комитетының октябрь Пленумы карарларында һәм КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Л. И. Брежневның Пленумда ясаган чыгышында билгеләнгән бурычларны тирәнтен аңлаган хәлдә, партиябез съездын яңа иҗади уңышлар белән каршыларга әзерләнүләре хакында сөйләделәр.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНЕҢ ЭШЕН ҖАНЛАНДЫРЫРГА

Язучыларның чираттагы ачык партия җыелышы иҗат секцияләренең эшчәнлеген тикшерүгә багышланды.

Татарстан Язучылар союзы каршындагы иҗат секцияләренең эше турында доклад белән Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин чыкты. Ул әлеге юнәлештә башкарылган эшләр, ирешелгән уңышлар һәм алда торган бурычлар турында сөйләде.

Көн тәртибенә куелган мәсьәлә буенча фикер алышуларда язучылар Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов, драматург Диас Вәлиев, тәнкыйтьчеләр Рафаэль Мостафин, Ринат Мөхәммәдиев, һ. б. иптәшләр чыгыш ясады.

Шушы ук җыелышта язучыларга тантаналы шартларда СССР Язучылар союзының яңа членлык билетлары тапшырылды. Аларны ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты Гариф Ахунов тапшырды.

## МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ ТУЛУНЫ ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА

КПСС өлкә комитеты секретариаты 13 февральдә М. Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театрында Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 75 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш үткәрергә карар бирде.

Юбилей уңаеннан культура йортларында, китапханәләрдә, музейларда, уку йортларында герой-шагыйрьнең әсәрләре буенча укучылар конференцияләре, язучылар һәм сәнгать әһелләре белән очрашулар оештырылачак.

Татарстан китап нәшриятына Муса Җәлилнең шигырь җыентыкларын, аның иҗаты турында тикшеренүләрне бастырып чыгарырга тәкъдим ителде. ТАССР Культура министрлыгына һәм халык депутатларының Казан шәһәр Советы башкарма комитетына шагыйрь яшәгән биналарда мемориаль такталар куярга, ТАССР Художниклар союзына һәм сынлы сәнгать музеена, М. Җәлилнең тормышы һәм иҗатына багышлап, республика рәссамнары әсәрләреннән күргәзмә оештырырга кушылды.

Карарда шулай ук республика газета-журнал редакцияләренә, ТАССР телевидениесе һәм радиотапшырулар комитетына Муса Җәлилнең әдәби, хәрби-политик һәм иҗтимагый эшчәнлеген, аның совет әдәбиятын үстерүгә керткән өлешен киң яктыртырга тәкъдим ителде.

## СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ АТНАЛЫГЫНДА

Төркмәнстанда үткәрелгән совет әдәбияты атналыгында илебезнең төрле төбәкләреннән килгән әдипләр катнашты. Атналык көннәрендә язучылар республика буйлап сәяхәт иттеләр, колхоз-совхозларда һәм

промышленность предприятиеләрендә хезмәт иясләре белән очраштылар, әдәби кичәләр оештырдылар.

Ашхабад академия театры бинасында үткәрелгән зур кичәдә Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе язучы Гариф Ахунов чыгыш ясады.

Совет әдәбияты атналыгына Татарстаннан драматург Диас Вәлиев тә барган иде.

* * *

Китап сөючеләр җәмгыятенең Ялта шәһәр бүлеге, КПССның XXVI съездын лаеклы каршылау йөзеннән, әдәби-музыкаль кичәләр үткәрә.

Шундый кичәләрнең берсендә татар шагыйре Зәки Нури катнашты.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

Язучы Гариф Ахунов, шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Әхмәт Рәшитов һәм Роберт Миңнуллин республикабызның Куйбышев районында булып кайттылар. Алар Пропагандистлар көне уңае белән Куйбышев район культура йортында уздырылган әдәби-музыкаль кичәдә катнаштылар.

Шагыйрьләр Мөхәммәт Садри, Хәкимҗан Халиков, язучы Габдулла Шәрәфи Апас районы хезмәт иясләре белән әдәби очрашулар оештырдылар. Районның «Спартак», Ленин исемендәге, «Татарстан», Тукай исемендәге, Муса Җәлил исемендәге, Пушкин исемендәге, «Память Ленина», Куйбышев исемендәге колхозларында һәм берничә мәктәптә үткәрелгән әдәби кичәләр апаслыларның күңеленә хуш килде.

Совет сугыш ветераннары комитетының Казан секциясе чакыруы буенча фронтовик-шагыйрьләр Мөхәммәт Садри һәм Геннадий Паушкин Совет Армиясе офицерлары йортында үткәрелгән очрашуда катнаштылар. Бу кичәдә Язучылар союзы идарәсе секретаре язучы Мөсәгыйт Хәбибуллин да катнашты һәм чыгыш ясады.

В. В. Куйбышев исемендәге «Тасма» производство берләшмәсендә үткәрелә торган Предприятие көненә язучыларны да чакыру күркәм гадәткә әверелде. Берләшмә клубында уздырылган бәйрәм кичәсендә язучы Ф. Шәфигуллин, шагыйрьләр Р. Мингалим, Р. Гатауллин, Ә. Рәшитов һәм Р. Миңнуллин катнашты.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Язучылар союзы каршындагы поэзия секциясенең чираттагы утырышында көн тәртибенә тәнкыйтьче Тәлгать Галиуллинның «Хәзерге татар поэзиясенең үсеш тенденцияләре» дигән кульязма җыентыгын тикшерү куелган иде.

Фикер алышуда катнашкан шагыйрьләрдән Хәсән Туфан, Нури Арсланов, Әхсән Баянов, Зөлфәт, Әхмәт Рәшитов, Зиннур Мансуров, тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин һ. б. иптәшләр тикшерелгән хезмәтне уңай яктан бәяләделәр, аны тагын да тулыландыру һәм камилләштерү юнәлешендә авторга файдалы киңәшләр бирделәр.

Секция утырышы Т. Галиуллинның әдәби тәнкыйть мәкаләләре китабын Татарстан китап нәшриятына тәкъдим итте.

Әдәби тәнкыйть секциясенең Фуат Галимуллин иҗатын тикшерүгә багышланган утырышы булып узды.

Яшь тәнкыйтьченең мәкаләләре турында филология фәннәре докторы, тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече Нил Юзиев һәм филология фәннәре кандидаты Рифат Сверигин сөйләде.

Фикер алышуларда Фәрваз Миңнуллин, Флүн Мусин, Ринат Мөхәммәдиев, Фәрит Хатыйпов, Салих Маннапов һәм башка иптәшләр катнашты.

Секциядә Ф. Галимуллинның әдәби тәнкыйть мәкаләләре җыентыгы Татарстан китап нәшриятына тәкъдим ителде.

Балалар әдәбияты утырышында яшь язучы Нурислам Хәсәновның кульязма җыентыгы тикшерелде.

Сөйләшүне язучы Барлас Камалов башлап җибәрде. Ул яшь авторның иҗатына тулы анализ ясады, аның уңышлы якларын билгеләп үтте, үзенең теләк һәм фикерләре белән уртаклашты.

Кульязма җыентыкка кергән хикәяләр турында Шамил Рәкыйпов, Адлер Тимергалин, Рифкать Кәрами, Әхәт Гаффар һ. б. иптәшләр сөйләде.

Секциянең утырышы Н. Хәсәновның хикәяләр җыентыгын «Минем профессиям» сериясендә бастырып чыгарырга тәкъдим итте.

## ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР ТҮГӘРӘГЕНДӘ

«Казан утлары» журналы каршындагы яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәге үзенең чираттагы утырышын Р. Бикчуров һәм З. Хәсәтдинов язган рецензияләрне тикшерүгә багышлады. Утырышта яшь авторларга конкрет киңәшләр бирелде, рецензияләре, төзәтелгән һәм тулыландырылганнан соң, журналга тәкъдим ителәчәк.

## «ЯШЬЛЕК» ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘСЕНДӘ

«Татарстан яшьләре» газетасы редакциясе каршындагы «Яшьлек» әдәби берләшмәсендә (шеф-консультанты язучы Әхсән Баянов) шагыйрь Нури Арсланов һәм язучы Барлас Камалов белән очрашу үткәрелде. Танылган әдипләр яшь язучыларга әдәби хәрәкәт үзенчәлекләре, үзләренең иҗат лабораториясе турында сөйләделәр.

Шул ук утырышта берләшмәнең оештыру мәсьәләләре дә каралды. Аның бюро председателе итеп яңадан шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов сайланды.

## АВТОРЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Редакциягә бары тик машинкада басылган кулъязмаларның беренче нөсхәләре генә кабул ителә. Әсәрләр 210×297 мм лы форматтагы ак кәгазьгә кара төстәге тасма аша ике интервал калдырып басылырга тиеш.

Бер биттә иң күбе — 30 юл, һәр юлда — бары тик 60 (сүз араларын да исәпләп) тамга була.

Кәгазь битендә сулдан — 25 мм, өстән — 20 мм, уң яктан — 10 мм, астан 25 мм чиста ара калдырыла.

Әсәрнең исеме һәм бүлек исемнәре төп тексттан астан да, өстән дә өчәр интервал белән аерыла.

Кызыл юл өч хәреф урыны кадәр бушлык белән ясала.

Күләме ун биттән арткан кулъязмалар ике экземпляр җибәрелергә тиеш.

Редколлегия таләпләренә җавап бирә алмаган һәм шунлыктан журналда басылмаячак кулъязмалар анализланмый, рецензияләнми, авторга кире кайтарылмый.

РЕДАКЦИЯ

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫ

Инде журналның киләсе айда чыгачак 2 нче саны турында бер-ике сүз әйтеп узыйк. Беренче сәхифәләр февральдә булачак иң зур вакыйгага — КПССның XXVI съездына багышланалар. Монда Х. Камалов, Г. Рәхим, Ф. Сафин кебек шагыйрьләрнең партиягә, илгә, халыкка багышланган патриотик рухта язылган әсәрләре урнаштырылган.

Проза әсәрләреннән бу санда Ф. Шәфигуллинның «Өй салуның ние бар»... исемле яңа повесте укучыларның күңеленә хуш килер дип ышанабыз.

Гадәттәгечә, бу санда да проза әсәрләре белән шигырьләр аралашып бара. Повестьтан соң Р. Миңнуллинның «Киләчәккә таба» исемле яңа циклы килә.

**... Ашыгабыз! Кая ашкынабыз!**
**Алга юллар, дөрес, ачык тора.**
**Заманабыз, кочакларын җәеп,**
**Капкаларын үзе ачып тора...**

Бу юллар шагыйрь әйтергә теләгән фикерләрне аңлау өчен төп ачкыч кебек.

Солтан Шәмси бу санга «Соңгы юаныч» исемле хикәя белән катнаша. Аның моңа кадәр язган әсәрләре яшәү мәгънәсе, табигать бөеклеге турындагы фикерләргә бай иде. Бу яңа әсәрне язучының шул ук юнәлештә уйлануларының дәвамы дип кабул итәргә кирәк.

Шигъри әсәрләрдән тагын И. Беляев һәм Н. Акмалов шигырьләре бар.

Очерклар бүлеге КПССның XXVI съезды уңаеннан В. Шәриповның «Сынаулар аша», Р. Фәтхуллинның «Гап-гади Халиков» исемле язмаларын тәкъдим итә. Болар — КамАЗ алдынгыларына, бу гигант предприятие эшчәнлегендәге катлаулы мәсьәләләргә багышланган очерклар.

2 нче сандагы әдәби тәнкыйть материаллары М. Җәлилнең тууына 75 ел тулуга багышланган чыгышлар белән башлана. Бу бүлектә алардан тыш Ф. Урманчеев, Ф. Мусин һәм Т. Миңнуллин мәкаләләре бар.

«Әдәбият тарихына материаллар», «Тәрлесеннән», «Фольклор», «Безнең календарь», «Кечкенә рецензияләр» рубрикалары астына урнаштырылган язмалар да укучының игътибарын җәлеп итәрлек.

2 нче сан әдәбият һәм сәнгать яңалыкларын эченә алган язма белән тәмамлана.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210